# КАЗАН УТЛАРЫ

8.1997










«Казан утлары» журналының 70 еллыгы I Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә үткәрелде (1992). Шул тантанадан күренешләр.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**8**

**(898)**

**1997**

КАЗАН

## *Бу санда*

II БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫН КАРШЫЛАП

Тарихым — данлы дастан, Ватаным — Татарстан. *Шигырьләр* ..... 3
Ә. БОРҺАНОВ. Милли идея мәсьәләләре ..... 117

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

М. ЮНЫС. Соңгы сулыш. *Юльязма* ..... 8
М. ӘГЪЛӘМ. Кеше булып кычкырасы. *Шигырьләр* ..... 49
Т. ГАЛИУЛЛИН. Элмәк. *Роман* ..... 59
З. МАНСУРОВ. Фәрештәгә әверелү. *Шигырьләр* ..... 103

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. НИЗАМИ. Азатлык — татлы сүз ..... 111

МӨХӘММӘДЪЯРНЫҢ ТУУЫНА 500 ЕЛ

МӨХӘММӘДЪЯР. Әсәрләреннән парчалар ..... 113
Т. ГАЛИУЛЛИН. Тарих мизгелләре ..... 171

ЗӘЕТ МӘҖИТОВКА — 70 ЯШЬ

Р. ГАТАШ. Ир җанында — ни булмас ..... 128
З. МӘҖИТОВ. «Ачулы еллар» дәфтәреннән. *Шигырьләр* ..... 129

РӨСТӘМ МИНГАЛИМГӘ — 60 ЯШЬ

Р. МИНГАЛИМ. Тау астында илле бүре. *(Ике пәрдәле сәер тамаша)* ..... 141

НАИС ГАМБӘРГӘ — 50 ЯШЬ

ЗӨЛФӘТ. Уйный йөрәк ..... 133
Н. ГАМБӘР. Еллардагы юллар. *Шигырьләр* ..... 134

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Проза турында сөйләшү ..... 158

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Ф. УРМАНЧЕ. Сөембикә бәете ..... 161

ТАТАРНЫҢ ЯҢА ӘЛИФБАСЫ

Ф. ЛАТЫЙПОВ. Тарихи зарурият ..... 176
КОЛ ГАЛИ. Кыйссаи Йосыф. Өзек ..... 177
«Казан утлары» архивыннан ..... 182

ГАРИФ ГОБӘЙНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Р. РАХМАНИ. Тормыш чынлыгын эзләп ..... 183

Һиҗридән — миладига һәм киресенчә ..... 185
Ф. Латыйфи. Дуска соңгы сүз. *(Ф. Зөлкарнәй истәлегенә)* ..... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«К II Всемирному конгрессу татар»: стихи поэтов разных времен; статья А. БУРГАНОВА «Проблемы национальной идеи».
«Проза и поэзия»: окончание романа Т. ГАЛИУЛЛИНА «Петля», начало документальной повести М. ЮНУСА «Последнее дыхание»; стихи М. АГЛЯМОВА, З. МАНСУРОВА, З. МАЗИТОВА, Н. ГАМБАРА.
«К 500-летию Мухаммедьяра»: отрывки из произведений поэта и статья Т. ГАЛИУЛЛИНА «Мгновения истории».
«Драматургия»: комедия Р. МИНГАЛИМА.
«Литературная критика»: размышления о современной прозе.
«К истории народа»: статья Ф. УРМАНЧЕ «Баит Сююмбике».
В номере отмечаются юбилеи З. МАЗИТОВА, Н. ГАМБАРА, Р. МИНГАЛИМА.
Навыки чтения на основе латинской графики.
Последнее слово другу.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: праздник поэзии на площади Свободы г. Казани; родные просторы.

## IN OUR ISSUE

«To the World Congress of Tatars»: the verses of poets of different times; A. Burganov's article «The Problems of National Idea».
«Prose and Poetry»: the termination of T. Galiullin's novel «Loop»; the beginning of M. Yunus's documental novel «The Last Breathing»; the verses of M. Aglyamov, Z. Mansurov, Z. Mazitov, N. Gambar.
«Commemorating the 500 Anniversary of Mukhammediar»: extracts from the works of literature of the poet; T. Galiullin's article «The Moments of History».
«The Drama»: R. Mingalim's comedy.
«Literary Critique»: thoughts about modern prose.
«To the History of Nation»: Ph. Urmanche's article.
«The Legend about Syuyumbika».
Anniversaries of Z. Mazitov, N. Gambar, R. Mingalim are celebrated in the issue.
The skills of reading on the base of Latin script.
The last word to the friend.
The diary of the social and cultural life.
In our covers: the holiday of prose on the Freedom Square; the naitve space.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев, Тәүфикъ Әйди**

*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 27.06.97 ел. Басарга кул куелды 29.07.97 ел. Офсет ысулы белән басылд. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12 347. Заказ Н-353.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1997 ел.

## Тарихым — данлы дастан, Ватаным — Татарстан

* * *

Әй Идел-йорт, Идел-йорт!
Идел буе имин йорт!
Атам кияү булган йорт —
Иелеп тәгъзим кылган йорт —
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам биргән йорт,
Кендегемне кискән йорт,
Керем-коңым юган йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт,
Идел-Җаек арасы
Елкы белән булган йорт,
Казан — Болгар арасы
Кала белән тулган йорт.

*«Идегәй» дастаныннан.*



* * *

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр —
Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр
Моң-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
    Рәнҗемим, зинһар, күтәр!
    Рәнҗемим, зинһар, күтәр!

Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каүмем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
    Сөт калыр, ватан китәр!
    Сөт калыр, ватан китәр!

*Дәрдмәнд*

## Без Казаннан, Иделдән

— Сез кайдан? — дип сорыйсыз.
— Без Казаннан, Иделдән.
Идел — эчкән су булыр.
Иделдә иген иккән,
Яшәгән, көнен иткән
Татарстан шул булыр.

— Сез кайдан? — дип сорыйсыз.
— Без Казаннан. Казанны
Идел кичкән — шул белер.
Урамнары ак ташлы,
Җырлый Сәйдәш, Такташны —
Татарстан шул булыр.

— Сез кайдан? — дип сорыйсыз.
— Без Иделдән. Җиреннән
Кара алтын ургылыр.
Туфрагына Лениннан
Мәңгелек бәхет иңгән —
Татарстан шул булыр.

*Сибгат Хәким*

## Атлантида

Атлантида булды микән чынлап?
Тынгы бирми сорау һич кенә:
Әллә кайдан, ерак-ераклардан
Һәлакәтле бер моң ишетелә.

Кинәт юкка чыккан бөтен кыйтга,
Тау-дулкыннар күккә ашканнар:
Бер мизгелдә илләр, шәһәрләрне,
Һәйкәлләрне сулар басканнар.

Океан упкан кебек Атлант җирен,
Дәүләтләрне монда җир упкан:
Дәшти-Кыпчак, Болгар, Алтын Урда...
Бер-берсенең тамырын корыткан.

Ничә тапкыр килгән монда яулар,
Кичергәннәр илне кылычтан...
Калдыгын да көлгә дүндерергә
Миссионерлар күпме тырышкан.

Сәхифәләр тузган, юкка чыккан...
Ә без — менә, без — бар, булганбыз!
Фал ачабыз ләкин, баш ватабыз:
Әллә кыпчак, әллә болгар без?

Кем булгандыр бабам, кыпчакмы ул,
Болгармы ул? Нинди аерма?!
Татар дигән исем йөртәбез без —
Татар каны ага тамырда!

Атлантида! Атлантида баткан.
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без — менә, без — бар, эз бар җирдә,—
Без батырган саен калыккан.

Атлантида язмышы юк безгә,
Оныкларның анык бабасы:
— Нәселең кем?— диң сорасалар әгәр,
Әйтерләр:— Без — татар баласы!

Татарстан дигән ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын.

*Нури Арслан*

## Бар!

Гасырлардан, иске заманнардан
Тутыкмаган иске хәбәр бар.
Кем әйткәндер, кайчан әйтелгәндер:
Татар барда, диеп, хәтәр бар.

Кайда гына хәтәр юк икән соң?
Ул бар, булган һәм ул булачак.
Хәтәрсезме булды безнең заман,
Безнең яшьлек, безнең балачак.

Безгә генә килгән кебек иде
Дөньяның бар хәтәр көннәре.
Яуда гына күпме ятып калды
Татарның да кеме, кемнәре?!.

Кайда бакма — хәтәр җирдә татар,
Адәм ышанмаслык даны бар.
Карбышевтан кем сораган? Ә ул
Миндә, дигән, татар каны бар.

Океан агымнарын авызлыклап,
Үлемнәрне җиңгән кем дисез?
Брест ташларына исем куйган
Билгесезме? Түгел билгесез!

Кайда бакма — хәтәр җирдә татар,
Үлемнәрнең сыртын сындырып.
Утлардан да, Моабитлардан да
Кем соң чыкты моңлы җыр булып?

Палач балтасына башын тотып,
Көлеп үлгән икән татарлар,
Дошман өчен, сатлык җаннар өчен
Татар барда, чынлап, хәтәр бар...
Бар!

*Наҗар Нәҗми*

* * *

*«Чакырылмаган кунак — татардан да яманрак».*
Рус мәкале

...Җилдерде ул дала атларында,
Гөслә чиртеп аю биетте,
Көрәш белән биеклекләр алды —
Заманына лаек биеклек.
Дастаннары аның урда кебек
Җан яулаган... Алга күченгән.
Чакырылмаган кунак булып үткән,
Үткән татар дошман өстеннән.
Чакырылмаган кунак булып кергән
Зимнийларга, Перекопларга;
Чакырылмаган кунак булып кергән
Паулюс качып яткан йортларга;
Чакырылмаган кунак булып кергән
Яман кунак булып — Берлинга.
Чакырылмаса да утырган ул
Өстәл артындагы урынга.
...Тезләнүне белми татар халкы,
Дошманнарын җиргә яткыра —
«Чакырылмаган кунак татардан да
Яманрак»,— диләр,

Хактыр да.
Үз-үзеннән яманрак татар
Дошман барда җирдә, үч барда.
Чакырылмаган кунак —
Дошманнарга,
Күтеп алган кунак — дусларга...

*Зөлфәт*

## Халкым минем

Кемнәр әйтә: «Җир тар,— диеп,
Милли кораб батар»,— диеп.
Яшик: «Таңнар атар!— диеп,
Без — болгари татар»,— диеп.
...Халкым минем — алтын халык,
Җаны белән ялкын халык.
Дусларына алкын халык,
Дошманына салкын халык.
...Халкым минем — батыр халык,
Ярдәмчел һәм матур халык.
Күпме генә екмасыннар,
Алып булып калкыр халык.
...Халкым минем — моңлы халык,
Җор халык һәм җырлы халык.
Ирек хисе күңелендә —
Дәүләте зынҗырлы халык.
Халкым эшчән, күркәм халык,
Дан юлында йөргән халык.
Күпме чит-ят милләтләргә
Бөекләрен биргән халык.

Кемнәр сөйли: «Шом бар...»— диеп,
Милли кораб батар, диеп.
Язып куйыйк йөрәкләргә:
«Без мәңгелек татар!!!»— диеп.

*Рафаэль Сибат*

# Чәчмә әсәрләр



## Миргазиян Юныс

# СОҢГЫ СУЛЫШ

«ЮЛДА УЙЛАНУЛАР» ӘСӘРЕНЕҢ ӨЧЕНЧЕ КИТАБЫ

### Беренче бүлек

**1**

Оркестр тавышы мине яшьлегемә кайтара. Гүзәл ялгышулардан тукылган кайнар дуамаллыкларыма. Яшьлек — үлемсезлек чоры. Тирә-юньдә тоташ зәңгәрсулык, алда — бетмәс, кимемәс гомер, йокыдан уянуыңны ярсу теләкләр, алсу өметләр көтеп тора. Әйе, таныш тавыш иде бу. Музыка уйный башлау белән егет чакның матур алданулары уянды, биттәге җыерчыклар тигезләнде, чәчтәге картлык кыравы жуелып төште, инвалидлык юкка чыкты. Маңгайга бөселеп төшкән куе коңгырт чәч. Төз гәүдә. Йөрәк ярсып тибә.

Минут эчендә мине үзгәртеп ташлаган тавышны күңел салып тыңлыйм. Оркестр уйный. Аста — «Котып» кунакханәсенең беренче катында ресторан. Тавыш шуннан ишетелә. Минем бүлмәм икенче катта, шуңа күрә оркестр тавышы аяусыз көчле. Тиздән идән такталары күтәрелеп китәр дә, музыканың җиз ташкыны ургылып, бүлмәне айкап ташлар шикелле тоелып китә.

Инде икенче тәүлек Мурман портында диңгез сәяхәте юллап йөрим. Картлыкның чарасызлыгына ышыкланып тыныч кына яшәп ятканда кинәттән офыклар артындагы билгесезлеккә ашкыну өянәге, сәяхәт җене тынгы бирми, бимазалый башлады. Кайчандыр дулкыннар сыртында бергә чайкалган дусларым белән киңәшләшеп карадым. «Андый хәл булгалый инде ул,— диде дусларым,— сабыр ит, үтәр. Көчле мавыгу табарга тырыш, йә булмаса әйдә, җыелып диңгезчелек чорын искә алыйк»,— диделәр.

Юк, үтмәде. Теләгем, киресенчә, көннән-көн көчәя генә барды. Башта диңгезчелек министрлыгына, аннан соң җир читендәге Мурман пароходчылыгына килдем. Тәкъдимне врачлар кулына тапшырдылар. Иртәгә медкомиссия. Кылдан нечкә, кылычтан үткен медицина сираты аша үтү...

---

Миргазиян Юныс (1927) — *язучы, диңгезче. «Тозлы җил», «Теләп алган давыл», «Биектә калу» һ. б. күп кенә китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

Яшьлек чорында ресторан оркестры җиңү маршын даими уйный иде. Нигә болай үксеп елый оркестр? Гитара, барабан, пианола, контрабас... Гитара, нечкә хисләр колы, елый-елый зарлана:

— Ялгыша ул,— ди гитара,— Нык ялгыша. Нигә кирәк аңа ерак сәфәр? Ямаулы йөрәк белән кем сәяхәткә чыга? Күрерсез, әйләнеп кайта алмас ул... Аңлатыгыз аңа, үгетләгез. Чыкмасын юлга. Өендә калсын.

Егерменче гасыр коралы — пианола бәндәләр язмышын, тәкъдирнең катлаулыкларын мелодия аша аңлатмакчы була:

— Заманалар авырайды,— ди пианола.— Һаман авырая. Мең төрле яңа мәшәкатьләр туып тора... Бәлки, шулардан качып котылмакчы була торгандыр? Язмыштан качып котылып булмый. Туган көннән алып, үлгәнче язмыш синең белән.

Юкка тырыша пианола. «Язмыштан узмыш юктыр»,— дигән борынгылар. Менә аның аңлатмасы. Бигрәк тә татар тәкъдире. Гасырлар буе, буыннан-буынга кара тәкъдир, канатларын җәеп, безне сагалап тора... Көтә.

— Сабырлык саф алтынга тиң,— ди контрабас.— Бу акылны бабаңнар васыять итеп калдырган. Ата-баба васыятенә колак салмаганнар югала.

Барабан — карт куштан, минем гомерлек дошманым, дөп-дөп килеп оркестрга боерык бирә:

— Әшегезне карагыз. Китсен. Дөмексен. Үз иркеннән йөри. Ирек? Ирек булган җирдә тәртип бетә. Мин начальник — син дурак. Син начальник — мин дурак. Менә нәрсәдә ул яшәү сере. Яшәеш — тәртип. Тәртип — буйсыну. Дөп-дөп, дөп-дөп!.. Кемгә кирәк аның сәяхәте? Айть-два, айть-два...

Минем язмышымны кызганып елый нечкә билле гитара. Сафлыгы пычратылган яшь кызлар тавышы чыгарып үкси нечкә хисләр коралы.

— Юл озын,— ди ул, күз яшьләренә тыгылып.— Алда — давыллар, дымлы кайнар һава. Чайкалулар. Исән кайта алмый ул, күрерсез. Кем чыга ди озын, хәтәр юлга ямаулы йөрәк белән? Туктатыгыз! Зинһар, туктатыгыз үзен. Җибәрмәгез...

Гитараның елавы агулы ук булып йөрәгемә килеп кадала. Бәгырь әрни. Акыл аңлый. Тукталырга кирәк. Акылдан көчлерәк, тойгылардан сизгерерәк шомлы бер көч һаман котырта, һаман алга куа мине...

## 2

Бик борынгы гадәт бу: диңгез портларында оркестр ерак юлга китүче моряларны елап озата, әйләнеп кайтучыларны үксеп каршы ала. Авыр, аяныч диңгезчеләр язмышы. Көннәр гаилә җылысыннан читтә, тоташ шыксызлыкта, заяга уза. Диңгезченең газиз гомере акчарлаклар юлында, тынгысыз дулкыннар өстендә кире кайтмаска китеп югала тора. Күмәк ялгызлыкта яшь диңгезче, тар, кысынкы тимер диварлар әсирлегендә. Туганнар еракта. Газиз баласы ятим үсә. Хатыны — тол. Дуслары бары тик күңелдә генә.

Кабат гитараны тыңлыйм. Белеп үкси моңлы хис мәҗнүне. Дөньяларның начарга таба үзгәрүеннән шомлана мескенкәй. Ил өстенә ябырылган тәртипсезлекләрне кичерә алмый. Өмет-баганышларның кинәт юкка чыгуына шулай өзгәләнә. Саксафон гитараны туктатырга тырыша. Пианола аны юата. Барабан карт солдафон, дорфа куштан, боерык бирә:

— Җитте! Тукта! Безнең вазифабыз — боерыкны җанландыру. Парадларда, атакага ташланыр алдыннан уйныйбыз без...

Күңелгә сәер бер фикер килә: «Әллә ахырзаман шушымы икән?» Әбиемнең җыры колагыма иңә!

> ...Урманнарда балан пешкән, өзәргә кирәк, балам.
> Заманалар авырайды — төзәргә кирәк, балам...

— Түзәргә кирәк?— дип сорый контрабас.— Күпме түзәргә? Әгәр түзәр хәлең калмаса?

Гитара һаман елый. Ул рәсәйлеләрнең язмышларын сыктый. Бу дөньяда һәр бәндә үзен генә тыңлый. Ишетми адәм балалары берберсенең тавышларын. Ишетсәләр — аңламыйлар. Өнсезлек чоры. Һәр меңьеллыкның азагында ахырзаман. Без бит икенче меңьеллыкны өченчегә алыштырырга җыенабыз...

Кабат диңгезчеләр язмышы турында уйларга тотынам. Ялгызлык — диңгезченең даими юлдашы. Тирә-юньдә ят киңлекләр. Алар — тышта. Кораб эчендә кысынкылык. Төрмәдәге шикелле. Күренеп кенә югалып торалар коры җир ярлары. Ят һәм таныш утраулар, тулы континентлар узып китә күз алдыннан. Узып китәләр, югалалар. Күктә ят йолдызлар. Һәр таңда кояш яңа офыктан калка, яңа горизонтка иңеп югала. Атналар, айлар бер-бер артлы алышынып тора. Алышынып торган яңа күренешләр... Һәм тәкъдиреңә сеңгән коллык газаплары...

Оркестр тавышы эзеннән яшьлегемә кайтам. Ул чорда музыка бөтенләй башкача яңгырый иде. Маҗарага, яңалыкка сусаган яшь йөрәкне музыка тавышы көрәшкә өнди, камчылап киләчәккә куа иде. Кая китте соң ул үлемсез яшьлек? Нишләде аның мәңгелекнең барлыгына инануы? «Котып» кунакханәсенең икенче катына урнашкан кечкенә бер бүлмәсендә миңа бөтенләй таныш булмаган ят кеше оркестр тыңлап утыра. Әйе, идән астыннан ишетелгән музыка тавышын бөтенләй башка кеше тыңлый...

Нинди зур ялгышлык икән бу киләчәктән бәхет көтү. Бәхет көтү мине дә алдады. Зарыгып көтеп алган алсу-зәңгәр бәхет гап-гади картлык булып чыкты. Мин көткән киләчәк тыныч, абруйлы, ихтирамлы рәхәтлеккә төренгән иде. Яшьлек чорында туктаусыз яңгырап торган музыка миңа шуны вәгъдә итә иде. Ә бүген миңа идән астыннан кисәтү яңгырый. Кисәтү һәм янау... «Комсызланма,— ди оркестр тавышы.— Күргәннәрең — җиткән. Тагын нәрсә кирәк сиңа? Дөньялар тыныч түгел. Фарсы култыгында менә-менә сугыш кабынып китәргә тора. Яшь чагыңдагы шикелле корабың белән Сүәеш каналында бүленеп калсаң, нишләрсең? Ясалма клапанлы йөрәк белән ерак юлга чыкмыйлар. Син үткән юлларның озынлыгы җитәрлек. Аларны синнән тартып алып та, киметеп тә, юкка чыгарып та булмый. Син үткән юллар үзең белән гүргә керәчәкләр...»

Идән астыннан ишетелгән музыка реквиемне — матәм көен хәтерләтә иде. Сискәнеп киттем. Ә бит мин әле күптән түгел генә сират күпере аша үттем. Шул мизгел искә төште. Башымны мендәр астына яшереп, ишетмәскә тырышам.

Минем ерак бабаларым, яу чабар алдыннан мәҗлес җыеп, таңга кадәр җыр тыңлаганнар. Сазның талгын үгете, кубызның сак, сабыр кисәтүе ерак бабаларымның язмышларын юраган. Нәрсә соң ул музыка? Аның безгә ясаган тәэсиренең сере нәрсәдә? Чыннан да, бит минем ерак бабаларым тынычлыкта, иминлектә яшәү нияте белән ничәмә тапкыр җиргә тоташкан тамырларын өзеп еракларга китеп урнашып караганнар. Саз һәм кубыз тавышы киләчәктә дә тынгы булмаслыгын даими үҗәтлек белән кисәтеп торган.

Кунакханә мендәре бәләкәй, сыек, аның эчендәге мамыгы тузанга әйләнеп беткән. Музыка тавышы мендәр аша үтеп керә.

— Чынбарлык шәфкатьсез,— дип үкси гитара.— Бәндә бәндәне аңлый алмый,— дип өзгәләнә ул.— Кешелек дөньясы тормышны җайга салырга, рәхәт яшәргә омтыла. Нигә соң яшәеш көннән-көн кырыслана, шыксызлана?.. Нишләп бу илнең тәкъдире шундый аяусыз? Кая китте көмештән дә чиста ак хыяллар? Безне киләчәк өчен яшәргә күндерделәр. Киләчәк дигәннәре бүгенгелекнең корбаны булып чыкты... Әнә, Америкадан Фарсы култыгына корал ташыйлар...

3

Әйе, Фарсы култыгына Америкадан корал ташыйлар. Без ташыган коралны юк итү өчен. Әле дә хәтеремдә, Николаев порты янындагы Балабановкадан төяп китергән танклар, туплар, самолетлар Басра портында озак бушатылганга күрә, Советлар Союзыннан ташылган коралны бушату өчен махсус Умм-Каср исемле порт төзеделәр. Коралны без шул портка ташый башладык. Йөк бушатырга докерлар житми. Сәддам Хөсәен гасырлар буе чүл иркендә яшәүче бәдәвиләрне портка куып китереп корал бушатырга кушкан. Бәдәвиләр безгә жирәнгеч нәфрәт белән карыйлар. Гарәп хатыннары ирләренә әбәд ашы китерәләр. Хатыннарның өсләрендә үкчәләрен каплап торган озын кара күлмәк, кара чадра. Чадра ярыгыннан гарәп хатыннарының күзләре генә ялтырап күренеп тора. Күзләрдә — нәфрәт. Гажәп көчле ул хатын-кыздагы абайлау тойгысы. Бәдәви хатыннар без китергән танклар белән илгә үлем килгәнен сизәләр... Без алып килгән үлем — аларның ирләренә, балаларына...

Егерменче гасырның азагында сугышның максаты гына түгел, тулысынча аның табигате дә үзгәрде. Гайрәтле бай илләр корал ярдәмендә көчсез ярлы илләрне буйсынуда тоталар. Совет империясе корал белән куркытып үзенең колониаль яшәвен дәвам иттермәкче була. Корал күп, халыкның бар көче, дәүләтнең бар байлыгы корал ясауга китеп беткән. Совет иле сугышсыз яшәгән очракта да корал авырлыгын күтәрә алмыйча сытылып юкка чыгачак. Кунакханәнең беренче катында уйнаган оркестр миңа шушы хакта сөйли.

Музыка кузгаткан авыр, катлаулы уйларым мине һаман бимазалый, агулы ук булып йөрәгемә кадала... Егерменче гасыр — яңа корал гасыры булып чыкты. Атом көче һәм кеше үтерү машиналары гаскәр сугышы урынына корал сугышын тудырды. Гасыр азагында комсыз көч белән ачулы көчсезлек сугыша. Байлык тәкәбберлеге белән ярлылык аяусызлыгы бугазлаша. Сугыш вакытында коелган кан жиргә генә сеңми. Сугыш каны бәндәләрнең иманнарына саркып керә. Шул канны радио, газеталар, телевизор аша бөтен дөньяга тараталар.

Күзләремне чытырдатып йомам. Миңа йокы кирәк. Иртәгә хәлиткеч көн. Миңа ял кирәк. Тынычлану кирәк. Ә галәмне салкын котып төне чорнап алган. Үткән көннәр, бүгенгелек, безнең киләчәкләр — барысы да караңгылыкка томаланып югалган. Ә музыка туктаусыз рәвештә шом агызып тора. Һаман йокларга тырышам. Шушы тырышу качыра йокымны. Ниһаять, йокыга кул селтим, уйлар давылына ташланам...

Тукта әле... Мин бит утыз елга якын туган туфрагыма кайтып, бабаларым сулаган һаваны сулап, алар эчкән суны эчеп яшәү турында хыялландым. Хыялымны Мәскәү жимерде. Ул эләктереп алды минем якамнан. Һәм жибәрмәде. «Тотса мәскәүләр якаң...» — дип Тукаебыз юкка гына әйтмәгән икән. Мин шул аяусыз кулдан качарга жай эзлим, күрәсең... Сәяхәткә чыгарга рөхсәт итсәләр, кабат баш өстемдә ят күк йөзе, суларга ят һава, ят күренешләр дөньяны чорнап алачак мине. Инде ике тәүлек Мурманны күзәтеп йөрим. Монда хәзер тоташ төн пәрдәсе. Таң да юк монда, ахшам да. Тәрәзәләрнең шомлы сыек утлары куе караңгылыкка баккан. Дөньясы да нәкъ шушы төндәге шыксыз караңгылыкны хәтерләтә... Ә мин көләч, кояшлы көнгә омтылам. Бу омтылыш иртәгә каралачак.

4

Мин урамга чыкканда тугыз тулып килә иде. Тротуарга тезелгән таш баганаларда соргылт шәүләгә төренгән тоныкутлар яна. Вольфрам жепләрендә сүлпән өметсезлек. Суык һава битне че-

метә. Аяк астында кар шыгырдый. Шомлы Тәүрәт төне. Әйтерсең, котып шәһәренең кешеләрен караңгылык йоткан.

Ниһаять, караңгылыктан бер шәүлә калкып чыкты. Эчемә җылы кергәндәй булып китте.

Башымны дөңкеткән йокысыз төн нәтиҗәсе — шактый озак адашып йөрдем. Ниһаять, каршымда мин эзләгән бина — диңгезчеләр поликлиникасы. Бетон блоклардан әмәлләнгән өч катлы соргылт тартма — индустриаль кетәк. Памир тауларына кунаклаган Кушка каласыннан алып сукыр эчәк булып Котып диңгезенә төртелгән Кола ярымутравындагы Мурманга кадәр Рәсәй империясе совет чоры тудырган җансыз, килбәтсез стандарт кетәкләрнең берсе минем каршымда иде. Мин ашыгып шуның эченә керә башладым.

Поликлиника коридоры. СССРдагы башка меңләгән шифаханәләрнең игезәге. Кырыгынчы еллар комсомолкасы авыр швабра белән коридорның тапталган ленолиумын ышкый. СССР — сугыш иле, ирсез картайган карчыклар иле, шакшы сортирлар, кәгазь куаныч — хезмәт ветераннары иле.

— Баш врачның кабинеты кайда?— дип сорадым мин исәнләшкәннән соң?

Карчык швабрасына таянды. Беләге белән маңгаена төшкән сыек соргылт чәчен өскә таба сыпырды:

— Уникенче кабинет,— ымлап коридор очын күрсәтте.

— Рәхмәт,— дидем мин ашыгып. Эчкә җылы кергәндәй булып китте. Ярый әле уникенче. Унөченче булса, өмет өзелә иде.

Хлороформның кискен әчкелт исе. Авырулар тәкъдиренең авыр, укшыткыч аңкуы. Шушы исне йота-йота баш врачның кабинетына таба атладым. Коридор буш иде. «Мин беренче» — совет чынбарлыгы тәрбияләгән вакчыл, мәсхәрәле куаныч эчемне җылыткандай итеп чеметеп алды. Ишеккә янәшә куелган урындыкка барып утырдым.

Нинди бәндә икән баш врач? Шушы фараз айкый иде баш миемне. Итләч битле, чиртсәң каны чыгарга торган мыеклы ир? Алла сакласын! Җәлпәк күкрәкле, кансыз юка иренле чандыр хатын? Мондыйдан шәфкать көтү — ай-һай? Күңелем нигәдер баш врачның хатын-кыз булуын тели иде. Шәфкатьлелек. Бу сыйфат совет чорында иң зур кытлыкка әйләнде. Бигрәк тә ир-ат арасында. Империя шартларында яулап алган җирләрне, анда яшәүче халыкларны даими буйсынуда тоту бюрократлык тудыра. Миллионлаган хәрбиләр. Даими сугыш көтү, шуңа әзерләнү. Явыз Иван чорыннан башланган яулап алулар сугыш-буйсыну — буйсындыру, аның гадәтләре көндәлек тормышта бюрократлыкны туктаусыз үрчетеп тора. Түрәлек бәндәләрнең каннарына, күзәнәкләренә үтеп кергән. Генсек Горбачев үзенең бер докладында СССРда 18 миллион бюрократ-түрә барлыгын билгертте. Бу белешмә бит бюрократлык шөгыле белән тамак туйдыручылар турында иде. Ә бюрократизмга көйләнгән гадәтләр? Мөнәсәбәтләрнең бюрократлашуы? Бу мизгелдә минем өчен иң куркыныч нәрсә — баш врачның бюрократ булуы иде.

Әйе, тыныч кына көтәргә кирәк. Тырышырга. Тәкъдиремә нәрсә язылгандыр бит? Әйе, тәкъдир. Татар тәкъдире. Минем эчемне аяусыз киеренкелек тырный. Коридорда бер бәндә күренде. Боек кына атлап миңа таба килә. Диңгезче. Аяк атлавыннан абайлап алдым. Карт диңгезче. Ишеккә кадакланган 12 санын укыгач, туктап сорады:

— Бу баш врач кабинетымы?

— Әйе,— дидем мин сорау бирүченең күз кабагы астындагы капчыкланып торган күкшел тирегә карап. Бу бәндәнең сулыш алуы таныш иде миңа. Сиңа, туганкай, тынычрак эш эзләргә кирәктер, бәлки? Әйе, дулкыннар өстендә яшәү шулай итә ул. Пенсия көненә ирешә алуың, ай-һай, бик тә бәхәсле, туганкаем. Янәшә урындыкка авыр итеп килеп утыручы иллеләр тирәсендәге диңгезче иде. Илле яшьтә тормышны яңадан башлап җибәрү — дөньяда моннан да катлаулы, моннан да авыр нәрсә

бармы икән? Урам чатына утырып, тезеңә мичманканны әйләндереп салырга да: «Братишки! Не жалейте копейку бывшему мариману!..»— дип кулыңны сузарга... Горурлык харап итә диңгезчене. Чын диңгезчене. Диңгезнең бөек кырыс таләпләрен кабул иткән шәхесне. Әзәйде чын диңгезчеләр. Чын язучылар да шулай әз бит. Алар да һаман әзәя баралар. Бәлки, бу җәмгыятьтә берзаман бөтенләй бетәчәкләр. Кем белә?..

## 5

Тагын берәү килеп чиратка басты. Бусы да өлкән яшьтәге ир иде. Әкренләп баш врач кабинеты янына халык җыела башлады. Авыр тынлык хөкем итә. Һәр килгән кешенең күңелендә авыр таш булып тәкъдир ята. Котылгысыз хөкем. Югалтулар.

Кабинет янына җыелган төркем кинәт хәрәкәткә килде. Башлар бер якка борылды, күзләр бер ноктага төбәлде. Ондатра тун кигән хатын ишек янына килеп туктады, сумкасыннан ачкыч чыгарып бикне ачарга керешге. Сулышлар ешайды. Йөрәк тибүе чигәләргә күтәрелә.

Бала чакта әбиләрдән ишеткән тылсымлы сүзләр искә төште. «Төкле аягың белән килүең булсын... Карчыгадан — кан, ябалактан — йон. Кошка-киеккә түмгәк булып күрен...» Мәҗүсилек чоры уянды канымда. Иминлек эстәү, ялвару. Тылсымга инану җанланып китте. Куркыныч килгәндә гайрәтле юрауларга ябышу. Дәһрилек пропагандасы. Аллаһы Тәгаләнең юклыгына инандырырга тырышу. Шул кешелек сыйфатларын сындырырга юнәлтелгән чараларның берсе генә дә нәтиҗә бирә алмады. Менә әле дә мин сабый чактагы ышануларымда идем. И Ходаем, мәрхәмәтеңнән ташлама!

Дөм сәләтсез бәндә буламы бу дөньяда? Ә нигә соң советлар илендә сәләтсезлек хөкем итә? Сәләтсезлек һәм дөм томаналык. Дөм томаналык һәм аяусыз хорафат. Аның сере шунда,— җитмеш ел буе идеология сәләтсезлек тәрбияләде. Сәләтле кеше үзенчә эшләргә, мөстәкыйль фикер йөртергә ярата. Режим өчен иң куркыныч нәрсә — мөстәкыйльлек. Совет системасының асылында тоташ буйсыну, коллык гадәтләре ята. Баш врач кабинеты янына җыелучыларны күзәткәндә туды бу фикер. Монда җыелганнарның күбесендә йөрәк авыруы, ә ул авыру — мин аңа шаһит — буйсына белмәүдән, куштанлыкны, тәлинкә тотуны инкяр итүдән барлыкка килә. Шушы турыда уйлаган арада кабинет ишеге ачылырга, баш врачны эчкә кертергә һәм ябылырга өлгерде. Ә мин, гомер буе авыз ачып күзәтеп йөрергә күнеккән бер мәҗнүн, шушы кыска мизгел эчендә баш врачның тун якасына бүселеп таралган куе кара чәчләрен, тун эченә серле итеп яшеренгән буй-сынын, салмак хәрәкәтләрен сиземләргә өлгердем.

Мәскәүдәге Пушкин исемендәге музейда Борынгы Бабил, Борынгы Мисыр, Борынгы Грек, Борынгы Рим һәм Ренессанс чорыннан соң ясалган француз, итальян һәм башка Аурупа илләрендә туган сыннар саклана. Кешелек дөньясының иң оста сынчылары — кыпчаклардан калган сыннар гына юк анда. Кыпчаклардан калган сыннарны Урыс империясенең варварлары тулысынча диярлек ватып бетергәннәр. Ә мин ерак бабаларым ясаган сыннарны шактый күп күрдем. Мелитополь гарнизонында хезмәт иткәндә шул сыннарны эре калибрлы авиация пулеметыннан атып күнекмә ясый торган тирның артына пуляләрне тоткарлыклау өчен өйгәннәр иде. Мариуполь портыннан Мәскәүгә очар өчен Донецк шәһәренә барганда шундый сыннарны мин таш коймалар эчендә күрдем. Кыпчак сынчылары социалистик реализм ысулына буйсына белмәгәннәр. Шунлыктан, кыпчаклар калдырган сыннарда искиткеч бай, символика эчтәлеге, аллегория һәм фантазия көче давыллары тупланган иде. Ул сыннарның эчтәлеген, алар чагылдырган чынбарлыкны аңлау өчен миңа Сорбоннага барып сәнгать белемен үзләштерү кирәк булмады.

Ул белем минем канымда иде. Менә хәзер баш врачның бармаклары белән борып ишекнең биген ачканын, бусага аша атлап эчкә кергәнен күзәткәндә кыпчак сыннары аша безнең көнгә килеп җиткән хәрәкәтләрне абайлап алдым. Затлы, тыйнаклыкка яшеренгән эчке горурлык тәшкил итә иде баш врачтагы хәрәкәт пластикасын. «Пластика» сүзен кулланырга мәҗбүрмен. Мин аның татарчасын белмим, сүзлеккә карап безгә гарәп һәм фарсы теле аша кергән сүзне кулланырга теләмим.

Әйе, сөн, бәҗәнәк, болгар, кыпчак, татар — алар барысы да бер тамырдан, мәгърур зур, бөек бер агач ботаклары,— ханбикәгә генә хас табигый, тыйнаклыкка яшеренгән горурлык сиздем мин бу хатынның табигатендә. Эчемә җылы йөгерде. Киеренкелек йомшарды. Миңа нәкъ шушындый тынычлану җитми иде бу мизгелдә.

Ябык ишеккә карап торган арада шушы фикер баш миемне айкап узды. Мин тагын менә нәрсә турында уйларга өлгердем: буйсынуга, ялагайлыкка күнеккән кол табигатьле ир хәләл җефетенең матурлыгын, аның зифа буен, сокландыргыч горурлыгын җимерә. Дүрт гасырга сузылган татар коллыгы да татар хатыннарындагы сылулыкны тулысынча җимерә алмаган. Җитмеш елга сузылган ирдәүкәлек сәясәте, ишәк аяусызлыгы белән «уфалла» арбасы сөйрәү, көне-төне эш, боерыклы, җанны кыйный торган коллар эше безнең хатыннарны тәмам йөк атына әйләндереп бетерде. «Ватан» сугышы дип аталган кара еллар. Бу елларны берзаман без айнык баштан бәяли алырбыз әле. Дөрес, урыслар ул сугышта үз ватаннары өчен сугыштылар. Ә Кырым татарлары? Ә чеченнәр? Балкарлар? Карачайлар һәм черкесләр? Ниһаять, без Казан татарлары? Лубянка коллыгы кайсы ягы белән гестапо коллыгыннан өстен иде? Гитлер золымы Сталин золымыннан аерыла идеме? Белмим, «халык» аталган аморф бердәмлеккә барып җитәрме бу хакыйкать? Мөстәкыйль фикер йөртүчеләр бу хәлләрне инде күптән ачыкладылар. «Ватан» сугышы турында сүз кузгалганда менә нәрсә өстисе килә: сугыш елларында барлык эш хатын-кыз җилкәсенә ятты. Сугыш бетте. Исән калганнар өйләренә кайттылар. Кайттылар һәм авыр эшне хатын-кыз җилкәсеннән алып ирләр җилкәсенә салырга оныттылар. Онытмадылар, сугыштан кайтучыларның күбесе командир иде. Ничек инде отделение командиры кара эш эшләп йөрсен! Тимер юлда кувалда белән шпалга бармак юанлыгы костыль-кадак кагучы хатыннарга ефрейтор погоны тагып кайткан «командир» боерык бирә башлады. Старшина мал карaучы хатыннарның командирына әйләнде. Менә шушы турыда кан йотып уйлап йөрүләр бәрде минем йөрәккә. Шушы газаплы уйлардан арыну әмәлен тапкан булсам, мин бүген шушы кабинетның ишеге янында ут йотып тормас та идем...

Кабинетка яшь кенә шәфкать туташы узды. Ишектән кереп китәр алдыннан безгә карап елмаерга өлгерде. Кызның вазифасын аклый иде бу елмаю. Елмаю ишек каплаганчы безгә шәфкать җылысы сирпеп торды.

— Рәхим итегез,— диде шәфкать туташның матур тавышы. Бисмиллаһи...

Өстәлдә кан басымы үлчи торган прибор. Календарь-көндәлек. «Паркер». Ак халат эченнән чия көрән йон күлмәк якасы күренеп тора. Чия көрән — минем яраткан төсем. Өстемдә нәкъ шул төстәге күлмәк иде. Йа раббым... Мондый чакларда күлмәк төсенә дә ялварулы өмет белән карый башлыйсың икән...

— Министрның соңгы карары нигезендә, бер генә тапкыр сәяхәткә комиссиясез дә чыгарга рөхсәт ителә.

Хәерле булсын. Искиткеч зур томаналык иде бу. Җавапны минем башсызлыгым әзерләде.

— Рөхсәт ителгәч, нигә соң монда килдегез?

Җөмләнең эчтәлегеннән тыш аның кинаясе, фәнчә әйткәндә, подтексты була. Эчтәлектән һәм кинаядән тыш сөйләшүчеләрнең бер-берсен

сүзсез аңлый торган җаннары, тойгылары да катнаша әңгәмәгә. Юк, баш врач бу сүзләрне ярлыкаулы итеп әйтте.

— Кораб врачлары министрның карарын белмиләр,— дидем мин акланырга тырышып.— Белгән очракта да ышанмаска тырышалар.

— Чишенегез.

Йөрәккә җылы йөгерде. Тойгыларым «чишенегез» сүзен «мин сезне карарга, гозерегезгә колак салырга әзер» дип тәрҗемә итте.

— Нәрсә борчый сезне?

«Минем диңгезгә чыгуыма хатын каршы»,— дип шаярып әйтмәкче идем. Вакытында тукталып калдым. Чишенү искиткеч газаплы иде. Бигрәк тә майканы салу. Ниһаять, майкам ишек янындагы элгечкә барып кунды. Баш врачның күз карашы бугазымнан башланып кендек янына туктаган көрәнсу кызгылт җөйне тикшерә иде.

## 6

— Күптәнме?— диде баш врач тәҗрибәле табибларга хас тышкы кызганусыз, ихлас мәрхәмәт белән.

— Моннан ике ел элек. Мин операция өстәлендә ятканда Әрмәнстанда җир тетрәү башланды.

— Кайда ясадылар?

— Мәскәүдәге Трансплантология институтында.

— Институттан чыкканда бирелгән кәгазь үзегез беләнме?

— Аны кайдадыр алып калдылар. Поликлиникада булса кирәк,— дидем мин эшнең һаман җитдиләнә, өметемнең кечерәя баруын сизеп. Йә хода! Мәрхәмәтеңнән ташлама!

— Ятыгыз.

Яттым. Үземне тыныч тотарга тырышам.

Баш врач мине бик озак як-якка әйләндерә-әйләндерә тыңлады. Тыңлап бетергәч, күкрәк сөякләре астына бармакларын тыгып бавырымны тикшереп карады.

— Озак басып торганда аякларыгыз бүртенәме?

— Юк, бүртенми.

— Торыгыз.

Тордым. Баш врач кан басымын үлчәде.

— Йөз һәм алтмыш. Һәрдаим шулаймы?

— Монда килгәч бераз төште. Гадәттә, йөз егерме һәм сиксән,— дидем мин.

— Кан басымы төшүен каян беләсез.

— Миләр томаланып киткәндәй итә. Тәндә сүлпәнлек башлана. Андый чакларда каты чәй, кофе эчәм. Бүген эчмәдем.

— Киенегез.

Ашыкмыйча гына майкамны, күлмәгемне кидем. Күлмәк итәген эчкә кертеп, чалбар каешын тыгызлагач, курткама үрелдем. Хәзер минем язмышыма кагылышлы сүзләр яңгырарга тиеш иде. Шул сүзләрдән соң миңа йә күк капусы ачылачак, яисә поликлиникадан чыгып, туры вокзалга билет алырга юнәлергә туры киләчәк. Хөкем мизгелен ерагайтасым килә. Йә Хода! Бу юлы да барып чыкмасмы икән?

## 7

— Ялгышмасам, ясалма клапан аорталь клапанда.

— Әйе, шунда,— дидем мин, ашыгып.

— Митраль клапандагы кан юлын киңәйтеп чистарттылармы?

— Әйе, киңәйттеләр.

— Тагын нәрсә эшләделәр?

Бер генә мизгелгә калганнарын яшерәсе, башка берни эшләмәделәр, дип әйтәсе килү вәсвәсәләп алды. Ялганлыйсы килүне җиңдем. Мондый мизгелдә, бигрәк тә сиңа ихласлык һәм шәфкать белән караган кешегә бер генә микъдар ялган, ярымдөреслек, күз буяу булмаска тиеш. Ялган — һәр очракта гөнаһ. Мондый мизгелләрдә тәмуг уты да чистарта алмаслык каты гөнаһ. Безне күнектерделәр. Көчләп. Сизми башладык без ялганны. Күнектек...

— Сыйрактан тамыр алып ике шунт куйдылар,— дидем мин тыныч калырга тырышып.— Сул як карынчык чиктән тыш тузган, зурайган иде. Шуны бәләкәйләтеп тектеләр.

— Шушындый катлаулы операциядән соң сезгә ерак юлга чыгу кирәкме икән соң? Сакланганны Алла саклый диләр бит?

«Катлаулы операциядән соң...»

## 8

Ул көннәрне мин онытырга тырышам. Мавыктыргыч, иҗат уты таләп итә торган эш белән мавыккан чакларда күпмегәдер оныткандай итеп торам. «Иҗат уты» дигәнне башкача аңлаулары мөмкин. Иҗатның иң кайнар уты җир белән эш иткәндә, бәрәңге утыртканда, кыяр үсентеләрен тиресләгәндә кабына. Һәм сыйфатлы агач табып, шул агачка яшеренгән сурәтне үткен пычак белән уеп күзгә күренерлек иткәндә. Бу очракларда да оныту тулы була алмый. Аңның ерак бер почмагында 1988 елның көзендә булган хәл сизелер-сизелмәс кенә әрни, моң биреп тора.

Халык Бөек Октябрьнең (кайсы ягы белән бөек икәнлеген мин үтерсәләр дә аңлый алмыйм!) җитмеш бер еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнә. Мин сумкама фарфор кружкамны, Шарль Бодлерның «Явызлык чәчәкләре»н, пыяла банкага тутырган балны һәм кәгазь-каләмемне салып соңгы тапкыр фатирыма күз йөртеп чыктым. Әнә, агачтан ясаган сыннарым. «Казан ханлыгы тарихы». Шул сынны ясар өчен кара агачны мин Калькутта базарыннан соңгы валютамны түләп алган идем. Бу сын өч символ бердәшүдән барлыкка килде: Казан ханлыгы турындагы шома ялган, җир астыннан дүрт гасыр аваз биреп ятучы хакыйкать һәм дүрт гасыр дәвам иткән кан елау[1]. Иерусалим каласында яһүдләрнең җимерелгән гыйбадәтханәләреннән калган бер таш дивар бар. Шул ташларны яһүдләр «елау-сыктау дивары» дип атап йөртәләр. Безнең Казанда да шундый урын булырга тиеш. Инде менә ярты гасырга якын шундый диварны булдыру турында хыялланып йөрим. «Казан ханлыгы тарихы» аталган сыннарның бер кырына мин тарихны күз яше белән юарга килүчеләрнең сурәтләрен ясадым.

Әдәби әсәргә кертергә ярамаган, миңа төрмә китерәчәк һәр уй-фикеремне мин агач сыннарга урнаштыра килдем. Әнә алар бүлмәнең стенасын каплап торалар. «Ирдәүкә». «Карагруһлык». «Кол Гали». «Самодержавие». «Урыс фашистлары». «Сәясәт»...

Чит илләргә йөрү Барселона портында өзелде. Әнә Каталониянең башкаласында соңгы тапкыр булуым истәлегенә соңгы рейста бирелгән барлык валютама алган ат сыны. Мин аны Манжуик тавындагы кибеттән алдым.

Киштәләрдә яраткан китапларым. Сез мине кабат күрә алырсызмы икән? Бу бүлмәгә кабат керергә язганмы икән? Аллаһы Тәгалә! Юк, ул сиңа сүз белән әйтми. Ходай әйтәсе фикерен турыдан-туры синең күңеленә китереп сала. Билгеле, ихлас инанган бәндәсенә...

Тапшырдым Синләрнең кодрәтенә... Бисмиллаһи...

---

[1] Хәзер ул сын Президент Шәймиевтә саклана.

Үлемтеккә акча әмәлләү. Менә нәрсә кайгырта иде мине ул чакта. Карачи портында алган күн пальтомны комиссионкага илтеп тапшырдым. Пальтога магнитофон өстәлде. Кувәйт портыннан алган аппаратура...

Бәлки, ясаласы операциянең уңышлы тәмамлануына өмет баглап азапланасы да булмагандыр? Ул чакта мин рәттән йөз адым атлый алмый башлаган идем инде. Икенче катка ярты сәгать менәм. Басма аралаш туктап хәл җыям... Кан басымының өскесе алтмышка якынлашып килә. Аскы өлешен тыңлап та булмый диярлек. «Туши фонари!»— диләр дингезчеләр мондый очракта. Ә мин көрәшеп азапланган булам. Кемнең тора салып якты дөнья белән саубуллашасы килә?

Врачларның күбесе шушы хәлгә җитеп таушалган йөрәкне ремонтлап булуга ышанмыйлар иде. Бары тик бер генә нәрсә бәхәссез — озакламый Газраилнең килеп ишек шакуы... Кулдан килгән кадәр гаиләгә мәшәкать калдырмаска тырышырга кирәк. Ә колагыма кемдер пышылдап белгертеп тора: «Өзмә өметеңне! Өзмә!»

Операция өстәле шыксыз. Мин бит инде аны өч тапкыр татып карадым. Бәлки, соңгы юлга җылы түшәктән кузгалу хәерлерәктер? Соңгы юлның беренче адымы? Аңа күпме калган икән? Биш ай? Өч? Ике атна? Бер тәүлек?..

## 9

Мин баш врачның хөкем чыгарганын көтеп утырам. Аңа да авыр бит. Җаваплылык. Өстә утыручы астагыны җавапка тарттыра, ә үзе җаваплылыктан читтә калырга тырыша. Иң өстәгеләр җаваплылыкны белмиләр дә. Теләсә нинди эш, теләсә нинди җинаять эшли ала иң өстә утыручы.

Баш врач чыгарганчы минем операция хәлләренә кабат кайтыйк әле.

Мине биш кешелек палатага урнаштырдылар. Җыештыручы хатын урын җәйгәндә әйтергә өлгерде:

— Бу караватта сезгә кадәр яткан кеше шундый әйбәт иде.

«Иде». Менә шушы өч хәрефтән торган сүз ул әйбәт кешенең кайда икәнлеген ачыклады. Бу хакта җыештыручыдан сорарга курыктым да, базмадым да.

Палатадагы биш кешенең икесе — авар егете Рамазан, Коломна заводының конструкторы Павел Лазутин мәеттән кисеп алган донор йөрәк килгәнен көтәләр иде. Керчь шәһәрендә туып үскән яшьтәшем Вадим Григорьев белән беренче көнне үк уртак тел таптык. Ул минем татар икәнлегемне ачыклагач, Кырым татарларын туган туфракларыннан ничек куулары турында сөйләде. Аларны туган җирләреннән сөргәндә Керчь шәһәрен өч катлы бөҗра белән уратып алган булганнар. Иң эчтә НКВД җәлладлары. Уртада гаскәрләр, ә тышкы яктан армиягә озатырга әзерләнгән допризывникларны куйганнар. Шулар арасында Вадим да булган.

Урыслар сан ягыннан гына да йөз кырык биш миллион. Бу — аларның күплегенә, зур саннар кагыйдәсе (теория больших чисел) күзлеге аша караганда, бик күп өстенлекләр бирә. Көчле дәүләт булып укмашкан зур милләт кенә Лев Толстой масштабындагы гигантларны бирә ала. Коллык шартларында яшәгән милләтләрнең Мәрҗани зурлыгындагы даһи шәхесләрен ирек юклык, кысынкылык һәм хакимият оештырган эзәрлекләүләр имгәтә.

Вадим Григорьев кан тамырына зонд тыгып тикшерүне күтәрә алмады. Хатыны, балалары килеп мәрхүмне алып киттеләр. Аның урынына Одесса киностудиясендә режиссер булып эшләүче кырык яшьлек Александр Васильевич Гришинны салдылар. Гришинның йөрәгенә бер тапкыр операция ясаганнар инде. Ул операциядән исән котыла алуына


Татарстан Җөмһүриятенең
Милли китапханәсе

ышанмый. Әллә чыннан да аның хәле авыр иде, әллә шул ышанмау алып китте аны.

Авар егете Рамазан йөрәк авыруын армия хезмәтендә эләктергән икән. Тикшереп карасак, палатадагы биш авырудан дүртесенең сәламәтлеген армия сындырган булып чыкты. Ә без күпме мәдхия җырладык Кызыл Армиягә, күпме еллар аны күкләргә чөеп мактадык!

Бер көнне Рамазан иртүк торды, палатадан чыгып тәһарәт алып керде, караватына намазлыгын җәеп озак кына намаз укыды. Әйберләрен җыеп сумкасына тутырганнан соң минем караватыма килеп утырды.

— Габдрахман ага,— диде ул урыс телен вата-җимерә.— Саубуллашыйк. Сез миңа шәригать кагыйдәләре турында сөйләдегез. Урыныгыз җәннәттә булсын. Кяферләрнең пычагына язмышымны тапшырасым килми. Тәкъдир — Аллаһы Тәгалә кулында. Аның үзенә тапшырам. Бәхилләшик.

Ишек ачылып ябылды. Рамазан яткан караваг бушап калды. Төштән соң ул караватка Кубадагы сугышка катнашкан пенсиядәге артиллерия капитаны Валерий Ушаковны салдылар. Казахстандагы Павлодар шәһәреннән иде Ушаков... Мурманга китәргә җыенып йөргәндә Валерийның хатыны Нина минем өемә чылтыратып хәбәр тапшырды:

— Иртәгә Валерийның кырыгы. Сез аның белән сердәш идегез. Җан бирер алдыннан Валерка сезнең исемегезне телгә алды.

Рамазаннан гына хәбәр юк. Минем палатадашларымның барысы да киләчәктә без барасы җирдә. Беләм, мине дә тиздән урын көтә? Бәлки, шуңа күрә ерак диңгезләрдә калган эзләремне карап кайтырга ашыга торганмындыр?

## 10

«...Катлаулы операциядән соң ерак юлга чыгу кирәкме икән сезгә?» Мин операция мажаралары турында уйлаганда шушы сорау әрнетеп җавап көтеп торды. Баш врач белән минем арада һаман шушы утлы сорау. Ышандырырлык, шул ук вакытта минем теләгемә юл ачарлык дәлилле җавап кирәк. Әйе, дәлилле җавап. Каян алыйм соң мин андый дәлилне?

Сорауның төрлесе була. Кайбер сорау — үзе җавап. Сорау — сөаль, сорау — эз яшерү, сорау — өмет, сорау — пычрак ату... Санап бетерерлекмени сорауларның төрләрен. Баш врачның соравы минем язмышымның бугазын кысып тотты. Бу сорау Мәнкир-Нәнкир сөалена тиң иде. Ялган да, хәйлә дә катнашмаска тиеш минем җавабыма. Мөнәсәбәтләр, мин сизмерлим, әлеге саф, эчкерсез, хәтта күпмедер дәрәҗәдә изге. Шул килеш калсын иде минем җавабымнан соң да...

— Бу хакта күп уйладым,— дип башладым мин.— Бу сорауны үземә-үзем ничә тапкырлар биреп карадым. Кирәк миңа сәяхәткә барып кайту. Бик тә кирәк. Миңа хәзер ансыз рәтле яшәү юк. Мин үземә ышанмый башладым. Мин бит инвалид. Инвалид хәлен сәламәт кеше белми. Аяк атлаган саен кимсетелүгә һәм кимсенүгә килеп абынып торасың. Сәламәт чакта минем күз алдымда берәр бәндәне җәберләсәләр, шул нахалның якасы шундук минем кулымда була иде. Ә хәзер... минем хәлне сез беләсез инде. Диңгезне сагынам мин. Диңгезгә чыгып бер йөреп кайта алмасам, үләрмен дип куркам. Павел Коганның нәкъ сугыш алдыннан иҗат ителгән «Бригантина» исемле җырын беләсезме икән сез? Минем буын, юк, минем буынның кечкенә бер өлеше, шул җыр тәэсирендә тәрбияләнде. Мәсәлән, минем өчен романтика яңгыравыклы матур сүз генә түгел. Романтика минем өчен күпмедер дәрәҗәдә дин дә, яшәү максаты да, бәхет тә. Озын, авыр сәяхәттә йөреп кайта алсам, инвалидлыгымнан арынырмын, кабат яшәреп китәрмен дип ышанам мин...

Нәрсә иде икән баш врачның күзләрендә сурәтләнгән билге? Сагыш микән, әллә курку идеме? Бәлки икеләнү һәм шуны яшерергә тырышу булгандыр?

Тирән итеп сулыш алды баш врач. Көрсенгәндәй итте. Тыштан тыныч күренә иде бу хатын. Вентспилс портындагы поликлиниканың баш врачы әйткән сүзләр исемә төште. Кырык яшьләрдәге таза, матур ир иде ул. «Әгәр сез сәяхәттә үлсәгез, мине төрмәгә утыртачаклар,— диде ул минем беренче килүемдә.— Минем хатыным, балаларым бар. Инвалид үзен инвалидча тотарга тиеш. Диңгезне сагынам дисез? Җәйге кызу сүрелгәч, Кырымгамы, Кавказгамы барыгыз да көннәр буе ярдан диңгезгә карап утырыгыз».

— Сез утырасы корабның кая баруы билгелеме?— диде баш врач, ниһаять.— Күпмегә?

— Мине Япониягә барасы корабка утыртмакчы булалар,— дидем мин.— Кораб әлегә диңгездә.

— Мин бит сезне диңгез белән танышу өчен генә Мәскәүдән килгәнсездер дип уйлаган идем. Язучылар, журналистлар еш киләләр монда. Өч-дүрт көнгә, берәр атнага диңгезгә чыгып урап кайталар. Кайткач, диңгезчеләр турында язалар. Андый язмаларны без кызыксынып укыйбыз. Ә сез Япониягә кадәр бармакчы икәнсез,— баш врач кинәт өшеп киткәндәй учлары белән җилкәләрен каплады.

— Әйе,— дидем мин ашыгып.— Озын һәм авыр рейска чыгасым килә. Нәкъ шундый рейс җан кертер дип өметләнәм. Бары тик шундый сәяхәттә генә инвалидлыгымны онытa алырмын дип уйлыйм.

— Озын һәм авыр?— дип сорады баш врач миңа карамыйча.— Мин сезне аңлыйм шикелле. Мәскәүдә туып үстем мин. Әтием проректор, әнием кафедра мөдире. Икесе дә профессор, икесе дә медиклар. Мин аларның фәнни эзләнүләрен дәвам иттерергә тиеш идем. Мединститутны кызыл диплом белән бетердем. Аспирантурада миңа урын әзер иде инде. Ә мин тоттым да Котыпта йөрүче бозваткычка врач булып киттем. Әтием дә, әнием дә инфарктка юлыга яздылар. Ирем — диңгездә. Елына күп дигәндә ике-өч тапкыр күрешәбез. Тугызынчы класстагы бердәнбер улым мореходкага керү турында хыяллана. Мин каршы. Елый-елый үгетлим. Тыңламый. Мин сезне кисәтергә тиешмен. Диңгезчеләр «романтика» сүзен өнәмиләр. Шул сүзне ишетү белән аларның чырайлары сытыла.

— Ул сүзне пропаганда пычратты,— дидем мин.— «Романтика» сүзен ишетү белән палаткаларда туңып ревматизм эләктерү, баракларда бет ашату күз алдына килеп баса.— Баш врач мине аңлый иде. Мин ашыгып зарланырга тотындым:— Инвалидлыктан да мәсхәрәле нәрсә юк икән бу дөньяда. Бигрәк тә кызым каныга. Кибеттән азык-төлек күтәреп кайтсам, шундук үлчәп карый. Ярамый сиңа авыр күтәрергә,— дип ачулана башлый. Әгәр төнлә ютәлләп җибәрсәм, кызым шундук минем янымда. Әтием, әллә салкын тигердеңме? Ярамый бит сиңа салкын тигерергә. Әллә сөт кайнарлап китеримме? Әллә дару биримме? Инде түзәр хәлем калмады.

Баш врач миңа кәгазь кисәге сузды:

— Кардиограммагызны ясатып килегез,— диде ул һәм шәфкать туташына чираттагы авыруны чакырырга кушты.

## 11

Кардиограмма кабинетының ишеге янына чират тезелеп өлгергән иде. Мин дә барып бастым. Көтә башладым. Авыр, газаплы уйларның күбесе чиратта торганда килә. Медкомиссия вакытындагы врач белән пациент арасындагы көрәш турында уйлый башладым. Министрлыкта эшләгәндә диңгезчеләр тормышының статистикасын өй-

рәндем мин. Сәүдә флотында эшләүче җитмеш меңгә якын диңгезченең һәр айда егерме биш-утызын каютага бикләп алып кайталар. Диңгез тормышының кырыслыгына түзә алмыйча акылдан язганнарның саны бу. Елына өч йөздән артык морякны, ике тимер мичкәне сварка белән бергә ябыштырып, шуның эченә салып алып кайталар. Бусы — юлда авырып үлүчеләр саны.

Җилкәнле кораблар чорында диңгездә вафат булганнарны брезентка төреп, аякларына авыр тимер тагып суга җирли торган булганнар. Мин озак еллар су асты авы белән шөгыльләндем. Суга җирләнгән мәетне күз алдыма китерә алам: акулалар килеп эшкә тотынганчы, ул мәрхүм агымда аягүрә торып, чайкала-чайкала әкрен генә соңгы юлында баруын дәвам итәдер инде?

Мәетне мичкә эченә урнаштырып автоген белән ябыштыргач, рефрежераторның бер камерасыннан азык-төлекне чыгаралар да мәрхүмне шунда урнаштыралар. Чайкалу вакытында тәгәрәп йөрмәсен өчен, бау белән тарттырып палубага беркетәләр. Шуннан соң корабның флагы флагштокның ярты өлешенә кадәр төшерелә. Корабта мәет барлыгын һәр диңгезче нервылары белән, бәгырь әрнүе аша тоеп тора. Шулкадәр авыр, ялыктыргыч тоела флагы яртылаш төшерелгән корабта йөзүе!

Яртылаш төшерелгән флагны көч-хәл белән күз алдымнан куып җибәрдем. Баш врач турында уйларга тотындым. Матур иде бу хатын. Мондый тәэсирле матурлык ана булу бәхетенә ирешкән, иреннән уңган, күңеленә ятышлы эш башкаручы хатыннарда гына очрый. Гәүдә һәм йөз-бит матурлыгына тышка бәреп чыгып торган акыл көче өстәлгәндә гүзәллекнең тәэсире бермә-бер арта. Хатын-кыз акылы, әгәр дә ул акыл чын хатыннарныкы икән, бөтенләй башка төрле акыл. Ул ирләрдә (сирәк) очрый торган кылычтай үткен, кырыс мантыйкъ акылына охшамаган. Хатын-кызда — аналар акылы. Йомшак, җылы акыл. Ул сине юата, инандыра, көч бирә, тәвәккәллек уята. Хатын-кыз акылына наз да катнашкан була. Тән назы — секс түгел, анысы акылсызларда да очрый. Җанны, күңелне рәхәтләндерә, хозурлый торган җан эреткеч нечкәлек назы. Урта гасырлардан башлап җәмгыять менә шушы сирәк очрый торган хәзинәне — хатын-кыз акылын юкка чыгару өстендә артмый-талмый эшләде. Көнбатыш тәрәккыяте шул бөек сыйфат урынына түшәктә кирәкле сыйфатлар тәрбияләде. Бездә, социализм төзү дәверендә, хатын-кыздагы йөк аты сыйфатларын гына калдырып, калганны төрле чаралар белән юкка чыгара килделәр. Әнә, минем янымда нәкъ йөк атына охшашлы хатын утыра. Беләкләр кыска, юан. Ботлар да шундый. Бил юк. Муен да юк. Баш турыдан-туры җилкәгә утыртылып куелган. Ул мескен тумыштан андый булмаган, билгеле. Менә аны кабинетка чакырдылар. Ишекне шапылдатып япканда стеналар дер селкенеп куйды.

«Йөк аты» чыккач, мин керергә тиеш. Һаман уйландыра. Мин бит инде өйләнгән кеше. Кызым үсеп җиткән. Гаиләмнән зарланырга хакым юктыр дип уйлыйм. Ә нигә соң күңел түрендә тоныкына, сизелерсизелмәс нииндидер яшерен аңлашылмас бер билгесез өмет яши. Егет булып өлгерә башлагандагы беренче мәхәббәт белән бергә туган тынгысыз, сукыр бер омтылыш. Кайдадыр күңел түрендә бер матурның сурәте мыштым гына качып яши бирә. Инде күптән, алтынчымы, бишенчеме класста укып йөри башлаганнан бирле. Җир шарының беренче гүзәле ул. Мин аны «Бөек Идеал» дип атап йөртәм. Матур кыз-хатын очраганда шул Бөек Идеал иплән кенә сорый: «Кем матурырак, улмы, минме?» Шушы көнгә кадәр Бөек Идеал белән ярыша алырлык хатын-кыз очраганын хәтерләми идем. Ә менә бүген баш врач кабинетында өстәл аша миңа каршы Бөек Идеал белән ярыша алырлык хатын утыра иде... Аның һәр сүзе, ымы, күз карашы, һәр хәрәкәте зур вакыйга булып минем хәтеремә сеңеп калды.

Эчемне ачыттырып, йөрәгемне әрнетеп «йөк аты» кабинеттан чыкты. Елый иде мескен. Димәк, социализм төзүдә мескенкәемне көне-төне

камчылап куып, аны да имгәткәннәр. Без бит «якты киләчәк, бәхетле тормыш»ны төзүдә эштән чыгарылып ташланганнар — миллионнар...

Кабинетка үттем. Чишендереп, салкын клеенка җәйгән ятакка яткырдылар. Беләкләремә, сыйракларга кургашын электрод бәйләделәр. Кардиограф эченнән бөселеп чыккан кәгазь тасмага йөрәгемнең тибеше языла башлады. Приборның тавышы мине кабат операция көненә кайтарды...

## 12

Үлгәнче котыла алмам шикелле бу сораудан: «Операция барышында мин яшәгәнменме, юкмы?» Йөрәге тибүдән туктагач, кеше үлә. Сигез сәгатькә якын минем йөрәгем тибүдән туктап торган. Димәк, сигез сәгатькә якын мин үлем кочагында булганмын. Дөрес, ул чакта йөрәк урынына канны тимер насос куып торган. Насос бит ул, моны сабый да белә, җансыз металл. Аның адәм баласына, кешенең яшәвенә бернинди катнашы юк. Юк, йөрәк кенә түгел, баш мием дә эшләүдән туктаган булган. Бусы инде катгый рәвештә минем Теге дөньяда булуымны раслый. Шул ук вакытта, врачлар миңа: «Син бөтенләй үлеп бетмәдең, кан әйләнеше эшли иде бит»,— дип ышандырырга тырышалар. Ә мин аларга менә нинди сорау бирәм: «Әгәр адәм баласының йөрәген кисеп ыргытып, йөрәк урынына тимер насос тегеп куйсаң, ул кеше саналамы, әллә робот дәрәҗәсендәге механизмга әйләнәме?» Төрлесенең җавабы төрлечә.

Испаниянең Таррагона портында торганда мин телевизор экраныннан йөрәккә операция ясаганны күргән идем. Америкада төшерелгән документаль фильм. Пациентны наркоз белән йоклаттылар. Дөресе, мәрткә җибәрделәр. Түге кырылган шәрә күкрәген бик озак спирт белән юдылар да йод сөрттеләр. Хирургның ассистенты җыйнак кына циркуляр электропычкы белән күкрәк сөякләрен нәкъ бугаз турыннан кендеккә кадәр ярып җибәрде. Ярадан ургып чыккан канны резин көпшә аша насос белән суыртып торалар иде. Махсус тиски белән күкрәк сөяген ике якка аерырга тотындылар. Хирург, кулын пациентның астына тыгып, умыртка сөяге турыннан кабыргаларны тикшереп тора иде. Белмим, кабыргалар чатный башладымы, ул ымлап аеруны туктатырга кушты. Күкрәк эченә җыелган кан эчендә пациентның йөрәге тыпырчынып тибә иде. Йөрәкне сак кына тышка чыгардылар һәм зур дикъкать белән кан тамырларын өзеп, «ясалма йөрәк»кә тоташтыра башладылар. Бераздан йөрәк тибүдән туктады. Хирург, аның ярдәмчесе һәм инструмент биреп торучы шәфкать туташы операциягә керештеләр.

Адәм баласының иң кадерле, иң газиз әгъзасы, кешегә җан өреп, аны кешелек сыйфатында тотып торучы йөрәкне скальпель белән яргалап, нәрсәнедер кисеп алалар, аңа нәрсәдер тегәләр иде. Йөрәксез калган бәндә ята бирә. Аның гәүдәсе җансыз. Ясалма сулыш аппараты пациентның үпкәсенә һава өрә һәм кире суырып чыгара.

Ул чакта операцияне азагына кадәр карарга түземем җитмәде минем. Телевизорны сүндереп, кают-кампаниядән чыгып киттем. Пациент яткан өстәл, аның өстенә япкан көрәнсу җәймә, хирургларның перчаткалары — барысы да канда йөзә иде. Операциягә әзерләнгәндә дә, операциядән соң торып йөри башлагач та шул канга батып яткан пациент урынында үземне күреп күп тапкырлар газапландым мин. Менә әле дә, Мурман диңгезчеләренең поликлиникасында кардиограмма ясатканда нәкъ шул йөрәкне телгәләү күз алдымда тора иде.

Торып киендем. Врач кардиограмма тасмасын кулыма тоттырды. Мин баш врач кабинетына юнәлдем.

## 13

Кардиограмманы карап чыккач, баш врач өстәл тартмасыннан кәгазь алып язарга кереште. Кәгазьнең өске өлешенә ташка басылган хәрефләр белән поликлиниканың баш врачы биргән рәсми документ расланган иде. Аста имза һәм мөһер урыннары билгеләнгән. Совет кешесенең язмышы кәгазьдә. Хакимият кирәк-ярагын үти торган мең төрле рәсми кәгазь бар бездә. Баш врач яза. Мин көтәм.

Язып бетергәч, баш врач кул куйды. Өстәл тартмасын кабат ачып, мөһер чыгарды. Мөһерне имзасы янына басып бер тын тотты да кәгазьне миңа сузды:

— Хәерле юл, Рахманкулов,— диде ул миңа аңлашылмас караш ташлап.— Корабыгыз астында җиде фут тирәнлек булсын.

Нигә соң ул миңа рөхсәт бирүнең җаваплылыгы турында киная ясамады. Нигә куркуын яшерде? Ә бит беренче килүемдә Вентспилс поликлиникасының баш врачы — баһадир кыяфәтле мыеклы ир мине бүре куган шикелле итеп кабинетыннан куып җибәргән иде.

Язуны кулыма алгач, сүзсез калдым мин. Әйтергә сүз табып булмый иде. Рәхмәт? «Спасибо в рюмку не нальеш»,— дип кенә җибәрәләр урыслар бу сүзне ишетү белән. Югалып калдым. Бәлки, кирәк булыр дип, сумкама бер тартма кыйммәтле конфет салып килгән идем. Әгәр шуны чыгарып баш врачка тәкъдим итә башласам, ике арада барлыкка килгән изге тойгылар пычраначак. Бәлки, тиз генә базарга барып чәчәк алып килергә? Кызганычка каршы, чәчәк бәйләме дә инде күптән ришвәткә манчылып пычранды. Чәчәкне бит арада рәсми мөнәсәбәт булмаган очракта гына бүләк итәргә була. Онытырга тырышабыз без бу кагыйдәне. Акыллы хатын бу турыда белә торгандыр. Мондый изге, пакъ мохитка бернинди матди нәрсә катнашмаска тиешлеге ярылып ята иде. Шул ук вакытта, нәрсәдер эшлисе, үземнең шушы бөек һәм изге гамәлгә лаеклы булуымны күрсәтәсем килә иде. Урта гасырлар, Ләйлә һәм Мәҗнүн чоры, Артур корольның рыцарьлары чоры искә төшә. Җан сыкрый...

Бугазга тыгылган төерне, күзләрдәге кайнарлыкны яшерергә тырышып, тыныч кына саубуллаша башладым. Баш врач миңа кулын сузды һәм...

— Сез, Рахманкулов, Кырым татарымы, әллә Казанныкымы?

— Казан татары мин,— дидем сорауның мәгънәсенә төшенеп җитмичә.

— Минем әбием, әтиемнең әнисе, Кырым татары кызы иде. Шуның тәрбиясендә үстем мин. Искиткеч матур иде. Затлы нәселдән. Әбиемнең туганнары егерменче елларда чит илгә киткәннәр.

Мондый сүзләрне мин инде күпме еллар, ничә тапкыр ишетәм. Ишетәм һәм югалып калам. Җавап юк, аңлатма да юк бу сүзләргә. Бәгырь ачытканын сизәсең. Милләтнең иң матур, иң акыллы, иң таза вәкилләре сазлыкка суга ыргытылган асылташ шикелле шул тарафка китеп бара, югала тора. Туктатырга көч тә юк, чара да... Каршы чыгарга, туктатырга теләүче дә юк — битарафлык. Урамда күкрәгемне тотырып һава суладым һәм озак тыелган күз яшьләре тышка бәреп чыкты.

## 14

ССРда унҗиде пароходчылык. Шуларның барысы да Мәскәүдәге министрлыкка буйсына. Министрлык диңгезләрдән ерак. Анда эшләүчеләр диңгезчелек эшеннән тулысынча читтә. Чиновниклар арасында йөзү эшен аңлаучылар бик сирәк. Хәбәрдарлык җитмәү һәр очракта битарафлык, хәтта диңгездә йөзүгә нәфрәт тудыра. Мәскәүдә чакта мин никадәр тырышсам да үзем утырасы кораб турында юньләп берни ачыклый алмадым.

Поликлиникадан пароходчылыкка юл тоттым. Миңа инде «Капитан Нугай» исемле корабка утырырга рөхсәт иткәннәр иде. Шуның кайларда йөрүен, аңа утыру өчен кайсы портка барырга кирәклеген ачыкларга кирәк иде. Мин балкерлар белән идарә итүче диспетчерны эзләп таптым.

«Капитан Нугай»ның диспетчеры шушы елларда гына институт бетергән яшь, чибәр кыз иде. Гадәттә, пароходчылык тирәсендәге эшкә яшьрәк чибәрләр урнашырга тырыша. Урнашу авыр, диспетчерлыкка медицина комиссиясен үтә алмаган авыру диңгезчеләрне куялар. Яшь чибәр кызлар монда урнашу өчен башта министрлыкта, яисә өлкә комитетында эшләүчене табалар. Шулар ярдәмендә урнашуы җиңелрәк. «Капитан Нугай»ның диспетчеры эшенә шундый юл белән урнашканга охшаган иде. Автомобиль фарасы зурлыгы тылсымлы зәңгәр күзләр озын, куе керфекләр астына яшеренеп торалар. Ә күкрәкләр!.. Сынчыларга өлге булып кына хезмәт итәрлек сылу гәүдә һәм җилкәләр. Чиктән тыш авыр, искиткеч катлаулы бит ул шушындый матурлыкны күтәреп йөрү. Шушындый матурлыкка ия була торып, авыр җаваплы эшне башкарып кара әле! Гүзәллек аулаучыларга каршы торырлык көч тә, егәр дә табып булмый табигать сиңа матурлыкны артыгы белән биргән очракта.

Аңлашыла иде чибәр диспетчерның проблемалары. Яшь, сөләгәй штурманга кияүгә чыгасы килми. Мәһабәт капитаннар исә барысы да гаиләлеләр. Өйләнгән булсалар да, зур-матур лайнерларны йөртүче капитаннар диспетчер кыз матурлыгы яныннан тыныч кына узып китә алмыйлар. Сәяхәттән кайткач, семьялы капитаннар туктаусыз сугылып торалар диспетчерга. Каш сикертү кораблар белән идарә итүдән күп тапкыр җиңелрәк.

— Мин «Капитан Нугай» белән кызыксынам,— дидем диспетчерга.

— Бүген кич ул Гданьски портыннан чыгып китәргә тиеш,— диде чибәр кыз, корабларның позициясе язылган кәгазьгә карап та тормыйча.

— Ул туры Мурманга кайтамы?

— Монда кереп бункер, азык-төлек, техснабжение алгач, Вентспилс портына йөк төяргә китә.

— Ул монда кайчан кайтып җитәчәк?

— Бер атнадан,— диде диспетчер өстәлендә яткан кәгазьгә күз сирпеп алгач.

— Корабның рейсы үзгәрмәдеме?

— Юк, әлегә үзгәрмәде. Вентспилстан соң Япониягә юл тота.

Кыз белән саубуллашканда аның блат аша эшкә урнашуы турындагы фараздан ваз кичәргә туры килде. Диспетчерның миңа биргән информациясе тулы һәм төгәл иде. Бу эшкә аны сәләтенә карап билгеләгәннәр булса кирәк.

Газаплы нәрсә ул диңгездән кораб көтү. Күпме агуладым мин канымны, күпме нервыларымны боздым утыз елга сузылган... диңгездән кораб көтү дәверендә.

Урамга чыккач план кора башладым: кунакханәгә кайтып бераз йоклап алыргамы, әллә кино карargaмы? Инде ничә тәүлек күзгә йокы кермәгәнгә диңгезгә чыгарга рөхсәт алгач, бераз җан тынычлангандай итте. Бәлки, йоклап булыр? Әллә берәр китапханәгә кереп әдәбият дөньясына чумаргамы?

Һава салкын, дымлы иде. Төньяк-көнбатыш җиле Атлантикадан җылылык ташыса да, Баренц диңгезе өстеннән узганда суынып өлгерә. Урамга чыгуыма чирек сәгать тә узмады, күшегә башладым. Йортларның нигезләрендә, багана төпләрендә шомлы шәүләләр. Төш вакыты булса да көн караңгы. Тукта әле, мин бит диспетчердан күп нәрсәне сорарга онытканмын. Корабның Япониянең кайсы портына баруын, йөген бушаткач кайларга юл тотуын, рейсның озынлыгын — боларның барысын да ачыкларга кирәк. Диспетчерны кабат бимазалау уңайсыз иде. Бүлек начальнигына керергә кирәк. Мин кабат пароходчылык идарәсенә юнәлдем.

## 15

Коридорның ике ягына тезелеп киткән ишекләрдәге белдерүләрне укып барам. Начальникның кабул итү бүлмәсе. Бу ишек башкалардан аерылып тора. Урыс рәссаме Верещагинның «Аксак Тимернең ишеге» дип аталган рәсеме бар. Начальниктан курку, аның бөек, хәлиткеч көч икәнлеген тою ишектән үк башлана. Туктап кабинет хуҗасының фамилиясен укыйм. Таныш. Мин министрлыкта эшләгәндә ул үзәк комитетта инструктор иде. Еш керә идем мин аның янына. Ул да минем янга кергәләп йөри иде. Әллә кереп хәлен белеп чыгаргамы? Начальник белән мөнәсәбәтне яңарту чиктән тыш отышлы. Тоталитар системаның серен белгән кеше һәр очракта иң өстәге, иң зур начальник белән элемтәгә керергә тиеш. Элемтәгә керә алу—үзе бер зур уңыш. Карьера ясауның төп кануны бу. Файда каезлау да нәкъ шушы законга буйсына.

Әйе, эшеңне зур түрәдән, аның хуплавыннан башлый алсаң, текә үрдән аска таба төшкән шикелле, эшең җырлап кына барачак. Астан өскә таба күтәрелү, ай-һай, авыр. Ләкин... Белмим, нәрсә булгандыр миңа? Шул җайлашуга керә торган механизмның нәрсәседер сынды шикелле. Нәчәльникләр белән эш итүне җаным сөйми, вөҗданым кабул итми башлады. Кайчан, нәрсәдән башлануын ачык кына әйтә алмыйм. Үз җаемны карауга каршы эчке бер протест, гыйсъян башланды. Гаделсезлек. Ничек узып китә алганмын икән яшьрәк чакта, белмим? Үз файдасын күздә тотып яшәүче гаделсезлекләрне күрмәскә, күрсә, күрмәмешкә салышып, тыныч кына үтеп китеп йөрергә тиеш. Менә шушы кагыйдәне үти алсаң, син инде нинди генә шартларда да майда йөзеп яшисең. Рәсәй шартларында бу канун аеруча каты, котылгысыз катгый.

Миңа бит берни кирәкми шикелле. Дан-шөһрәтнең өч тиенлек бакыр акча икәнлеген мин инде күптән аңладым. Кирәкмәгәч, тыныч кына яшәргә, коры куыкларны, саламторханнарны урап үтәргә кирәк иде бит? Юк, үтә алмыйм. Адым саен, минут саен җаныма төкерергә, бәгыремә кундырырга үземә үзем җай ясап йөрим. Инде җанымның кара көймәгән, кан саумаган җире дә калмады шикелле... Мазохистлыкмы бу? Ничек аңларга? Ничек аңлатырга?..

Элек тә күреп йөри идем бит. Барысын да: гаделсезлекләрне, күз буяуны, җәберләрне, коллык гадәтләрен һәм шулардан саклану чарасын—мескенлекне. Күрә идем, белә идем, аңлый идем. Бу бит инде безнең психологиябезгә сеңеп беткән. Аерым шәхес моңа каршы чыга алмый. Чыкса—бетте. «Если ты не с нами, то против нас». Тоталитар аңның формуласы бу. Миллионнарның газиз башларына җиткән аяусыз канун. Мөмкин кадәр гадел булырга, хакыйкатьне сакларга тырыша идем. Белә идем, каршы чыктың—беттең. Әхлак өлкәсендәге Александр Матросовлык бит инде бу. Ул чакта минем сабыр булырга, түзәргә көчем җиткән, эш шунда. Әллә түзүнең чигенә чыктым, юк, нервылар бозылды булса кирәк, үзем дә сизмәстән шәрә күкрәк белән амбразурага ташланганмын. Ярсып ташланганмын булса кирәк, соңыннан, берничә очередь минем абруемны умырып ташлаганнан соң гына аңладым.

«Үзгәртеп кору» дип аталган яңа уенның пүчтәк эш икәнлеген дә аңларга зиһенем җитте шикелле иде. Ничек инде гасырлар буе үзгәртеп булсын? Европа демократиягә дүрт гасыр килде. Авырлыклар аша, һәр буын бары тик бер-ике генә адымга якынлашып. Шул дүрт гасыр Көнбатыш көне-төне демократия тарафына атлаганда Рәсәйдә яулап алулар, кан кою тукталып тормады. Искиткеч зур, Карпат тауларыннан Тын океан ярларына кадәр җәелгән казарма иде башта патша, аннан соң большевиклар империясе.

Менә пароходчылык житәкчесенең кабинеты. Тыелдым, кермәдем. Үземне узып китәргә мәҗбүр иттем. Кереп сөйләшсәм ни булган инде? Хәтта уртача ялагай да калҗасыз калмый, нәчәльник тирәсендә йөрсә.

Халуйлар турында сөйләп тә торасы юк. Нишләп соң әле мин үз мәнфәгатемне күрүдән биздем? Нәрсә биздерде мине? Бәлки, бу берәр чирдер? Аутизм атала ул фәндә. Андый кеше аралашудан кача башлый, үзенең эчке кичерешләренә кереп бикләнә. Көнбатышта андый кешеләрне дәвалыйлар. Шул өянәк эләкте бит миңа, нишләргә? Бу бит инде мине үтерә, харап итә...

Горбачев «үзгәртеп кору» дип аталган нәстәкәйне уйлап чыгаргач, чиновникларны әзәйтү турында яза башладылар. Диңгез флоты министры Тимофей Борисович Гуженко пароходчылыкларны ХЭГС (хозрасчетно-государственная служба) аталган берәмлекләргә бүгәләп ташлады. Министрлык үзе өч хозрасчетлы берәмлеккә: Көньяктагы берләшмәләр флоты, Көнчыгыштагы һәм Көнбатыштагы берәмлекләргә бүленде. Һәм шул өч берәмлек тә кабара, бүртенә башлап чиновниклар саны буенча министрлыкны куып житте. Һәр ХЭГС пароходчылык күләменә житкәнче үсте. Шул чакта диңгезчеләр ХЭГС аббревиатурасын «Хреновину эту Гуженко сотворил» дип мыскыл итеп йөртә башладылар.

«Бозваткычлар ХЭГС»ы, «Ролкерлар ХЭГС»ы, «Балкерлар ХЭГС»ы. Бусы минеке булырга тиеш. Ишек шакыдым. «Әйе», сүзен ишеткәч кердем. Хужасының карашында: «Йөриләр шунда эш бүлеп» дигәнчәрәк мәгънә язылган иде. Телефон трубкасына кыска җөмлә белән, һәр сүзенә басым ясап әмер бирә:

— Юк, ярамый. Әйттем бит ярамый, дип. Үзең эзлә. Юк. Үзең тап. Министрлык головотяплары контракт төземәгәннәр. Ташырга йөк юк. Тоннаж яртылаш бушка ягулык яндыра. Үзең тап. Бетте!

— Тыңлыйм.— Начальник миңа борылды.

— «Капитан Нугай» кайчан Мурманга кайтып житәргә тиеш?

— Мурманга? Аны кем кайтара? Әллә сезгә диспетчер әйттеме?

Беренче фикерем дөрес булган икән. Диспетчер кызны кызганып куйдым.

— Бер хәрби әйтте. Унсигезенче кабинетта утыручы кап-два,— дидем мин хәрби разведка вәкилләренең тәрәзәләренә таш ыргытып. Диңгезчеләрне куркыту, кысу юлы белән тамак туйдыручы ул мәлгуньнарга берни булмаячак.

— Көтегез алай булгач. Хәрби кеше әйткән бит. Дүрт-биш айдан «Капитан Нугай» чыннан да, Мурманда булачак.— Начальник алдындагы кәгазьләрне актарырга кереште. Кәгазьләр, мин шундук танып алдым, кораблардан килгән радиограммалар иде.

— Мин бит «Капитан Нугай»га утырырга тиеш. Ул Мурман портына кайтмыймени?

— «Нугай» — диңгездә. Вентспилс портына якынлашып килә. Тагын нинди соравыгыз бар?

— Йөкне Япониягә илтү өчен төйиме?

— Әлегә Япония өчен.

— Япониядән соң кая юнәләчәк?

— Сез... нәрсә? Әллә мине Аллага саныйсызмы? Ташырга йөк юк. Кая карама, бардак. Кая карама — начальник. Беркем бернәрсә белми. Берәү дә эшне өстенә алырга теләми. Бардак һәм җавапсызлык. Вакытым юк минем, аңладыгызмы?

Мин саубуллашырга ашыктым. Бу кешегә ышанырга була иде. Аның телефоннан сөйләшүен күрү белән начальникның экстра класслы профессионал икәнлеген аңладым. Моңа кадәр капитанлыкта эшләве күренеп тора һәм нервылары бозыклыгы, медкомиссияне үтә алмавы да ярылып ята иде.

Коридорга чыккач туктадым. Тирән итеп сулыш алдым. Бисмилламны әйтеп, план кора башладым. Кораб бүген кич Вентспилс портына кайтып житсә, иртәгә-берсекөнгә Япониягә китеп баруы да мөмкин. Мурманскидан Ленинградка, аннан соң Ригага, Ригадан Вентспилска барып житү өчен ким дигәндә ике-өч тәүлек вакыт кирәк булачак.

Белешеп торасы да юк — һичшиксез, самолетка билетлар сатылып беткән. Билетның бер өлеше пассажирлар кулында, калганнары (бәлки «калганнары» дигәнем туксан процентка җитәр торгандыр?) — спекулянтларда. Минем бит әле «диңгезче паспорты» аласым да бар.

Рәсәй! «Бите юылмаган Рәсәй. Коллар һәм түрәләр иле...» Синнән дә бөек кеше булмаган бу илдә, Михаил Юрьевич! «Мин Шотландиядән (Скотлэнд) чыккан алпавыт Лермант нәселеннән дип аклансаң да, синең шәҗәрәң Алтын Урда бәге Чәләбәйгә барып тоташа. Белмим, башка империяләрдә дә юл газабы Рәсәйдәге шикелле аяусызмы икән? Юктыр. Мәсәлән, Алтын Урта империясендә почта Сарай-Батудан Мәскәүгә ике тәүлектән килеп җитә торган булган. Почтаны самолетлар ташый башлагач, ике атнадан артык вакыт кирәк.

## 16

Рәсәй бит бу — «широка страна моя родная... где так вольно дышит человек»... Белмим, ничәмә еллар җырлаганбыздыр шул җырны? Бу илне, дөресе — империяне күптән аңларга тырышам. Юк, булмый. Әлегә аны бары тик кретиннар һәм урыс фашистлары гына аңлаган булып кыланалар. Без, үги милләтләр, СССРны озак еллар «туган ил» дип атап йөрттек. Туган иттеме ул безне? Әле Мурманга килер алдыннан гына, Мәскәү татарлары акчасына салынган Асадуллаев йортын кайтарып бирүләрен таләп итеп, пикетка бастык. Милиция безне чукмарлап куды. Бер милиционер кыргый җанвар тавышы чыгарып кычкыра:

— Аларга монда нәрсә калган? Кайтып китсеннәр үзләренең Татарстаннарына!

«Үзләренең?» Димәк, СССР — безнең ватан түгел. Мәскәү дә безнең башкалабыз түгел. Димәк, без, татарлар, үз илебезгә кайтып китәргә тиешбез. Ә безнең үз илебез кайда соң? Дөрес, пропаганда Татарстанны «автоном республика» дип атап йөртә. «Автоном» — мөстәкыйль дигән сүз. Ә кайда ул Татарстанның мөстәкыйльлеге? Татарстан — өлкә. Аның бары тик өлкә, иң хокуксыз бер өлкә икәнлеген исбатлап та торасы юк. Татарстан белән өлкә комитеты идарә итә. Хокук ягыннан ул башка өлкәләрдән зәгыйфьрәк, чөнки милли төбәкләргә идарә итү өчен иң ялагай, холуй табигатьле бәндәләрне сайлап утырталар. Нинди мөстәкыйльлек булсын колларча Мәскәүгә буйсынып яшәгәндә?

«Без рәсәйлеләр» дип лаф ора Татарстанга килеп урнашкан урыслар. Аларга ярашыр өчен без, татарлар да, «без рәсәйлеләр» дип дер калтырап кабатлыйбыз. Чагыштырып карыйк: әгәр Алтын Урда чорында урыслар «без алтын урдалылар» дип тукып торсалар, мөстәкыйль урыс дәүләте оеша алыр идеме? Колониаль шартларда ирек яши алмый. Ирек булмаган җирдә хакыйкатькә урын калмый. Дөреслекне, гаделлекне бары тик ирек кенә саклый ала.

1947 елны безнең эскадрилья Запорожье янындагы хәрби аэродромнан Чукотканың Уэлен шәһәре янына кадәр очып барды. Сугыш вакытында СССРга ленд-лиз шартларында бирелгән «Бостон» самолетларын без АКШка кире кайтарып бирдек. Шул чакта мин борынгы Дәште Кыпчак далаларыннан башлап Америка кыйтгасыннан Беринг бугазы гына аерып торган территориясендәге җир шарының иң зур империясе — СССРны һавадан карап бардым. Аста чал кылганнар каплаган дала җәелеп ята. Атилла, Кубрат хан, Батый, Идегәй чорларында яңгыраган тояк тавышларын сагынып ятучы Кыпчак далалары. Даланы Урал тавының көрәнсу ташлары алыштырды. Тубыл елгасын уздык — Себер башланды. Иге-чиге булмаган тайга чытырманлыклары, яссы таулар, мул сулы ургыл елгалар. Карынына дөнья хәзинәләрен яшергән Вилюй, Лена, Алдан приискалары. Мәңге туң, даими сөргенлек — Колыма, Анадырь. Шул чакта мин СССР аталган илнең тоташ бер дәүләткә әверелә

алмыйча, тавык бүтәкәсендәге ташлар шикелле бер-берсенә кушыла алмас кисәкләрдән торган, уртак камчы, уртак штык ярдәмендә генә берләштерелгән, коллар көтүе икәнлеген аңладым. СССРны аерым ил итеп күз алдыма китерергә тырышам. Газапланам. Көчем җитми. Ул чиктән тыш зур. Үзара ябышмаслык, бер-берсенә ят, хәтта дошман булган кисәкләрдән тора. Карпат тауларыннан Чукоткага, Франц-Иосиф җиреннән Тау Бадахшанына кадәр җәелгән куркыныч бер чиксезлек. Шул чиксезлекне тоташ бер сурәт итеп күз алдына китерә башлау белән кинәт югалып каласың. Иге-чиге юк аның. Никадәр генә газапланма, Урта Азия белән Балтик диңгезе буе дәүләтләрен барыбер бергә кушып булмый. Ике тәкә башы бер казанга сыймый, дип аңлата бу хәлне татар мәкале. Бу төбәкләрнең табигатьләре, климатлары гына түгел, культуралары, тарихи юллары, хәтта милли космослары үзгә, ят һәм үзара кушылгысыз... «Әшәкелек империясе»нең җирләре шулкадәр зур, шуларны тоташтырырга тырышып аркылыга-буйга күз йөртә башлау белән күз карашың илнең игенә-чигенә чыга алмыйча, ярты юлда туктап кала. Никадәр тырышсаң да бу дәүләткә кергән аерым төбәкләрне бергә укмаштырып булмый. Шуңа күрә, бу ил белән идарә итеп тә булмый, чөнки Балтик буе илләренә файда китерерлек карар Урта Азия республикаларына бары тик зыян гына салачак.

Соңгы көннәрдә мин Мурманны карап йөрим. Монда яшәгәндә дә Мәскәүнең синнән нәрсә теләгәнлеген, аның сиңа ярдәм итә алырын, сиңа карата үзәк хакимиятнең игелекле ниятгә булуын берничек тә тоеп булмый.

Шушы авыр, газаплы уйлар порт тирәсендәге биек таш койма буенда күшегеп йөргәндә килделәр. Порт эченә кулында паспорты булган кешеләрне генә кертәләр, ә паспорт бирә торган контора үзе порт эченә урнашкан. Өченче көн портка паспорт алу өчен бирелгән кәгазьләрне күрсәтеп кергән идем. Ул кәгазьләр порт капитанының конторасында калды. Сакчыга аңлатып та, ялварып та карадым. Паспорт бирелә торган конторага шалтыратуын үтенеп сорадым. Рәсәй бит! Куып җибәрде.

Әллә койма аша элдертергә инде? Атып төшерәчәкләр. Ниһаять, кабат сакчы янына килдем. Гражданлык паспорты эченә пенсиянең нәкъ чиреген, өч унлыкны тыктым да сакчыга суздым. Сакчы «тикшерде» һәм үткәреп җибәрде. Каты режим, аяусыз тәртип һәр очракта кемнеңдер файдасына корылган... Файдалана белергә генә кирәк. Бу традиция Петр Беренче, юк, Явыз Иван заманыннан бирле килә.

Паспорт бирелә торган бүлмә эчтән бикле иде. Сәгать ике. Ул дүрттә генә ачылачак. Ә минем һәр минутым кадерле иде. Ничек булса да билет табарга, Вентспилс портына «Капитан Нугай» килгәнче барып җитәргә кирәк. Түзмәдем, шакыдым. Тынлык. Тагын шакыдым. Әкрен генә, сөйгән яр янына куна керергә килгәндәгечә итеп.

Миңа ишек ачкан кыз каушап калды. Өлкән яшьтәге бер абый. Кызга таныш, аңа кадерле кешене кертергә дип ачылган иде бу ишек. Аңлап алу белән кыз ишекне кире бикләп куячак. Башта мин тырышып елмайдым. Бала яратучы әтиләрчә. Һәм вәкарь белән генә, паспортны сәгать дүрт тулганчы алу мөмкинме, дип итальянча сорадым. Кыз миннән тупаслык, дау куптарып эчкә керергә омтылуны көткән иде. Ул кинәт йомшарып китте.

— Институтта мин инглизчә генә өйрәндем шул,— диде сабыйлар беркатлылыгы белән. Инглизчәмнең «бишле»гә укыган кызның колак пәрдәсен ертырлык тупас яңгыравыннан куркып, «великий и могучий» телдә иртә килүемнең сәбәбен аңлаттым. Кыз мине бүлмәсенә чакырды:

— Бер генә минут көтегез,— диде ул һәм тиз арада тутырылган паспортны эзләп тапты. Фоторәсем ябыштырылган. Мөһер сугылган. Порт капитанының имзасы гына җитми иде. Ярдәм йөзеннән имзаны үзем куйдыртырга әзер булуымны белгерттем.

— Юк, ул чит кеше кереп йөргәнне яратмый,— диде асыл туташ һәм өч минут эчендә әзер паспортны кулыма ук тоттырды. Кыз порт капитаны янына кереп киткән арада мин сумкамдагы тартмалы конфетны кызның өстәленә куеп өлгергән идем инде. Конфетны күрү белән кызның чырае сытылды:

— Мин сезгә, абый, ихтирам йөзеннән. Ә сез!..

Тау тишеге күренми иде якын-тирәдә. Конфетны кире алуы урлашудан да оятрак иде... Кинәт империядәге тәртипләрне тәнкыйтьләвемә, урыс бюрократларының әшәкелегенә ләгънәт укуыма үкенгәндәй итеп куйдым. Кыз эшләгән игелек шул әшәкелекләрне капларлык шикелле тоела иде миңа.

## 17

Ничек билет табуымны, нинди газаплар белән Мурманнан Вентспилска барып җитүемне сөйлисем килми. Әсәрем болай да зар, тәнкыйть, сыкрану белән тулган. Әгәр тормыш-көнкүреш башкачарак булса, мин укучыга гел Мурмандагы баш врач, миңа паспорт биргән тыйнак кыз шикелледәр турында гына сөйләр идем. Шуларга мин әле үземнең дусларымны: Нуриханны, Рәис Даутов, сеңелем Зәрияне, Рәшит Әхмәтҗанны, Хәбипов Шәрипҗанны, Равил Рахманины, Наис Гамбәровны, Фәнзаман Батталны, Разим Вәлиуллинны өстәр идем. Тагын кемнәрне? Диңгезче дусларым: Александр Дроздов, Виталий Биденко, Леонид Сивер, Геннадий Федосеев — бары тик шулар турында гына язар идем. Саный башласаң күпкә китә икән, журналист чакта дуслашкан Юра Амбернади, Владимир Шевелев, яисә соңгы еллардагы дусларым — Әгъдәс Борһановны, Фуат Мансаповны, Мидхәт Хәйруллинны онытып буламыни? Шушы кешеләрнең исемнәре генә искә төшкәндә дә күңелемдә җылы хисләр дулкыны кузгала. Шушы кешеләр янында мин үземне беркайчан да бәхетсез итеп тоймыйм. Яраткан кешең янында син үзеңне акыллырак итеп тоясың. Җир йөзендә мәхәббәт һәм дуслык шикелле бөек көчләр булмаса, адәм баласы әкренләп кыргыйланыр, ерткыч җанварга әйләнеп бетәр иде.

Ниһаять, Вентспилска да килеп җиттем. Мин хәзер чын-чыннан бәхетле. Югыйсә, Һиндстандагы буддалылар: «Бәхетле буласың килсә, бернәрсә теләмә, бәхетнең иң биек ноктасы — нирвана»,— дип кисәтеп торалар. Бәхетлелекнең иң бөек ноктасы — нирвана, теләкләрдән, өмет-ганлашлардан тулысынча арынып, галәмгә кушылып эрү. Шушы очракта адәм баласының сулышы галәм сулышына кушыла, аның йөрәгенең тибүе космик ритмда эшли башлый. Менә шушы халәткә омтыла Һинд буддалылары.

Такси ялларга акча беткән иде. Автобус тукталышын эзләп карадым. Табылмады. Чемоданымны күтәреп җәяү киттем. Чемоданымны сөйрәп кереп номерымның караватына ауганда нирванага ирешкән бәндәдән дә бәхетлерәк идем мин. Миңа бит авыр күтәрергә ярамый. Йончырга да, салкын тигерергә, артык дулкынланырга да рөхсәт ителми миңа. Йөрәгемдәге клапанны теккән җепләр ычкынмаган булса инде?.. Үтереп йөрәк авырта иде. Ачыттырып, көйдереп сызлый моторым... Сорау бирер, сөйләшер хәлем калмаса да, сөйрәлеп коридорга чыктым. Телефоннан чылтыратып «Капитан Нугай»ның Вентспилс портының тышкы рейдында торуын ачыкларга өлгердем.

Миңа сәламәт булу шулкадәр кирәк иде. Сәламәт булуым турындагы мөһерле язу минем курткамның түш кесәсендә, ә үзем авырыйм...

Саташуымы бу, әллә үткән газаплы мизгелләрнең махсус мине җәзалау өчен кире әйләнеп кайтуымы? Төш бит ул кабатланмаска тиеш. Кабатланган очракта да шулай ачык, шулай чынбарлык аяусызлыгы белән сиңа бәрелергә тиеш түгел. Бу төш инде өченче тапкыр кабатлана. Бәлки, күбрәктер дә. Хасталана башлау белән күрәм мин бу төш-чынбарлык-өнне...

...— Сал күлмәгеңне! Майкаңны да сал!

Ир кешене шәфкать туташы дип атап булмый бит инде. Шул, авыруларны операциягә әзерләүче «шәфкать абыйсы» тора янымда.

— Ясадылар бит инде операцияне, ышанмасагыз, күкрәгемдәге җөйне карагыз,— дип кычкырам. Каршылык күрсәтмәкче булам. Тыңламый. Ишетми дә. Башта күлмәгемне, аннан соң майкамны өстемнән йолкып алганнан соң үтмәс бритва белән күкрәгемдәге төкне кырырга тотынды. Сулышыннан суган исе, кичә эчкән аракының сасысы аңкый. Укшудан көчкә тыелып торам. Күкрәгемдәге төкне кырып бетергәч, ачыттырып йод сөртте. Озаклап, ышкый-ышкый, ниндидер сасы җилем белән күкрәгемә өч кат итеп бөкләнгән марля ябыштырды.

— Мә, йот!— «Шәфкать абыйсы» (мин аңа «җәллад» кушаматы тактым) миңа йокы даруы бирә. Нембутал. Иң көчле дару. Йотып, артыннан су эчкәнемне карап торды.

— Йокла. Иртәгә сәгать сигездә.

«Каталка» дип атыйлар ул көпчәкле носилканы. Болары шәфкать туташлары. Аларга күтәрергә авыр булмасын дип үзем менеп яттым. Коридор буйлап алып киттеләр. Һәр нәрсәдән, кешенең фаҗигасеннән, хәттә үлеменнән дә тамаша ясарга яратучы токым яши безнең арада. Андыйлар бигрәк тә больницаларда еш очрый. Менә шулар иртүк торып коридорга чыкканнар иде инде. Аларның күз карашлары шундый авыр. Шул салкын, гөнаһлы кызыксынуның лайлалы тәэсирен тәнем белән тоеп барам. Операция бүлмәсенең ишеге төбендә ике газиз кеше: кызым белән хатыным.

Язмышның кыл өстендә. Бу мизгелдә кинәт гомер буе камилләшкән гадәтләрең югалып калалар. «Гадәт» дигәнем — шул психолог инде. Аңга, акылга буйсынмыйча үзләренчә эш итүче сәер кыланышлар. Суга батучы мәхлүк салам бөртегенә дә чытырдатып ябыша бит. Син дә күзләреңне йомып, теләсә нинди пүчтәк өметкә чытырдатып тотынасың. «...Мин бу ике якынымны кабат күрә алырмын... алырмын»,— дип сулкылдап сөрән сала өметемнең авазы. Инану шулкадәр көчле, шулкадәр тәрәксез. Бәгырьләрне көзән җыера...

«...Бигрәк тә килбәтсез инде бу больница халаты»,— дигән фикер сакланып калган. Мине озатып баручы өстендә иде шул хлоркалап юудан, теләсә кем җилкәсендә йөрүдән, киеп йөрүченең битарафлыгыннан төсен югалтып, мескенләнеп беткән кәҗүннәй халат...

Хирургия кабинетының ишегенә таба борылганда «каталка» бер генә мизгелгә тукталгандай итте. Нәкъ шул чакта мин тәрәзәнең өске өлгесеннән җептәй нечкә ботакка эленгән ике сары яфракны күреп алдым. Коела алмыйча калган ике ятим яфрак. Көзге җил аларны әкрен генә селкетә. Сары яфракларның миңа кул болгап саубуллашулары иде бу. Шул ике нәни теләгән теләкләр әнкәемнең васыятедәй күңелемнең иң түренә кереп урнашты: «Курыкма, бар әле синең гомереӊ... Шикләнмә, бар... Ышан. Бирешмә, яме». Мин дә ым белән генә булса да яфрак-фәрештәләргә җавап бирдем: «Сау булыгыз, яфраклар. Уяна алмасам, миннән бәхиллек... Туган җиремә, минем Кара ярыма, туганнарыма сәлам тапшырыгыз. Кайгырмасыннар. Үкенерлек түгел, яшәдем мин...»

Бу минем дүртенче тапкыр пычак астына ятуым иде. Тәкъдиремә язылгандыр инде. Язмыштан узмыш юк, диләр бит...

Заманалар авырая, дип зарланалар. Әллә ничек, танымаслык булып үзгәрде бу тормыш... Без югалып калдык, чөнки киләчәкне икенче төрле итеп күз алдыбызга китерә идек... Кием-салым һаман яхшыра. Әллә нинди затлы ашамлыклар сата башладылар. Урам тулы чит ил машиналары. Никель елкылдый. Байлык. Ә кешеләрдә стресс. Экологик кризис. Үзара шәфкатьсезлек көчәя һәм комфорт. Мәхәббәтнең җанын кисеп ташлап, секс ясадылар... Күпләрдә чынбарлыктан качу теләге. Мине бөтенләйгә качырмаслармы, коткарумы икән бу, үтерүме?.. Башта әле сине мәрткә озаталар. Ансыз булмый...

— Дөнья мәшәкатьләрен онытыгыз,— диде яшь, таза, матур хирург.

— Өч нәрсә хәтердә тотылырга тиеш: уянгач, уң кулны урыныннан кузгатмаска — бер. Торып утырмаска — ике. Тамакка тыгылган көпшәне тартып чыгармаска — өч. Хәтерләдегезме?

— Әйе, хәтерләдем.

— Кабатлагыз.

Кабатладым.

— Наркоз!— диде экран артындагы врач.

— Йөзгә хәтле санагыз әле,— диде баш очымда басып торган хатын.— Бер, ике, өч... Ашыкмагыз.

Монда адәм баласының яшәү өчен иң мөһим әгъзасын — йөрәген төзәтәләр. Дәвалыйлар түгел, ремонтлыйлар. Пычак белән. Бу инде соңгы чара. Катгый, аяусыз. Операция өстәленнән күпләр туры зиратка юл тота. Күпме өлеше? Бу турыда белгертмәскә тырышалар. Шундый шартларда, телисеңме-юкмы, мәсьәлә сырты белән алдыңа килеп баса. Көндәлектә син үзеңнең отышлырак якларыңны зурайтыбрак күрсәтергә, кимчелекләреңне кулыңнан килгән кадәр яшерергә тырышасың. Операция өстәленә ятар алдыннан боларның кирәге калмый. Рәсми дәрәҗәләр, сиңа таккан купшы, мактаулы исемнәр — боларның барысы да көл, тузан бөртеге. Хәтта, тормышта сиңа канат булып, пычракка егылудан, ялагайлыктан, вакланудан, хәтта күпмедер дәрәҗәдә коллыктан да саклап, канатландырып йөрткән чын абруй да, әйтик, аяк бармагы тырналу яисә төшкән томау шикелле пүчтәк нәрсәгә әйләнә. Хакыйкать мизгелен аңлау сәләте күпләргә бирелмәгән...

Саный башлаганда шактый көр яңгыраган тавыш егермеләр тирәсендә зәгыйфьләнә, сүнә башлады. Тәнгә суырылып хәлсезлек керә. Битарафлыкта эри башлавыңны тоясың.

Кырыклар тирәсендә тавыш бөтенләй ишетелми иде инде.

## 19

...Колакта ерактан килгән ялгыз торна тавышы. Мәгарәне хәтерләткән тар караңгылыкта мин... Ара-тирә каршымда шәүләләр кыймылдагандай булып китә. Тынгысыз шыксызлык. Еракта тычкан утыдай зәгыйфь бер яктылык. Мин шуңа таба хәрәкәтләнүемне тоям.

Ниһаять, мәгарә кысынкылыгы әкренләп югалды. Таудан чана шуганда үзеңне шулайрак сизәсең. Ниндидер көч алга таба очыртып куа. Ут сизелер-сизелмәс кенә яктыра, якыная. Шул яктыру тизәйтә шикелле очуны. Очып баруым әкренәя башлады. Ниһаять, туктадым да шикелле. Аста бушлык, шуңа карамастан, басып торам. Каршымда бер шәүлә пәйда булды. Әкрен генә яныма килә. Тукта. Телгә килде:

— Йә Хода! Сезгә дә сугыш ачысын татырга язган икән... И-и-и балакайларым!

Бу бит минем әтиемнең соңгы сүзләре. Бу сүзләрне мин 1941 елның 24 июнендә ишеттем. Әтием җан биргәндә. Сугыш башланып ике генә тәүлек үткән иде. «Ачысын татырга»,— диде әтием. Соңыннан туганнар

бергә җыелган чакта без бу турыда күп тапкырлар сөйләштек: сугышның хәбәре генә дә кешене үтерә ала икән. Сугыш башланмаган булса, әтием яшәр иде әле...

Тукта әле, моны ничек аңларга? Кырык беренче елны вафат булган әтием янымда басып тора бит... Өстендә итәкләре җиргә тиеп торган сәдәпсез ак чапан. Йөзе шәүлә эченә яшеренгән. Буе-сыны, төсмерлим, әтиемнеке. Тавыш та анык. Басынкы, йомшак, сиңа көч-дәрман бирә торган шифалы тавыш... Ниһаять, очраштык. Тукта әле... Вафат кеше белән очрашу мөмкинмени? Кулымны сузып, әтиемне тотарга телим. Бушлык.

— Әти, синме бу? Нишләп сиңа кул тигереп булмый?

— Мин бу, улым. Синең әтиең. Син дә монда килдеңмени инде?

— Әтием, син гомер буе безне кайгырттың. Балакайларым, мин сезне укытам, кеше итәм, дип ут йотып яшәдең. Укыганга карап кына кеше була алсаң икән ул!.. Безне бит кеше итәр өчен түгел, буйсынырга, ялганга инанырга өйрәтер өчен укыттылар.

— Әйе шул. Хәзер аңлыйм инде, сезне томаландырыр өчен укыттылар.

— Әти, сине сугыш харап итте бит, әйеме? Ике сугыш имгәтеп ташлады, өченчесе бөтенләйгә алып китте. Син катнашкан сугышларның икесе дә империяне ныгытып, безнең коллыкны көчәйтү өчен иде бит? Шулаймы?

— Сугышның барысы да кан коюя, кеше үтерү өчен инде. Моны сез дә аңлый башлагансыз икән.

— Әти, бүген дә дөньялар тыныч түгел бит. Тагын сугыш кузгалмасмы икән?

Бушлык пәйда булды. Кая китте минем әтием? Сорауларым эленеп калды...

...Шул ук караңгы бушлык. Алга һәм аска таба очуымны дәвам итәм... Ерактагы ут һаман җемелди, чакыра, суыра. Җиңеләюемне, бәләкәйләнүемне тоям...

— Кайттыңмыни, Габдрахман? Мин сине иртәдән бирле көтәм... Һаман кайтмыйсың. Нишләп шулай озак йөрдегез? Әллә тагын атың арыдымы?

Бусы минем апам. 1943 елның көзендә егерме яшьне яңа тутырып егерме бер белән баручы Мәһүбә апам бу. Әйе, апам. Тукта әле, ул бит миңа уналты тулып килгәндә гүргә керде. Ә үзе, әнә, койма аркылы минем белән сөйләшеп тора. Апам мин Ютазы элеваторына ашлык илтергә киткәч өзлеккән иде. Мин кайткач кына җан бирде...

Нишләп соң мин шушы сәер хәлемдә әнкәемне күрә алмаганмын икән? Мин моны берничек тә аңлата алмыйм. Әллә ул миңа рәнҗи микән? Чыннан да, әнкәемнең рәнҗергә хакы бар иде. Мәскәүгә соңгы килүендә аның минем белән эчләре бушаганчы сөйләшәсе килде. Ә мин нәрсәдер яза идем. Ул һаман язудан туктавымны көтеп утырды. Башында почмаклап бәйләгән яшел кәшимир яулык. Үкчәләрен каплап торган шакмаклы шотландкадан теккән күлмәк. Кулында дисбесе. Иреннәрен генә кыймылдатып тәсбих әйтә. Үзе һаман минем язудан туктавымны көтә. Зарыгып көтә...

Соң аңладым мин ләгънәткә лаек язучы вазифасын! Яшәеш болай да авыр, катлаулы, син аны тагын да катлаулыландырасың. Шул катлаулык беренче чиратта синең үзеңә китереп кундыра. Юк ул рәхәт яшәү язучыга, юк! Китап язу аша байлыкка, дан-шөһрәткә омтылучылар да бар. Язучылык аша депутатлыкка, хакимияткә омтылучы кәсепчеләр дә тәрбияләде совет чоры. Миңа исә каләм тибрәтү зыяннан, дошман ясаудан, йөрәгемә кан саудырудан башканы бирмәде. Шул өстәл артында озаклап утырып, әнием белән сөйләшүдән мәхрүм итүем искә төшкәндә чәчләремне йолка-йолка елыйсым килә...

Кайчан сүнгәндер мине чакырып торган тылсымлы яктылык? Ул мизгел хәтердән юылган. Үземне тоймый башлавым да истән чыккан. Шыксызлык һәм ялгызлык. Шушы ике газаплы халәт хәтеремдә тамгаланып калган. Күп нәрсә онытылган. Авыр бит безнең тормыш. Тамак кайгысы... Идеология золымы... Авыр безнең тормыш. Яшисе килми торган чаклар күп... Шыксызлык. Ялгызлык. Гарык булу... Боларны бер мин генә тоймый торганмындыр?

## 20

...Күземне ачып җибәргәндә үземнең кайда икәнлегемне аңлар хәлем юк иде әле. Галәмне авыр шыксызлык чорнап алган. Газаплы тынлык. Нишләткәннәр мине? Тән белән җан арасында тоташсызлык. Нинди бүлгәләнү бу? Гомумән, минме соң бу? Газаплы билгесезлек...

Тамакка, әйтерсең, утлы тимер тыгып куйганнар. Сөякләр сызлый. Гәүдәне авыр салкын металл баскан. Уң кулымның беләгендә нәрсәдер сулкылдый. Бу газапка мин барыбер түзә алмам. Бу авырту, бу сулкылдаулар мине барыбер үтереп ташлар... Ничек туктатырга да ничек котылырга?

Нәкъ түземнең соңгы чигендә, тәрәзә пыяласының өске өлешендә нәни каен чыбыгында миңа кул болгап торган ике сары яфрак күренде.

— Хәтерлисеңме? Бу — без. Без синең уянуыңны көтеп утырдык,— дип шатланып кул болгый иде яфраклар.

— Нинди газап бу? Үләм бит! Нишләргә миңа?— Әйтә алмадым мин бу сүзләрне. Ләкин яфраклар мине сүзсез аңладылар.

— Түз, бирешмә,— диделәр алар бергәләп.— Курыкма, яшисең әле. Без бит сине кисәттек. Оныттыңмыни?

Эчкә җылы йөгергәндәй булып китте. Димәк, бу — мин. Димәк, мин — исән. Һәм ерактан, җир астыннан гаҗәеп аваз, бер таныш тавыш ишетелде. Яфраклар миңа ымлыйлар, тыңла шул тавышны, дип ишарә ясыйлар иде... Тукта әле... Тукта! Бишек җыры түгелме соң? Бишек җыры бит бу. Әниемнең тавышы. Үзенең яшь чагындагы, миңа бишек җырын җырлагандагы моңлы тавышы.

Тамакны яндырып торган каты нәрсәне тартып алырга дип кулымны күтәрә башлаган идем, келт итеп яшь хирургның кисәтүе исемә килеп төште. «Уянгач, уң кулыңны кузгатмаска... Торып утырмаска... Тамакка утырган көпшәне тартып чыгармаска...» Әйе, шәфкать туташын чакырырга кирәк...

Кычкырырга авызымны ачам... Авырту бәгырьләрне телгәләп, баш миемне айкап үтте. Кабат караңгылык... Үлү шушыдыр инде? Шәфкать туташы үзе килде. Аны сары яфраклар чакырды булса кирәк? Үзләре күренмиләр. Яфракларны караңгылык каплаган. Мин аларны барыбер тоям. Алар да мине тоеп торалар, хәтта күрәләр дә. Чакырдылар бит шәфкать туташын. Хәлиткеч, тылсымлы, илаһи билге иде ул яфраклар. Тәкъдиремне галәм белән тоташтырып торучы бер серле көч иде. Бәлки, шушы хәлиткеч мизгелдә Аллаһы Тәгалә яфракларны миңа сакчы итеп куйгандыр? Яшәеш белән үлем арасы — мәңгелек сер. Мәңге аңлашылмас сер. Яшәү үзе дә сер. Дипломлы томанлык, фәннең үзенә түгел, аның дәрәҗәсенә табыну — менә нәрсә комачаулый бу бөек серне ачыклауга. Бәлки, адәм баласы бу илаһи тылсымны аңларга да тиеш түгелдер? Кешенең аңы, белү мөмкинлеге шактый чикле. Чиксезлек Аллаһы Тәгалә карамагында... Адәм баласы мәңге баш вата, әмма күп сорауларга җавап таба алмый.

* * *

Уянып киттем. Таң беленеп килә. Кайда мин? Каршымда тәрәзә. Пыяланың өске өлгесеннән нәни ике яфракны эзлим. Тәрәзәнең өске өлешеннән кызгылт чирәп, кирпеч торба күренә. Кунакханә бит бу. Вентспилс. Балтик диңгезенең бер порты. Нишләп ятам мин монда? Хәл юк. Кем коткарыр мине авыруымнан? Торырга кирәк...

Урынымнан кузгала башлаган идем — әйтерсең, күкрәгемә пычак кададылар. Дөньяны караңгылык каплап китте. Йөрәк тибүен сизәм. Йөрәгемнең леп-леп тибүе чигәләремә күтәрелгән, бармак очларына барып җиткән. Авызда тәмсез корылык. Тел кибә. Күзләрдә ачыттыргыч кайнарлык. Температурам күтәрелгәнгә шулай. Ярамый бит миңа салкын тигерергә... Авырсынырга да ярамый. Чираттагы ревматик һөҗүм мине бөтенләйгә алып китәчәк.

Тирә-юньдә тынлык. Кунакханә йоклый. Шәһәр дә йокыга талган, ял итә. Океан лайнерын сөйрәп порттан тышкы рейдка ашыгучы буксирның дөп-дөп килеп двигательләре эшли. Лайнерның машинасы эшли башлады. Порт эченнән тимер юл уза. Диспетчерның тавышы: «Третий путь свободный».

Көч-хәл белән үрмәләп идәнгә төштем. Азаплана торгач, чемоданымны ачтым. Юлга алган даруларымны капшап таптым. Алсу таблетканы сытып оясыннан чыгардым. «Ибопруфне». Бер, ике, өч, дүрт... Юк, әз булыр? Алты таблетка йоттым берьюлы. «Ударная доза». «Ятып калганчы атып кал», ди татар әйтеме. Урыслар исә, «или пан, или пропал», диләр. Безнең тарихи тәкъдиребез хәтта әйтемгә дә сеңеп калган. Әнә бит татар әйтемендә һөҗүм итүче колонизаторларга каршы оборона тоту, атышу, ә аларда — яулап алу, хакимияткә, панлыкка омтылу.

Караватыма менеп ятканда мендәрдә уч төбе зурлыгы кара тап күреп алдым. Тәмам яктырып беткән иде инде. Мендәрдәге тапның барлыкка килүен аңлау тетрәндерде мине. Тамактан кан килә иде. Менә каян икән авыздагы тоз тәме. Минем дуамаллыкларымны күзәтеп торучы икенче бер Габдрахман шелтәле һәм үртәүле тавыш белән әйтеп куйды:

— Ну, что, достукался?!

Минем гороскобым — Игезәк йолдыз.

«Капитан Нугай»ны төяп бетергәнче терелә алмасам? Вентспилснең поликлиникасына үлсәм дә барасым юк. Аның зур корсаклы, мыеклы, симез баш врачы миңа үлемнән әшәкерәк тоела иде. Юк, диңгезгә чыгарга рөхсәт итмәве өчен генә түгел.

Аңа мин утырасы корабның капитаны врач аша ришвәт бирде. Мине утыртмас өчен. Сөйли башласаң, озакка китәр иде. Табиб вә ришвәт, чит кешедән курку. Ничек кенә булса да терелергә, аякка басарга кирәк. Минем бит әле ике тәүлек валчык та капканым юк. Бар акчамны Мурманда билетка тотып бетердем. Самолетка билет таба алмагач, Ленинград аша Ригага барырга тимер юл билеты сатып алдым. Шул билетны аварийный запас итеп, кесәмә салдым да аэропортка киттем. Башта спекулянт кулыннан Ленинградка очар өчен билет сатып алдым. Һавага күтәрелер алдыннан гына Риганың үзенә билет табылды. Ленинград билетын кире тапшырырга вакыт юк иде инде. Нәтиҗәдә, кесәмдә бар акчамны йоткан ике кирәксез билет утырып калды.

Акча табу. Юк, ул әллә ни катлаулы түгел. Аякка басу белән өйгә телеграмма сугарга. Табарлар әле. Терелергә кирәк. Төп мәсьәлә шул...

## 21

**И**нде менә өченче тәүлек бара. Тырышам — терелеп булмый. Күпләп дару эчкәндә ашарга кирәк. Гомумән, дару эчмәгәндә дә ашау бер дә зыян итми. Минем рацион — су һәм дару. Сахалин утравы-

ның истәлеге — гастрит кузгалды. Организм агуланды булса кирәк... Эшләр начар, иптәш Габдрахман Бакирович. Бу юлы да... Юк, минем бу турыда уйлыйсым килми. Җиденче кат күкләрдәге Бөек Көч әлегә яклый. «Капитан Нугай»ны әле һаман тышкы рейдта тоталар. Мин терелгәнне көтәләр булса кирәк? Иншалла...

Ишек шакыдылар.

— Әйе.

Рөхсәт итмәсәм дә керә иде. Кунакханәнең администраторы. Элекке килүдә мин алар белән танышкан идем. Алар өчәү. Икесе латыш хатыннары, бусы — маржа. Ире — отставкадагы полковник.

— Сезнең фамилиягез Рахманкуловмы?

— Башта исәнләшик әле. Исәнмесез,— дидем мин администраторга.

Ишетмәмешкә салышты. Кыяфәтендә кырыс тәвәккәллек. Нимес дзотына ташланыр алдыннан Александр Матросовның күзләре менә шулай ут янып торгандыр?

— Мин сезне кунакханәдән чыгардым.— (Урысча «выписал» сүзе «чыгардым»нан кискенрәк).— Җавап бирергә өлгергәнче администратор өстәде:

— Әйберләрегезне җыегыз да, әйдә, аска төшәбез. Мин бу номерны диңгезчегә бирдем. Хәзер җыештыручы керен бельены алыштырачак.

Хәзер инде офицер хатыннарының мондыйлары — реликт. Мин хезмәт иткәндә алар күпчелек иде. Көрәшче спорт мастерларында гына очрый торган юан, тыгыз гәүдә. Әгъзалар тупас, нык. Сугышчылар тудырыр өчен махсус эшләнгән хатын. Бу бәндәнең барлыкка килүенә Аллаһы Тәгалә катнашмаган шикелле. Таштан ясалганга охшашлы калын күкрәкне калын йон кофта кысып тора. Зәңгәрсу кара юбканы эчке яктан бәреп чыгарга торган тыгыз янбашлар. Химия ярдәмендә катырылган чәч өемен танк астына ташласаң да янчелмәс иде. Моннан кырык ел элек мин армиядә чакта модага кергән «Красная Москва» одеколоны исе аңкый иде администратордан. Ишектән кергәндә үк күзгә ташланды — атакага барган сугышчыда гына була мондый тәвәккәл омтылыш.

— Аңлатыгыз әле, рәхим итеп,— дидем мин үземне тыныч тотарга тырышып.

— Торыгыз. Киенегез. Чыккач әйтермен. Давай, җыеныгыз. Мин сезне коридорда көтеп торам.

— Мин бит авырып киттем әле,— дидем хаста булуыма артык басым ясамаска тырышып.— Авыру кешене урамга куып чыгарырга ярыймыни?

— Нинди саташу бу? Безобразие. Мин бит сезгә урысча аңлаттым: бу бүлмә хәзер сезнеке түгел. Мин сезне моннан чыгардым — выписывать иттем.— Карышасызмы? Хәзер милиция чакыртам...

Җавап бирергә өлгерә алмый калдым, икенче мизгелдә корыч хатынның үкчәләре ачу белән коридор идәнен таптыйлар иде инде. Күпме вакыт үткәнен хәтерләмим. Администратор белән сөйләшкәндә сәгатемә карамаганмын. Бу мине бүлмәмнән чыгартачак иде. Кунакханәдән дә кудыртачак. Йә хода! Нигә минем юлымда шундый кешеләр еш очрый башлады икән? Бу бит инде юкка гына түгел...

Ишек киерелеп ачылды. Юк, ачылмады. Бүрәнә белән китереп тондырган шикелле тавыш ишетелде. Борылып караганда идән уртасында милиция сержанты басып тора иде инде. Андый милиция көндәлек тормышта бик сирәк очрый. Америка боевикларында исә гел менә шушындый полицейскийлар уйный. Җилкәләр киң. Авыр, тупас ботинка кигән аяклар як-якка аерылып басылган. Куллар артта. Яңак мускуллары кабарып куя. Сыек боз булып эчемә курку йөгерде. Бу мине йә сөйрәп, яисә типкәләп урамга чыгарып ташлаячак. Ә тавыш нишләптер нечкә иде. Хатын-кызлар һәм турсыклар тавышы:

— Җыен!— Төкерегә лач итеп идәнгә барып төште.— Карышырга уйласаң, мин сиңа унбиш тәүлек чәпим.

Бу администратор хатынның малае түгелме икән? Охшашлык шулкадәр зур... Төрле җирдә эшләргә туры килде миңа. Хәтта җитәкчелек эшендә дә, әгәр өстән килгән боерыкны аска таба төшереп утыруны эшкә санарга яраса. Тәҗрибә зур, ләкин начальник булуларын байрак итеп күтәреп йөрүчеләр, юктан көрәк булган нуворишлар, «шәүлә» бизнесе белән шөгыльләнүче «крутойлар» белән, үтер, сөйләшә алмыйм. Юк, аңгыралыктан түгел. Бавырыма хәтле кабул итми. Шулар белән очрашканда эчемә Иблис кереп оялый. Шул сөйләшә алар белән... Ә менә милиционерлар белән, мактану түгел бу, сирәк булса да сөйләшә алам:

— Фамилиягез?— дидем мин ястыгымнан күтәрелә төшеп.

Сержант авыз эчендә ботка пешереп алды — аңламадым. Сержантка серле итеп моряк паспортын суздым:

— Мине Мәскәү җибәрде. Спецзадание...

— Рах... Рахман... Нинди милләт бу?— диде тәртип саклаучы.

— Скиф. Борынгы греклар безне «патша скифлары» дип атап йөрткәннәр.

— «Дублер старшего штурмана». Нәрсә ул дублер?

— Сезнең начальнигыгызның эшен кем тикшереп тора?

— Ригадагы начальник.

— Ригадагы начальникның эшен кем тикшерә?

Сержант җилкәсен кашып алды. Аллага шөкер. Шөлли башлау дигән сүз иде бу. Миңа нәкъ шул кирәк иде. Курку һәм куркыту — Рәсәйнең идарә итү ысулы...

— Мин бит Мәскәүдән килдем,— дидем мин.— «Килдем» сүзенә басым ясап. Әгәр милиционер латыш булса, «Мәскәүдән килдем» мине харап итәчәк иде. Күренеп тора сержантның теге Бөек Болгар чорында ушкуйник булып йөрүчеләр токымыннан икәнлеге. Мондыйларга Мәскәү — Мәккәи Мөнәвәрә, изгеләр яши торган шәһәр.

— Әйдәгез, җыеныгыз, абый...

— Ашыкмыйк әле, иптәш сержант. Сез минем документны тикшердегез. Эчке эшләр министрының йөз кырык беренче приказына таянып, хәзер мин тикшерергә тиеш сезнең документларыгызны.— Башта мендәр астына кулымны тыгып блокнот алдым.— Бирегез әле документыгызны. Менә нәрсә, эш болай катлаулыга киткәч, мин сезнең начальнигыгызның да исем-фамилиясен белергә тиеш, объектка чыгар алдыннан инструктаж ясаган кешенекен дә.

Милиционерның кыяфәте бөтенләй икенче иде хәзер. Ул кесәсенә кулын тыккандай итте. Фуражкасын төзәтеп киде. Каешының тыгызлыгын тикшереп карады. Хәзер ул танымаслык булып үзгәргән иде.

— Җыена торыгыз (баштагыча «тор» түгел, «торыгыз»). Минем ашыгыч эшем бар. Кайтышлый керермен.

Милиционер да, администратор да башкача кермәделәр. Икенче көнне, полковник хатынының дежуры тәмамлангач, икенче администратор — латыш хатыны керде. Айя белән мин беренче килүдә танышкан идем. «Танышкан идем» шул, гадәттә, кунакханәдә яшәүче клиент белән администратор арасындагы танышлык чикләреннән чыкмас иде, әгәр латышлар азатлык көрәше алып бармасалар. 1990 елның азагы, көрәшнең тәмам кызып, хәлиткеч финалга якынлашып килгән чагы иде. Минем татар икәнлегемне белгәч, администратор Айя миңа латышларның колонизаторларга каршы көрәшүләре турында сөйли башлады. Уртак тел тапкач, без рухи якынаеп киттек.

Полковник хатыны да миңа серләрен сөйли иде. Аның серләре дә азатлык турында иде. Ләкин аңа, марҗага, латышларның мөстәкыйльлеккә омтылуы коточкыч зур җинаять тоела. Ничек инде үзләрен фашизмнан азат итеп коммунизм юлына чыгаручы олкән абыйларыннан аерылырга теләүне гаделлеккә санап булсын?! Мария Дмитриевна Мәскәү җитәкчеләренә, бигрәк тә Горбачевка рәнҗи иде. «Әнә бит Сталин чорында латышлар безне ничек ихтирам итәләр иде. Хәзер безне кешегә

дә санамый башладылар. Барысы да шул Горбачевның «үзгәртеп кору» аталган томаналыгы аркасында. «Искегә ягылсаң — исең китә»,— ди татар әйтеме. Череп таркала башлаган империяне коткару мөмкин түгел иде. Горбачев Латвияне СССРдан аерылып чыгарга өндәп, коткы таратып йөрүчеләрне төрмәгә ябып дөмектермәсә, «дуслык», һичшиксез, янарыр иде».

Бу фикерне кабул итәргә, хупларга тиеш идем мин. Мин исә киресенчә, Рәсәйгә буйсынган илләрдә ни сәбәпле халыкның урысларны яратмавын аңлатырга керештем. Ничек аңласын инде урыс марҗасы? Ара чатнады. Дуслык ташка бәргән аракы шешәседәй челпәрәмә килеп ватылды. Полковник хатыны турыдан-туры миңа дошманлык күрсәтә башлады.

## 22

— Сезне кунакханәдән чыгармакчы булалар,— диде администратор Айя.— Акчагыз беттемени? Күпме кирәк, мин сезгә әҗәткә бирәм.

Мин тумбочкадан ике билет алып, Айяга суздым:

— Акчам менә шушы билетларга китеп бетте,— дидем.— Мин бит бик каты авырып яттым. Хәзер инде тора башладым. Иртәгә акча сорап өемә телеграмма бирәм.

— Язык, мин хәзер үк җибәрәм,— диде администратор.— Ә бу билеттагы акчаларны алып булмасмы әле? Минем сеңелем Аэрофлот кассасында эшли. Шуның белән киңәшеп карармын. Әгәр бүген кичкә кадәр түләмәсәгез, сезне бүлмәгездән чыгарачаклар,— Айя мин язган текстка күрсәтеп өстәде:— Акчагыз килгәч, бирерсез әле, мин түлим. Врач чакыртыйммы?

— Юк, кирәкми,— дидем ашыгып.— Хәтерлисезме? Беренче килүдә сәламәтлеге начар дип мине сәяхәткә алмадылар. Тагын калдырулары ихтимал.

— Ә сез ач ятмыйсызмы?

— Аппетитым юк минем,— дидем инде өченче тәүлек ач торуымны яшерергә тырышып.— Мин гел шулай, чирләгәндә валчык та ризык каба алмыйм.

— Ач килеш терелеп буламыни? Ярый, мине аста көтә торганнардыр. Тизрәк терелегез.

Айя чыгып китүгә ярты сәгать үттеме икән, кулына поднос тотып буфетта эшләүче хатын Валда килеп керде.

— Айя әйтмәсә, сезнең тагын Вентспилскә килүегезне белми идем,— диде буфетчы хатын.— Ачлык игълан итмәгәнсездер бит?

Бу дөньяда иң кадерле, иң кыйммәт нәрсә — татулык. Шул көч мине кунакханәдән куып чыгарудан саклап калды, тамагымны туйдырды. Шул бөек көч, ни хикмәт, мине акчалы да итте. Айянең сеңелесе минем авиабилетымны тапшырып акча алды.

— Тимер юл билетын Ригада тапшыралар,— дип аңлатты Айя.— Иртәгә сеңелем шунда бара. Паспортыгызга салып билетыгызны бирегез. Иртәгә тапшырыр.

Номерга түләнгән. Тамак тук. Күңел тынычланды. Моннан да көчле дару бармы икән бу дөньяда? Һәм мин юлга чыкканнан бирле беренче тапкыр тирән йокыга талдым. Төн урталарында әзгә генә уяндым. Күңелне бер мәзәк фикер кытыклый иде: латышларның азатлыкка омтылуын хуплау мине бүлмәдән куылудан коткарып калды. Әгәр латышларның ирек даулауларына каршы чыгып, урысларны яклаган булсам да, мин оттырмый идем бит. Бу очракта, һичшиксез, мине полковник хатыны яклар иде... Халыклар арасында гауга купкан чакта җиңел генә файда ясап була. Җаен гына таба бел. Табалар да бит. Бигрәк тә татарлар

арасында мондый мөмкинлекләрдән файдалана белүчеләр ишәеп китте. Колонизаторлар ягына бастың — мә, ал. Алар сине зур урыннарга күтәрә алалар. Телисең икән, байлык туплап була торган җиргә утырасың. Власть бит алар кулында.

Туган җиремнән еракта, Балтик диңгезе буенда татарлар арасында, мөстәкыйльлеккә омтылу хәрәкәте шыта башлаган чор турында уйлап ятам. Хәрәкәт уянуга халык мәнфәгатен сату, милләткә хыянәт итү дә башланды. «Литературная газета»да басылган бер мәкалә исеме килеп төште. Мәкалә «халыклар дуслыгы»на багышланган иде. Күренекле шагыйрь шул «дуслык»ны бизәкле матур келәм, думбраның кыллары белән чагыштырган иде. Келәмнең бизәген кисеп алсаң, умырылган җир, думбраның бер кылын өзсәң, тавыш зәгыйфьләнә, дип дәлилләгән иде автор. Келәмнең иң күркәм бизәкләрен — Кырым татарларын, Кавказ халыкларын Лубянка кайчысы белән кисеп алып үлемгә озатуларын, дуслык думбрасыннан ыңгырашкан, кан елаган тавышларның ел ишетелеп торуын яшерергә тырыша иде бу шагыйрь. Һәм шул ук «Литературка»да бер-бер артлы сатлык татар Җан Миндубаевның мәкаләләре күренә башлады.

Сәясәт Иблискә охшашлы. Аны аңлаучы чиктән тыш аз. Аңламау отышлырак. Аңлаучыларның да әле сәясәтнең тышын, күзгә бәрелеп торган камуфляжны гына күрәләр. Мөстәкыйльлек яулаган татарларны бикләп куябыз, дип яныйлар. Татарлар колониаль хакимияттән аерылсалар, ачка үләчәкләр, дип куркыталар. Тикшереп карыйк. Беренчедән, Татарстанны бит Башкорт, Чуаш, Удмурд, Мукшы республикалары, Ырынбур, Самара, Нижгород өлкәләренең тоташтан диярлек татар яши торган районнары чолгап алган. Икенчедән, Италиянең үзәк бер территориясенә урнашкан Сан-Марино дәүләтен, зур, көчле илләр эченә кереп урнашкан Лихтенштейн, Андорра, Люксембург шикелле мөстәкыйль дәүләтләрне нишләп күршеләре чәйнәп йотмыйлар икән? Ул нәни дәүләтләрне корал көче белән яулап алуны бер тәүлектә түгел, берничә сәгатьтә гамәлгә ашырып була. Өченчедән, Татарстанның көлен күккә очырабыз дип янаучылар, бөтен бер халыкны бикләп куеп, беркая чыгармыйбыз, дип куркытучылар урыс халкын кыргый җанвар табигатьле дип фараз кылалар. Гади урыс халкы арасында шәфкатьлеләр бөтенләй юк микәнни? Бар алар. Лев Толстойлар, Андрей Сахаровлар, Михаил Худяковлар, Лев Гумилевлар — күп алар һәм киләчәктә, Аллага шөкер, тагын да күбәячәкләр. Дөрес, Явыз Иван башлап җибәргән кан коек, җимерү, янау, куркыту дәвам итә, әмма аңа каршы беренче чиратта урыс гуманистлары протест белгертә башладылар.

## 23

Аңларга тырышам: нишләп әнием төшләремә керми? Вафат булган елларында әниемне атна саен диярлек төшемдә күреп тордым. Ә нигә ул керми башлады?

Ана сөте. Әниеңнең җылы, йомшак куллары. Бишек җыры. Әнкәеңнең баласы булудан берничек тә арынып булмый. Кендек киселгәнгә ярты гасыр, җитмеш ел узган. Инде без үзебез күптән әти. Без барыбыз күзгә күренмәс меңләгән тамырлар белән газиз әнкәебезгә тоташканбыз. Шул әңкәңә тоташтырып торучы җепләрне өзү белән син шундук кешелек сыйфатларын югалта башлыйсың. Җепләр өзелгәч, син инде чын кеше түгел. Хәтта хайван да була алмый торгансыңдыр? Хайванда да анасына булган изге тойгы беркайчан сүнми.

Күз алдыма бала чагымның бер онытылмас манзарасы килеп баса. Нефть катламының басымын көчәйтү өчен җир астына куып керткәнгә кадәр безнең инеш мул сулы, тирән иде. Ул чакта аның холкы да бөтенләй башка иде. Язгы ташу вакытларында ел саен бер тапкыр

ярларыннан чыгып, дулап та ала иде. Авыл буйлап тезелеп киткән буаларның өчесен дә ерып ыргыта, күперләрне җимереп ташлый, түбән очның йортларына су керә...

Ташу вакыты иде. Малларның ашар азыгы беткән чак. Иртәнге якта ташу басыла төшә. Малларны инешнең сай җиреннән тау ягына турыга куып чыгарып була. Кояш төшкән җирдә тау битләренә яшел үлән шытып чыккан. Маллар көне буе шуны утлап йөриләр. Кичкә таба ташу көчәеп китә дә, малларны уравыч юл белән түбән очтагы олы күпер аша алып кайтырга туры килә. Бу инде гадәткә кереп киткән иде.

Язгы ташу безнең гаиләгә ел саен бер афәт алып килә иде: әтиемнең ревматизмы кузгала. Ул хәлсезләнә. Аякларын көчкә сөйрәп йөри башлый. Эш күп. Мәшәкатьле чак. Малларга печән беткән. Иң авыр, иң кытлык чак. Бәрәңге бакчасын казырга, бәрәңге утыртырга кирәк. Әти авыру.

Сыер һәм сарыкларыбызны иртән су төшкәндә ул көнне тау ягына куган идек. Алып кайтыр вакыт җиткәч, әти абыемны чакырып кисәтте:

— Сәлимҗан,— диде ул.— Су күтәрелде. Бүген көн бик җылы булды. Агым көчледер. Малларны кичү аша чагарып булмас. Син аларны түбән очка куып төшер дә күпер аша алып чык.

Үзе генә барган булса, сүз дә юк, абыем шулай эшләр иде. Безнең гаиләдә әтиебезнең сүзе закон иде. Абыем маллар артыннан күрше малайлары белән китте. Малайлар күпергә кадәр төшеп йөгерергә иренгәннәр, малларны турыга, сайлык аша куганнар. Билгеле, күршеләргә абыем да кушылган.

Хәбәр шундук җитте.

— Фәрихәттәй,— дип кычкырды күрше кызы Саимә.— Малларыгыз суга ага!

Ишетү белән әнием чыгып йөгерде. Әтием дә китте.

Әтием йөгерә алмый, көч-хәл белән аягын сөйрәп бара.

Без инеш буена төшеп җиткәндә күршебез Куян Заһидулласының сарыклары суда агып бара иде. Су өстендә сарыкларның башлары гына күренеп тора. Мескеннәр талпынып су читенә таба йөзәргә телиләр, ташкын аларны һаман уртага, боргаланып торган чоңгыллыкка таба сөйри. Яшь бәрәннәр җаннарыңны өшетерлек итеп мәэлдиләр. Заһидулла абзый ачы тавыш белән малаена кычкыра:

— Үтерәм мин сине! Өрлеккә асам!

Күршеләребезнең хатыны, Бәдигыльямалттәй, үкереп елый:

— И-и-и оланнар! Күпер аша алып кайтыгыз дип атагыз кисәтте бит. И ходаем, сарыксыз калдык бит!..

Шулай кычкырышып, паникага бирелеп торган арада күрше сарыкларын агым йотты. Безнең сарыклар агымның көчле урынын узып, бу як ярга якынлашып киләләр иде. Шул чакта олы сарык әллә абынды, әллә аяклары чокыр җиргә туры килде. Ул кинәт янтаеп китте дә, кырын ятып, ага башлады. Яшь сарыклар әниләре ягына борылдылар. Агым аларны күрше сарыкларын йоткан чоңгыллыкка таба куып алып китте.

Сарыксыз калуның фаҗигасен авыл кешесе белә. Бигрәк тә ул елларны. Ул чорда эш көненә берни бирмиләр иде. Эшкә чыкканнарга икешәр йөз грамм он өләшәләр. Кырда эш бетү белән ул да туктала. Колхозчының ачлык тырнагыннан котылу өмете — бәрәңге һәм аяклы маллар.

Каршы як ярда абыем әрле-бирле йөгереп йөри. Кемдер кычкыра. Бәдигыльямалттәй үкси-үкси елый. Без үлемгә таба йөзеп барган сарыкларыбызны күзәтәбез. Яр буена халык җыела башлады, тамашачылар. Нәкъ шул чакта күрдем мин әниемнең суга ташлануын. Әти әле һаман инеш буена килеп җитмәгән иде. Инешкә төшә торган тыкрыктан аның тавышы ишетелде:

— Фәрихә, нишлисең син! Әллә исәрләндеңме? Чык судан. Батып үләсең бит. Чык!

Текә яр астында кайнаган су әниемне сарыклар белән бөтерелдереп йөртә башлады. Агымның ярга бәрелүеннән файдаланып, әни сарыкларны бер-бер артлы судан ярга этеп чыгара башлады. Соңгы сарык ярга чыгып суын селки башлау белән борылды да, ырләрчә, колачлап, йөзеп китә башлады. Ниһаять, ул ярда. Өйгә таба йөгерә. Әтием белән очраштылар. Үтешли, пышылдап кына әтиемә нәрсәдер әйтте. Әти һаман бер сүзне кабатлый:

— Исәрләнгәнсеңдер син! Кем инде сарык өчен бозлы суга керә?

Мин өйгә кайтканда әнием яулыгын чөеп бәйләгән, өстендә кунакка барганда гына кия торган бәрхет җиләне, шаулап торган самавыр янында кипкән кура җиләге белән чәй эчеп утыра.

— Габдрахман, бар карап кайт, мунча мичендәге утыннар янамы икән? Сүнсә, яндырырга азапланма, миңа гына кайтып әйт.

Нәкъ шул көнне мин гомеремдә беренче тапкыр әниемнең матур икәнлеген аңладым. Судан чыгып өйгә таба йөгергәндә аның озын буйлы, нечкә билле, гәүдәсе гомер буе авыр, имгәндергеч эш белән шөгыльләнгән хатыннарныкына охшамаган иде. Суга чыланган толымнары да гадәттәгедән озынрак шикелле тоелды. Һәм мин тагын шуны аңладым: дөньяда менә шушындый әниең бар чагында сиңа беркем берниндн зыян, берниндн начарлык эшли алмаячак. Фаҗигага юлыксак, ул безне дә менә шулай җиңел генә коткара алачак. Шушы инану мине гомер буе саклап йөртте. Әни мине курыкмаска өйрәтте. Шуңа күрәме, агитпроп китапларындагы батырлык миңа көлке тоела иде. Чын батырлык әле һаман бозлы суга кереп сарыкларны коткару булып тоела миңа.

Әти авыру булгангамы, без әни балалары булып үстек.

Бу төш минем терелә башлавымны, хастамның хәтәрсез тәмамланачагын белгертә иде. Чыннан да, бу көнне мин беренче тапкыр урынымнан торып, үз аягым белән буфетка киттем. Үтешли фойегә администратор янына сугылдым.

Дежурда полковник хатыны Мария Дмитриевна иде. Аңа җылы сүз әйтәсе, шул әйбәт сүз ярдәмендә арадагы дошманлыкны юкка чыгарасым килә иде:

— Хәрби пенсионерлар үзләре нәрсә сөйлиләр соң?— дип башладым мин администраторның зарын искә төшереп. Ул миннән тик әшәкелек кенә көтә иде. Аның йөрәгенә дошманлык оялап өлгергән иде инде. Дошманлык хисе исә бары тик үч алу, каршы якка зарар китерерлек эш кенә таләп итә. Хатын нәрсәдер мыгырдап алды. Аның нәрсә әйткәнен аңлый алмадым. Хәзер нәкъ татар әйтемендәге «таш белән аткан» бәндәгә «аш белән ату» мизгеле иде. Мин дәвам иттем:

— Кемдер коткы тарата,— дидем мин.— Латышларга каршы кампания башлаган карагруһларга сезнең ирегез шикелле абруйлы кешеләрне үз якларына аударырга кирәк иде. Алар отставкадагы хәрбиләрне, Латвия СССРдан аерылып чыкса, пенсиягездән колак кагасыз, дип куркыталар. Әнә, яһүдләр Израилгә дә, Америкага да җиңел генә китеп баралар. Барып урнашалар, гражданлык кабул итәләр һәм пенсия ала башлыйлар. Пенсия түләү халыкара хокукка бәйле. Бер генә илдә дә аны түләмичә кала алмыйлар.

— Латышлар безгә дошманлык күрсәтәләр. Без аларның каршылыкларын аяк атлаган саен тоеп торабыз.

— Менә бит әле латыш хатыннары белән бергә эшлисез. Алар сезне тотып ашамыйлар. Эш хакын тигез түлиләр, эшегездән куып чыгармыйлар.

— Латышлар аерым дәүләт булып яши башлау белән безне моннан куа башлаячаклар. Аларның безне күрә алмауларын инде күптән сизәбез. Элек болай ачыктан-ачык дошманлык күрсәтмиләр иде. Хәзер инде «Китегез Латвиядән, колонизаторлар!»— дип теләсә кая язып элә башладылар.

СССРның Явыз Иван башлап җибәргән колониаль сәясәтне дәвам итүе, латышларның азатлык, мөстәкыйльлек өчен көрәшүләренең табигый икәнлеген аңлатырга тырышып, Мария Дмитриевна белән сүз көрәштермәдем. Урысларның башка халыклардан өстен, аларның башка милләтләрдән әйбәтрәк булуы полковник хатынының инануы иде. Көчле инануны дәлил белән дә, мантыйк ярдәмендә дә җиңеп булмый. Өстенлек һәр очракта урыс ягында булырга тиешлеген аксиома итеп кабул итү бу хатынга пропаганда ярдәменнән тыш, ана сөте белән үк кереп оялаган иде. Мин капма-каршы карашлы кешеләр арасындагы татулык турында хыялланам. Администраторның миңа булган дошманлыгын берничек тә йомшарта алмадым.

## 24

Көтә торгач, Яңа ел да килеп җитте. Кораб әле һаман тышкы рейдта тора иде. Кара диңгез портларында тышкы рейдка сәгать саен порттан катер йөреп тора. Котып шартларында катер белән ачык диңгезгә чыгу хәтәр иде. Монда рейдтагы кораблар белән бердәнбер элемтә — радио иде.

Ирләрен каршыларга килгән диңгезче хатыннары диспетчерның теңкәсен корытып бетерделәр булса кирәк. Хәзер ул, «Капитан Нугай» турында сүз чыгу белән, сөйләшүдән баш тарта башлады. Күңелне бары тик бер генә сорау тырный. Корабны причалга куярлармы, әллә тышкы рейдтан туры башка портка җибәрерләрме? Башка портка җибәрү — рейсның үзгәрүен белгертәчәк. Бу очракта Японияне башка ил, яисә «Капитан Нугай»ның даими линиясе — Дудинкага алышачак. Кораб экипажының, шул исәптән минем дә тәкъдирем кайдадыр өстә, министрлыкта хәл ителә иде.

Философлар, нинди генә авыр шартларда да юаныч табу мөмкин, дип исбатлыйлар. Мин дә юаныч таптым. Минем Латвиядә яңа ел каршылаганым юк иде әле. Куанырга кирәк — яңа елны яңа җирдә каршылыйм.

1978 елны Мариупольдә каршыладым. Җитмеш тугызны Гибралтар бугазында. Сиксәненче елны Хәбәшстанның Асәб исемле портында «Академик Арцимович»тан танклар бушата идек. Сиксән беренче елны Һинд океанында. Сиксән икенче ел Италиянең Равенна исемле портында торганда килде. Сәгать төнге уникедә портта торган корабларның экипажлары причалга коелдылар. Күккә ракета ата башладык, аннан соң күмәк җырлашып биергә тотындык. Кем генә юк иде Равенна портында: испаннар, гарәпләр, алманнар, японнар, хәтта Яңа Зеландия моряклары да бар иде. Икенче көнне бер-беребезгә кунакка йөрү башланды. Шундый үзенчәлекле булып истә калган сиксән икенче елны каршылау. Сиксән өч Британиянең Бристоль култыгындагы Эйвонмоут портында каршыланды. Сиксән дүрт — Болгариянең Варна портында куып җитте. Минем соңгы корабым, контейнер йөртүче лайнер «Ростов-на-Дону»ны кабул итеп флаг күтәрү вакыты иде. Сиксән биш — Атлантик океан ярында урнашкан Марокко порты Касабланкада. Сиксән алты — Канар утравындагы Лас Пальмас портында. Сиксән җиде, ниһаять, үземнең җылы фатирымда, гаиләм янында. Сиксән тугыз — Мәскәүдәге Трансплантология институтының биш кешелек палатасында.

Менә 1991 ел килә. Мин ялгызым. Күршедә кораб көтүче диңгезчеләр гөж киләләр. Өстәлемдә ялгыз шешә — шампан шәрабенең иң сыйфатлысы: «Абрау-Дюрсо»да әзерләнгән «брют». Буфет ябылганчы ашамлык алырга онытканмын. Тумбочкадан закуска эзлим. Ярты телем каткан ипекәй кисәге таптым.

Әнә, күрше бүлмәдә тынып калдылар. Спасс манарасындагы сәгать сукканы яңгырый. Диңгезчеләр дәррәү кычкыра башладылар:

— Яңа ел белән! Яңа бәхет белән!

Ахмаклар. Бәхетнең «искесе» яисә «яңасы» буламыни?

— Күңел тынычлыгы өчен, Габдрахман! Сер бирмик, яшик әле! Бу дөньяда яшәүдән дә бөек нәрсә бар? Теге дөньяда булуы мөмкин. Бу дөньяда яшәүдән, тере булудан, зәңгәр күкне күрә алудан, сандугач сайравын ишетә алудан да зур бәхет бармы икән? Юктыр. Әйдә, яшәү өчен эчик. Яшәсен яшәү! Яныңда гаиләң, якыннарың булмау авыр. Шыңшыма, үзең теләп киттең... Яшәсен тормыш! Яшәсеннәр адәм балалары! Яшәсен дуслар! Дошман да яшәсен! Дошман булмаса, дуслар да булмас иде...

Әйе, ритуал үтәлде. Мин ярты бокал шампан шәрабе, ярты телем ипекәй белән яңа ел каршыладым. Өстән авыр йөк төшкәндәй булып китте. Нәрсә китерер икән 1991 ел? Нәрсә генә китермәсен, ул әле яңа гына туып азаплана. Мин — шат, чөнки мин — яшим.

Күрше бүлмәдә кычкырып сөйләшәләр, көләләр. Башта гел ирләр тавышы ишетелә иде. Менә инде ярты сәгать чамасы хатын-кыз тавышы да ишетелә. Ике төрле тавыш. Димәк, алар икәү. Берсенең тавышы миңа таныш. Без аның белән Ригадан Вентспилскә килгәндә автобуста янәшә утырдык. Чаллыныкы. Күршесен каршыларга килгән. Ике балалы ирне. Бу хатынның да ире бар шикелле тоелды. Мин аның тел очыннан сиздем. Башка хатынның ирен каршыларга килүен ул миңа болай аңлатты: «Диңгезченең хатыны яхшы булырга тиеш. Аның үзенә тиң хатын».

— Ә диңгезче булмаган кешенең хатыны начар булса да ярыймыни? — дип сорадым мин.

— Әйе, — диде ул шундый изге беркатлылык белән. — Диңгезче түгел кешенең хатыны начар булса, ул яхшы сөяркә табып, шуның белән вакыт уздыра ала. Мескен диңгезче берни эшли алмый. Диңгездә бит хатын-кызлар йөзеп йөрми.

— Диңгезчеләр бит гел диңгездә генә йөрмиләр. Хатыны начар булган очракта портта сөяркә табу мөмкинлеге бар, — дидем мин.

— Юньле сөяркә табу өчен вакыт кирәк, — диде күршесен каршыларга килүче. — Алар бит бер-ике көн торалар да тагын китеп баралар.

Диңгезчеләр тормышын белә иде бу энтузиастка. Димәк, аның беренче тапкыр гына каршылавы түгел, һәм «сөяркә» мәсьәләсенә дә ул заманча, җиңел карый иде. Мондый очракта мин Мәҗит Гафуриның «Кара йөзләр» исемле повесте турында уйлана башлыйм. Авыл аксакаллары, чыннан да, бу мәсьәләне бик кискен куйганнар...

Корабның тышкы рейдта торуы озакка сузылды. Озаклыкның минем өчен бер отышлы ягы да бар иде. Корабның Гданьски портында алган суы, экипажның азык-төлеге шактый такырайган булырга тиеш. Димәк, «Капитан Нугай»ны турыдан-туры башка портка җибәрмәскә тиешләр. Башка портка китәр алдыннан кораб портка кереп су, азык-төлек, ягулык алырга тиеш. Нәкъ шул чакта мин аны эләктереп өлгерәчәкмен.

## 25

Бүген елның беренче көне. «Яңа бәхет» алып килгән яңа ел. Ә кая ул «яңа бәхет»? Кыш бабай чыршы төбенә бүләк куеп китә, дип сабыйлар шатлана. Мин дә йокыдан уянгач, «Кыш бабай», Санта Клаус калдырып киткән бүләкне күз йөртеп эзләп карадым. Бүлмә буш иде. Чыннан да, бит яңа ел бәйрәме Иисус Христосның туган көненә багышланган. Ул христианнар бәйрәме. Христиан миссионерлары исә, гомер гомергә мөселманнарга «бәхет» урынына басып алу, чукындыру алып килгәннәр. Совет чорында бәйрәм итә башладык без христиан яңа елын һәм, урысларга ияреп, Раштуада нәни чыршыларны кисеп, урманнарны корытырга керештек. Менә әле дә минем күңелемдәге Икенче Габдрахман, минем «алтер эго»м, мыскыл итә, үрти иде:

— «Яңа бәхет» көтәсеңмени? Әйдә, көт, көт... Син «бәхет» дип көткәнең, җан кисәгем, битеңә сузылып ятачак яңа җыерчыклар, чәчләреңә төшәчәк яңа кыраулар ул. Спасс манарасындагы сәгать уникенче чаңны сугу белән хатының тагын бер яшькә картайды. Син белмәсеңмени хатыннарның картайган саен ирдәүкәләнә баруларын? Шулмы «яңа бәхет»? Ирләр, киресенчә, картайган саен хатыншалана баралар. Синең һаман йомшара, ир-егетлегеңне югалта баруың — шулмы ул «яңа бәхет»?

Син коммунистлар партиясенең «хокукка таянып эш итүче» дәүләт төзибез дигәненә хәбәрдарлык, ирек, иреклe эшмәкәрлек игълан итүенә ышанасың. Шул ышанудамы ул «яңа бәхет»? «Иреклe эшмәкәрлек». Коллар илендәме? «Тимер пәрдә»не ерткалап ташлыйбыз, чит илләр белән аралашып, сәүдә итеп, үзара йөрешеп, дуслашып яшибез... Син шуңа ышанасыңмы? «Яңа бәхет»не менә шушы карар алып килер дип өметләнәсең син. Әйдә, өметлән, ышан дөм томана булсаң... Рәсәй бу, җанкисәгем. Рәсәйне ымсындырган ирек — Степан Разин ирегe, ирекле талау, ирекле кан кою, ирекле ушкуйниклык, ниһаять, ирекле урлашу. Рәсәй ирегe анархия белән генә дә чикләнеп кала алмый. Бу илдә тәрбия ирекне ерткычлык инстинктларын тоткарлыксыз, чикләнүсез эшкә ашыру дип аңлата. Рәсәй беркайчан да «хокукка таянып эш итүче» дәүләткә әверелә алмаячак. Ул — талау, кан кою, күрше дәүләтләрне басып алып буйсындыру аркасында барлыкка килгән дәүләт. Рәсәй — зур бер казарма. Ул хәрбиләр иле. Бу дәүләт оеша башлаганнан бирле туктаусыз сугышып торды. Аның экономикасы, дәүләт төзелеше, гореф-гадәтләре генә түгел, халкының психологиясенә кадәр сугышка, хәрбилеккә «чин чина почитай»га көйләнгән. Шуңа күрә бу ил бары тик сугыш, яулап алу шартларында гына яши ала. Бәлки, син бу илдә демократик тәртип урнашуны көтә торгансыңдыр? Европа илләрендә демократия урта гасырларда диярлек шытып чыгып, Ренессанс чорында шәхеслеккә табыну, шәхеснең чиксез мөмкинлекләренә мәдхия җырлаудан башланып, туктаусыз үсте, ныгыды. Рәсәй исә әле һаман крепостнойлык психологиясеннән арына алмый. Бу дәүләт барлыкка килгәннән бирле монда кеше язмышы чиновниклар кулында. Милек чиновниклар кулында. Милексез кешене егылып үлсәң дә ирекле итә алмыйсың. Ипи турында уйлый ул. Буйсынмасам, ашарыма бирмәсәләр, ачка үләрмен, дип курка милексез кеше. Үзе кол ул һәм аның бер яшерен теләге бар: колның колбиләүче буласы килә, ләкин ул шушы теләгеннән дә мәңге өркә.

Әйбер алырга чират торганда, поездларда совет кешесе — «совок»ның сөйләшүенә колак салыгыз. Совет кешесе палач-диктаторны — Сталинны сагына. «Сталин чорында тәртип бар иде,— ди ул.— Сталин әйберләрнең бәясен ел саен, һәр апрельдә төшереп тора иде. Әгәр ул исән булган булса, без бит инде бар нәрсәне пачти бушлай ала башлаган булыр идек»,— дип, диктаторны сагына. Бу сагынуда пәйгамбәрне сагынуга охшашлы мистик инану, дини багланышлар барлыгы сизелә. Йә хода, нишләтте адәм балаларын агитпроп! Атна саен уздырылып торган политдәресләр кешеләрнең фикер йөртү сәләтләрен генә түгел, ишетү, күрү, аң аша үткәрү мөмкинлекләрен дә тулысынча җимереп ташлады. Без бит күпме еллар нефть ашап яшәдек. Җирләребез уңдырмый, эшләп чыгарган әйберләребез чит илләрдә генә түгел, үзебездә дә сатыла алмыйча чүплеккә, утил-сырьега тапшырыла иде. Шуңа күрә «үзгәртеп кору» янды да. Чөнки үзгәртер нәрсә юк иде. Үзгәрткән очракта да Рәсәй элеккечә чабаталы килеш кала иде. Дөрес, гади чабаталы түгел, кулына Калашников автоматы тоткан, космоска кораб очыртуы белән кәпрәюнең чигенә чыккан чабаталы иде урыс тәкәбберлеге.

Менә мин «яңа бәхет» көтеп утырам. Искесе булмагач, каян, кемнән төсын бәхетнең яңасы? Минем күңелемә, мәсәлән, ике Габдрахман оялаган. Шуның берсе ихластан бәхет көтә. Икенчесе исә, беренче Габдрахманны беркатлылыкта, хәтта томаналыкта тәнкыйтьләп: «Каян килсен ул безгә яңа бәхет? Коллар бәхете хет бер генә мәртәбә туйганчы

колкыну һәм шул «патшалыкка ирешә» алуы турында гомер буе кешеләргә сөйләп йөрү. Бәлки, шул, туктаусыз тәнкыйтьләп торучы Габдрахман гына мине кешелек рамкасында саклап кала алгандыр? Яшәеш катлаулы. Искиткеч катлаулы бу тормыш. Катлаулы булмаса, ул шулай газиз була алыр идемени? Гомеремнең алтмыш дүртенче басмасына басып азапланам. Күтәрерме мине бу басма? Җимерелеп төшмәсме? Ел саен басма өсти торган баскыч яшь чагымда өскә, биеклеккә күтәрелә шикелле тоела иде. Хәзер күрәм, баскыч аска, караңгы упкынга төшә. Курыкмаска кирәк. Күрдем бит мин болытлардан да биек өстенлекләрне... Мәсәлән, министрлыкта эшләгәндә. Диңгез тирәнлекләрен дә күрдем. Кайда да галәм һәм чиксезлек Алла карамагында... Бәхетлеме мин, бәхетсезме? Җиденче кат күкләрдән иңгән бер аваз: «Кара аны кайларга кизәнә?» һәм урысча яңгыраган кайтавазы: «Ишь ты чего захотел»?

## Икенче бүлек

### 1

Кабат Шарль Бодлер... Син нәрсә? Син нигә диңгезгә чыккан саен тагылып йөрисең? Артыңа тибеп, куып җибәргәнне көтәсеңмени? Син бит диңгезче дә түгел. Бер тапкыр җилкәнле корабка утырып Таитигә барып кайту сәяхәтмени ул? Юк, шаярып кына әйтәм. Син — Шагыйрь. Чын шагыйрь диңгезче дә ул, патша да, фәрештә дә. Шагыйрь кайчакларда Пәйгамбәр булу вәсвәсәсенә омтыла һәм гомерен фаҗигале итеп өзеп ташлый. Беләм, син шундыйлардан. Бездә дә бар андый шагыйрьләр. Мин аларны «татар плеядасы» дип атап йөртәм: Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Розалина Шаһиева, Газинур Морат, мәсәлән. Болар гына да түгел, күбәйтәсем генә килми...

В один ненастный день,
В тоске невыносимой,
Не вынося тягот
Под скрежет якорей,
Мы всходим на корабль
И происходит встреча
Безмерности мечты
С предельностью морей...

Һәм шигырьнең «ля илаһасы» — «Что нас толкает в путь?» Нәрсә куа мине, карт донкихотны, озын сәяхәткә? Нигә мин картайган көнемдә ямаулы йөрәк белән әллә кайларга, «Паллада» фрегаты артыннан калган кильватер сукмаклары эзләреннән җир читенә, тропик тәмугына элдертәм? Җавап бирә алмыйсыңмы? Шул шул... Ирекка омтылу дисеңме? Нәрсәгә ул сиңа ирек, халкың коллыкта яшәгәндә? Халкың бит үзенең коллыкта, колониаль шартларда яшәвеннән канәгать. Төкерә ул синең ирекка омтылуыңа. «Экстремист» дип утлы тимер кыздырып маңгаеңа тамга куярга риза ул, «милләтара кенфликт ясап йөри» дип зинданга бикләп куярга да күп сорамаслар... Ну?

«Капитан Нугай»ны кунакханә каршысына диярлек куйганнар иде. Латыш хатыннары белән кочаклашып саубуллаштым. Ак күңлешү белән күңләшеп тә куйдым аларның ирләреннән: бу ханымнар диңгезчене озын сәфәргә озата беләләр иде.

Әнә ул, дөмеккере, нәкъ минем каршымда гигант кабыргасы белән причалга ышкыла-ышкыла мине көтә. «Чтобы ты подох»! — дип кычкырасым килеп китте мине җылы фатирымнан, йомшак түшәгемнән сөйрәп чыгарган сихерле кимәгә. Син бит Юныс пәйгамбәрне балык карынына озатучы... Карынына илле җиде мең тонна йөк сыйдыра ала.

Әле алтмышынчы елларда гына мондый корабларга «супер» сүзен өстәп сөйлиләр иде: «супертанкер», димәк, мин йөзәсе кораб — «супербалкер». Мин флотка килгән елларны балкерларны угле-рудовоз дип йөртәләр иде.

Кораб янына килеп җиткәч, кабат туктадым. Хәзер мин теплоходның һәр «әгъзасын» аерып, җентекләп карый ала идем. Әнә, корабка ямь, күркәмлек биреп торучы торба. Юан һәм түгәрәк. Инде күптән җәлпәк, озынча, корымны палубага төшермәс өчен канатка охшашлы җайланмалар куелган торбалар модага кергән. Тупас форштевень. Боз өстендә күтәрелеп авырлыгы белән сытар, җимерер өчен эшләнгән борын. Коерыкка утыртылган корылма шактый шөкәтсез. Алманнар ясаган кораб. Немесләрдә тәртип бар, тырышлык бар, ә зәвык шактый чамалы. Дөресрәге, алманнар зәвыгы — матурлыкны икенче урынга куеп, беренче чиратта уңайлылык ягын карау.

Кораб палубасына дүрт зур, көчле кран утыртып куйганнар. Фальшборт белән трюм арасында ике грейфер-чүмеч. Димәк, кораб теләсә нинди крансыз, техникасыз Котып портына кереп йөк төяп-бушатып чыга ала. «Капитан Нугай»ны махсус Котып диңгезе ярларындагы портларга йөрер өчен төзегәннәр.

Мин озак еллар Италия, аннан соң Испания һәм Франция портларына барып йөрдем. Бу өч илдә матурлыкка омтылу, гүзәллеккә табыну аяк атлаган саен күзгә чалынып тора. Гүзәллеккә омтылу — шул ук ирекккә омтылу. Ә ирек ул — бәхетнең нигезе. Ирексез бәндә берничек тә бәхеткә ирешә алмый, чөнки аның ирекккә тоташкан бәхете чиновник, колониаль түрә кулында. Шушы бөек хакыйкатьне без нигә аңлый алмыйбыз икән? Мәсәлән, безгә хатын-кызның матуры ошый. Хатын-кыздагы матурлык нидән гыйбарәт? Нечкә бил, матур аяклар, кабарып торган күкрәкләр. Соң бит бала тудырырга, аны имезеп, карап үстерергә иң кулай камил әгъзалар ясый түгелме соң матурлыкны?

Корабның корылмасын кызгылт тутык каплаган иде. Ак буяу сирәк урыннарда, ямаулык рәвешендәрәк кенә сакланып калган. Нишләгән соң ул буяу? Нишләп кораб шәрә калган? Буяр алдыннан пароходның металл тәненә грунт салалар. Грунт та кубып төшкән иде. «Капитан Нугай»ның тәне шәрә. Бу нинди хәл? Әллә кораб янгынга юлыкканмы? Мин җентекләп тикшерә башладым. Ачыкланды. Котыптагы илле градуслы зәмһәрир суыгында тимер корпус шулкадәр кысылган ки, кораб тәнендәге буяу кубарылып һавага очкан.

Кинәт корабны кызганып куйдым. Нинди авыр шартларда эшләргә туры килгән сиңа, мескенкәем! Котып шартларына кораб түзә алмаган. Әнә бит буявын югалткан. Шундый шартларда адәм баласы ничек түзде икән? Кайбер диңгезчеләр картаеп пенсиягә чыкканчы Котып шартларында эшлиләр бит әнә.

Бисмилламны әйтеп, сул кулым белән релингка тотындым. Уң аягым белән трапның беренче басмасына бастым. Хәерлегә булсын. Сул аякны причалдан күтәрдем. Тәнемдәге күзәнәкләр сизеп алды: мин хәзер Җир-Анадан аерылам. Хәзер минем язмышым диңгез кулында. Җирдә йөргәндә синең һәр әгъзаң катылыкны тоеп тора. Җаның да җир кануннарына буйсына. Буйсына гына түгел, ышана да, чөнки Аллаһы Тәгалә Атабыз Адәмне кызыл балчыктан яраткан. Җирдә яшәр өчен яралган адәм баласы. Иблис котыртуына бирелеп, Анабыз Хава, Инҗилдәгечә әйткәндә, Белем агачының җимешен өзгәч, адәмиләрнең башын җәннәттән куганнар. Шул көннән башланган михнәт күрүләр.

Адәм баласы җирдә яшәр өчен яратылган булса да, комсызлык аны балыклар дөньясы — суга алып кергән, аннан соң күккә — кошлар вә фәрештәләр дөньясына. Башка җан ияләре ареалына басып керү белән генә чикләнмәгән адәми зат, ул тынычлыкны бозып, үзе белән кан кояр өчен уйлап табылган корал алган. Әнә, корылманы нечкә генә тимер көпшә белән уратып алганнар. Атом коралы кулланган очракта корабка утырган радиоактив матдәләрне юып төшерү өчен ул.

Кораб сизелер-сизелмәс кенә чайкала иде. Диңгез чынбарлыгы чайкалудан башлана. Мохитнең туктаусыз үзгәреп торуы. Мажаралар. Бер-бер артлы алмашынып торган күренешләр. Ялгызлык. Адәм баласы болай да ялгыз. Диңгез шартларында — күмәк ялгызлык. Экипаж әгъзаларының шәхси ялгызлыклары укмашудан барлыкка килгән искиткеч авыр, чыдап булмаслык каты газап. Бер-береңне аңлый алмый интегү, курку, көчсезлек — адәм баласының даими юлдашлары бу. Җәза юлдаш... Җәза аңы... Сукыраеп беткән күңел. Без — коммунистик идеология корбаннары...

* * *

— Сез кемгә? — диде вахтада торучы матрос эшен ташлап. Ул фальшбортның тутыгын кырып азаплана иде. Өстендә каешланып беткән иске сырма, башында оекбашмы, әллә свитер җиңеме. Башта корабның тышкы кыяфәте күңелне кайтарды, хәзер матросның өстендәге киеме. Тәртипсезлек хөкем иткән корабларда гына вахтага менә шушылай киенеп чыгалар.

— Миңа өлкән штурман кирәк иде.

— Ул шәһәргә китте, — матрос эшен дәвам итте. Мин көтәм. Ул минем якка борылып та карамый. Тагын бер тәртипсезлек, хәтта тәҗрибәле карт диңгезче моны мәнсезлек дип үк атар иде. Матрос минем чемодан күтәреп килүемне күреп тора. Ул бит минем ят кеше икәнлегемне күрү белән чамаларга тиеш иде. Кабат сорарга туры килде:

— Вахтадагы штурманны чакырыгыз әле, рәхим итеп.

— Ул сезгә нигә кирәк?

«Куда я попал!» — дип кинәттән урысча уйлап алдым. Тәртипкә өйрәтелгән, тәҗрибәле матрос, гомумән, диңгезчелекнең әлебен таяк дип белгән кеше бу сорауны бирергә тиеш түгел иде.

— Әллә сез теге Мәскәүдән килгән журналистмы? Капитан көтә сезне.

Диңгез тәртибе хөкем иткән корабта бу сүзләрне миңа вахтада торучы штурман әйтергә тиеш иде һәм ул мине капитан каютасына кадәр озата барырга тиеш иде. Ә мин капитанны үзем эзләп киттем.

Коридорга керү белән лифт ишеген күреп алдым. Эчем чымырдап куйды. Кораб лифты бер фаҗигале вакыйганы искә төшерде. Генуя портында торганда булды бу хәл. Новороссийск пароходчылыгының бер танкерында янгын чыкты. Бу очракта үзәк пультта автоматик рәвештә эшли торган бер җайланма була. Син кызыл кнопкага басасың. Һәр отсекның тимер ишекләре автоматик режимда ябыла, янгын чыккан отсекка системадагы углекислый газ бөркелә. Янгын чыгу белән машина бүлегендә вахтада торучы өченче механик авария сигналы бирә дә лифтка кереп утыра. Өскә күтәрелү өчен кнопкага баса. Янгын электр тогы йөртүче кабельны яндырып өлгергән була. Вольт дугасы! Лифт туктый. Урыныннан кузгатып булмый лифтны. Ишеген дә ачып булмый. Өченче механик вахтадагы штурманга чылтырата:

— Машина бүлегендә янгын чыкты, — ди ул. — Мин лифтта. Ток килми. Бикләнеп калдым.

Вахтадагы штурман капитанга чылтырата. Икенең берсе: углекислый газны ачсаң, янгын сүнәчәк, механик тончыгып үләчәк. Газны ачмасаң, танкер шартлап, һавага очачак. Кайсын сайларга? Нишләргә белми торганда механик кабат чылтырата:

— Сез мине барыбер коткара алмыйсыз. Соң инде. Ачыгыз углекислый газны...

Бүгенге көндә флотта сирәк очрый торган Чын диңгезчеләр токымыннан булган, күрәсең, мәрхүм өченче механик. Ул үзенең үлеме белән кырыкка якын диңгезчене үлемнән коткарып калган. Авыр туфрагы

җиңел, йомшак булсын. Урыны җәннәттә булсын ул бәндәнең. Белмим, нигәдер, корабтагы лифтка кереп утыру белән шул фаҗигале вакыйга эчемне ачыттырып, көйдереп ала.

Җәяү менә башладым...

## 2

Сөзәк, тар маңгай астына тирәнгә кереп яшеренгән соргылт күзләр миңа шикле караш ташлап алды. Куе соргылт чәч һәм юка ирен. Капитан миңа утырырга кушты. Урын күрсәтергә онытты. Капитанның эш өстәленә янәшә куелган кәнәфигә чумып утыргач, кабат карадым. Җилкәләр киң. Беләкләрдә көч барлыгы вельвет күлмәк җиңе аша сизелеп тора.

Сөйләшүне корабның бик озак тышкы рейдта торуы, мине зарыктырып көттерүеннән башларбыз дип өметләнгән идем мин.

— Исем-фамилиягез ничек?— дип башлады капитан.

— Габдрахман Бакирович Рахманкулов,— дидем мин сәерсенеп. Ул бит министрлыктан җибәргән радиограмманы алган булырга тиеш. Анда минем исем-фамилиям тулысынча язылган иде.

— Ә урысча ничек була?

Бу мине җенләндерә торган сорау. Гадәттә, бу сорауга каршы мин үзем. «Ә сезнеке татарча ничек була?»— дип сорыйм. Һәм, гадәттә, шундук ара бозыла. Исемең урысча ничек, дип сораучы үз исеменең татарчасын күз алдына китерә алмый. Бу хәл аңа мәсхәрә тоела. Ничек инде ирекле көннән саф урыс исемен «басурман» исеменә алыштырырга?

Фәндә психологик тест аталган бер алым бар. Кинаяле сорау аша кемнең кем икәнлеген, аның культурасын, аңын, интеллектын ачыклап була. Татар исеменең урысчасын сорау психологик тестка тиң. Бу тест аша сорау бирүченең, кояш астында бары тик урысларга гына урын булырга тиешлеккә, киләчәктә һәр милләт үзенең «артта калуын» бетерер өчен» урыслашырга һәм шул юл белән чын, культуралы милләткә әверелергә тиеш булуына шовинист инанучы икәнен ачыклап була. Капитанның соравы мине бик тә хафаландырды. Димәк, сәяхәт вакытында аның белән дустанә серләшеп, рәхәтләнеп сөйләшеп булмаячак. Шулай да мин өметемне өзмәскә тырыштым.

— Исем инде ул,— дидем мин.— Урысча да, инглизчә дә үзгәрми, шул килеш кала. Беләм, «Габдрахман Бакирович» сүзен әйтү сезгә шактый авыр булачак. Андый сәер сүзне хәтердә тоту да җиңел түгел бит. Белмим, дөрес эшләдемме икән, мин исемемне урысчага әйләндермәдем.

Соңгы җөмләне әйтергә кирәк түгел иде. Капитан бу җөмләнең эчтәлегенә таянып, турыдан-туры карар чыгарды булса кирәк: «Ә-ә, бу өстәвенә милләтче дә икән».

— Радиограммада сезне язучы дип атаганнар. Сезнең язучы булуыгыз дөресме соң?

Бу сорау артында да капитанның аң үлчәме, аның күзаллавы, менталитеты җәйрәп ята иде. Беренчедән, диңгезчеләр шикаятьчеләрне, гаеп эзләп, жалоба язып торучыларны «язучы» дип атап йөртәләр. Икенчедән, капитан татар милләтеннән булган кешенең язучылыкка ирешә алуына ышанып бетми кебек тоелды миңа.

— Әйе, мин язучылар берлеге әгъзасы,— дидем һәм ышанычлырак яңгырасын өчен өстәдем.— Мәскәү оешмасыннан.

Бу сөйләшү медкомиссияне үтү шатлыгы биргән күтәренкелекне сындырып ташлады. Капитан «Мин бит сезгә урысча әйттем, сез нәрсә, әллә аңламыйсызмы?» дип кычкырырга өйрәнгән, бары тик урысча сүз генә сүз, урысча ярарлык итеп эшләнгән эш кенә эш булуына тайпылышсыз ышанучы катып калганнардан иде. Әйе, бу кеше белән ботка пешерү,

ай-һай, авыр булачак. Ә бит капитанга якын булу, аның ихтирамына ирешү миңа шактый киң мөмкинлекләр бирер иде. Бәхетсезлегемә каршы, мин ялагайлана да белмим. Күпме авырлык күрдем мин үз гомеремдә түрәләргә тәлинкә тота белмәү аркасында.

— Сез «Капитан Нугай»ның экипажы турында язарга җыенасызмыни?

Бу сорау мине кабат сискәндереп җибәрде. Чыннан да, бу инде гадәткә әйләнде. Язучы бер тапкыр корабка утырып сәяхәткә барып кайта да диңгезчелеккә багышланган повестьлар, романнар аударып ташлый. Шуңа күрә, күпләр бер тапкыр сәяхәт белән диңгез турында китап язып була дип ышана башладылар.

— Юк, экипаж турында язарга җыенмыйм,— дидем капитанны тынычландырырга теләп.— Мөмкин түгел ул диңгез турында бер генә рейска таянып китап язу.

— Ә алай булгач, сезне диңгезгә чыгарга нәрсә мәҗбүр итте?

— Диңгезне күрәсе килү,— дидем мин, кабат ялгышлык ычкындырып. Ышанмады капитан минем җавабыма. Киресенчә, ул минем ялганчылыгымны тотуына шатлангандай итеп куйды.

Телефон чылтырады. Капитан трубканы күтәрде.

— Тыңлыйм, капитан Гречаный. Әйе. Әйе. Юк әле. Юк. Тагын ике сәгать чамасы вакыт кирәк. Юк, юк, суны алып бетермичә причалдан китә алмыйм. Ярый, килештек.

— Причалдан куалар,— диде ул трубканы куйгач.— Әйе, сезгә бит урнашырга кирәк. Каютаны вахтада торучы штурман күрсәтер.

— Виталий Иванович,— дидем мин.— Мин сездән комфорт даламыйм. Миңа каютаның иң бәләкәе, иң уңайсызы да ярый. Шул ук вакытта, мин сездән каютаның иллюминаторы диңгезгә караганын сорар идем. Каютадан диңгез күренеп торса, миңа шул җиткән.

Капитан ниндидер сәер канәгатьлек белән елмаеп куйды:

— Соң бит диңгезне каютадан чыгып та карарга була,— диде ул.— Палубага чыккач саф һава сулыйсың. Сезгә, шәһәр кешесенә, саф һава сулау зыян итмәс, дип уйлыйм.

— Рәхмәт минем сәламәтлегем өчен кайгыртуыгызга,— дидем мин капитанның мине командирлардан, бигрәк тә үзе яши торган каютадан ерагракка олактырачагын чамалап. Ул мине машина бүлегендә эшләүче мотористлар янына урнаштырырга тели иде булса кирәк. Гадәттә, экипажны һәм пассажирны урнаштыру эше белән өлкән штурман шөгыльләнә. Бу вазифаны капитанның үз өстенә алуы мине шактый хафаландырды.

### 3

Причалда торганда ук күреп алдым, «Капитан Нугай» биш палубалы кораб иде.

Кайсы палубада нәрсәләр барлыгын мин причалда торганда ук абайлап алдым. Һәм өметем лоцман каютасында иде. Ул, гадәттә, буш тора. Килгән кунакларны, диңгезгә чыккан капитан-наставникларны лоцман каютасына урнаштыралар. Анда яшәүнең бер уңайсыз ягы бар — Сүәеш, Панама, Киль каналлары аша узганда сине башка каютага күчерәләр. Мин күчеп торырга да әзер идем. Бу каютаны миңа бирмәделәр.

Вахтада торучы штурман мине аска алып төшә. Инде командирлар яши торган палубаны уздык, кече командирлар палубасы да артта калды. Ниһаять, без иң астагы палубада. Одессалылар бу урынны «негритянский переулок» дип атыйлар. Монда, гадәттә, кочегарлар, диңгезчеләр телендә — «негрлар» яши.

— Капитан сезне менә шушы каютага урнаштырырга кушты,— диде штурман һәм мин аның карашында уңайсызлану сизеп алдым.

— Рәхмәт. Калганын үзем карармын.

Штурман китте. Ялгыз калгач тикшеренергә тотындым.

Коридордан керү белән кечкенә генә бер кетәк — алгы бүлмә. Шушы кетәккә өч ишек чыга. Каршыдагы ишекне ачтым. Душ һәм туалет. Як-якта ике каюта. Ике каютага бер санблок. Мәскәү университеты искә төште. Анда да ике бүлмәгә бер санблок иде. Үземнекенә кергәнче күрше каютаның ишеген ачып карадым. Бардак. Палубада тәмәке төпчекләре, тузан, олтаннан купкан пычрак. Өстәлдә зур чәйнек, кружкалар. Караватта бер төргәк бау, кубарып ташланган рундук ишеге аунап ята. Ташландык каюта. Өстәлдәге чәйнек һәм кружкалар бу каютага иртәнгелек белән әбәд арасында диңгезчеләр телендә «кофе-тайм» аталган тәнәфестә рабочая бригада чәй эчәргә җыелганлыкны аңлата. Корабта тәртип булмаган очракта унбиш минутлык «кофе-тайм» икешәр сәгатькә сузылуы мөмкин. Монда диңгез ләчтите — ирештерү, анекдотлар, сүгенү, ихахайлап көлү мин яшисе каютаны дер селкетеп торачак. Сау бул, иҗат!.. Ә бит мин рейс вакытында роман яза алырмын дип өметләнгән идем.

Үзем яшисе каютага кердем. Бусын ашыгып кына җыештырып алганнар. Чиста мендәр тышы, чиста җәймә, чиста сөлгеләр. Палубаны да юганнар. Юынгычның фарфор тасын чистартканнар. Шуңа карамастан, мин каютаның ташландык булуын, миңа кадәр монда беркемнең дә даими яшәмәгәнлеген аңлап алдым. Алмашка килүчеләр, өлкән яшьтәге диңгезче балалары берничә тәүлек торгалап алулары мөмкин. Әнә, юынгыч өстендәге пыяла киштәне, китап куяр өчен стенага эленгән кечкенә шкафны, кием элер өчен эшләнгән чөйләрне, хәтта өстәл тартмасының тоткаларына кадәр суырып алганнар. Рәсәй чынбарлыгы. Бу илдә шәхеснең беркайчан да милеккә хуҗа була алмавы рәсәйлеләрне урлашырга өйрәткән. Патша заманында крепостнойлар, соңрак — община әгъзалары, революциядән соң дәүләт, колхоз милке шартларындагы хуҗасызлыкта көн күрү. Шулай итеп, урлашу — әхлак кагыйдәләрен бозмый торган гади бер кәсепкә әйләнеп киткән. Угры үз кулына эләккән малның хуҗасы кем икәнлеген дә белми. «Все кругом колхозное, все кругом — мое». Совет чорында «карак» сүзен йомшартып, эчке мәгънәсен үзгәртеп «несун» дип атауга күчтеләр. Без, пароходны заводка ремонтка тапшырганда, барлык җиһазларны җыеп бер кладовкага йозак белән биклэп куя идек. Шуңа карамастан, борып һәм суырып алырлык бар нәрсә ремонт азагында урланган була иде.

Тагын бер кимчелек таптым мин яшисе каютамнан: монда бер генә дә агачтан ясаган нәрсә юк иде. Синтетика. Эрзац. Пластмасса. Егерменче гасырның фаҗигасе каплаган иде каютамны. Тәрәккыят! Учларың белән чәчеңне сыпырдыңмы, күзләреңнән чаткы чәчри. Күлмәгеңне сала башласаң, тәнеңә электр чаткыларының энәләре кадала. Һава салкын булганда әле моңа түзеп була. Тропикның дымлы эсселегендә пластик сасы ис аңкыта башлый. Тын алу читенләшә, баш авырта, тропикта йөзү озаккарак сузылганда аллергия башлана. Беренче булып каюталарны синтетикадан ясый башлаучы Көнбатыш илләре инде күптән агачка, табигый материалларга кире әйләнеп кайттылар. «Все для человека, все во имя человека» лозунгына таянып эш итүче социалистик илдә кеше турында кайгырту әлегә, күбрәк съезд трибунасыннан ясалган докладларда, агитпроп элгән плакатларда гына кала килә.

Чемоданымны кую өчен рундукны ачтым. Ишек күгәнен кубарып алганнар иде. Урындыкның аяклары какшаган. Караватыма утырып уйга калдым.

*Дәвамы бар.*

# ШИГЪРИЯТ



## Мөдәррис Әгъләм

### КЕШЕ БУЛЫП КЫЧКЫРАСЫ...

### Кинәт искә төшерәсең

*1995, август*

Уйларыңны, хисләреңне
чалгы итеп кайрыйсың да,
Бөтен җаның-тәнең илә
кошлар булып сайрыйсың да...
Нәкъ шул мәлдә аваз бирә
әрекмәннән бер чикерткә —
сулышыңа әремнәрнең
исе кереп исең китә.

Күке булып күкелдисең,
тукран булып тукылдыйсың —
сөенәсең, әле ярый
бүкән булып утырмыйсың!
Шундый чакта оеп кына,
коеп кына яңгыр төшә.
Барысы искә төшә-төшә
төшләнәсең кичәгечә.

Сандугачның теле бетә,
үләннәрнең тәме бетә —
калкынасың, әйтерсең лә,
дөньялыкның яме китә.
Күзнең исен сизеп, тәмам
шашынасың, эзләп дәвам.
...Кәйләп кояш барышына
тик табигать алышына.

Бозы булып челтерисең,
кары булып ишеләсең —

чыпчык булып чыркылдагач,
кинәт искә төшерәсең:
калган бары эш кырасы,
кеше булып кычкырасы...

## Бәлки...

Йөрәгемне татар китабыдай
ачам уртасыннан:
укыйм, дисәм, аннан Альберт Фәтхи
атлап чыга сыман...

Төнлә ачтым. Ачтым йөрәгемне,
һәрбер битен беләм.
Йөрәк китабына Альберт Фәтхи
каян килеп кергән?

Ап-ак ыштан, ап-ак күлмәк белән
кара кәзәкидән:
әйтерсең лә, татар китабын ул
кием итеп кигән.

Аккош күле. Ут юк. Йөреп торам,
китап ера-ера.
«Шәмең яндыр!» — диеп, Альберт Фәтхи
шырпы суза миңа.

Өй актыра. Ике кулын сузган
ике чатлы шәмдәл.
Альберт Фәтхи булып өскә килә
ышанмаслык хәлләр...

Котым чыга. Аягүрә басам,
ялгышамдыр, бәлки:
саф һавага чыгып карга чумам,
карда — Альберт Фәтхи.

Мунча ягып пар эченә кереп,
кысам да йөрәкне,
пар эченнән көлеп карап тора
миңа Альберт Фәтхи.

Шунда миңа пәйгамбәре аша
сүз иңдерә Ходай:
— Юк, ул синнән хәзер калмас инде
татар китабыдай.

Гаҗиз булып тәмам, арып-талып
өйгә кайтып авам.
Татар китабын япкандай
йөрәгемне ябам.

Юкка гына затлы кием киеп
йөрмәс Альберт Фәтхи:
татар китабының авыр хәле
җиңеләер, бәлки...

## Ләйләләрсез генә...

*1996, август*

Кимегән йә кимемәгән әле
Җанны Мәҗнүн иткән Ләйләләр,
Тик ни хикмәт,
Язмыш төеннәре
Ләйләләрдән башка бәйләнә.

Томырыла гашыйк акбүз атта,
Йөрәк кага, башы әйләнә...
Йә эләгә килеп кап тозакка,
Йә эләгә килеп хәйләгә.

Сула, сүнә... Кабына да сүнә,
Кабына да сүнә. Яралы.
Төзәлсен, дип, балчык һәм тоз сибә
Ярасына. Уйлап карамый.

Саф сөюдән халык арасында
Канлы бәет, үлмәс көй кала.
Мәкерле ук тигән ярасыннан
Таш йөрәктәй каты җөй кала.

Дөнья аны, ул дөньяны куа,
Чүлдә калган ялгыз бүредәй,
Башын чөеп төннәр уртасында
Улый-улый айга үрелә...
Төсләр алышынган.
Арган, туйган.
Айдан ак нур түгел, кан тама...
Хәле бетеп, үз Мәҗнүнен җуйган
Бер Ләйләгә килеп каплана.

Бала-чага баса, дөнья баса —
Чакма ташка чакма бәреләә.
Гаҗәпмени, Ләйлә керә калса
Бер убырлы карчык хәленә.

Ике гомер күмерләнә утта,
Чал йөгереп чәчләр бәйләнә.
...Һәммәбез дә шулай —
Дөньялыкта
Ләйләләрсез генә әйләнә.

## Дөнья читендә

*1996, гыйнвар*

«Җир читенә аяк салындырып
утырасы иде». Бу хыял
балачактан чынбарлыкка ашты —
Акыл, Фикер, Хәтер йоклыйлар.

Йокласыннар әйдә! —
Тик бу хәйлә,
үз-үзеңнән качу хәйләсе.
Чөнки чынбарлыкка беркемнең дә
үзен-үзе килми бәйләсе.

Әнә ак кар ява... гыйнвар кары
нидер сөйли аяк астында.
Балачакның хыяллары белән
дөньялыкка чыгып бастым да
таңнар калдым.

Ак-ак карлар яуган
могҗизалы, затлы бу көндә
утырабыз икән тезелешеп
һәммәбез дә Җирнең читендә.

## Көтү...

*1995, июль*

Харап!
Өч көн яңгыр — эре тешле тарак
үләннәрне үтте тарап-тарап.
Яшел дөнья аякланып басты
күтәрелгән сыман калкугарак.

Алар сине көтә!
Хәрәкәткә килде һәммә тараф,
бөҗәк иле гөжли тирәлектә.
Алар минем кебек
күз алдында
синең пәйда булуыңны көтә...

Вакыт үтеп тора.
Парашютын ачып җибәрергә
курыккандай, әнә төклетура —
бал эчәсе чәчәгенә анда
төшә алмый сине көтеп тора.

Гомер үтеп бара!
Әрем исе әрәм сиңа бүген,
дигән сыман бакча кыяклана.
Үткән белән киләчәкне генә
тоташтырыр идең...

Ерак ара,
гомер үтеп бара.

Какылары кара көеп катты.
Аягүрә басты балтырганы —
сине көтә әле җиләкләрнең
безне киләчәккә чакырганы.

Көтте... көтте... телсез калды күке.
Саный-саный ул да арды бугай...
Хәлсезләнеп телсез кала Сөю
замананың авыр елларыдай.

Дөнья хәрәкәттә!
Соң, әлбәттә,
еллар белән алар кабатланмас...
Бу табигать үзе сүз әйткәндә,
шагыйрь — сүзен
әйтми кала алмас!

## Әй, хан кызы

*1986*

*Ач ишегең, мин керәем...*
(Борынгы җырдан).

Ачма ишегең, кыз бала,
Мин яман углы Яманмын —
Күкрәгем тулы ярадыр,
Ярамны үзем ямармын.

Үз ярамны мин эт кебек
Үзем ялап төзәтермен.
Үзем чыга белермендер —
Бу утларга үзем кердем.

Ачма ишегеңне, кыз бала,
Бер ачсаң, гел ябылмастыр.
Әгәр инде кереп китсәм,
Туктар чама табылмастыр.

Ачма ишегеңне, кыз бала,
Ачма берүк, керим ватып:
Үзем төзәтермен — җиткәч
Бергә-бергә яшәр вакыт.

## Китеп баргандыр ул

*1992, февраль*

«Болдырдагы каен ауды»
дип язгансың. Ялган!
Ул бит минем балачакта
мәңгелеккә калган.

Болдыр идәненнән чыгып
кәрнизгә сыенган;
көндез — кояш,
төннәрен — ай
нурына коенган.

Каен-кайгы... Әнкәй китте,
Озатып калды ул да.
Бергә-бергә әзерләдек
аны соңгы юлга.

«Болдырдагы каен ауды...»
«Инде аумагае» —
дияр чакларым күп булды,
тик аумады кайгы.

Каен-кайгы... Әткәй китте
сугыш ярасыннан —
каен аның белән бергә
китеп бара сыман.

Безнең халык кайгысыннан
инде арып-талып
китеп баргандыр ул, сеңлем,
үзе аякланып.

Без кичергәнне кичерсәң,
тамырың аяк булыр.
җиргә береккәнлегең дә
кинәт онытылыр.
...Рәхмәт, сеңлем, хатың өчен,
мин ышана алмам:
каен ауды, дигән сүзең
шагыйрәнә ялган —
әнкәй китте...
әткәй китте...
ул да китеп барган...

## Кан тамырын кистем

*(1962—1996)*

* * *

Кайгыңны да, шатлыкларыңны да
бүләр кешең барын сизәсең,
Күз яшьләре аша күрсәң генә
аның күзләреңдә күз яшен.

* * *

Шигырь язу — татлы җимеш түгел,
катмарланып беткән нык тамыр —
шул яшәтә, шул яшәртә телне...
...Тамыр кипсә — яшәү тукталыр.

* * *

Елга яры яралы,
дулкын юа яраны.
бүген бер кыз миңа шундый
серле итеп карады,
йөрәк ярасын юачак
әллә шул дулкынмы ул?
әллә тик күземне йомып
төшәчәк упкынмы ул.

## Бәхет

Гөмбәнең дә ялганы бар,
Бәндәнең дә ялганы бар —
шөкер әле, арабызда
аера алганы бар.

## Ул кала

Илне, телне саклармын, дисәң —
Син китәсең — ул кала исән...

## Бетәм, дип көенмә...

Шәм яна...
Чиге бардыр.
Гамь яна...
чиге бардыр.
Янып беткән мизгелдә дә
Яшәүгә өмет калдыр.

## Хәсрәт

Дөньясын... һәм үзеңне
китәсе килә ташлап,
Яшьлек елаган чагында
үзен-үзе кочаклап.

## Кечке тынлык

Мәче башлы ябалакның
кычкырып куюы бар —
Әзер бул һәммәсенә.

Иркенәйгән уйларыңның
итәген җыюы бар —
әзер бул һәммәсенә.

...Тынлык ул җанга сеңә,
әзер бул һәммәсенә.

## Тәгәри китте йомгагым

— Булмадымы, әй, күрүче!
Җилдән җиң тегеп йөрүче
кешеләр белән бүген
үтте дә китте көнем.

* * *

...Кул сузса әгәр туганың
авырыксынып кына —
мул табындагы өлештән
син аңа сынык кына.

## Казан ханлыгы

Ак киндердә чигеш —
элмә-элмә...
Җилләр алыр төсен,
җилгә элмә.

## Сагыну...

Кеше үзе белми... әмма тели
әрнүләрне, әрнетүләрне —
Ә соңыннан үзен әрли-әрли
әрнеп сагына шул ук көннәрне.

## Уян, татар

*(Г. Тукай)*

Уяну дигән сүз дә бар,
Юк, түгел йокы туеп —
Чынлап уяну — уяну
Кирәклегеңне тоеп.

## Башка калып...

Заман шул ук...
...әмма башка калып...
...сыта сине шул калыпка салып —
тыныч ятам, димә,
читтә калып.

* * *

Мизгел уза,
Секунд уза,
Минут уза... сәгать...
Әмма үзенекен итә —
Әдәпсезлегемнән генә
Саклый күрче, әдәп...

* * *

Балачагым кайтып керде,
Мөлдерәмә карый.
Кара әле, шайтан малай,
Онытмаган — таный.

## Ятим балачагыма

Башыңнан сыйпап юату
иде юкса уем,
үреләм,
    еллар аркылы...
үреләм... җитми... буем.

## Керә калсаң...

Ялгыш кына бер яман ат алып
керә калсаң халык теленә.
Күргәннәрең чәлпәрәмә килеп,
Күрәчәгең меңгә теленә.

## Җитә

Урманнарны яндырырга
кайчак бер шырпы җитә —
янмаска һәм яндырмаска
кайчак бер курку җитә.

* * *

...Уйларың йөрәкне телеп,
ярып чыкмаса әгәр,
сүзләр мәгънәсен югалта
кара кипкәнгә кадәр...

## Башлана гомер

Вакытын, сәгатен белеп
һәркемгә килә әҗәл.
Башлана гомер —
Халкыңны
Яшәтә алсаң әгәр.

## Шул кояшта

Җан җылысын мин кояштан алдым,
Кояш төште гомер юлыма.
Шул кояшта җиләге дә пешә,
Еланы да чыгып җылына...

## Табигать җимеше без...

...Сөю дә сөю булдымы,—
ярат та көнләшмә дә...
Әкиятеңне кабатлама,
дәшмә дә эндәшмә дә —
Әнә, табигатькә кычкыр:
«Күкрәмә! — дип,— яшьнә дә!»

Әгәр дә ки шулай әйтсә,
ул зат миңа чит кавем.
...Сөюем — яшьнәвем минем,
Көнләшүем — күкрәвем.

* * *

Кан җибәргәч, җиңел була, диләр —
Кайбер табиб шулай акыл сата.
Мин ышанып, кан тамырын кистем,
Хәлем китте,
Шигырь агып ята...



**Тәлгат Галиуллин**

# ЭЛМӘК

(РОМАН)

## 19

Халык гакылын, фәлсәфәсен үзенә сеңдергән Әхмәдиша карт Сәетне күп нәрсәгә, аерым алганда бакый чынбарлыкны үз табигый барлыгында кабул итүгә, булганы белән канәгать калуга, «авыл» юморына өйрәтте. Аның бигрәк сабый күзләре, җор теле, шат, шаян сөйләшүе, бер үк нәрсәләрне кабатлавына карамастан, янаралның кәефен күтәреп, рухын үстереп җибәрә торган иде.

Сәет, берәр йомышы төшеп, Төньяк калавылындагы йортларына шалтыратып, телефонны кем алганны белсә дә, сорап куйган була:

— Кем әле бу?

— Кем кирәгенең үзе, маңгаенда ике күзе, башында ике колагы,— дигән җавапны ала.

— Нишләп яту, Әхмәдиша абзый?

— Тик яту белән бик тату булып киттем әле мин, Сәет энем, соңгы вакытта, әллә картлык, әллә ялкаулык инде шунда.

— Урындыклар җитәрлек бугай. Утырып тор!

— Мин үземә һәм башка бик күпләргә тиешлене утырдым инде, ходай дошманыңа күрсәтмәсен.

Картның шырпы кадап, астан чеметеп алырга яратуын белә Сәет. Үпкәләми.

— Урындыкка килгәндә... Хәерниса түтәң тегене кыл, моны эшлә дип, гел кымтырыклап тора. Вакытка кытлык... Исәнлегең ничек, дип сорар идең хет, яхшы анадан туган бала.

— Исәнлекләрең ничек соң әле анда, кадерле вә олылыклы Әхмәдиша абзый?

— Әй, сорап та торма.

— Йомыш әлләни юк. Хәл белү...

— «Бөлү» сүзен җенем сөйми. Һм... эһем. Йомышыңны йомышлап сөйләшергә өйрән.

Картның телефоннан шаяртып гәпләшергә ратканын белә Сәет. Гадәттәгечә, вакыты гына тар.

---

Ахыры. Башы 5—6 саннарда.

— Килеп чыкмакчы идек, дуслар белән, Хәерниса түти мунчасын дөрләтеп, казанын асып куя алмасмы икән?
— Безнең казан гел асылынып тора. Яхшы кешеләр өчен кар өстендә колын ите пешереп бирә ала.
— Ә мунча мәсьәләсе ничегрәк тора?
— Мунчаны дөрләтеп тормас апаң, миченә утны үзем төртермен.
Дөрес, ул көнне Әхмәдиша карт, сораган барча ихтыяҗны үтәгән булса да, Сәетне кунаклары белән бигүк якты булмаган чырай белән каршы алды.
— Хәлләр ничек?— диде Сәет, гадәтенчә тавышына мөмкин чаклы күтәренке рух, көр төсмер бирергә тырышып.
— Аллага шөкер. Тамактан ипи белән чәй үтә. Кешенең бәхете шунда.
— Чирләмисезме?— дип, сүз кыстырырга булды Салих Гаяров, Сакмановның җилкәсе аша сузылып.
Карт тулы җавaптан читкә китеп, үзенең үзгә моң-зары белән уртаклашты: «Туманны, этебезне агулап киттеләр әле. Бик интегеп, ярдәм итегез, кешеләр, дигәндәй, күзгә карап үлде. Апагыз белән тау итәгенә алып барып күмдек, өстенә агач утырттык. Гаилә әгъзабыз булып беткән иде. Мин җыр шыңшыганда кушыла иде».
— Нәселе калдымы икән?
— Булырга тиеш. Этле кешеләрдән сораштырасы бар.
— Яңа эт баласы китерермен. Үскәнрәген. МВД ярдәм итәр әле.
— Үзеңнең исәнлек ничек?— дип, янәдән белешергә булды полковник.
— Ярыйсы.
— Кашларың тартыша. Чирләп китә күрмә!— дип кисәтте хөкем оешмасы вәкиле.
Сый-хөрмәт белән тулы, әзер өстәлгә Хәерниса түти самовар китереп утыртты.
— Сән, карчык, чәең сыек, Мәскәү күренә,— дип, күнегелгән гадәте буенча, зарланып алгандай булды карт. Үзе канәгать. Чәйне җиренә җиткереп, дегет төсе чыгарып ясарга карчыгы урман сазлыгында, торф чыгарганда ук өйрәнгән.
Гаяровны урынбасарлары белән мунчага кертеп җибәргәч, Сәет Әхмәдиша карт белән бик озаклап сөйләшеп утырган иде ул кичне. Һәр җөмләсе, фикере хәтерендә уелып калган.
— Гөнаһлы заманда яшибез, энем. Шәригать кануннары буенча хөкемгә тотсаң, теләсә кемнең бүген төрмәгә утыртырлык, бер ишесенең алып чыгып атарлык гөнаһысы бар. Тик адәм баласы ялгышларын танымый.
— Нәрсәләрне күз алдында тотасың инде, абзыкай? Бик кырыс бәялисең заманабызны.
— Явызлык көчәнешен — көнчелекне күздә тотам. Кемнеңдер көнчелеге бугазына менеп, теге кара чорда безнең өстән шикаять-хат язарга этәрә. Күңел каралыгын сабын белән генә бетереп булмый. Ул көннәрнең бай дигәнен дә, ташка үлчим инде. Иске байның бөлгәне, яңа байның көлгәне генә иде инде.
— ГУЛАГ төрмәсендә интегеп үлгән әти-әниегезнең урыны оҗмахта гына була ала. Алар күргәнне, дошманыңа да теләмәссең,— дип, Сәет картның кайгысын бүлешкәндәй итә, аңа якынрак телдә сөйләшергә тырыша.
— Безнең нәселнең, гаиләнең дә гөнаһысы булгандыр инде анысы?
— Сезнең үз кул көчегез белән тапкан мал-мөлкәтегез гөнаһка ничек керсен инде?
— Еш кына ата-баба ялгышы өчен балалары, оныклары түли. Значит, куллары башкаларга тиешле җегәрне алган, ходай биргән акыл куәтләрен, уй-рәвешләрен үзмаксатларына гына эшкә җиккәннәр.
— Большевиклар: акыл һәм физик куәтегезне халыкка багышлагыз,— дип чакырдылар.— Син дә шуңа ышандыңмы?

Әхмәдиша карт бу шаяртуны көй бозуга санап, олы кулы белән һаваны кисеп төшерде.
— Аларныкы үзгә. Гомерендә җылы сүз ишетмәгән ач-әрвахның күзенә төтен җибәреп, үзләре типтереп яшәп калу иде максатлары. Сабыйларның бәхетен, киләчәген алу — төп миһербансызлыклары булды аларның.
— Без дә, мин дә, әйтик, бу йортны салганда, кемнеңдер өлешенә кердек бит инде. Сул як җилкәдә утырган фәрештә аны артык зур гөнаһка тиңләмәсме икән?
Елдан-ел дингә, ислам тәгълиматына тирәнрәк инана барса да, «кулак калдыгы» — елтыр башлы Әхмәдиша карт — дәрвиш, диндар түгел иде. Шундый фаҗигале тормыш сукмаклары үтеп, картлыгында теләгенә ирешкән, һәрхәлдә үз почмагын булдырган, күңел тынычлыгы, тирәлек белән якынлык, тәңгәллек эзләгән кеше бернәрсәгә дә сукырларча табынмый, күке мәсле тилереп кычкырмый. Балалар күрәге сабыдай юан күрсәткеч бармагын өскәрәк күтәрде карт. Янәсе, тагын бер уе бар.
— Сәет энем, синең нәрсә әйтергә теләгәнеңне чамалыйм. Бердән, бу йортны мин башладым, син — төгәлләдең. Гөнаһның күпмедер өлеше миңа бу чәчсез башка да төшә. Икенчедән, Мөхәммәтөммәтебез сату-алу, сәүдә эшенә уңай караган. Бу шөгыль тел-ләгать алышуга юл ача, исламны таратуга мөмкинлек бирә, адәм баласының акыл-зиһенен чарлый, кыргый дөньяны үзенә буйсындырырга мөмкинлек бирә.
— Алайса без — оҗмах кошлары.
Әхмәдиша карт чыраен сытты. Эре җыерчыклары ызан-ызан булып күз төпләренә, маңгаена сузылды.
— Оҗмах капкалары җиңел ачылмас, энем. Тәмугын татырга туры килмәгәе. Күбрәк яхшылык кылырга, җирдә акыллы эз калдырырга кирәк... Үз кавемеңне хөрмәт итсәң, чит кавемгә кол булмассың, диләр.
Картның әлҗегәнен күреп, Сәет әңгәмәне туктатты. Карт тәһарәтен алып, тәнен чистартып, намазына утыра. «Игелек» хуҗасы аңа сокланып карап тора. Ул Төркиядән алып кайткан яшел намазлыгында дөнья мәшәкатьләрен оныта, рухы күкләргә иңә.
Намазлыкта күңелен дингә, аллага биргән кеше күк кодрәтен үзенә җыеп сеңдерә, күрәсең. Гаяровларның әле мунчадан чыкмаганнарын ачыклагач, ял иткән карт янәдән Сакманов янына күчеп утырды.
— Мин синең нәрсә турында уйлап алганыңны беләм. Кеше ул, энем, завут кебек. Берәр чир эләктеме, бөтен тәне, рухы, бәдәне аксый башлый. Безнең илнең төп бәласе — завутны ялгау, ямау, төзәтү, сыйпаштыру, буяштыру белән сафта тотарга омтылу. Ә аны, җапуннар кебек, искесен ватып ташлап, яңабаштан корырга кирәк.
— Безне заводка тиңләвең белән килешмим, табигатьнең югары казанышы кеше — уйлый, сөенә, көенә, ярата, сата, сатыла,— дип, бүлдергән булды картны.
Карт юан күрсәткеч бармагын, гадәтенчә, өскә күтәрде: «Янәсе, туктале син, олыларны тыңла...»
— Кибәнемне очлап куйыйм инде, кем. Кешенең завутка тагын бер охшаш ягы бар әле. Завут, яхшы товар белән бергәттән, брагын да чыгара. Кеше үткән юлда да, игелек белән әшәкелек эзләре кала. Бер зат яхшылыкны күбрәк кыла, икенчесе начарлыкны артыграк тудыра, андыйларны начар, әшәке, алама бәндә, диләр. Хикмәт-то башкада. Берәү дә үзен соңгылары рәтенә кертми, бу турыда кемдер әйтсә дә ризалашмый, үпкәли. Һәр кемсәнең изгеләр рәтендә үк булмаса да, яхшылар исемлегендә йөрисе килә. Ә һәр кемсәгә урын җитми. Вакансылар күп түгел.
Карт тукталып ясады, чәен йоткан булды. Эчке икеләнүен, шикшөбһәсен җиңеп, максат ташына су коюны дәвам итте.
— Тормышыныңның кояшы сүнә, Тукаебыз әйтмешли, лампаң эчендә май кими, кичке зәңгәр күзеңә төшә башлагач, Сәет энем, күңелгә үзгә уйлар иңә икән. Яхшылыкны кирәгенчә кыла алдыңмы? Кешеләрне күп

рәнҗетмәдеңме? Миңа ярдәмең күп тисә дә, заманында бергә хәрәмләсәк тә, әйтим инде, синең тормышың да миңа ошамый.

— Ни өчен, дип сорарга мөмкинме? Минем гаебем нәрсәдә?

Картның аргы урам аша әйләнеп, аның тыкрыгына килеп чыгасын сизенгән Сәет дулкынланмаска тырышты.

— Гаеп дип инде... Шундый яшәү рәвешенә сезне замана үзе төртеп кертте. Исән калу, тук яшәү өчен көрәштең, җиңдең. Исән калдың.

— Мин бит әле, барыбер, дөрес яшәмим булып чыга.

— Син генә түгел. Күпләр хәзер тайгак юлны сайлый. Берәү уңышка ирешә, икенчесе, бозга эләккән бозау кебек, таеп егыла. Бүген кемсә башкалар исәбенә баеп калса, иртәгә аның балалары, оныклары кайгы-хәсрәтсез көн итәчәк.

— Барысы да байлыкка, хөрлеккә омтылгач, мин дә шулар рәтендә булгач... Минем ялгышым нидән гыйбарәт соң?— дия-дия, Сәет үзенең катлаулы, түгәрәк божра кебек, очсыз-кырыйсыз әхлакый бәхәскә тартып кертелгәнен аңлады.

— Юк синең хатаң. Тик барган юлыңда канлы эзләр кала.

Сәетнең битенә кызыллык менде, урыныннан корт чаккандай сикереп торып, бүлмәне урады да, лып итеп урынына утырды.

— Туры әйткән туганына ярамаган,— дигән тыныч, салмак, хөсетсез тавыш белән әйтелгән сүзләр аны аңга утыртты.

Башына иң әүвәл килгән фикер, бу ахмак бәхәсне туктатырга булса, икенчесе, картны ачуланып, әрләп ташлап, Гаяровлар янына кереп, бөтен кайгы-хәсрәтне, дөнья мәшәкатьләрен оныттыра торган эссе, юеш ләүкәгә үрмәләп менеп китү иде. Аң типкелендә, тирәндә өченче фикер үзенә сүз сорап этләште. «Ераккарак китеп карасаң, карт хаклы. Канлы эзләр, канлы тамгалар... барган юлларыңда».

— Көләч, рушан йөзле Зөлфия һаман күз алдымнан китми,— дип, карт шыңшып, елап ук җибәрде. Сүзләренә ачыклык кертә идеме карт, әллә кирәгеннән артык киеренке тартылган кылларны бушатырга омтылуы идеме, төшенеп җитмәде. Сәеткә бу минутларда йөз, мең тапкыр кыенрак икәнне чамалый иде бугай ул.

— Хатыным өчен үч алмасам, мине бу гөнаһлы дөньяда берәү дә гафу итмәс, ваемсызлыгым бернинди акыл тәртәсенә сыймас иде.

— Бу очракта син хаклы. Үч алу кешелекнең зиһенле казанышы булмаса да, борынгылардан калган гадәт, тиле йола. Киләчәктә мондый хәлләр азрак булсын иде, диюем.

— Мәчеткә, намазга йөри башларга вакыт димәкче буласыңмы? Миңа да...

— Мәчеткә мин үзем дә бик еш йөри алмадым. Изгелекнең юллары төрле... Дөресне белмәгән кеше генә сөйли, ә ялганны дөресен белгән кеше генә сөйли ала,— дип, гомуми бәхәскә бик үк ятышып бетмәгән нәтиҗәсе белән тәмамлады сүзен карт. Әхмәдиша агай бу сөйләшүгә күптәннән әзерләнеп куйган иде, күрәсең. Фикерен эзлекле җәйде, сүзен өздереп әйтте.

Шул арада Гаяровлар тирләп-пешеп, шау-гөр килеп мунчадан чыктылар. Җитди әңгәмәгә урын калмады. Әхмәдиша карт, яшьләрнең үзләрен генә калдырып, үз бүлмәсенә кереп китте.

...Бу аңлашудан соң, дүрт айлап вакыт, язгы кар сулары кебек, үткән дә киткән. Сәет, Ырымбурдан Мисхәт-Мишаны алып кайтканнан соң, шәһәрдәге фатирына күчәргә ният итте. Ишекне шакып, бүлмәсенә Әхмәдиша карт керде. Авыраеп киткән гәүдәсен диванга урнаштыргач, авыр сулап куйды. Күзләре дымлы иде.

— Безне ташлап китәсең инде, Сәет энем. Синең белән надежны иде,— диде керә-керешкә.

— Мин гел килеп йөрермен, Әхмәдиша абзый. Телефоннар бар.

Картның үзгә, җитдирәк уй белән кергәнен сизенә Сакманов. Сүзне аның башлавын көтә, фәлсәфәй карт берәр «заготовкасыз» кермәс. Кө-

рәк куллы, борчулы йөзле, дымлы күзле абзый аңа әтисе кебек якын иде. Зөлфияне туфракка тапшыргач, карт Ярулла улына аеруча игътибарлы, ярдәмчел булды. Сәет үзенең тышкы рәвешенә, кием-салымына игътибар бирми башлагач, нәкъ менә Әхмәдиша картның аны эттән алып этка салып әрләп ташлаганы хәтерендә.

— Киемнәреңә игътибар итмисең энем. Кырынмыйча йөрү дә Мексика балыкчыларына гына килешә. Аларның хет сакал-мыек үстерүенең сере бар: йөнтәс кеше балыкка ныграк охшый. Теге бичаралар — диңгез мәхлуклары, шуңа алданып, милициягә үз аягы белән килеп кергән бур кеби, җәтмәгә килеп кабалар, ди. Дөрес булса. Белүемчә, хуҗамның кулындагы балыклары да баштин ашкан. Төшерүне дә арттырмадык микән? Хәмер белән артык дуслашып барабыз түгелме?

Бу юлы да тынлыкны карт үзе бозды.

— Картаелды, кем Сәетҗан.

Тышта котырынган буранны тыңлагандай, тукталыш ясады. Җыерчыклар челтәре каплаган битен сыйпап, элеккечә үк кыска, пөхтә сакалын сыпырып алды.

— Йөзем балыкчы җәтмәсенә әйләнде, күзләрем арыды, колакларым миңа хезмәттән туйды, тешләрем күптәннән җирдә череп ята. Мием мумие төсле катып бара. Еллар саны сыйфатка күчми икән. Моны хәтереңнән чыгарма. Әле кичә генә ресторанда мәш килеп яткан кебек, баксаң, сигез кыш үткән дә киткән.

— Нишләп кыш?

— Яз, җәй, көзләрен санамыйм мин. Алары тиз үтә. Җелекне кыш киптерә. Ике ел элек кенә, ике «чуаш малае»н кәгеп куеп, рәхәтләнеп гәпләшеп утыра ала идек. Ә хәзер? Сиңа да вакытлыча ярамый. Рәхәтләнеп мунча чабына да алмыйсың... Синеке үтәр. Ә минем кояшым инде сүнеп бара.

— Юкны сөйләмә әле, Әхмәдиша абзый. Тормышны рәтләп, кешечә яши башлагач кына, син тагын... Син бер дә үзгәрмисең, бәлзәмгә төреп куйгандай,— дип теленә салышты пахан.

Бу сүзләрнең комагай ялагайлык, чеп-чи ялган, тел шомарту галәмәте икәнне белгән тәкъдирдә дә, адәм баласының шуңа, тәтигә алданган сабыйларча, ышанасы килә. «Кулак калдыгы»да Сәеткә барыбер рәхмәтле.

— Билдә — ыштан, телдә сүз тормау — чын картлык инде ул. Үлем куркыныч түгел. Әҗәлдән дару югын беләм. Иң аянычы шунда: гомер буена бөртекләп җыйган тормыш тәҗрибәң, дөньяны аңлавың, тоюың үзең белән кабергә китә. Җан күчсә дә, хәтер күчми шул.

— Ә без, яшьрәк буын, һәр үрне яңадан яулыйбыз. Шул ук хаталарны кабатлыйбыз.

Карт үз бураznасын еруны дәвам итте.

— Икенче яктан, кемгә хаҗәте бар инде синең ул тәҗрибәңнең, сазлыктан сасы су эчеп, урманда черки туйдырып, эттән талатып яшәгән гомер сөземтәңнең. Кемгә чәер, кемгә бәгырь, диләрме әле.

Карт авыр итеп көрсенеп куйды.

— Энем, әйтсәң — сүз, тәртсәң — күз инде. Дөнья матур, дөнья киң, аннан миңа ни файда, дигәннәр борынгылар. Барыбер сиңа күмәсе, Сәетҗан. Балалар кайтып җитәме-юкмы, әҗәлем тотканда алардан барыбер әлләни файда булмас, гозерләремне исән чакта сиңа әйтеп каласым килә. Бала ул үскәндә, йә гел янында яшәгәндә генә якын була.

Мин, энем, чыннан да җирдәге тормышымның соңгы чорына кереп барам. Теге көнне дә, лампам эчендәге май турында, гел шаяртып сөйләшмәдем. Рак дигән зәхмәт ябышты бугай үземә. Колорад жугы бәрәңге яфрагын бетергән кебек, эчне туный. Ризык тамактан үтми.

— Апа беләме?

— Юк.

— Әйтмәскә булдыңмы? Димәк, синең чирең җитди түгел. Воспаление хитрости, диләрме әле?— дип, картның кәефен күтәрергә тырышып, шукланган булды Сәет.

— Аһ-ваһ, кызгану, сыктану, агай-энене чакыру башланудан куркам. Курыкмыйм. Просто, яратмыйм.

— Әхмәдиша агай, син бик хәйләкәр кеше икән. Мин элек тә сизенеп йөри идем. Ну болай ук... дип белми идем.

— Ни өчен мине шулай рәнҗетергә уйлыйсың, энем?

— Яшәү өчен көрәшергә уйламыйсың.

— Тамакка берни үтмәгәч, ризыкның тәмен сизмәгәч, дөньяның кызыгы калмый икән.

— Тартышусыз бирешми торган идең, Әхмәдиша абзый. Нәрсә булды? Әнә Әлмәндәр карт, мәгълүм спектакльдә, ничек көрәшә Әҗәлетдин белән.

— Нәтиҗәсе шул ук. Этләшеп, талап алып булмый гомерне. Ходай күпме биргән.

Карт артык ачыргаланмый. Язмыш китабына пыяла аша карамый.

— Хаста килү, зәхмәт-михнәт чигү, кайгы-хәсрәт кебек фаҗигаләр, үлем кебек үк, кылган хаталарыбыз өчен түләү генә.

Кыскасы, Сәет Яруллович, ай бетте дә, төн җитте дигәндәй, мин ошбу дөньяны ташлап китәргә әзер. Ике үтенечем бар. Берсе — Хәерниса апаңны ташлама. Ул — артымнан шәүлә кебек йөрде. Миннән соң озак тормас, артык мәшәкать тудырмас.

— Апаны карауны үз өстемә алам.

— Җирләүне дә үз өстеңә ал. Икенчесе — бу олы йортны син үзең карап бетерә алмассың. Махсус бер кеше кирәк. Аның заһиты — икенче хуҗасы кем булыр? Уйлаганың бармы?

Мондый туры сорауга әзер түгел иде Сакманов. Ул картны мичкә куйсаң эреми, суга салсаң агып китми торган, мәңгелек кешегә санап йөри иде. Баксаң, ул да һәркемгә килә торган соңгы юлга җыенып ята икән ләбаса.

— Уйлап карарбыз бергәләп. Бу хакта баш катырганым юк иде.

Картның тагын нәрсәдер әйтәсе килгәне өмсенеп торган иреннәреннән, төсен югалткан рәнҗүсез күзләреннән сизелеп тора.

Сәет көтә белә. Үзенә кирәген адәм баласы барыбер әйтәчәк.

— Соң, энем, ачуланма инде. Бу йортта безнең өлеш тә бар бит әле. Аз булса да...

«Игелек» директоры күтәрелеп бәрелергә, картны әрләп ташларга да хаклы иде. Хикмәт Әхмәдишаларны тулы тәэминатта тотуда гына түгел. Җир өчен тулысы белән түләде. Картның сүтеп ташланган хибарасына алмашка шәһәр үзегеннән квартира алып бирде. Әхмәдиша карт анда торып карады да, кире кайтты. Тудыка сеңелесе яши ул фатирларында.

Карт, уфырып кулын селкеде дә, «тыңлама мине, карт тилене, гафу ит, бик арыдым»,— дип, үз бүлмәсенә кереп китте.

Соңрак сандык барыбер серен ачты. Картларның хыялы — Магнитогорск якларында адашып калган улларын Төньяк калавылындагы йортка кайтарып калдыру икән.

— Кешенеке — кештәктә заманында да улым Госман, аның киләчәгенә салкын карый алмыйм. Аның турында хак сүзне мин генә әйтә алам. Апаң улына тел-теш тидертми. Безнең ара — ит яхшылык, көт явызлык була алмый. Казык йолдызың сүнәргә торганда, алдашу килешми. Алма агачыннан шактый еракка тәгәрәп китәргә дә мөмкин икән, Сәет энем,— дип, Әхмәдиша карт, бүленә-бүленә, улына бәя бирде. Артык мактамады. Сакманов аңа каршы килә алмады. Сүзен тәмамлагач карт: «Кояшның кадере баегач кына беленә»,— дигән җөмләсе белән урынына кереп ятты. Шул ятуыннан тормады. Хәерниса апа да ирен озак көттермәде. Аның янына китте.

Бу олы хуҗалыкны кемдер карап, бакчасын үстереп, карын көрәп, мунчасын ягып торырга тиеш иде. Бер үк ата-анадан да төрле-төрле кешеләр туа икән. Госман атасын алыштыра алмады гына түгел, Сакмановка шактый мәшәкатьләр тудырды. Ул, зәмзәм суы белән тамагын гел чылатып торырга өйрәнгән, чын «балыкчы» булып чыкты. Бервакытта да кылганын танымас. Авызыннан ахырзаман исләре килеп торса да, «юк, билләһи, эчмәдем, бер стакан сыра гына капкан идем, алдасам, дөнья нурын күрмим, ипи йотсын»,— дип, каргана, ант итә башлый.

Чит-ят җирдә туып-үсеп, яшәү өчен берүзе көрәшеп, үз кабыгына бикләнгән, аз сүзле булып калыпланган. Сәет аның күзләрендә елмаю галәмәте күрмәде, диярлек. Алар, киресенчә, сыер күзләре мәсле, һәрвакыт кайгылы, хәсрәтле, мәэюс иделәр. Ул хәчтерүш белән бергә-бер калу, ачык чырайлы, тел бистәләре Әхмәдиша, Хәлил, Зөлфия, Гаяров, Мисхәтләр белән аралашып яшәгән Сәет өчен, тәмугның нәкъ үзе иде.

Сакманов, тешен кысып булса да, Әхмәдиша картның, Хәерниса апаның гозерен үтәп, аларны җирләгәннән соң да, Госманны куып чыгармады, йортның хуҗасы итеп тотты. Мәгәр өйдә элеккеге нур, ярты сүздән аңлашу, тулы ышаныч тудыра алган күңел көрлеге калмады.

## 20

Әлфия кырында иркәләнеп-назланып, хәл-әхвәл җыеп ятканнан соң гына, Мисхәт үзе белән булган тамашаларны бәян итәрлек хәлгә килде. Анда да әле Сәет егетнең нәрсәнедер яшереп, төшереп калдырып, курка-курка гына сөйләгәнен аңлады. Ул әле һаман үзенең азат ителүенә, иртәгә янәдән килеп алмасларына ышанмый бугай. Рухын изгәннәр, ихтыярын шактый сындырганнар егетнең. Йөзеннән көләчлек качкан.

Маликовның алты айга сузылган «Ырымбур риваятенең» асылында гадәти бер тормыш низагы. Ә инде нәтиҗәсе: безнең илдә генә була ала торган башбаштаклык.

Үргәнечтәге апасы чит-ят илдә яшәүнең мәгънәсе калмавы, туган якларына кайтып, Казан читендә йортмы, фатирмы сатып алырга теләге барлыгы турында яза. Үзен килеп алуын сорый, ялвара, үтенә. Маликовның заманага җайлашып, керләнеп бетмәгән күңеле, туган-тумача каршында үзен күрсәтеп алу нияте (кем идек тә, кем булдык) аны четерекле юлга алып чыга. Риясызлыгы белән апасының янә бер кинәшен күз уңына ала: «Бу якта нарат тактасы алтын бәясендә йөри, бер машина алып килсәң, юл чыгымнары акланыр, шактый сумма кесәгә керер». Балга ябышкандай җиңел килер байлык, адәм баласын мең тапкырлар сынап, йөз тапкырлар упкынга ташласа да, «сөннәткә утырта» алмады. «Артык акча Әлфия белән безгә мишәйт итмәс»,— дип, Мисхәт, ширкәттән олы йөк машинасы юнәтеп, такталар сатып алып, сәяхәткә чыгып китә. Дөрес, «малай, артыгын кыланасың, мондый ерак сәфәргә ашыгыбрак чыгасың», дип язмыш бабай аны искәртә искәртүен. Үпкәләрлеге юк. Әүвәл, яхшылары арасына черекләрен тыгып, такта белән алдап «шомарталар». Аннан КамАЗ шоферы Гамир, сөйләшенгән вакытка ләх исерек килә, сәбәбен аңлатып, гафу үтенерлек хәле дә булмый. Саубуллашып чыгып киткәч, тәртәнә кирегә борып булмый. Ерак юлга шулай «капитально» әзерләнгән Гамирның айныганын көтеп утыру файдасыз. Күпме вакыт заяга узачак, сәрхүш шайтан суын шыпырт кына өстәп куймас дип, берәү дә заминлек бирә алмый. Бичарадан ни чара дигәндәй, Мисхәтнең үзенә рульгә утырырга туры килә. Ә теге, чөгендер борын, Ырымбурга җиткәнче, уникe сәгать йокы симертеп бара. Барыбер айнып җитә алмый.

Юлыңның башы уңмаса, ахыры да хәерле булмас, диләр. Хак сүз икән. Татарстанның илләм бәйләнчек гаишникларын, күрше өлкәнең берничә постын исән-имин узып, ком вә җилләр каласын үтеп киттем

дигәндә, Мисхәтнең чабуыннан эләктерәләр. Машинаны көзге бурсык кебек симез гәүдәле, таба битле сержант туктата. Маликов, «әйдә инде, уян», дип Гамирның янтавына төртә дә, тиешле кәгазьләрен алып, чыраена тулы ваемсызлык чыгарып, юри читкә карап торган ГАИ әһеле янына килә. Җаваплы кеше, бөтен шартын китереп, кулын баш тирәсенә ташлап, үзе белән таныштыра:

— Постовой ГАИ. Сержант Давлетгареев. Ваши документы.

«Йөзенә, фамилиясенә караганда, үзебезнең милләт кешесе бугай. Татармы, башкортмы? Бәйләнеп тормас, абзаң бәхетле кеше ул»,— дигән уе, өмет дулкыны, Мисхәткә үз-үзенә ышану көче өсти.

— Документлар тәртиптә. Ургенечка, туган апам янына барышым. Казанга алып кайтырга исәп. Куалар аннан безнекеләрне.

Җаваплы адәм Мисхәтнең татарча сөйләнүен ишетмәмешкә вә аңламамышка салышып, тар маңгае астына оялаган күзләрен таҗрайтып, кәгазьләрне өйрәнүен дәвам итә, такталарга «сәлам» биреп төшә.

Кулын кысып, хәерле юл теләү көткән Маликовка, бик кырыс кына, үзе артыннан, кызыл кирпечтән салынган, бер катлы ГАИ йортына керергә боера. Бүлмәдә берүзе. Аркадашы урамда, тәрәзә янында йөренә. Сержант кулындагы документларны, башлангыч сыйныф укучысы мәсле, тәфсилләп, хәрефләп өйрәнү шөгыленә керешә.

Мисхәт исә, Давлетгареев иптәшнең ишәкнеке төсле үрә катып калган, зур колакларыннан күзен ала алмый тик тора. Бәла-казаны, хәйләне сизенми әле.

— Значит, такталарны Кырындык авыл советыннан сатып алдым, дисең инде. Аларга каян килгән агач материал?

Мисхәтнең эченә шик-шөбһә корты керә башлаган иде инде. Ышанычы, өмете сабын куыгыдай юкка чыгар микәнни? ГАИ дәһрие документларыңны сразы кайтармаса, этлек әзерләвен көт тә тор!

— Каян, ничек алулары алар эше. Мин шуннан сатып алдым. Документально.

— Мин сезне җибәрә алмыйм. Такталарны саныйсы, тикшерәсе булыр. Машина да сезнең исемдә түгел.

— Санагыз да артыгын үзегездә калдырыгыз,— диде егет, таба битле, ишәк колаклы абзыйга карата күңелендә усаллык кутәрелә барганын сизенеп.— Шофер машинада ял итә. Кирәк булса, чакырырбыз.

— Миңа ун такта калдырыгыз. Үземә түгел, дәүләт автомобиль инспекциясенә,— диде Давлетгареев, тавышына килешүчән төсмер йөгертеп.

— Кирәк кадәрен үзегез алыгыз,— дип карышты Мисхәт үз башына. Бурсыктай гәүдәле абзыйга нисбәтән күрә алмау хисе уяна башлауны тойды.— Алар бик тыгыз итеп, тимер чыбыклар белән бәйләнеп куелган.

— Үзең алып бир! — дигән әмер төште.

— Анысы ук булмас! Сезгә кирәк икән, алыгыз.

Сержантның күзләренә кызыл буяу менде. Өч бармак киңлегендәге маңгай сырлары бер буразнага җыелды. Колаклары тагын да тырпая төште.

— Мин сезне шәһәргә озатам. Паспортыгызны бирегез.

Гарьләнүдән калтырана башлаган Мисхәт чалбар кесәсеннән сары күн бумажнигын тартып чыгарды. Соралган документы шунда иде. Вак-төяккә дип өскә куелган биш, ун меңлек акчалары киң агач өстәлгә сибелде. Аларны җыеп алырга ашыкмыйча, Маликов паспортын чыгара башлады. Шунда көтелмәгән хәл булды: Давлетгареев кулын җәһәт кенә егетнең уң беләгенә батырды. Берни аңламаган Мисхәт, аягы капылт капкынга эләккән җанвар мәсле, кулын тартып алырга итте. Шул мәлдә гаишник икенче кулы белән аның күкрәгенә китереп төртте. Гарьләнүдән бәгыре өтелгән яшьлек тәҗрибәле шантаж-фетнәнең мәкерле ятьмәсенә эләкте. Яшен тизлеге белән кулын тартып алып, гаишникның ияк астына

манчыды. Йодрыгында гөрзи көче булмаса да, сугу саллы чыкты, таба бит чайкалып китте.

Әле генә урамда, ай шикелле битараф, ваемсыз сызгырынып йөргән икенче милиционер, алдан уйланылган тамашаның шаһиты, киеренке уктан ычкынган җәядәй бүлмәдә пәйда булды, кирә керешкә корбанының өстенә сикерде, идәнгә бәреп екты. Карышуның мәгънәсезлеген аңлаган Мисхәт берешне, тынды. Тилмереп күтә-күтә күз алмаларын талдырган апасы янына сәяхәткә нокта куелды.

Шул арада патруль машинасы килеп бөялә. Ишәк колаклы сержант, иягең уа-уа, өстәлдә яткан акчаларга күрсәтеп: «Ул миңа взятка тәкъдим итте, менә ул акчалар, санап, беркетмә төзегез, шуның өстәвенә ул миңа кул күтәрде» — дип, тантаналы белдерү ясый.

Аның гаепләвен шик-шөбһәгә алучы, табигый ки, табылмый: карга карганың күзен чукымый. Шунда ук беркетмә «төзү» башлана. «Ришвәт тәкъдим иттем, ГАИ хезмәткәрен сатып алырга уйладым»,— дип язылган рәсми кәгазьгә кул куюдан баш тартса да, изге ният белән юлга чыккан Мисхәт Маликовны шәһәргә алып китеп, милиция бүлегенең махсус бүлмәсенә алып кереп, бик тәмләп, озаклап арт сабагын укыталар. Мәсьәләгә иҗади килә беләләр икән хөкем оешмасы әһелләре. Мондый алым турында тарихчы егетнең укыганы да, ишеткәне дә юк иде. Кулларына тимер кыршау кидереп, гөнаһсыз гәүдәсен, сарык түшкәседәй, түшәмдәге ыргакка элеп куялар да, дүртәүләп «эшкә»ябышалар. Кем резина таяк, кем йодрыгы белән кыйный, кулын кызганганы, каратэ алымы белән сикереп, аягын ходка җибәрә. Бөер, бавыр, талак кебек нечкә әгъзаларның кая урнашканын белеп эш итәләр. Биткә тимиләр. Начальствога күрсәтәсе була. Кан кардәшен, милләттәшен Давлетгареев, шәхси дошманыннан үч алгандай, аеруча ясканып, кара шөгыленнән ләззәт табып дөмбәсли. Мисхәтнең иркә тиресе әүвәл кызыл, аннан шәмәхә, соңрак, аңын югалтканда, кара күмер төсенә керә, аркасында, аяк балтырларында нарасый йодрыгыдай кара түмгәкләр кала. Таш идәндә уянып китә. Уалган сөякләрен сизми, тәне дөрләп яна. Мис чыбарлыкны кабул итми.

Егетнең аңына килгәнен карчыгадай саклап торган ГАИ «дәһриләр»е алдына беркетмәне китереп куялар. Кулына каләм тоттыралар. Ирен-нәрен ача алмаган Мисхәт, баш ымы белән генә, ризалашмавын белдерә. Очлы туфли кабыргаларын эзләп таба. Маликовны кәгазьләргә кул тамгасын салырлык дәрәҗәгә җиткергәнче, тукталыш ясый-ясый, кыйныйлар. Максатларына ирешкәч, чишмә суы турындагы вәгъдәләрен онытып, корбаннарын төрмәгә илтеп ташлыйлар. Мисхәт янәдән аңын югалта. Бары тик һава җитмәгәнлекне генә сизенә. Аңына килә башлагач, үзенең мичкәдәге тозлы балыклар кебек, кеше белән дыңгычлап тутырылган камерада икәнлеген аңлый. Ярым ялангач тәннәрен корчаңгы, тимрәү, битләрен сакал-мыек баскан кешеләрнең бер ишесе ике катлы, аслы-өсле сәке-сәндерә сыман агач ятакларда утырып-ятып тора, башкалары идәнгә чүмәшкән. Бәгъзеләре арлы-бирле йөренеп тора. Берсе Мисхәт кырына килеп, янына чүмәшә. Бите генә түгел, муенын, бугаз төеннәрен чәч баскан карт, кара тамырлы куллары белән Мисхәтнең күлмәк изүен чишә. Күпне күргән абзый аһ итә. «Ну изгәннәр малайны. Минем бу чаклы кыйналган, сүнгән күмердәй кара тәнне күргәнем юк иде әле»,— дип, Мисхәтнең авызына салкын чәй агыза. Битенә тимәсәләр дә, иреннәре шешенеп, шартлап, бер-берсенә ябышкан. Телен аңкауга бәйләп куйганнар, диярсең. Умарта кучедәй гөжләп торган камерада тынлык урнаша. Мисхәтнең куштан колакларына аерым җөмләләр керә:

— Ни өчен шулай тукмаганнар егетне?
— Гади каракка охшамаган. Йөзе интеллигентный күренә.
— Кәчләгән өчендер?
— Шуның өчен кыйнап торырлар.
— Милисигә каршы әйткәндер.

— Взяткасын аз биргәндер!

— Кесәсен карагыз әле? Акчасы юкмы? Аңа мишәйт итеп тормасын!

Мисхәт бумажнигын шоферына ташлап өлгергән була. Чалбар кесәсендәге калдык-постык акчаларын алып, бүлмә «хуҗасына» тапшыралар.

Икенче көнне егет үзенең гадәти тәварихын фәһемләп бирә. Берәр отыры усал вакыйга уйлап чыгарасы булганда, вакыты җитми, рәвеше килми, хәле тартмый. Кесәләре буш, шәһәрдән посылка ташып торырлык туганнары, таныш-белешләре булмаган кеше кызыксыну, хөрмәт уята алмый төрмәдә. Тынычта калдырганнары өчен рәхмәтле булырга тиеш иде әле Мисхәт. Кызгандылар, күрәсең.

Яңа яшәешнең беренче атнасында аны беркая да чакырмадылар. Сорау алучы-мазар булмады. Көненә ике тапкыр ашарга кертәләр. Иртән — ике телем кара ипи, майсыз ботка, чәйне хәтерләткән сыекча. Төшке ашка бозылган маргаринда пешкән тары шулпасы, бәрәңгеле җылымса су, тозлы кәбестә яисә боткага охшаган изелмә. Тазара башлауга, яшь тән ашарга таләп итә. Баллы-майлы тормышка өйрәнгән ашказаны төрмә ризыгын кабул итми. Кан тамырлары, чүлдәге сусыз елгачыкларны хәтерләтеп, эчкә баткан йөнтәс карт Мисхәтнең Әлфиясенә язган хатын «вулега» чыгарырга булыша. Бернichә көн изоляторда тотканнан соң, исеребаш Гамирны, машинасын алып калып, тиешле штрафын түләтеп, кайтарып җибәрәләр. Ул да «сөенче» ала.

Ниһаять, Маликовны район прокурорына алып киләләр. Ишектә Хасаншин Марат Харитонович дигән язуны укыгач, эченә җылы кергәндәй була. Давлетгареев фамилиясе келт итеп исенә төшеп, кәефе кырыла бераз. «Бөтен татар кешесе дә андый миһербансыз була алмый бит инде»,— дип, хыялый кәеф белән бусаганы уза. Прокурорның бүлмәсе зур, киң икән, уртасына биллиард өстәле куярлык. Түр башында, олы ялтыравык өстәл артында, коңгырт-соры чәчле, күзлекле, өлкән яшьтәге абзый утыра. Алдында яткан кәгазьләрен укуында.

Бүлмә хуҗасы, башын күтәреп, тәмуг фәрештәләредәй Маликовның ике ягында басып торган төрмә сакчыларына чыгып торырга кушып, мәхбүскә сынап-сөзеп карый. Арык гәүдәсе аша рентгент нурлары үткәрә диярсең. Исәнләшеп, фамилия-мазар сорашып торуга вакыт әрәм итмичә, тәҗрибәле тикшерүче үгезне мөгезеннән алырга була.

— Тәк... тәк... Кем Маликов, взятка биреп котылмакчы булдым, дисең инде алайса? Безнең гаишниклар андый түгел. Осечка чыккан. Күпмерәк тәкъдим иттең инде?

Мондый текә борылышны көтмәгән, татар кешесенең үзен башкачарак кабул итүенә әзерләнгән Мисхәт югалып-төртелеп кала, ни әйтергә, ничек җавап бирергә белмичә, песнәк баласы мәсле, авызын яртылаш ачып, аптырап басып тора. Ул әүвәл Казан, Татарстан хәлләре, һава торышы, кайда укуы, гаиләсе турында сораштырулар көткән, һич югында, энем, нәрсә булды анда синең, түкми-чәчми, дөресен сөйләп бир,— дип сорашыр, Мисхәт ихластан сөйләп биргәч, үзенең нәтиҗәсен ясар: «Мин нәкъ шулай фараз кылган идем, изге ният белән юлга чыккансың, туган җанлы егет икәнсең, менә бу кәгазьгә кулыңны куеп, штраф кереп түлә дә, юлыңны дәвам ит», кебегрәк аңлашуны көткән иде.

Прокурорның бернинди өмет, таяныч, дөреслек вәгъдә итмәгән сүзләре миенә үтеп кергәч, егет югалып кала. Аңлатырга тырыша.

— Юк, абый, мин бернәрсә дә тәкъдим итмәдем. Барысы да ялган,— дип, сүзен татарча башлаган Мисхәтне хуҗа тупас итеп бүлдерә.

— Никакой мин сиңа абый. Тамбов бүресе сиңа абый. Синең алда Россия Федерациясенең дәүләт прокуроры утыра, гражданин Маликов.

Хөкем әһеленең ата-анасы шивәсендә сөйләшүне кабул итмәве, хәләхвәлне сорашмавы Мисхәтнең баягы беркатлы өмет-ышануларын иртәнге рәшә төсле юкка чыгара. Тоткын аның ата-анасы телендә лыкылдый башлагач, хәтта як-ягына, кара дермантин белән тышланган ишеккә каранып ала. Прокурор эш бүлмәсендә генә түгел, гупчим рәсми дәүләт

тelендә аралашырга тиеш. Гомумән, ул берише татарларның азатлык, мөстәкыйльлек дип, авыз суларын корытып йөргүен кабул итми. Инкыйлабка чаклы бүленеш дөрес булган: Оренбург губернасы, Уфа, Казан губерналары... Милләт ул — тышкы бер алдавыч, фикция. Берәүләр: «Мин халкымны яратам»,— дип лаф ора, ә Хәсәншин, мәсәлән, таштан уелган өй җиһазын ярата. Аларда хет чал тарих җилләрен, заманалар бәйләнешен тоясың, яшәешнең мәңгелеген һәм, ахыр, суыклыгын сизәсең. Кеше үз шәхси бәйсезлеге, тәмле ашау, йомшак мендәрдә йоклау, престижлы зыяраттә күмелү өчен көрәшергә тиеш. Совет власте һәммәбезне тигез дәрәҗәгә куйган иде. Әйтик, аның әтисе 30 нчы елларда казакъ даласында көтү көткән, ә улы — прокурор. Дөрес, ул атасы вафат булуга, хатынының киңәше белән, Хисмәтулловичны паспортында Харитоновичка алыштырды. Интернационализм үрнәге күрсәткәне өчен, бер атнадан яңа йолдыз өстәделәр.

Маликов, сүз дә юк, чибәр, яшь егет, юләрлеге белән килеп капкан. Аның бәхетсезлегенә каршы, өлкәдә соңгы өч елда ришвәт алу, бирү маддәсе буенча бер эш тә каралмаган икән. Мәскәү бу җитешсезлеге өчен өлкә хөкем оешмасына бармак янаган: «Карагыз аны, сез йә үзегез взяточниклар, йә юк белән шөгыльләнеп, туннан бет чүпләп утырасыз...».

Тәҗрибәсез, яклаучысыз яшь егетнең өстенә нинди чүп-чар өйсәң дә, ышаначаклар. Татарлар элек-электән бу шөгыльгә маһир булганнар. «Татарин ГАИ хезмәткәренә зур сумма акча тәкъдим иткән, безнең данлыклы милицияне сатып алырга ниятләгән» дисәң, берәү дә шикләнмәячәк. Әгәренки аны, шул җинаяте өчен татарин прокурор акласа, олы җәнҗал чыгуы бар. Ел ярымнан пенсиягә чыгасы...».

— Маликов, мин сиңа түкми-чәчми, дөресен сөйләп бирергә киңәш итәм. Ришвәт тәкъдим итүең хакмы?

— Бу гаепләүләрнең барысы да чеп-чи ялган.

— Беркетмәләрдә башкача әйтелгән, гражданин Маликов.

— Анда язылганнарның бер сүзе дә дөреслеккә килми. Чакырыгыз гаишникларны, барысын да күзләренә карап сөйләп бирәм.

Прокурор кәгазьләр өстендә яткан күзлеген бер күтәреп, янәдән кискен рәвештә төшереп, мәче күзләрен почмакта торган култыксалы урындыкка юнәлтте. «Шунда утыртып, астан ток җибәрәсе үзенә. Юк гөнаһларын да таныр иде».

— Алдашасың, Маликов. Үзең әле югары белемле икәнсең. Җитмәсә, тарихчы. Оят.

— Паспортны бумажниктан алганда өстәлгә юлга алынган вак-төяк акчалар чәчелде.

— Минем әкият тыңлап утырыр вакытым, теләгем юк. Менә бу таныкнамәгә кул куйсаң, бер айдан чыгарырбыз,— диде Марат Харитонович, ышандырырлык, алдан уйланылган, кырыс вә басынкы тавыш белән.

— Мин бу гаепләүдән баш тартам. Барысы да ялган, нахак,— диде Мисхәт, җирле татар кавеменең үзен яклаячагына тәмам өметен өзеп.

— Маликов, бу сезнең имзамы? — дия-дия, прокурор артын урындыктан аерды. Мәче күзләр Мисхәтнең имзасына кадалды.

— Минеке,— дип, танырга мәҗбүр иде Мисхәт-Миша.

— Шулай булгач, ник минем миемне черетәсең,— диде Марат Харитонович, бу юлы аталарча йомшак, назлы, иркәләүле тавыш белән.

— Хәзер мин сезгә барысын да аңлатам,— диде Мисхәт, тавыш дулкынының үзгәрүенә сөенеп.— Мине милиция бүлегендә ифрат каты кыйнадылар. Кулларымнан түшәмгә элеп куеп. Сусыз интектерделәр. Аңыма килгәч, янәдән тукмадылар. Имзамны куйганчы газапладылар. Мин аңгы-миңге хәлемдә идем. Төшемдә күргәндәй. Хәзер мин ул күрсәтмәләремнән катгый рәвештә баш тартам.

Прокурор, кара өсле, олы өстәле артыннан, бүлмә уртасында басып торган Мисхәт янына, сугып җибәрердәй булып, йөгереп чыкты. Бармак янады, мәче күзләрен елтыратып, кычкырына башлады:

— Әле син Оренбургның хөкем оешмаларына яла ягасыңмы? Оятсыз. Ялган, әләк тараткан өчен ике-өч ел өстәрләр сиңа, Маликов. Минем үтенеч буенча.

Мәхбүснең күңелен салкын чарасызлык биләде. Аны аңларга, тыңларга теләмиләр. Хәтта менә бу — татар фамилиясен йөрткән абзый да. Ачык тәрәзәгә карап алды. Өченче кат. «Аска сикерсәң, скандал күтәрелер, чын-чынлап тикшерерләр иде, бәлки. Соң аннан сиңа ни файда. Зурлап күмәрләр ди, туган иленә апкайтып. Кыйнаганнарына ун көннән артык узса да, ямьсез, шыксыз каралыгы сакланган тәнне күрсәтергә кирәк бу мөртәткә. Безнең милициядә кыйнамыйлар, дип бара бит, барысын да белә торып».

— Ышанмасагыз, карагыз,— дип, кискен хәрәкәт белән чәчәкле күлмәген изүдән аерып җибәрде, борылып, аркасын күрсәтте.

Әлеге манзара прокурорның ниятенә керми иде, бугай. Йөгереп барып чыгу ишеген ачты, сакчыларга: «Алыгыз бу бандитны, башка күземә күрсәтмәгез»,— дигән әмер төшерде.

Мисхәт мәче күз, йөнтәс озын кул белән артык очрашмады. Дөресе: шуннан соң гүя аны оныттылар, җавап алуга да, судка да чакыручы булмады. «Бераү төрмәдә ришвәт маддәсе буенча утыра»,— дип, үзәккә информация бирделәр дә, тынычландылар. Сизгерлеге, уяулыгы өчен гаичы Давлетгареев акчалата премия алды, погонына бер сызык өстәлде.

Ялланган яһүд адвокат кына нәрсәдер кылган, кемнәр беләндер очрашкан булып мәтәште. Мисхәт Маликов белән хөкем оешмалары арасын дөньяның иң олы хуҗасы — акча килештерергә тиеш иде. Бусы инде, маңгаена «клеймәсе» сугылган, закондагы карак кебек, «рәсми» ришвәт булырга тиеш иде. Ул хәтлесен Маликов соңарып кына белде.

## 21

Каршысында утырган җанлы матурлыкка, табигать бизәгенә хәйран калып, бер караганда, гади, якын, кадерле, шул ук вакытта, серле, тирән кара упкындай күзләрнең балкышына буйсынган Сәет, ханымның кайнар кулын учына алды. Күңелен дөрләп кабынган хисләр ялкыны биләде.

— Син бик матур икәнсең, Фәридә. Шуны беләсеңме?

— Хатын-кызга артык матурлыкның хаҗәте юк.

— Ни өчен шулай уйлыйсың әле син, сөеклем?

— Безнең җенеснең матурлыгы — аның бәхетсезлегенең башы, ул — туйда гына кирәк, диләр. Чибәрлеге белән һич кенә дә мактана алмастай, май сөртеп бирмәсәң, мәче дә яламастай таныш, дус-иш кызларым, кияүгә чыгып, ирләрен теләгәнчә биетеп, кол ясап, рәхәтләнеп, типтереп яшәп яталар. Яшьлегендә гүзәллеге белән масаеп йөргәннәрнең күбесе, гафу ит, минем көнгә калды.

— Үзеңне рәнҗетмә әле! Күңелем сизә ки, син дөньяда иң бәхетле хатыннарның берсе булачаксың,— дип, вәгъдә бирүдән тартынып тормады Сәет.

Фәридә, бу вәгъдәгә ышанасы килеп, эре «карлыганнарының» яктысын алдында утырган иргә юнәлтте. Тик керфекләре хуҗабикәләрен тыңламады, күбәләк канатлары кебек, аска-өскә җилпенде. Салмак борылышлы кашлары кечтеки сырлар белән бизәлгән маңгай белән күзләр арасында элемтәче, килештерүче вазифасын башкардылар. Килешле түгәрәк борыны, тойгылы иреннәре, ак тигез тешләре битараф: алар бу уенда катнашмый.

— Хатын-кызның тышкы, ялтыравык сылулыгы — үзе бер бәхет дип саный идем мин.

— Аның белән йоклаган ирләр өчен,— дигән аңлатманы колагына элде кыланчык ир...

— Татар хатыннарының иң күренеклеләре башка милләт ирләренә эләгә шул,— дип, Сәет сөйләшүне кинрәк җирлеккә күчерергә булды.— Алар — галәм түшәге. Чөнки синең татарыңа горурлык, милли үзаң җитешми.

— Хикмәт башкадарак, минемчә. Хатын-кыз табигатькә якын, хыялый халык. Гаилә, тупылдап идәндә йөгереп йөргән кечкенә тәпиләр, кишер, чөгендер, суган, бөтнек түтәле аның өчен милли аерма-уртаклыкларга караганда кадерлерәк, якынрак. Без, күрәсең, тумыштан интернационалистлар. Без — женси тартым колы,— дип, Фәридә хатын-кызның асылын аңлатырга тырышты.

Катнаш никахларны бер дә хупламаган Сәет усалланды.

— Татар кызы — булачак иренең милләтенә карамыйча, аның кочагына ташлана һәм соңыннан инде, иренең, дәресрәге, балаларының кавемен якларга мәҗбүр була. Казанда гына күпме шовинист, безнең халыкны сукырларча куралмаган ирнең хатыннары татар нәселеннән, көндез, эшендә ул безнең ирләрне кыса, сыта, ә төнен — хатынын, шул ук милләт вәкилен, ятагында изә. Беришесенең күңелендә татарлыгы яшәсә дә, үз язмышына буйсына. Аңа — курку, өркү, көчлегә баш ию хас. Барысы да милли узаңның үсеп җитә алмавыннан килә. Татар халкының гасырларга сузылган фаҗигасенең төп сәбәбе шунда, дип саныйм мин. Милләтнең киләчәге хатын-кыз карынында хәл ителә. Ул тапкан олан нинди булыр?

Үлемнән чүт-чүт исән калып, хәзер халкының язмышы турында борчылып, хәтта тирәнтен кичереп утырган Сәет, Фәридәнең абзасының олы җәмгыяви фикерләренә битараф калуын аңлады. «Без монда күпме генә сайрашсак та, чәпчесәк тә берни үзгәрмәячәк. Зоя булып киткән Зөһрә иртәгә барыбер Иван белән языльшачак, Нәфисә Андрейның озын муенына карасу кулларын салачак, агылҗым чәчләрен сыйпап, йокыга талачак, кичке мәҗлестән соң Гүзәл Серега куенында калачак»,— ди иде аның күз карашы.

— Ә менә мин,— диде Фәридә, гади генә итеп,— синең яныңда үземне иң чибәр, иң бәхетле хатын итеп сизәм, хәтта көнләшәм. Кемнән дисеңме? Үземнән.

«Артык җитди булып киттем әле» дип, үзен битәрләп, ир-зат уенны кабул итте.

— Әйт әле, Фәридә, синең буадан упкынга сикертерлек, шашкын, тиле мәхәббәтең булдымы?— диде Сәет, авыр әхлакый-фәлсәфи уйларыннан арынганына сөенеп.

Ханым, кыскалык үрнәге күрсәтеп, үбешүдән кызышкан иреннәреннән бер генә иҗек кысып чыгарды: «Әйе».

— Кем иде ул шундый бәхетле, оҗмах кошы?— дип, кытыгы килсә дә, ваемсыз булырга тырышты Сәет.

— Ул син, Сәет иптәш. Бик беләсең килсә. Минем әти: «Күп белгән күкенең башы авырта»,— дип, кабатларга ярата иде. Бәлки, күңелемдәген әйтеп ялгыша торганмындыр?

— Ә ни өчен ялгышасың була инде? Үкенәсеңме?— дип төпченде бәйләнчек ир.

Фәридә, кара күзләреннән нур көлтәсе балкытып: «Мәхәббәт ул учак төсле, коры утын өстәп торганда гына дөрләп яна ала»,— дип әйтеп ташламасынмы.

— Гомер буе учак яндырып кына яшәп булмый торгандыр?— ди-ди, шигә белән уртаклашты көчле токым вәкиле.

— Күмерендә бәрәңге пешерербез,— дип, Фәридә бәхәскә нокта куйды.

— Синең белән бәхәсләшүе кыен, матурым. Син — олы сәясәтче.

— Син әле чирле. Катлаулы сораулар бирмәскә тырышам. Борчылу кебек үк, артыгын уйлау кешене иртә картайта, үтерә.

— Риза түгел. Кешене кеше үтерә!

— Кеше үк терелтә дә,— дип, Фәридә үзенә мәдхия бакчасыннан чәчәк бүләк итәргә булды.— Адәм баласының асылын аңлавы кыен. Ул аны бик тирәнгә яшерә белә.

— Бу тәнкыйть миңа карыймы?

Җавап көтелмәгәнчә булды.

— Юк, миңа карый.

Бәхәстән арыган Сәет Фәридәне ярсулы кочагына алды.

Фәридәгә якынайган саен, Сәет шәфкать туташының үз-үзен тотышында, тыңлаучан бирелгәнлегендә, ярарга тырышканда да, эчке мөстәкыйльлеген, «мин»ен саклый белүендә Зөлфияне хәтерләткән, мәрхүмәсенә якын чалымнарны таба башлады. Һәр чагыштыру, тиңләштерү бер аягына аксый, диләр. Бу уртаклык — җәйге көн төнгә күчкән, саба җиле караңгылыкны тараткан, шәмдәлләр төбенә төшкән күләгә кебек, сиздермичә, салмак талгынлык белән туа, югала, тагын калкып чыга. Рәшә төсле. Икесе дә хатын-кызга алиһәлек сыйфатлары сирпегән тышкы уртак бизәкләргә ия. Йомры тез башлары, күкрәкләрне, көндәшлек итмәсеннәр дип, аерып торган сихәт елгачыгының күркәмлеге, билләрнең, тормыш вә баллы ризык басымына бирешмичә, нечкәлекләрен сакларга омтылышлары, хәрәкәт көязлеге арасында якынлык зур. Шул ук вакытта аерма — җир белән күк арасы. Зөлфиянең күгелҗем-яшел күзләре янында Фәридәнең өлгергән кара карлыганнары, янган каен күмере төсле, аерылып тора. Шуның өстенә соңгысының саргылт тиресе, буйсынмас, каты чәчләре үзгәлекне тагын да арттыра төшә.

Сәет һәр мәхәббәте арасында рухи охшашлык сизде. Көчле, дәртле, ялкынлы иде аның һәр гашыйк булуы. Ул хатын-кыз белән беркайчан да файда-мәгънә эзләп танышмады, очрашмады, йокламады. Үз-үзен белештермичә, сукырларча бары тик Зөлфияне генә яраткандай тоелса да, акрынлап Фәридә аның бөтен барлыгын биләп алды, судан алып утка салды. Ул үзенә рухи терәк итеп, Туфанның теге вакытта Әлфиягә укыган «Әйткән идең...» шигырен алды.

Җитмәсә Фәридә, аның таң йолдызы кебек үк, әхлакый темаларга сөйләшергә, гәп корырга маһир, араларны ачыкларга ярата икән. Дөрес, артык тирәннән сукалаган юморны кабул итми, Зөлфия кебек, беркатлы ышанучан, хәйләсез, саф күңелле дә түгел иде бугай шәфкать туташы.

— Без якыннарыбыз, туган-тумачаларыбыз, үзебез турында нәрсә беләбез? Яшьлек хыялларыбызның кайсылары тормышка ашкан? — кебек сорауларны Фәридә үзалдына уйланып, сөйләнеп утырган кыяфәттә бирергә ярата. Йөзе сагышлы. Йөгереп барып үбәсе килә үзен.

Сәет читкә алып китү, киная, шаярту алымын иярли. Шаярту — киеренкелекне алырга, тауны әйләнеп үтәргә мөмкинлек бирә.

— Күп белгән тиз картая, дип язылган «Йосыф» китабында.

— Белсәк нишли алабыз, аңа карап бәхетебез ишәяме, гомеребез озаямы?

«Сүздә барыбыз да изге, пәйгамбәрләр шул. Сораулары катлаулы мәгънәле, четерекле. Ул мине исән, тулы кыйммәткә ия кешегә санап, эч серләрен сүтеп утыра. Афәрин, Фәридә. Үзем дә башын катырыйм әле асыл гөлнең».

— Ә мәхәббәт агачының кайчан чәчәк атасын, кайчан корып, сынып төшәсен белеп буламы?

— Мин исәп, акыл, зиһен кушуы белән яратып булмаганны тәгаен беләм. Үз башымнан үткән хәл.

— Акыл белән чит-ят иргә бирелеп була,— дип кысылды торма тел.

— Мәхәббәт шартлы киртәләрне, чикләрне, язгы ташкын кебек, җимереп үтә торган хисси шашкын, тиле көч булырга тиешме һәр очракта да, син андый мәхәббәтнең яшәвенә ышанасыңмы, Сәет?

— Унҗиде-унсигез яшьләрдә булуы ихтималдыр. Романтик әдәбиятта... аннары.

— Син... үлгән хатыныңны шулай яраткан диләр?

Сәет, ирексездән, күзенең агын әйләндереп, усал итеп карап алды сорау бирүчегә. Каны саркып торган ярага орынырга бирәүгә дә рөхсәт ителми. Бәхәскә кереп, нәрсәнедер раслап, инкяр итеп утырасы килмәде. Бу темага табу салырга булды.

— Мәхәббәт кешегә бәхет алып килә ала. Тормыштан биздерүе дә мөмкин.

Фәридә җайсыз сорау биргәнен аңлады. Гомуми җавабы өчен иргә рәхмәтле. Акыллы кеше белән эш итү ансат.

— Мәхәббәт ул — яраткан кешеңне шәхес итеп тану, аның барча булмыш — ходай бирмеш сыйфатларын хөрмәт итү, бер-береңне җенси аңлау, кичерә белү. Ярату — күңел баглану,— дип, Сәет хатынның барлык сорауларына берьюлы җавап бирергә тырышты. Фәридә сөйләшүгә яңа юнәлеш бирде.

— Кичә мин, синнән кайткач, бик озак йокыга китә алмый яттым. Таң беленеп килгәндә генә, чүпрәгә тарган җылы камырдай изрәп киткәнмен. Төш күрдем.

Икесен дә катлаулы әхлакый аңлашулардан коткарган юнәлешне Сәет теләп кабул итте.

— Төшеңне бәян итәргә керешкәнче, бер сорау.

— Рәхим ит, әфәндем!

— Иртәнге төшнең раска килүен беләсеңме?

— Беләм.

— Мине начар күргән булсаң, сөйләмәвең хәерлерәк.

— Төшнең киресе дөрескә чыга дип тә ишеткәнем бар. Тәк вот. Мин мул сулы елга буйлап атлыйм...

— Миннән качыпмы — берүзеңме? — дип бүлдерде Сәет. Зөлфияне шулай ирештереп, тәм таба торган иде. Теге чабалана, үпкәли, ачулангандай итә. Медикларның нерв күзәнәкләре тирәндәрәк утыра икән. Керфеген дә какмады.

— Карыйм, судан бер баш йөзеп килә. Чәче ап-ак комга баткан. Бераздан гәүдәсе дә күренде.

— Ул адәми зат мин идемме? Бальниста үлгәннән соң...

— Куркып уянып киттем. Тиз генә киенеп, машина алып, синең янга килеп җиттем. Рәхәтләнеп, тәмләп, гырлап йоклап ятасың. Шулчаклы сөендем... синең теге мәет булмавыңа. Шунда үзеңне чын-чынлап яратканымны, минем өчен дөньяда иң газиз кеше булуыңны аңладым. Курку — хисләрне ачыклап җибәрә, «аңлатып» бирә ала икән.

Сәет, урыныннан торып, диванда ямь-яшел халаттан, аякларын татарча бөкләп, түгәрәк тез башларын «урамда» калдырып утырган Фәридә янына килеп, идәнгә чүгәләде. Ярылы, гасабилы уйлар, шик-шөбһәләр, үкенү-сораулар белән тулы, ак ком сибелгән башын хатынның итәгенә салды.

— Яшисе килә, Фәридә. Синең белән...

Фәридә Сәетнең битен кайнар кулларына алды. Ирнең йөзе бу мизгелдә үзенә тартып торучан, илаһи һәм ниндидер нур сирпеп тора иде. Ярым йомык күзләрендә, тоемлы иреннәрендә, муен җыерчыкларында хәсрәти рух дулкыны чайкала, назлы җаны, сизгер йөрәге, кайнар тән сулышы, үзен тәкәббер санап йөргән ханымны кол итә, ихтыярын сындыра алырлык иде. Буйсына белмәгән кешенең хуҗа була алмасын чамалый иде зирәк ханым. Башын тезләре өстенә салган ирне ул ярата, аның мәхәббәте табада чыжлап торган көнбагыш мае кебек кайнар. Бәяли генә белсен ир-зат.

Бәдәвилек тормышыннан туйган иде Сәет. Зөлфиясен күмгәнгә дә ике елга якын узган. Каядыр тукталырга кирәктер. Гомер узып бара...

— Безгә чын-чынлап бергә яши башларга вакыт түгелме икән?

— Минем үземнең дә өй хатыны буласым, бала үстерәсем килә. Безнең илдә ирсез хатын бозык, әдәпсез, фахишә санала. Гаиләле булуның аңардан гына тормаганлыгы, ике кешенең игелекле теләге булу кирәклеге исәпкә алынмый

Фəриданең бик тиз килешүен ир үзенчə юрады. «Син, күзле бүкəн, аңгыра, тинтəк, берни аңламыйсың. Хатынның просто кияүгə чыгып аласы килə икəн. Шул кысыр хəсрəтен тормышка ашыру нияте белəн, ул сине тəрбиялəп терелткəн, аякка бастырган. Хəзер син — аның шəхси милке. Приватизировать итеп куясы гына калды».

Бальниснын баш табибы да, саубуллашканда: «Фəриданең сезне аякка бастыруга керткəн өлеше бик зур»,— дигəн иде.

Катлаулы, каршылыклы хислəре күңелен кара мəчедəй тырнаса да, ул үз тəкъдименнəн баш тарта алмады. Җитди булмас иде.

— Кайчанрак, Фəридə, сине күчерəбез инде. Кирəк дисəң, сразы языльшырбыз.

Шəфкать туташы, урыныннан торып, тəрəзə янына барып басты. Җитди карар кабул иткəндə, аның яктылык белəн «киңəшү» гадəте бар иде.

— Мин хəзер үк сиңа күчеп килə, тормышка чыга алмыйм, Сəет. Ачуланма.

«Игелек» хуҗасы берни аңламый. Шаярта,ялынуны көтə, бəясен күтəрə, дип фараз кыла.

— Ни өчен? Нəрсə булды?

— Берни булмады. Соңрак. Əйдə, синең урынның йомшаклыгын тикшерик тə мине озатып куярсың.

Мондый татлы очрашулардан соң да Фəридə Сəетнең «бергə тора башлыйк»,— дигəн тəкъдименə уңай җавап бирергə ашыкмый. Араларында ул белмəгəн сер, күтəртмəле бусага ятуны сизенгəн Сəет шəфкать туташы белəн ешрак күрешергə, күбрəк аралашырга тырыша. Аны аз белгəн кешелəргə ханым йомык, үз эченə биклəнгəн, авыллыгы чыгып бетмəгəн булып күренергə мөмкин иде. Холкы шундыймы, əллə ачы тормыш тəҗрибəсе өйрəткəнме, Фəридə урам телбистəлəре төсле, телəсə кем алдында ачылып китəчəк түгел. Кеше синең кабул итүеңə, күңелеңə, җаныңа ни рəвешле килеп керсə, аны шулай тəкъдир итəргə кирəктер.

Чынында Фəриданең хəллəре шактый катлаулы, хəтта мөшкел иде. «Ике ут арасында калдым» дигəн гыйбарə яши. Шəфкать туташының əхвале тагын да кыенрак икəнен ул үзе генə белə. Бу хакта берəү белəн дə киңəш-табыш итеп булмый. Əле бит ике утның берсен сүндереп, һич югында сикереп чыгып була. Кайсы җиреңдер аз-маз янар, көяр, өтелер. Туйга чаклы төзəлер!

Сəеткə ул күрəалмау, ачы нəфрəти дошманлык аша гашыйк булды. Үзе өчен аякка бастырды. Үсə, камиллəшə килгəн мөнəсəбəтлəре күплəрне көнлəштерерлек. Арага Нургали Ваһаповның җирəн сакчысы килеп кермəгəн булса, Фəридə инде күптəннəн Сакманов өенə күченеп килер иде. Җирəн ир, явыз иблис, дəҗҗал, көчне, куəтне үзенə суырып ала торган убыр төсле, гел үзенə кирəк булган вакытта килеп чыга. Авыр язмыш, кара тəкъдир төсле. Теге вакытта Фəриданe коткарды, əмма үзе үк ханымның фатирында йоклап калды. Ярым мəет Сəет Сакмановны хастаханəгə китереп ташлаган көнне үк, Җирəн ир ишек төбенə сакка килеп басты. Һəртөрле юллар белəн җаен табып, берничə тапкыр Фəриданe көчлəп диярлек алды. Ханымның фикере, каршы килүе белəн һич санашмый. Аңа кирəк, бетте...

Əүвəл Җирəн, үзе үк, Сəетне аякка бастырырга кушты, ə инде хатынның чирле-морлыга битараф булмавын сизенгəч, шəфкать туташын кисəтə, куркыта, үбешүлəрен күргəч, ысылдый ук башлады. Фəридəгə ишектəн үтəргə бирми, Сəетнең игътибар күрсəтүен, бармакларын кулына алуын, тезлəренə кагылуын күрсə, имəн күмере салынган самавырдай, котырынып кайный башлый.

Фəридə үзендə Җирəнгə нисбəтəн бернинди хис, тойгы сизми. Җаны, тəне бер якка тарта, ə җил коймəне икенче ярга этəрə. Араларны кискен рəвештə өзəргə җөрьəт итми, үзеннəн дə бигрəк, Сəет өчен курка. Бер көнне ул хатынны өе янында саклап торып, «аны ташламасаң, йөрəгемə

җәрәхәт ясасаң, мина хыянәт итсәң, үтерәм сине дә, аны да» — дип, явызланды. Аяк астыннан килеп чыккан җирән афәт, тәкъдир, күрәчәк язмыш кебек, Фәридәне эзәрлекли, бәхет калачын, агач корты кебек, эчтән кимерә. Ханым — аптыраштa, Сакманов берни аңламый...

## 22

Туйлар үткәреп, балага узгач кына, Әлфия Мисхәткә чын-чынлап гашыйк булганлыгын аңлады. Чаткыдан янгын үрләде, ялкын бөтен барлыгын биләде. Шул ук вакытта ул айга карап уфырып, йолдызлар санап утыра торган кеше түгел иде. Аның холкында, мәсләгендә туган хыялый дөнья тормышчан тупсага утыртыла. Рухында, җанында шыткан омтылыш-ниятләрен ул гамәли җирлеккә күчерә барыр. Ясаган хаталарына үкенә белеп, кайгы-хәсрәтләрен яшьлеккә хас булганча, тиз онытып, яңадан бәллүр кальгалар кору шөгыленә керешер. Омтылышлы холкы, тәкәбберлек тузы, максатлы яшәүгә омтылышы аны гел алга, билгесезлеккә әйди.

Хыялында йөрткән «принцы», өлешенә тигән көмеше Мисхәт-Миша булып чыкты. Ире әле балавыз, аңардан теләсә нинди сын, рәвеш әвәләп булачак. Элек Әлфия кызларныкыдай нечкә тиреле, сакал-мыек авырлык белән үскән йөзле, дөньяга сәерсенеп карау сәләтен югалтмаган Маликовтан хыялында Сәет Сакманов тибындагы кеше «ясады». Күзләреннән явызлык, бәйсезлек рухы бөркелеп торган Мисхәте чем-кара йон кәстүмнән, җиңнәре алтын сәдәпкә утыртылган ап-ак күлмәктән, кара ялтыравык туфлидән мерседеска чыгып утыра. Эрелегенә, һавалы карашына шаклар катарсың. Санамыйча тыгылган акча көлтәсе күкрәген төртеп тора. Кыскасы, Әлфия Мисхәте кеше гомерен өтәч канына да санамаган мафия башлыгы... Бу ягы бата. Әгәренки, җан тынычлыгы килмәсә, аның үзен дә Зөлфия язмышы көтсә... Ханымның йөрәге жу итеп китте. Юк, юк, бу Ленин бабай сызып калдырган, якты киләчәккә илтә торган юл түгел... Күңелендә, хыялында бердәнберен төрле кәнәфиләргә утыртып, аңардан әлләкемнәр ясап бетерде. Берсе дә батмады. Төпле, хисне үзенә буйсындыра алган акылы өстенлек алды. Ул — галим булырга тиеш.

Шул арада Мисхәткә Ырымбур эпопеясын үтәргә туры килде. Ул үз теләгеннән башка дала якларыннан әйләнеп кайтканда, Әлфиясе аның киләчәк үсеш юлын билгеләп куйган иде инде. Маликов кесәсендә тарих факультеты дипломын йөртә ич. Начар укымаган. Ни өчен әле ул тулы, түгәрәк гәүдәле, чәчләрендә бөдрәле чоры чалымнары сакланган, кычкырып сөйләшергә, дөньясын онытып, шаркылдап көләргә яраткан, кешеләргә гел яхшылык теләгән профессорга аспирантурага кермәскә тиеш? Җөмләләрен, хаталарын үзе төзәтер! Кичекмәстән, нәкъ әбисе өйрәткәнчә, шулпалы, итле милли пәрәмәчкә чакырырга булыр татар халкының мөхтәрәм затын. Бернинди «баганалы» уйсыз, болай гына, диплом җитәкчесе булган өчен, рәхмәтле булып кына. «Кешеләр бу языклы дөньяда гел очрашып яшәргә тиешләр», — дип кабатларга ярата иде сөекле әбисе.

Төрмәдән исән-имин кайтып, сөякләренә ит кунгач, инде нәселләрен үрчетер көннәре якынлашып килгән Әлфия хыялый серен чишкәнче, иренә шактый сырпаланды, ялагайланды. Карга авызындагы сырны алдап-йолдап җиргә төшергән төлкең бер якта торсын.

— Оят булса да әйтим инде. Син минем Мисхәт исемле йолдызым гына түгел, син — аллам минем.

Әле берни аңламаган ир, иңбашларын турайтып, кукыраеп, гайрәтләнеп алды.

— Рәхмәт, Әлфиям. Аның ни оялы бар?

— Сине Ходай тәгаләбез минем бәхеткә яраткан.

— Мәхәббәтебезне сынап карау өчен башын төрмәгә тыгып алган...

Әлфиянең түбәнгә, гадәти кешеләр таптап йөргән туфракка төшәсе килми.

— Мин уртак бәхетебезнең түм-түгәрәк булуын телим. Син, Аллам, минем бер үтенечемне үтәргә тиешсең!

Мондый сүзләрдән боламык кебек изрәп, таралып беткән Мисхәт хатынының — кыр кәҗәсенең теләсә нинди кәпризен үтәрлек хәлгә җиткән иде.

— Син аспирантурага укырга керәсең, күренекле галим буласың!

Көтелмәгән тәкъдим, уйламаган борылыш. Теге карышкан булды.

— Әлфия, мин хәзер Сәет Ярулловичны ташлый алмыйм. Мин аңа мәңге бурычлы. Мине йолып алуга аның күпме сәмән вә мани түккәнен чамалыйсың булыр.

— Кем сине остазыбызны ташларга чакыра. Тузга язмаганны.

— Соң аспирантурага керсәм, дөньямны онытып, архивка, фән базына кереп чумарга тиеш булам. Бу эш көнне-төнне кушып, үзеңне кызганмауны таләп итә,— кебек, Әлфия өчен җитди булмаган дәлилләрен тезеп китте.

Иренең гыйльми тирәнлеккә дәгъва итә алмавын, дипломындагы бишлеләрнең «ясалма» икәнен, мәгарәгә кереп утырудан куркуын аңлый ханым.

— Без икәү, Мисхәтем, барысын да җиңеп чыгарбыз. Сәет Ярулловичта да хезмәттә калырсың. Аспирант, хәтта кандидат акчасына да яшәве кыен. Тәвәккәлләдек.

Ике көннән соң, Әлфия кыз бала тапты. Зөлфия дип атадылар. Бәбәй туена Сәет Сакманов белән профессор Рамил Вәлишин генә чакыру алдылар.

Ирләрне таныштыруны Әлфия үз өстенә алды.

— Сәет Ярулловus, таныш булыгыз, Мисхәтнең фәнни җитәкчесе, диплом эшен яздыручы — Рамил Кәримович Вәлишин. Күренекле галим, профессор.

Дамелля үзен мактауга, олылап тәкъдим итүгә бер дә исе китмичә, кулын Сәетнең учына тыкты да, һәртөрле салатлар, тәмләткечләр белән бизәлгән, коньяк, аракы, шампан шәрабе, сулар белән тулы әгъла өстәлне бәяләп, түр башына узды. Урманның эченә үтәргә мөмкинлек булганда аның кырыенда, әрәмәлектә вакыт уздыру тарафдары түгел иде Вәлишин. Кыз алып кайтканнан соң, тәне таң нурларыдай гүзәлләнеп, пакъләнеп киткән, күкрәкләре күлмәгенә сыймас булып калыккан, үзеннән яңа туган бала исе килеп торган Әлфия киләчәктә тук яшәешләре өчен иң хаҗәт кешеләрне өенә китерә алу шатлыгыннан йөгерепме йөгерә. Үзен кая куярга, ничек тотарга белми интеккән Мисхәт әллә бар аңа, әллә юк...

Үзен нарасый «тәпиен» юу уңае белән генә чакырылган дип юраган беркатлы фән әһеле Әлфияне белеп бетерми иде әле. Әдәп, гадәт вә әхлак тәртипләрен яхшы тота хуҗабикә. Профессорның олуглыгын һәм аларда кунакта беренче тапкыр булуын (Мисхәтнең диплом яклавында танышканнар иде) искә алып, игътибардан беренче өлешне аңа чыгарса да, матди тормышлары, киләчәкләре кемнән торганны да ханым тәгаен белә иде.

— Сәет Ярулловuc Сакманов, безнең якын кешебез. Рәхмәтебезнең чиге юк аңа. Мисхәтне тормышка, яшәргә өйрәтте. Минем вакытсыз вафат булган, иң кадерле, эч сердәш дустымның ире.

Йомылып кына утырган профессор, олы башындагы озын чәчләрен селкетеп алып, кечкенә коңгырт күзләрен Сәеткә текәде. Карале син аны, бүлмәдә тагын бер, җитмәсә чит-ят кеше бар икән ләбаса. Сорауны ирнең үзенә юнәлтмәде, Әлфиягә бирергә булды.

— Хатыны чирләп үлдеме?

Хуҗабикә сөальгә туры җавап бирүдән тайчынып, әмма бу темага кагылуына һич кенә дә үкенмичә, Зөлфияне мактап, такылдап китте.

Нәтиҗәсен дә ясап куйды: «Шундый инсафлы, гүзәлләрнең гүзәле, якын дустым хөрмәтенә кызыбызга Зөлфия дип куштык».

Чакыру-мазар көтеп тормастан, өстәлдәге нигъмәтләрдән авыз итә башлаган профессорның күңеленә килгәнне әйтми калдыра торган гадәте юк иде, күрәсең.

— Соң сез атаклы мафия башлыгы Сакманов буласыз түгелме?

— «Мафия» сүзе безнең илгә читтән, дөресе, Италиядән күчереп утыртылган. Язарына башка азык таба алмаган журналистлар уйлап тапкан уйдырма. Акыллылар тәмугта да җайлырак яшәү җаен таба, диләр. Шул гына. Тарихны теләсә ничек язып була, ә тормыш кануннарын үзгәртүе кыенрак,— дип, Сәет сорауга туры җавап бирүдән читкәрәк китте.

Профессоры да бәйләнчекнең тәҗрибәлесе, өрми тешли торганы булып чыкты.

— Ишеткәнем бар, сезне Казанның рәсми урын биләмәгән иң бай кешеләренең берсе, диләр? Дөресме?

Сәет үпкәләмәде. Кеше күбрәк укыган, озаграк яшәгән саен сабый бала халәтенә әйләнеп кайтканны чамалый иде. Талгын тавыш белән аңлатты.

— Байлык бит ул бүген бар, иртәгә юк. «Мин өмиднең сул кулыннан Бер сынык нан алмадым»,— дип язган Дәрдмәнд бабабызның артында алтын приискалары торган. Ата-анамнан калган мирасым булып, киләчәге ышанычлы илдә яшәсәм, мин дә үземне башкача тотар, күтәрмә ак якага «кара чикерткә» тагып куяр идем дә, өстән аска карап, гел акыллы киңәшләр биреп йөрер идем. Безгә, мин житәкчелек иткән ширкәткә, кул белән чәчкәнне капчык белән җыярга туры килә. Рәтле-путьлы яшисең килсә, кырмыскалар кебек, йокы турында онытасың инде.

Профессорның күңеленә җавап хуш килде бугай. Бу ясcылыкка кире чыкмады. Мәгәр бик кызыксынучан кеше икән. Сорауларны бозлы яңгыр кебек тондыра.

— Кешенең эчке иреге нәрсәдә, дип уйлыйсыз?

— Иртәгесе көн өчен курыкмыйча яшәүдә.

— Үзеңә-үзең хуҗа булу, зур бәхет ул. Анысы өчен дә артыңда байлык торуы зарур,— дигән нәтиҗәсен ясагач, Рамил Кәримович сорауларны катлауландыра барды.

— Хакимияткә, җылы кәнәфигә адәм баласы байлык өчен генә омтыламы?

— Барысы да ходай кулында. Тырышкан улларына ул һәрдаим мәрхәмәтле,— дип, Әхмәдиша карт кебегрәк кенә җавап тотты Сакманов.

— Мин хакимият һәм карьера турында сорамакчы идем. Фикеремне ачык итеп әйтә алмадым бугай. Башка китте. Күптәннән эчкән юк иде,— дигән булып, кус кашларын уйнатып, элеккеге киноларда сурәтләнгән байлар чырае кергән, тулы яңакларын сыйпап алды.

— Без — хөкүмәт яклы. Ул — үзе дә яши, башкаларга да ирек бирә. Коммунистлар күбрәк үзләрен карадылар.

— Сәет Яруллович, син... шулай атыйм инде. «Сез» алмашлыгын җенем сөйми. Ничек диләр әле хәзер яңача. Нәзари яктан әзерлекле кеше икәнсең. Соңгы соравым: мафиягә элгү җинелме?

— Гариза язып караганым юк. Сезнең университетның юрфагына укырга керү белән бер кимәлдер, дип уйлыйм. Истфакка элгүе җиңелрәк дип ишеткәнем бар.

Профессорның шаркылдап көлеп җибәрүеннән өстәл биеде, түшәмдәге бәллүр люстралар, артыгын салган кешеләрдәй чайкалды. Авызын ачып тыңлап торган Әлфия бала йоклаган бүлмәнең ишеген ябарга элдерде.

— Ха-ха... Ну эләктердең. Ике дә бер — синең файдага.

Сәетнең янына килеп, учын аның учына сугып алды. «Абзый — пижон, яшьләрчә, заманча кылана»,— дип, Сәет тә канәгать калды кичәнең башланып китүеннән.

— Әлфия бая дөресен әйтергә яхшысынмады. Яраткан хатынымны үчлеләр үтерде. Ятим калдым.

Елап туйган бала төсле, көрсенеп куйды.

Профессор тулы гәүдәсе өчен шактый сәер җиңеллек белән янә урыныннан торды, кулын Сәетнең җилкәсенә салды.

— Гафу ит, дустым.

— Һәркемнең үз язмышы.

— Татар халкы борын-борыннан: «Кешеләрдән кеше һич ким түгел, тик бәхеткәйләре тиң түгел»,— дип белми җырламаганнардыр.

— Хәсән Туфан бу хакта язып калдырган. Нәкъ минем рухи халәтем турында, диярсең!

Бирде дөнья кирәкне,<br>
Еламаска өйрәтте...<br>
Кайсыгызның кулы җылы?—<br>
Бәйлисе бар йөрәкне...

Үзен таба алмый утырган Мисхәт сүзгә катнашып китте: «Дөрес әйткән Туфан бабабыз, урыны оҗмахта булсын. Әйдәгез, кызыбызны дөньяга килүе белән котлап, янә берәрне күтәреп куйыйк».

Бу фикерне профессор әлегә игътибарга иң лаеклысы, дип тапты. Ул артык хисси дулкыннарны, куе, томанлы кичерешләрне, хакыйкый хәлләрдән читкә китүне өнәми.

Икенче буын Зөлфия исәнлегенә чәркәләрне күтәреп, тамакны ялгап, Мисхәтнең белемен дәвам иттерү юнәлешендә мәслихәтләшеп алгач кына, Сәет профессорны таныды. Мәскәү, Донбасс татарлары белән мунчада очрашканнар иде ич. Ул вакытта үзен тәкәбберкиеренке тоттымы шунда, ачылып китмәде. Чынында ул егет кеше, көрәшче икән, агымдагы көнүзәк хәлләргә битараф, вак-төяк сөйләшүләргә катышмаган булып кылануы ясалма битлек кенә булган икән. Чынында ул татар халкы язмышы белән янып-көеп яшәүче булып чыкты.

— Бездәге иреклек, хөрлек иблис мыегына уралган,— дигән метафорасы белән Сәетне шаккатырган иде теге күрешү вакытында да.

Рамил Кәримович бая өзелгән сөйләшүгә аныклык кертүне сорады: «Нәрсә булган? Ни өчен үтерделәр хатынын?»

— Һәр кешенең үткәне — ямаулы юрган кебек, төрле-төрле. Ул аныкы гына, ә киләчәгебез билгесез,— дип, туры җаваптан киная белән читләште «янарал».

Вәлишин аның бу катлаулы, четерекле мәсьәләгә керешеп, серен кем беләндер уртаклашып торырга теләмәвен аңлап, сөален артык кабатламады.

— Һәркем тормыш хакыйкатен аңлауга үзенчә килә. Чуер ташка бәреп аягын канатырга, кылчыкны үзе йотарга тиеш шул,— дип, профессор гомуми фәлсәфәгә кереп китте: «Сезнең халыкны түбән каста, нәселсез байлар рәтендә йөртергә тырышалар. Соңгы мәлдә сезнең... («мафиягә», дип әйтәсе килсә дә, яхшысынмады, башка сүз тапты)... ыруга мөнәсәбәт яхшы якка үзгәреп килә».

Сакмановның иреннәрендә мәкерле, ироник елмаю биеп алды. Янәсе, төкерә ул кемнеңдер, ниндидер мөнәсәбәтенә.

— Сез дә шулай дип уйлыйсызмы?

Табадан чыжлап төшкән, чираттагы кайнар пәрәмәчләр күтәреп чыккан Әлфия, әңгәмәгә үз юнәлешен бирүне кирәк тапты.

— Ашап утырыгыз, кунаклар. Сүз белән туеп булмас. Минемчә, бүген һәммә нәрсәне акча янчыгы хәл итә.

Бит алмалары, пешергән ризыклары шикелле кабарынып, алсуланып, гөлсуланып, соры күзләре чәчәккә төшкән чык тамчысыдай сафланып киткән хуҗабикә, Мисхәтне төрмәдән «чокып» алган «капчыкны» гына

күздә тотса да, өстәл артындагылар аны житди кабул иттеләр. Зиһенләшүнең өченче, югарырак баскычына күтәрелү вакыты житкән иде.

Яше, гыйльми дәрәжәсе җәһәтеннән өлкәнрәк булса да, сөйләшергә яраткан, үзен бик гади тота белгән фән әһеле белән Сәетнең борчаклары пеште. Бер-ике чәркәне, затлы азыклар илә бастырыклап куйганнан соң, телләре тәмам ачылып китте.

Сакманов мәҗлестәшенең башын вак-төяк, әбер-чебер сораулар белән тинтерәтеп тормастан, үгезне мөгезеннән алырга булды.

— Сез миңа әйтегез әле, иптәш профессор, без хәзер Рәсәйдә, аның сукыр эчәге — Татарстанда, нинди дәүләт төзибез? Илнең, чак кына янә хакимиятне кулларына төшермәгән большевиклар әйтмешли, якты киләчәгенә ышанасызмы?

Вәлишин киң, сырлы маңгае астына, тирәнгә кереп оялаган коңгырт күзләрен әрле-бирле йөгертеп алды. Бизнесменнарның сәясәткә битараф ваемсызлыгын белгәнгә, Сәетне «юморист» дип уйлады, бугай.

— Безгә барыбер түгелмени, дустым. Акмаса да, тамып тора. Ходай тәгалә без мескеннәрен мәрхәмәтеннән ташламый. Менә шәкертем бәбәй туена чакырды, хәзер биешеп тә алырбыз әле,— дип, шомартып котылырга уйлаган иде дә, барып чыкмады.

— Мин үзем Рәсәйне урталыкта калган илләр рәтенә кертәм,— дип, сөаленә үзе үк җавап элде «Игелек» хуҗасы.— Дөнья сәясәтендә аның нинди урын аласы билгесез. Бөтен ышанычыбыз атом-төш коралында, хәрби көчтә иде. Чичнә, Босния, Таҗикстаннар белән пычранып, абруебызны шактый төшердек куәтле, абруйлы мәмләкәт буларак. Көчләр бизмәнендә элеккеге СССР дәрәҗәсенә дәгъва итүне Америка житди кабул итми. Җиһанда һәммә нәрсә дә безнең теләктән генә тормый шул. Рәсәй сәясәтчеләренә аеклык житми...

— Анысы үзебезгә дә житми, гел аек йөреп тә туйдыра,— дип, сүзне һаман да җиңел ызанга төшерергә тырышты дамелля. Ул мондый сөйләшү-аңлашулардан эшендә дә гарык булган иде, күрәсең. Көн дә ашасаң, майлы ботка да туйдыра.

— Житмәсә, Рәсәйнең үзенә генә хас дини, милли юлы бар, ул берәүне дә кабатларга тиеш түгел,— дип, ышандырырга тырышалар хәсрәт икътисадчылар, мескен политиканнар.

— Бу, дустым, мәгънәсез гоман. Ирекле базар белән хөррият юлына чыгабыз дисәң, шул ук Америка белән Германия, Франция белән Япония узган юлны читләтеп үтеп булмас. Теләсә нинди базарның эчтәлеге шул ук, ул ике тиледән тора: берсе — сата, икенчесе — ала...

Профессор, йомры гыйбарәсеннән канәгать калып, бугазыннан шарлавык агызды да, Сәетне игътибар белән рәк тыңлап, мәҗлестәшендә сәясәтче һәм житлеккән шәхес күрә башлады. Бәхәс-аждаһа аны да үзенә суырып алды.

— Һәр илнең, хәтта һәр чорның алга әйдәп баручы маягы, өмет йолдызы була. 1985 елга кадәр сакалыбыз марксизм-ленинизмның тимер чәнечкеле кулында иде. Яңартып кору дип аталып яманаты чыккан елларда, без — самими табигать балалары — демократик кыйммәтләр җиңәр дип, дәрвишләрчә хыялланып йөрдек,— дип, сүзен дәвам иттерде Сәет.— Ләкин өметләребез, ярамаган кешесенә кияүгә чыгып, гаилә бәхете турында хыялланган кызныкы кебек, чәлпәрәмә килде. Илне ахыргача таркатмау өчен, «бердәм һәм какшамас Рәсәй» дигән иске, корама идея тартып чыгарылды.— Кыска, таза бармаклы кулын өскәрәк күтәреп, Вәлишин сүз сорап алды.

— Миллилек, милли горурлык тойгысы, башка халыклар мәнфәгатенә каршы юнәлтелгән булмаса, куркыныч албасты түгел әле. Ул — бәйсезлеккә ирешкән бик күп халыкларның легитимлыгының нигезенә ятты...

Башка җәмгыяви җирлектә яшәгән яңа танышын профессор ихластан тыңлый, бәхәстә тешe чыккан кеше буларак, үз фикерен кыстырып куярга

да жай таба. «Кара син аны, мафиозник кына димәссең, һәр өлкәдән хәбәрдар. Рәсәй халыклары язмышы да, татарының киләчәге дә борчый икән үзен. Туктале, мин аңа сорауның борычлырагын ташлыйм әле. Йотып карасын».

— Күп милләтле, күп телле илләрдә, син әйткән миллилек җирлегендә, үзара якынлык, уртаклык ук булмаса да, тирән аңлашу була аламы? Һәркайсы буразнаны үз ягына тартып, уртак байлыктан иң симез калҗаны, бәлеш төбен — кызлар телен эләктереп калырга тырышмыймы?

Мисхәт чәркәләрне тутырып, чәйне яңартты. Кызын тукландырып килгән Әлфия, өстәлгә яңа тәгамнар — баллы әйберләрен, үзе ясаган «Наполеон торты»н чыгарды.

Сәет эленгән сорауга җавап эзләгән булып, фикер җебен үзенчә үстерде.

— Бу очракта хикмәт башкада. Безгә килеп ирешкән тарихыбыздан күренгәнчә, ә минем нигез белемем шул тарафка якын, татар халкы Болгар, Казан ханлыгы чорларында үзаңлы, мөстәкыйль милләт буларак аякка басып өлгерә алмый кала. Вакыт җитми. Шуңа күрә ул орышны оттыра. Урыс халкы да, милләт буларак формалашканчы, көчләп империя составына кертелә. Бу — аның фаҗигасе. Хәзергәчә безнең өлкән братны, аның бөеклеге, аерымлыгы, тарихи миссиясе турындагы, хакимият дилбегәсен кулында тотучылар уйлап тапкан, уйдырма миф, әкият укмаштырып, дөресендә, алдап тота. Өстенлек вәзгыяте, безнең кебек, Рәсәй составындагы вак халыкларга нисбәтән кулланыла. Лоторея уенындагы алдавыч кебек. Шовинистик милләтчелек — хәзерге җитәкчелекнең бердәнбер таянычы, умыртка баганасы. Нигезендә державачылык ята.

— Стоп, туктале син! — дип, тулы гәүдәсе өчен сәер җитезлек белән, аягына калыкты Сәетнең әңгәмәдәше.— Держава ни дигән сүз, мәгънәсе?

— Каядыр укыган идем. Держава сүзе һәм төшенчәсе урыс вә украиннан башка бер телдә дә юк икән. Үзгә лөгатьләргә тәрҗемә ителми, диләр.

— Вот... Вот... Россиянең милли сыйфаты шундадыр әле.

Профессор «ачышыннан» канәгать калып, рәхәтләнеп, шыр ярып көлде.

Икесенә дә мондый ачыктан-ачык сөйләшү, дөньяга карашларын чагыштырмалы тәгаенләү кирәк булган икән. Вәлишин кебек аңлаучан һәм төртмәле, вакытында утка коры чабык-чыбык ташлап торуга маһир кеше булганда фикер үзеннән-үзе, су түсле агып тора.

— Рәсәйдә табына торган башка анык юнәлешнең әлегә табылганы юк. Тиз генә табылмастыр да. Искечә фикерләүдән котылуы кыен, сез әйткән майлы калҗаны кулдан ычкындырасылары килмәү аңлашыла. Дәүләт бүгенге көн белән яши, аппаратка эләккән бәхетлеләр баеп, чумып калырга ашыга. Конституция халыкны, кешене якламый.

— Соң, дустым, сез дә, хәтта мин дә шул ук хыял белән яшибез түгелме?

«Синең абзыкай, хәерче булсаң да, кесәңдә профессор кенәгәсе ята. Җиргә нык басып йөрү өчен ярап тора ул. Мине үзеңә тиңләмә, бутама»,— дип уйлап алды Сәет. Теленә күчкән фикере башкарак хәрефләргә төрелде.

— Аерма зур безнең арада. Безләргә өлгерергә, алдарга, алданырга, кәлтә еланы кебек, бишкә бүленеп шыбырдарга туры килә. Ә хөкүмәт әһеленең яшәеше, хәл-әхвәле кулайрак, җайлырак, кулында санаусыз байлык, артында аңа буйсынган саклау, яклау оешмалары. Караклыкны законлаштырып, тәртәгә кертеп була.

— Сезнең дә, белүемчә, арка терәкләрегез, ничек дисез әле, крышагыз, яклаучыларыгыз бар,— дип, Сәет белән эчтән килешкән хәлдә дә, профессор тыштан бәхәскә кергән булды.

— Бередә күзгә бәрелеп тормаган сызык яши. Безгә кемдер ярдәм итсә, аны билгеле бер максатлы нияте йөртә. Бередә мәҗбүрият була алмый. Бик якының булмаса, шома кулына кытыршы кәгазьне салуны туктаттыңмы, ул яныңнан таячак, урамда очрашканда сәламеңне саламга да тыңламаска мөмкин. Хакимият белән хөкем оешмалары арасындагы мөнәсәбәт бөтенләй үзгә. Аерым алганда, шул ук милиция аларга обязана служить и выслуживаться. Шуның өчен тоталар аны, яхшы хезмәт хакы түләп.

— Синең белән килешә алмыйм,— дигән булды Вәлишин, чәркәсе төбендә калган коньягын авызына озатып.— Хөкүмәт ул барыбер икенчел. Обслуживающий персонал кебегрәк. Югарырак дәрәҗәдә, әлбәттә.

Киң учын аксыл-соры чалбарының кул керү-чыгу урыннары таушалган кесәсенә тыгып, Вәлишин йөренеп алды.

— Хакимияткә артык тел-теш тидермәгез әле. Минем дус-иш, миндә белем өстәгән егетләр күп араларында. Илләм тәнкыйтьне яратмыйлар,— дип, рәхәтләнеп шаулап алды.

Сәетне якын итеп, күңеленә алып өлгергән иде. Сүзгә юмор бәпчекләре, шук төсмерләр кертеп җибәрергә кирәк тапты: «Хәзерге яшәвегездән канәгать булмасагыз, башкача хәяткә күчегез. Заводка эшкә урнашырга ярдәм итә алам. Бик теләсәгез».

Төрттерүеннән ифрат канәгать калуы кечкенә коңгырт күзләренә, кабартма иреннәренә бәреп чыкты. Бүлмәне тамак тасмасыннан агылган көлү тутырды.

— Безне, алыш-биреш, сәүдә белән шөгыльләнүчеләрне, җәмгыять җилкәсендә утыручы, халыкны талап яшәүче сорыкортлар рәтендә йөртүчеләр җитәрлек,— дип аңлатма бирде Сәет, Вәлишиннең җәлпәк чемегүен йөрәгенә үткәрмәсә дә.

Кадерле кунак шаяртуында тирәнгәрәк кереп китүен аңлап, Сәетнең күңелен күрергә булды: «Киләсе атнада, бергәләп мунчага барырбыз»,— дип ычкындырды. Бераз уйланып торганнан соң, өстәп куйды:

— Сезнең һөнәр, дустым, мәңгелек ул, дөресен әйтсәм. Иртәгә җир кояш тирәсендә әйләнүдән туктаса да, сез калачаксыз. Янар таулар, ташлар өстенә басып, башлаган эшегезне дәвам иттерәчәксез.

Үзеннән канәгать калып, профессор юан бармакларын ике яклап чәчләренә батырды. Әйтерсең лә, ул аннан яңарак фикер кысып чыгара. Тапты тәки. Киңәшен бирде.

— Сине, Сәет Яруллович, якын иттем. Акыллы, башлы адәм күренәсез. Әмма артистлык, кылана белү, күзгә төтен җибәрү җитенкерәми сезгә. Мисхәткә дә кирәк булыр бу сыйфатлар. Дөньяга карашыңны беркайчан да ахыргача ачып-актарып җибәрергә ярамый. Баш мие, искемоскы киемнәренә нафталин сипкән әбиләр сандыгы төсле, биктә тора белергә дә тиеш. Зарланырга өйрәнегез! Теге юк, бу җитешми, банк акча бирми, налог җыючы хәерчеләр, борча кебек ябыша... булган байлыкны кысып тота белергә дә кирәк. Бар кешегә дә юмарт булып кара...

Әлфиянең аш бүлмәсе ишегеннән колагын салындырып торуын сизеп, юри өстәп куйды:

— Табигать биргән байлыгын, матурлыгын кысып тотмаса, хатынкыз да тиз таушала, иртә картая.

— Кешене тере килеш идәнгә кадаклап куеп, яныннан эре генә үтеп китәргә өйрәнүе җиңел түгел шул,— диде Сәет, ни өчендер көрсенеп.

— Кемдер кирза итеге белән аягыңа баса икән, гаепне үзеңнән эзлә,— диде Рамил Кәримович, Сәетнең фәлсәфәсен үзенчә бәяләп.— Значит, син шуңа лаек. Тырнагыңны кимер дә юлыңны дәвам ит. Тормыш ул — уңай каһарман һәрдаим җиңеп чыга торган, Голливудта ясалган фильмдагыча гына була алмый.

— Ул картиналарның беришесен мин тормышка пародия, икенчеләрен хакыйкый дөреслектән качу, дип кенә кабул итәм. Бертөрлелекләре белән туйдырдылар инде тәмам.

Чит ил фильмнары белән ясалма әдәби әсәрләр абруена агу тамызгач, Сәет яшәешенә, табигатенә якынрак үзәнгә төшәргә булды.

— Тормыш тиз үзгәрә, Рамил агай. Кичә зәмһәрир суык белән бозлы яңгыр явып, бүген кызынырлык эссе көн килгән кебек.

— Сезгә нәрсә, самолетка утырдыгыз да, киттегез Каһирәгә, Гарәп Эмиратына... Бездә кыш, анда эссе.

Яңа байлар токымын фаш итү тудырган көлү бүлмәне тутыра. Сәет үз юлын бирми.

— Кичә без күн куртка, джинсы чалбар, алтын чылбыр артыннан кудык, өч МММ исәбенә баеп калу турында сәрхүшләнеп, күбебез ярык тагарак янында калдык. Хәзер балчык чүлмәгебезне чит илләр хисабына сипләргә, ямарга тырышабыз. Ә анда тилеләр нема... Шуннан ни кала?

Юк, юк, мондый гамәли якка борылышны профессор кабул итә алмый. Аның, галәмне иңләгән олы сәясәттән, сукыр тиененә чукынып киченгән җиргә төшәсе килми. Аңа ни: укыган кеше Африкада да укыган кеше инде ул.

— Чынбарлыкка милли яссылыктан караш турында сүз чыкты бая-гынак. Синең татарыңа андый тәгълимат кирәкме соң? Гасыр башында ук бер татар язучысы ачыргаланып, милләт үлгәнме, әллә йокыга гына талганмы, дигән сорау калкытып куйган иде. Җавап бирелдеме соң?

Сәет уйланып алды. Чәен йотып куйды: «Бу мәсьәләләр, үзен билгеле бер милләт кешесе дип санаган, ата-анасын таныган теләсә кемне борчый, дип уйлыйм. Сезнең карашны беләсе килгән иде».

Профессор шактый ризыкны сыйдырган салмак гәүдәсен урындыгына ипләбрәк урнаштырды: «Бергәләп җавап эзләп карыйк әле»,— дигән булып, сүзен элеп китте.

— Миллилек, милли хис кебек, тулаем алганда, изге төшенчәләрнең ике кыйбласы, ике төп юнәлеше бар, дип фараз кылам. Күпчелек зыялылар аңлаган, шуның өчен көрәшкән, саф, пакь, киләчәкле, өмет чаткысы үзенә әйдәп торган кыйбласы. Бусы — һәр халыкның азатлык, мөстәкыйльлек, суверенлык өчен көрәше. Өстен даирәләр, хакимиятне кулларына шул хәрәкәт барышында кулга төшергән кемсәләр өчен дә, миллилек идеясе шулай ук лазем. Әгәренки, миллилек, милләтчелек, башка халыклардан өстенлек кебек төсләргә буялса, ул залимлеккә, монархиягә алып килә. Иң отышлы мисаллары — большевиклар кулына төшкән безнең ил һәм фашистик Германия.

— Карале, Мисхәт, азрак кой әле шайтан суыңны. Бик тирәнгә кереп киттек, допинг кирәк.

Бәллүр чәркәгә телен генә тидереп алды да, фикерен дәвам иттерде.

— Баш миендәге сыекчаны җәлләмичә эшләтеп уйлап караганда, режим белән халык арасында арадашчы, элемтәче, бәйләүче вазифасын депутатлар уйнарга тиеш түгелме соң?

— Үзфикерле кешеләрне үткәрмиләр. Исемлекне әнә тегендә төзеп, алдан эшен бетереп куялар,— диде Сәет, бүлмәнең сырлы сөлгегә охшаган, тавыш үткәрми торган материалдан эшләнгән түшәменә төртеп күрсәтеп.

Фәнни җитәкчесен, уңышлы киңәш-табышлары белән фикер алышуга юнәлеш биреп барган Сәет абыйсын онытылып, авызын ачып тыңлап торган Мисхәт тә, сорау биреп булса да, сүзгә катнашып алырга булды. Соңыннан уңышлы килеп кысылуына шатланып бетә алмады:

— Халык депутатлары кая карый?

— Кая карасын, үз җаен карый. Ха... ха... Хикмәт, энем Мисхәт, шунда, безнең илдә гражданлык җәмгыяте оеша алмыйча калды. Мультэлитар идарә туды.

Фикер алышуны Вәлишин янәдән үзенә якын әхлакый сукмакка алып керде.

— Күпмедер вакытка, мин сезгә әйтим, җәмгыять, халык белән хакимдарлар омтылышы якынлашырга, берләшергә мөмкин. Тик бу көчәне-

шле дуслык озакка бара алмый, юллар әкияттәге төсле аерыла. Берәүләр хәттин байый, төрле исемнәргә, әллә ничәшәр коттеджлар салдыра, чит ил банкларында счетлар ача... Гавам хәерчелек сазлыгына кереп бата, аракысына акчасын юнәтсә дә, закускасына иске кәстүм җиңе генә кала.

— Хөкүмәт оешмалары шулай бердәм, дус яши, араларына чөй кагып булмый, дип уйлыйсызмы?

Камырга чүпрә вакытында өстәлде.

— Җитәкче даирәләр арасында җәмәгатьчелекнең, бигрәк тә ач-әрвах зыялыларның йөрәгенә бәлзәм булып яткан каршылыклар күренгәндәй булса да, куркыныч, афәт күтәрелгәндә режим шунда ук берләшә, чөнки бу каршылыклар принципиаль түгел, сабан туенда ат чабышында туган көндәшлек кенә. Беренче булып барыбер сыер килми ич. Ярый, бу хакта җитте.

Үзеннән торган кешедәй кыланып, профессор: «Синең, Сәет Ярулович, биографияне үзгәртү ихтыяҗы бар»,— дип куйды.

— Ертык җире юк кебек чапанымның. Әти — Ватан сугышы участнигы, инвалид иде. Әнинең әтисен кулак, ягъни кулы ак булганы өчен, атканнар. Бабам урыс, татар телләрен яхшы белгән, беренче дөнья сугышында катнашып, әсирлектә немецчә сукаларга да өйрәнгән. Үзем — хәрби. Милициядә хезмәт иттем, гаделлекне булмаган җирдә эзләгәнем өчен, арт ягыма типтеләр. Язмыш иң якын кешемне тартып алды...

Ярларына сыеша алмаган дулкындай, профессор шаулап, котырынып алды.

— Ир башына — мал җитә. Акча, байлык артыннан куып, бер-берегезне кырып бетерәсез... Синең тормыш тәҗрибәң зур икән. Депутатлар корпусын бизи алыр идең.

— Миңа ни пычагыма кирәге бар өстәмә мәшәкатьнең,— дип, күзләреннән очкыннар учмасы чәчсә дә, Сәет бераз тынычлангач, ихластан өстәп куйды: «Кем сайласын анда мине?»

Шактый кызган профессорга вәгъдә бирү капчык ташу кебек үк авыр шөй түгел иде.

— Без сайлыйбыз! Мин, Әлфия, Мисхәт... Соңрак Зөлфия.— Фикере яңачарак, бәяләре ачык, җете булуы белән Вәлишин аның күңелен эретте, югала барган кыйммәтләр турында уйланырга мәҗбүр итте.

— Сезнең халыкка әле шикләнеп, куркып карыйлар. Әйтик, син — Югары Советка узсаң, башка депутатларның күпчелеге кебек, юк-бар акчаларына, килде-китте төшеменә, табышына кызыкмас идең. Сиңа фатир, машина кебек алдавычлар кирәк түгел. Күпләр депутатлыкның матди файдасына мөкиббән китәләр. Шул подачкаларга кызыгып, халык ышанычын акларга тиешле әһел бәйсезлеген югалта, кабалага килеп эләгә. «Коммуналкадан» чыккан депутатка үзәктән затлы квартира бирәләр дә, аның бәйсезлеген, иреген алалар, авызын юеш чүпрәк белән каплыйлар...

Вәлишин тәмам кызып җитте. Әйтерсең лә профессор студентларына демократия турында махсус курс укый. Сәет көчкә-көчкә сүз алуга ирешә.

— Бизнес белән шөгыльләнүчеләрдән гел яңалык, гайре гадәти борылышлар көтәләр. Үтереше, атышы, сөяркәсе белән януы, көндәшләреннән тимер рәшәткә артына кереп качуы кебек, «кайнар» хәбәрләр килеп торсын. Урам белән урам сугышсын, «мерседес-600»лар һавага очып торсын. Ә без, киресенчә, гадәтилек, югары мәгънәсендәге тыйнаклык, эчке рухи байлык кебек төшенчәләргә омтылырга тиешбез. Заманә агышына җайлаша алмасак, безгә — капут,— дип, сүзләрен кулы белән өстәлгә кагып, җөпләп куйды Сәет. Ул күбрәк Мисхәт өчен сөйли иде.— Безне тормыш гел үзгәреп торырга мәҗбүр итә. Шул ук коммерцияне алыйк. Безнең ширкәтне, заманында, «торна ботларын»нан җиргә аягы белән бастырган КамАЗ машиналарын элеккеге тиле бәягә бирү дә

алмаячак. Безнең көннәрдә акчаны банклар, түгәрәкләр аша әйләндерү, чит ил хәлләләре белән хезмәттәшлек һәм үзең нәрсәләрдер эшләп чыгару, производство аша гына арттырып була... Мин заманында өй җиһазлары эшләп чыгару, вак-төяк ремонт эшләре буенча цехлар ачкан идем. Аны ватып, җимереп, акчасын талап киттеләр. Мисхәтләргә аны яңадан аякка бастырасы булыр... Тик башка әйберләр эшләп чыгарырга, әйтик, барча халык яратып кия торган чуар омон киемнәрен тегү — акланыр иде.

Безне киләчәктә ни көтәсен берәү дә әйтә алмый. Күбебез кемнедер гаепләү, гөнаһлыны эзләү белән мәшгуль. Гөнаһ-то үзебездә, холкыбызда, баш миебездә...

Ил бүген кыл икегә бүленде. Гаеплеләргә һәм гаеп эзләүчеләргә, ягъни мәсәлән, үзләрен изгеләр рәтендә йөртүчеләргә һәм әшәкеләргә. Җеназа тотучыларга кытлык юк, җаваплылыкны үз өстенә алучылары гына офыкта күренми. Чечняда аккан кан өчен кемдер гаепкә тартылырмы? Кистереп әйтеп була: юк.

Тирә-ягыбызга күз салыйк: гөнаһсызлык, саф күңеллелек янәшәсендә үк вәхшилек, варварлык. Барысы да кешенең үзен хөрмәт итмәвеннән килә. Тышкы дөньядагы, сәясәттәге, икътисадтагы һәр үзгәреш, яңалык адәм баласының табигатеннән килә, көзгедәгедәй чагылышы булып тора. Режим кешене тудырмый, теләсә кайсы режимны кеше тудыра түгелме?

Мондый озын-озак нотыктан профессор арыды. Үзе сөйләргә өйрәнгән кеше — тыңларга яратмый.

Сәет Сакмановның тормышны үзенчә күрүен ул ошатты.

— Соңгы соравым. Рөхсәт булса. Менә хәзерге сәясәт, адәми затның елдан-ел бозыла баруы сезгә — бизнес белән шөгыльләнүчеләргә кайсы кыйбласы белән кагыла? Яхшыгамы, зараргамы?

— Арадашчы оешмаларга, хакимият белән халык арасындагы кешеләргә, үз уен, кагыйдәләрен тәкъдим итәргә, аны кирәк чакта, фил борыны мәсле, алга чыгарырга яисә тәвә кошыдай башны канат астына яшерергә кирәк була. Төп шарт: сине ахыргача аңлап җиткермәсеннәр. Гадәти яшәешең дә серле күренсен. Күзгә төтен җибәрү,— дип атала бу халыкта...

Олы төшенчәләр белән эш итү ашау-эчү мәсьәләләренә һич кенә дә зарар итмәде. Әлфиянең мул өстәле бәләкәй атом бомбасы төшкән, хәрабәле бушлыкны хәтерләтеп калган иде. Сәетнең башы аек. Бу чаклы җитди вә ачыктан-ачык сөйләшү кирәк булдымы икән? Ул — нәрсә бирә?

Бик җылы аерылыштылар. Бу тарихи очрашудан соң да Сәет профессор белән күрешкәләп торды. Факультетларына бернichә компьютер бүләк итте, башка матди ярдәмнәр күрсәтте. Мисхәт алдынгы аспирант булып китте.

Сакманов үзенең акрынлап олы сәясәткә тартыла баруын, илдә туган үзгәреш-яңалыкларга элеккечә битараф кала алмавын аңлады. Элгәре яңа төр машинага, фатирны бизәгән күн тышлы йомшак диванга, хәтта әтәч койрыгыдай төсле «муенчак»ка да мөкиббән киткән «Игелек» хуҗасын чосрак хәл-әхвәлләр борчый башлады.

Ул депутатлыкка кандидат булып теркәлергә ризалык бирде. Хәтта беренче турны уңышлы гына үтте. Мәгәр аның ыргылып барган тулпар атына киртә куеп, үзен иярдән сөйрәп төшерерлек көчләр табылды. Бәла иң көтмәгән җирдән, кыр тавыгыдай, аяк астыннан килеп чыкты.

## 23

«Иртә торган икеләтә бәхетле, ул кояш чыкканны күрә»,— дип, офисына урам җыештыручылар тузан туздырып өлгергәнче үк килсә дә, әлләни майтара алмады Сакманов ул көнне. Виль-

нюс белән сөйләшү шатландырмады. «Русия чыгымнарны бик күп өстәде, шунар да агачтан эшләнгән өй җиһазларын озатуны туктатып торабыз»,— диде күптәнге танышы, ышанычлы партнеры. Андагы егетләр белән даими гамәли мөнәсәбәт ширкәткә шактый табыш китергән иде заманында.

Урамында нур әсәре юк. Шәһәргә, урап-чолгап, Лондон томаны төшкән. Салым җыючы әрәмтамаклар белән җылы булмаган сөйләшү дә күңелендә авыр эз калдырды. «Картаям бугай» дип, туйганчы хисләнеп, үзен-үзе юатып, иркәләп алырга исәбе бар иде хуҗаның, әмма хыялы фәрештәләрнең амин тоткан вакытына туры килмәгән булып чыкты. Урынында кыр кәҗәседәй үрле-кырлы сикергән шәмәхә трубкәне теләртеләмәс күтәрде. Теге яктан килгән тавыш әүвәл аңа хәрби хезмәте буенча таныш монгол ишәге бакыруын хәтерләтте, аны җилле көнне ятимә авыл карчыгының җимерек морҗасыннан чыккан авазлар алыштырды... Тавыш хуҗасын, бик теләсәң дә, бу фани дөньяда сохари кимерүче башка бер зат белән дә бутарлык түгел. Ул, әлбәттә, Нургали Ваһапов иде.

— Гомерең янгырашлы булсын,— ди «кит», исәнлек-саулык сорашу урынына. Салмак сөйләшүгә җавапны уйлап өлгерергә вакыт бирә. Чынында, мәчене тычкан фикере борчымаган сыман, каршы якның җавабы аның өчен сукыр бер тиенгә дә тормый.

— Мине итагатьле, кешелекле адәм димәкче буласызмы инде, Нургали агай?

— Башкаларга хас сыйфатларны үзенә ябештерергә ашыкма әле, браток.

— Соң нәрсә кала инде бу тормышта? Яңгырап торабыз. Янып, яндырып торабыз.

— Хәзер килеп җитәм. Чәеңне куйдыра тор.

Сакманов ял бүлмәсендә чәй әзерләткән арада, җирән сакчысы белән, боз тауларын эретердәй, күктә очкын уйнатырдай туфан, тайфун, котелмәгән афәт кебек бәреп тә керде. Җиһанда аңа каршы тора алырлык көч юк иде кебек. Очрашуга бер атна әзерләнгән диярсең. Йөртүчесе калдырып чыккан төргәктә кара, кызыл уылдыктан, ысланган иттән, каклангин тавыктан алып, «Родник» аракысы белән әрмән коньягына чаклы бар иде. Сәеткә үзенең сыр, тозлаган балык, салями кебек вак-төяк кабымлыклары өчен түзеп булырлык оят. Җитмәсә, сәркатип кыз, яшьлек юләрлеге белән, тозлы кәбестәсен дә чыгарып куйган. Кесәдән акча чыгаруны өнәп бетермәсә дә, Ваһапов үзе өчен әзерләнгән өстәлнең мул булуын ярата. Бу, аның уенча, үз-үзенә хөрмәтнең төп күрсәткече.

Тирәнгә кермичә генә дөнья хәлләре, сату-алу, керем-чыгымнарның торышы хакында сөйләшеп алдылар. «Кит», кабул ителгән тәртипне бозмыйча, «дөнья кочу көннән-көн авырлаша, халыкның азуы соң чиккәчә, ахырзаман фаразына килеп житте»,— дип, нәүмизләнеп, мескенләнеп алды. Татарстан җелегеннән, Төмән жиреннән табылган чималда утыручы бу ширкәтнең табышы базар хөрлегенең беренче елларындагы шикелле түшәмгә төкереп ятарлык яхшыдан булмаса да, хәле түзәрлек икәнлекне Сакманов белә. Зарланып алу, йомгакның очын яшерергә маташу — татарның канында.

Хуҗа кунагын өстәл янына дәште, «ризыкка тәм кертү өчен генә берәрне тотыйкмы әллә»,— дигән булды.

Олпат гәүдә бу юлы да кабул ителгән гадәтенә хилафлык итмәде. «Мотор ыңгыраша, бөер сыкрый, бавыр зарлана, әйдә бүген мәнсуҗлар көненә төшмичә, берәрне генә тотыйк та, чәйгә күчик»,— дигән булды.

Бу алым Сәеткә күптәннән таныш. Ваһаповның бер шешә коньякны «үгетләп» бетермичә, урыныннан селкенмәячәгенә иртәгә таң атасына, яңа көн туасына инанган кебек үк ышана, тәгаен белә.

— Синең сүзне, Сәет Яруллович, аяк астына салып таптау кәферлек булыр,— дигән булып, «кит» өстәл янына күчте.

Тамакның кытыгын бастырып, ашказанын тынычландыргач, хәл-әхвәл белешкәндә башлаган сүз ызанына кереп киттеләр «яңа байлар».

Ваһапов халык теленнән алынган берәр үткен гыйбарәне, әйтемне, күзәтүен урынында, вакытында кыстырып куя белә. Карашы ягымлы. Илаһи ихтыярын күрсәтеп, Гали баба унтагайларыныкы төсле ияге дә алга чыгып тормый. Олы башын алгарак авыштырганда, муен «ияге» әрсезләнеп китә, алга асылынып төшә. Андый вакытларда ул карт күренә.

— Хөкүмәт белән тартышу — ахмаклык. Аны бәреп төшереп була, әмма җиңеп булмый. Анда да кальбе кара кешеләр җитәрлек.

«Кит»ның ваемсыз гына әйткән бу җөмләсен Сәет акыл казанына үткәрде һәм аның хаклы булуына кат-кат инанды.

— Хөкүмәт безгә хезмәт итү өчен ятырылган оешма ул. Без — җир асты кешеләре, чын хуҗалар. Моны исеңдә тот. Мажар сыеры мөгезедәй алга чыгып тормаса да, безнең йогынты һәр тарафта, һәрдаим сизелеп торырга тиеш,— дип дәвам итте фикерен Ваһапов.

— Барыр юллар кисешеп, хакимият хуҗалары яшәргә бирмәсә, нишләргә? — кебек Сәетнең саф күңелдән әйтелгән, самими соравына да җавабы әзер.

— Мөмкин чаклы дус яшәргә тырышырга. Барысы белән түгел. Җитәкче оешмалар, бигрәк тә шул ук гавам малын бүлеп, үзләштереп, сатып утыручылар белән әшнә яшәргә кирәк. Әшнәлек татарының бүсере ул, браток.

— Әгәренки, алар теләмәсә? — дигән икенче беркатлы сорау төшә Сакманов теленнән.

«Кит» фәһемле итеп аңлатып тормый. Туры җавап бирүдән тайчана. Кем булуына карамастан, төпченгән кешене җене сөйми. Шундый вакытларда, бер уч йокы даруы капкан кешедәй, йөзенә ваемсызлык пәрдәсе тартып төшерә. Кешенең фикер сөрешен, сөйләшү рәвешен, хәятка мөнәсәбәтен арка терәгенең ныклыгы билгели. Ваһапов байлыкны көчәнмичә, нерв күзәнәкләренә авырлык китермичә таба. Үз ягына җайлап авыштырып куелган улактан, гел акмаса да, һәрвакыт тамып тора. Тамчыдан күл җыела.

Сакманов сабахтан ахшамга тикле, койрыгы артыннан түмгәкләнгән мүчкәй төсле йөгереп, баскакларын узышчы атлар көненә төшерсә дә, әлләни майтара алмый. «Игелек»нең хәлләре кылдый-былдый килеп, Сәетнең «ата казга сәлам бирердәй» көннәре дә булгалады. Шул ук вакытта «Игелек» җаваплылыкның азын гына үз өстенә алган оешмалар арасында төшеп калганнардан түгел. Байлык өстәлә, процентлары килә тора. Нәфес кымтырыклый: җир маена, ясалма кушылмалар, каучук кебек җиңелрәк кәсепле юлга чыгып, Ваһаповтай ваемсызрак яшисе килә Сәетнең. Бернинчә кат кылын тартып карады «кит»ның. Якын китерми. Бүген шул хакта сүз катып карамакчы булып, киеренке утырды, иркенләп җәелеп китә алмады. Җае чыкмый, дөресе, дошман якынлашуын сизенгән мал төсле, Нургали ләчтит юнәлешен һәрдаим алыштырып тора. Нәкъ керпе. Кул белән алып булмый.

Җитмәсә, шайтан төкреген аз-маз каптымы, Нургалине җыруга тарта. Борынгы авыл көйләренә гашыйк, бахыр. Моңын китереп бетерә алмаса да, көчле тавышы калтыранып чыга, бугазына мандолина урнаштырганнар диярсең. Тыңлаучы мәнфәгате турында баш ватмый, үз шәхси ләззәте, күңел сөенече өчен чыгара сүзләрне. Үз галиҗанәпләре өчен булгач, татар халык җырларын дөньясын онытып, иләсләнеп, күзләрен яртылаш йомып, бик күп каршылыкларны җиңә-җиңә бавырдан ук күтәрелгән авазына ярдәм итеп, көй җаена башын чайкап, кулбашларын, җилкәсен, аркасын уйнатып, сәрхүшләнеп башкара. Бередә аңа тиң кеше юктыр. Иң күренекле сәхнә остаң да аны кабатлый алмастыр. Бу гадәте — аның коткаручысы. Бизнес мәсьәләләрендә ачылып, актарылып китәргә вакыт җиттеме, ул такмазага күчә, «бик күңелле булды сездә, сез

дә килегез безгә»,— сүзләре белән аягына торып баса. Отыры ашыга. Ата дәрте, ана сөте белән кергән акыллылык галәмәтеме бу, әллә болгавыр, буталчык замана өйрәткән хәйләме, мәкерле бер алыммы? Артыграк төшереп, теле тегермән ташын авыр әйләндергән очракларда да, кабартма ирennәрдән тирәлек өчен файдалы хәбәр ычкынмый.

Язгы үләнгә чыккан колын төсле иркен, көчәнүсез яшәвенең чыганагын Сәет белә, ә серенә төшенә алмый. Тыелган алманы татып карыйсы килә «Игелек» ширкәте сәрвәренең. Шайтан гел котыртып, кытыклап тора.

Кемдә хәбәрдарлык — шул хуҗа безнең чорда. Дәүләт малын бүлеп утыручы даирәләрдә Сакмановның артык ышанычлы шымчылары юк. Ул — читтән килгән кеше. Даруханә, ашханә, бензин агызучы бинаоешмаларның биржага куелып сатылуы турында хәбәрне алуга, Сәет хадимнәрен шунда җөгертә. Соңга калган булып чыга. Аларны инде берничә көн элек Ваһапов, Бабурин, Халяпов кебек өлгерләр сатып алган булып чыга. Бу кыенлыктан вәкарь генә чыгу юлларын эзләп «Игелек»нең генераль директоры чигәләрен кызартып бетерде. «Ярдәм» көтмәгәндә килде. Язмыштыр инде. Шул вакыйга Сәетне четерекле, киеренке юлга алып чыкты.

Нургали Ваһапов, көннәрдән бер көнне, очрашуга үзе белән ширкәтенең баш инженеры Мостафа Гаделевны алып килде. Буйга-сынга әлләкем булмаса да, бик һавалы, тәкәббер тота үзен. Тик күзләре куркак, өйрәнүчән, шикләнүчән тоелды Сәеткә. Мәгәр хәмер ярата һәм тиз исерә торган, үшән кеше булып чыкты. Үзенең күп белүен, һәр тарафта танышбелешләре, туган-тумачасы утыруын яшерми. Сәетне иң гаҗәпләндергәне шунда булды: Ваһапов Гаделевне лыкылдавыннан туктатмады, кисәтү ясамады, чабуыннан тартмады. Йөзенә балавыздан эшләнгән ясалма битлек төшереп, утыра бирде. Киеренке тотты үзен, җырулары турында да онытты. Шактый кызмача Мостафаны тизрәк урамга алып чыгу ягын гына карады.

«Һәр очрашу файда китерергә тиеш. Мыскаллап килгән жегәрне юкка сарыф итәргә ярамый»,— дип, Сәет «башның» үзен генә кунакка алырга булды. Бала-чага түгел ич, «әттәсенең» балагына тагылып йөрергә. Сколько можно!

— Нургали абыйны, наставнигымны бик хөрмәт итәм. Ул миңа дөньяга карашымны тәртипкә салырга булышты,— дип башлады сүзен Сәет, кунакны Төньяк калавылында әзерләнгән мул вә «симез» өстәл янына, түргә утыртып.— Аңа да эндәшмәкче идем дә, урынында туры килмәде,— дип, хәрәмләшергә булды.

Мостафа, авылда туып-үскән булса да, шәһәр монафикълыгыннан, икейөзлелек кагыйдәләреннән хәбәрдар булып чыкты. Сәетнең аның белән «те-те», ягъни мәсәлән, артык колакларсыз очрашасы килгәнен җиденче тоемы белән сизенгәнгә, шаяртып-кинәләп алырга булды.

— Аны табасы иде. Мин Нургали абзыйдан башка кунакка йөрмим. Бирәдәдер дип уйлаган идем. Машинасыннан, өеннән булса да эзләп карыйм әле,— дип, кәс-кызыл трубкәне күтәргән булды.

Сәет: «Кирәкмәс инде, эзләп тормыйк, башка вакытта»,— дип, кабаланып, сикереп торырга тиеш иде мантыйк кагыйдәсе буенча. Таушалган адәм баласының януы юктан, иләк-чиләктән, әтрәк-үтрәктән башлана. Сакманов ай төсле битараф, ваемсыз чыраен тәрәзә ягына борды. «Әгәр, чын-чынлап шалтыратып, «кит»ны эзли, чакыра башласа, бу адәм белән исәнлеккә зыян китереп, мәҗлесләп утырасы булмас. Берәр хәйлә табып, урам чатында очрашкан чит-ят этләр мәсле исәнәеп, тиз генә аерылышырга. Больше белешмәскә!»

Химия-технология институтын, үзенең әйтүенә караганда, кызыл дипломга тәгәлләп, табкушылма берләшмәсендә мастердан цех начальнигы, хәзер арзан бәягә ярты Казанны сатып алырлык матди куәткә ия ширкәтнең икенче сәрвәре дәрәҗәсенә күтәрелә алмас иде андый ахмаклык

эшләсә. Юк, эзләмәде. Шыпырт кына өстәл артына кереп утырды, затлы коньяк салынган бәллүр чәркәне кулына алды.

— Беренчене гадәттә очрашу өчен күтәрәләр. Мин бүген безнең белән утыра алмаганнар өчен эчәргә тәкъдим итәм,— диде Ваһаповның «уң һәм сул кулы». Чәркәне авызына чөнкәйтеп куйгач, тәненә көтелгән җылылык иңде, чыраена төс керде. Бер шешә араларын «сөбханалла» диярлек итеп рәтләде дә куйды.

Сәет аның йөгерек соры күзләрендә хәйләкәр, шаян чаткылар биешүен сизеп алды. Сыныймы, уйныймы? Сакманов кунагын аңларга, рухына үтәргә һәм үзе өчен мөһим елга ярына алып чыгуда файдаланырга тиеш.

— Сезнең тормыш рәхәт, кем, Мостафа туган. Миңа менә бер үземә кыен. Дөньяма, кара төн шикелле, пычрак караңгылык төште. Көндезем матур, ямьле, ә кичләрем ямьсез һәм күңелсез.

Майлы көмәч өстенә кара уылдык сылау белән мәшгуль Гаделев, хуҗаның моң-зарын фикри божрага кертмичә, беренче җөмләсенә чат ябышты. Кабарган ачуы сырлы маңгаена, коңгырт чәчләренә менде, хәтта чәркәсен дә читкәрәк этеп куйды.

Адәм баласын мин-минлек шаукымы, үзен зурга кую, кәперәю вакытлыча күтәреп, үстереп куярга, киресенчә, җир суалчаны дәрәҗәсенә төшерергә дә мөмкин.

— Сәет туган, сез чын-чынлап мине кемдер, аерым алганда, Ваһапов шулай рәхәттә яшәтә дип уйлыйсызмы?

— Урысларның: «Жить у попа за пазухой»,— дигән мәкале бар. Нургали абый исән чакта сезгә җил-яңгыр тими инде. Вакытында сөтле чәй эчеп, мәен капкалап, рәхәтләнеп утырасыз җылыда. Ә вакытында...— дип, затлы ашау-эчүнең файдасы турында сөйләмгә кереп китмәкче иде Сәет. Аны шактый усал, үз көченә ышанган тавыш бүлдерде:

— Сезнең якын дустыгыз минем аркада баеды, минем аркада балдамайда йөзә... Беләсегез килсә!

Сәет йөзенә гаҗәпләнү, аптырау, ышанмау чыгарды, күзләрен түгәрәкләде: «Янәсе, каен тузы да күтәрә алмаслык әкият сөйләмә, көлкегә калырсың, адәм рисвае булырсың...».

— Тәбәнәк буйлы, симез пеләш кеше беркайчан да, җиде пот тоз ашап бетерсә дә, озын буйлы, бөдрә чәчле, артык бәдәнле була алмаган шикелле, якын дустың Ваһапов та, мин аңа ярдәм итмәсәм, оргсинтезда смена мастеры дәрәҗәсенә җитеп, шунда череп, күптәннән гүр иясе булыр иде.

Кешенең чын йөзен белү өчен аңа дәрәҗә биреп, йә исертеп кара, диләр. Йомык кына күренгән Мостафа бик сүзчән булып чыкты. Йөрешенә чаклы үзгәрде. Гәүдәсе җиңеләеп китте. Көлеп куйды. Сәеткә эре генә карап алды да, дәвам итте.

— Сер итеп кенә әйтәм, минем хатын, бик беләсең килсә, шәһәрдә иң олы берләшмәнең баш экономисты, энем госкомимуществода җаваплы эштә.

— Соң, причем монда алар,— дигән булды Сәет.

Мондый «наданлык» шактый салып алган кунакны тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Хатын безгә арзан бәягә чимал җибәреп тора, ә энекәш вакытында нәрсәне «прихватизировать» итәргә кирәклекне колакка элеп бара.

— Энеңнән әлләни файда юктыр ла?

— Татарстанда якын арада ни нәрсәнең сатуга, аукционга чыгарыласын бер атна алдан белеп торабыз. Арттан килеп, хап... Шулай өч заправканы, ике аптеканы шалкан бәясенә сатып алдык. Тагын ике заправканы кесәгә салырга җыенабыз,— дип, Сәетне ышандырасы килеп, соңгыларның кайда урнашканнарына чаклы әйтеп бирде.

«Кит»ның үзеннән курыкмыйча, сер чишкәненә үкенмичә, Гаделевның җәелеп. бөердән сөйләнүенә шаклар катып, кирәкле хәбәрне баш дип аталган компьютерга салып утырды хуҗа. Ваһапов янында да Мостафа-

ның үзен иркен тотуы, «братокның» әледән-әле аның салпы ягына салам кыстыруы исенә төште.

Булганына шөкерана итеп яшәргә иде дә, юк шул, комсызлыгы жиңде, Сәет икенче көнне үк Гаделев атаган ягулык ояларын кулга төшерү хәстәренә керешге. Икесен дә шактый арзан бәягә сатып та алды. Икътисадый хәле рәтләнеп, куәтләнеп китте, мәгәр Ваһапов белән араларына таракан төште. Күрешүләре сирәгәйде. Кунакка йөрүгә хирыс Нургали Сакманов конторасының бусагасы аша үтүдән баш тартты. Аның каравы Мостафа Гаделев белән аралары җылынды.

Үтә саран Нургали кечтеки генә матди югалуын да авыр кичерә, әйтерсең лә, тәненнән бер тотарлык ит кисеп алалар.

Сакманов Ваһаповның холык-фигылен, менәзен яхшы өйрәнгән кеше буларак, мөнәсәбәтләренең тиктомалдан гына җайланмасын, «кит»ның үпкәчел кеше буларак, тиз генә гафу итмәсен аңлап, беренче адымны ясарга ашыкмады. Урысның теләсә нәрсәне сыйдыра һәм тиешле җиргә илтә торган «авоська»сы бар. Ул да шуңа таянды. Хаталанды...

Шау-шулы тормышны өнәп бетермәсә дә, Сәет дуслык һавасын ярата, шул ук вакытта, җилкәгә орынудан туган, мәҗбүри булмаган, өстәнөстән генә якынлыкны кабул итми. Дуслары күп түгел, әмма кемнедер йөрәгенә үткәрсә, ул аны ахыргача хөрмәт итә, аңа тугрылыклы.

Дуслашып йөргән кешесе белән аралары суынгач, Хәлил: «Сәет, син юкка аны рәнҗетәсең, ул бит яхшы кеше»,— дип кинәшен бирә башлагач: «яхшы кешедән күбрәк сорала»,— дип, сөйләшүгә нокта куйганы хәтерендә.

Олыгая барган саен, дуслашу, илаһи якынлашу кыенлаша, булганын саклый белү ихтыяҗы туа. Борынгыдан безгә күчә-күчә килгән җырларында халкыбыз, «дуслар кирәк дөнья күтәргә», дип, юкка гына айга карап моңаймагандыр.

Ваһапов белән мөнәсәбәтләре катмарланып китү миен туктаусыз бораулый. Үзгә фикер керми башына. «Игелек» мәшәкатьләреннән бушаганда, күңелендә ике шәхес: Фәридә, Нургали...

Ваһапов юк-барга исе китмәгән кебек, тыштан тыныч, ваемсыз, үпкәсез күренсә дә, аның чиген чыксалар, оясына таяк тыксалар, кышкы йокысыннан уятылган аю мәсле, теләсә кемне чәйнәп өзәргә әзер торуын Сәет исәпкә алмаган, дөресе, белеп бетермәгән икән...

— Миңа аяк чала башлавыңа түздем. Инде минем өлешкә керә башладың,— диде бер очрашуда Ваһапов.— Тычкан җир астын казыган, казыган да, мәчегә тап булган. Шуны онытма!

«Кит»ның бу сүзләрен йогенешле бәйләнү, ваклану, дип тапты Сәет. Ачык базарлы, иркле ил төзибез, дип әтәчләнәбез түгелме соң?

Ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк булыр. Сәетнең аны югалтасы килми. Ут чыкканда, җил астына качырга ярамый.

Сәет белән Нургалинең аралары кыл сыймаслык, үткен пычак кермәслек тоелса да, дуслыклары рухи якынлыкка корылмаган, тышкы, күрсәтмәле аралашу гына булып чыкты. Төше өлгереп җиткәнче, чикләвекләрен яшен сукты. Әүвәл, Сәет Мостафа Гаделевка үпкәләп йөрде. «Күрәсең, теге салган баштан, хуҗасына Сакманов белән очрашулары турында сөйләп ташлагандыр. Кеше үзе телен озынайтмаса, башка зат аның миенә, күңел түренә үтеп керә алмый. Халык: «Кәкре агачта кар тормас, алама кешедә сүз тормас»,— дип юкка гына зарланмагандыр». Атка иярсәң, ат булырсың, тайга иярсәң, тай булырсың», дип тә агай-эне зрә генә әйтмидер.

Сәет, Ваһаповның баш инженеры белән, ачыктан-ачык сөйләшеп карарга булды.

Сөйләшү, аңлашу Сакмановның машинасында булды. «Игелек» башлыгы, алдан уйланылганча, юри хисләнеп, хыялый романтикага бирелеп алды: «Мин Нургали абыйга мәңге бурычлы. Хатыным өчен үч алу юлын күрсәтте, ярдәм итте, хәзер дә мәрхәмәтеннән ташламый»,— дип башлады сүзен һәм озак итеп, бер дә иренмичә, Ваһаповны мәдхия гөлләре белән бизәде.

Гаделев машинаның эчен орынтын-яшертен иңләде дә:

— Әйдә, Сәет Яруллович, йөреп керик әле. Һава яратам мин,— диде.

«Куркып яшәргә өйрәнеп беткәннәр болар»,— дип көлемсерәп алды да, Сәет кунагын якындагы тар тыкырыкка алып чыкты.

— Мин сине, Сәет, яраттым, якын иттем. Безнең чорда сирәк очрый торган ихласларның берсе син. Хәзер минем фикерне тыңла! Акыл казанында кайнат, үзең нәтиҗә яса. Синең сәрхүшләнеп, алданып йөрүеңне теләмим.

— Тыңлыйм, Мостафа,— диде Сәет, тавышына, чыраена ваемсызлык, ис китмәү чыгарып.

— Каты әйтсәм, ачуланма. Үзеңне акыллыга санап йөрсәң дә, мәми авыз икәнсең. Ваһапов синең хатын өчен башын элмәккә тыгар иде мени? Таптың кешесен. Ул элеккеге «тәп-ләп» явызы Андрей Северцевны күптәннән аулап йөри иде. Эзенә төшә, җаен китерә алмыйча интекте. Синең фаҗигаңнан кул җылытып калды. Әгәр дә, җинаять өстендә тотылсагыз, соңыннан хөкемгә тартсалар, аның җавабы әзер: «Хатыны өчен үч алды, бензинны ул алып барды, шырпы аныкы, Северцев тәрәзәдән сикереп, исән каласы иде, Сакманов аны махсус мылтыктан атып үтерде. Кеше каны, кеше җаны аның намусында. Бетте китте. Ул — шаһит кына». Условно алты ай... Синең баш каторгада чери...

— Юкны сөйләмә,— дип кенә әйтә алды башына кургаш яңгырыдай төшкән авыр сүзләрдән каушап калган Сәет. Колакларына ышанмады. Эссе көнне өстенә чиләге белән салкын су тондырдылар диярсең.

— Тукта әле, Мостафа, син — бутыйсың. Ул миңа чын күңелдән ярдәм итте. Барысын да үзе оештырды. Шакал Северцев белән аның нинди алыш-биреше булсын?

— Үзе бу темага керергә яратмый. Сорасаң, җырлый башлый. Ул гадәтен беләсең. Озын телләрнең лыкылдавына караганда, Ваһапов «карьерасын» «тәп-ләп»тә башлаган. Ниндидер кара эшләрендә катнашып, көйгән ис чыга башлагач, коерыкны сыртка салган. Караклар даирәсе сатлык җанны гафу итми. «Тәп-ләп» җитәкчесе судта безнең дусның исемен атаган. Бик күп акча биреп котылган, диләр. Җирәнне дә Северцевны үтертү өчен генә яллаган иде. Экзотика ошап китте үзенә. Хәзер җансакчысыннан ничек котылырга белми. Тегеңәрдә информация күп...

— Аларны мин мәңгегә, кабергәчә бергә берекән, бик якын кешеләр дип кабул итәм. Ваһапов белән Җирәнне...

— Син бик наив кеше икәнсең.

— Мине Җирәннең шефына бирелгәнлеге, тәкъва кеше булуы сокландыра,— дип, үзенекен тәкърарлады Сәет.

— Алар икесе дә артист. Кеше алдында гына шулай кыланалар. Җирәннең Ваһаповка мунча яфрагы кебек ябышып йөрүенең тирәнрәк сере булырга тиеш. Акчага мохтаҗ кеше күренми. Гаиләсе барын-югын да белгән адәм юк. Башка галәмнән, НЛОдан безнең арттан күзәтеп йөрү өчен җибәрелгән, диярсең үзен.

Бу чаклы яңалыкны башына сыйдыра алмаган Сәет: «Ваһапов бит аны чукрак, телсез, әллә нимесмы, әллә яһүдме»,— ди.

— Аз сөйләшкәне өчен генә шулай ди. Мин күп лыкылдыйм, үземә зарар. Янәдән исеңә төшерәм: икесе дә артистлар. Драматикмы, комикмы, коммерческиймы, анысын әйтә алмыйм.

— Җирән миңа хастаханәдә өч ай ярдәм итте. Саклады. Мин аңа бик рәхмәтле. Акчаны да бик аз алды. Зур сумма тәкъдим иткән идем, баш тартты.

— Сере бардыр аның, Сәет Яруллович. Ашыкма. Аның кемне саклаганы соңрак беленер.

— Соңгы җөмләң белән нәрсә әйтергә телисең? — диде эченә суык борчылу, шом йөгергән Сакманов.

— Бәлки, ул сине, терелеп бетмәс борын чыгып качмасын, безгә ул исән килеш кирәк булыр, дип саклагандыр,— ди-ди, көлеп куйды Мостафа. Сүзне шаярту ярына борырга иде исәбе.

— Өрмәгән эттән куркырга кирәк. Ул сразы тешләп ала, иткә төшә.
— Мостафа, зиһенемне бутап бетердең. Аягында басып торганны башына бастырдың. Акылга сыймый... Әхмәдиша абзый «гайре мәгкуль нәрсәләр сөйлисең»,— дияр иде.
Гаделев үзе дә тирәнгә кереп китүен аңлады.
— Бу сөйләшү безнең арада калсын. Икесе дә үчле адәмнәр.
— Тагын бер соравым калды, Мостафа. Син бит без... теге йортны хәл кылганда, анда юк идең. Шунда булган, катнашкан кешедән бүтәнрәк хәбәрдарсың? Читтән күзәтеп тордыңмы әллә?
— Миңа абзый барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде. Хатын белән икебезгә хәтта.
— Бу бит... сату. Мине генә түгел, үзен дә... капкынга тыгу,— диде Сәет, тамагына балык кылчыгы кадалган кешедәй тотлыга-тотлыга.
— Ялгышасың. Ул — тылын ныгыта. Үзенең бу җинаятьтә катнашуын очраклы итеп күрсәтергә тырыша. Салган баштан хаталанган, янәсе. Сразы тәүбә иткән. Бөтен гаеп синдә.
— Ни әйтергә дә белмим. Син минем дөньяга карашымны, якын кешеләремә мөнәсәбәтне үзгәртергә тырышасың кебек. Үзеңне Ваһапов юлламадымы минем янга? Провокация белән. Бар әле син теге охломонны тикшереп, кылларын тартып кайт, дип шефың үзе җибәрмәдеме? Синең алибиең юк.
Мостафа Гаделев үпкәләгән балалар сыман чыраен сытты, авызын кыйшайтты. Берничә адым читкә атлагач, кире борылды.
— Күңелеңне, шикләнүеңне аңлыйм. Безнең мохиттә кругом алдау, ялган, күз буя. Булдыра алсаң, ышан. Көчләмим.
Соңгысы... Мин Ваһаповның матур исемле фирмасыннан киттем. Аерылып чыктым. Мөстәкыйльлек алдым. Мине югалткач, иптәш утлы табада борчак төсле сикеренәчәк әле.
— Нәрсә бүлешмәдегез соң?
— Үз ягына гына каера. Бик күп кирәк аңа. Әллә ничә коттедж салды, берничә квартира сатып алды.
— Кешегә ничә йорт, ничә фатир кирәк соң? Барысында да яшәп булмый ич?
— Малае нечкә сыйраклы марҗага өйләнде. Тегене өч бүлмәле фатирыннан куып чыгардылар. Әттәсе яңаны сатып алып бирде...
«Бу дөньяда мәңгелек кальгалар юк икән. Ваһаповны мин бөтенләй белмәгәнмен...»
Сакмановның «утырып алыйк» дигән тәкъдимен дә кабул итмәде Гаделев. «Башка вакытта, соңрак»,— дип, үз машинасына утырып, китеп тә барды.
Ахыры күңелсез бетәр кебек тоелды Сәеткә бу очрашу-күрешү, кавышу-аерылышуларның. Тоемы алдамый торган иде...
Шул арада Төньяк калавылына да караңгылык иңгән. Күк йөзенә энҗе-мәрҗәннәрдәй йолдызлар сибелгән. Ничек шулай асылынып торалар, егылып төшмиләр икән, мескенкәйләр? Йолдызлар аңа күз кыскандай тоелды. Янәсе, сәлперәеп төшмә, безгә монда бакый вакыт асылынып тору җиңел дип беләсеңме әллә? «Мин шундый карт инде, мин бит әле юньле кешеләрне дә хәтерлим»,— дип, йолдызларга кулын изәп, капканы узды.

## 24

Күк йөзен калын болытлар — кояш сагышлары каплаган көннәрнең берсендә ярдәмчесенә телефоннан Вильсур Садыйковны эзләп карарга кушты Сәет. Сугыштан, орыштан, үч алудан гарык булган иде. Аның, Фәридәне өенә төшереп, тыныч кына, ата мәче кебек мырлап, иркәләнеп кенә яшисе килә. Мөмкинлек бирсәләр, сәясәт белән шөгыль-

ләнер, үзе белгән алымнар, ысуллар ярдәмендә милләтенә, халкына хезмәт итәр. Унҗиденче ел инкыйлабына чаклы мәгърифәт, мәгариф үсешенә мөһим өлеш кергән олы шәхесләрнең эшчәнлеге, тормыш юллары, дөньяга карашлары белән танышып чыкты. Сокланды, тәэсирләнде, үзе өчен үрнәк-өлгеләр билгеләде.

Вильсур Садыйков төркеме белән бәйгене, бил алышуны туктатып, үзара килешү төзеп, бары тик алыш-биреш эшләре белән генә шөгыльләнергә булды. Җитте, булды, күпме кан коелды. Рафаэль, Зөлфия, Анатолий Павлович кебек бер гөнаһсыз кешеләр җир астында ята. Яшәргә дә, яшәргә иде әле аларга.

Бик озак эзләделәр «Эдельвейс» башлыгын. Инде телефоннан тапкач та очрашудан баш тартып кыланды, аңа ышанмады, Сакмановның аңа каршы теге вакыттагы, администрациядәге шикелле, чираттагы тозак әзерләведер дигән фикерендә нык торды. Ахыр чиктә: «Мин риза, тик ике яктан да сакчылар бер тигез санда булсын. Шәһәрдән читтә очрашыйк», — дип, ризалашты.

— Без икәү генә, арадашчыларсыз очрашыйк. Икебез дә рульдә килик. Беребезнең машинасына утырып, икәү генә сөйләшик, аңлашыйк,— дигән фикерне әйтергә кушты Сакманов.

— Акча таләп итмәсме?— диде Вильсур, балаларча беркатлылык белән.

— Фирмаларының банкротка чыкканын беләм ич мин. Безнең икътисадый хәлләребез яхшы. Курыкмасын!

Сакманов очрашу урыны итеп, үзенең Матюшинодагы йортын, «Тасма» берләшмәсе каршындагы мәйданны, башка бик күп урыннарны тәкъдим итте. Вильсур тормышка отыры ябышып ята икән, үләсе килми, үзе өчен аз гына куркыныч күренердәй урыннарны кире какты.

— Кабмин каршындагы машиналар куя торган урында очрашыйк,— дигән тәкъдим алынды Садыйковтан.

—Сез ул тирәдә эшләгән кеше, танырлар, сәламләп вакытны күп алырлар,— диде Сәет, ул тирәдә күренеп йөрүне өнәп бетермичә.

— Зато исән калырга шансы күбрәк булыр.

— Ярый, мин риза. Иртәгә сәгать өчтә.

— Юк, бүген,— дип үҗәтләнде Вильсур. Сакмановка капкын куярга вакытны азрак калдыру иде нияте. Бер тәүлек эчендә ул снайперларын һәр чердак башына утыртып куячак. Америка президенты Джон Кеннедины үтергән шикелле хәл кылырлар үзеңне.

— Шигегез зур, миңа ышанычыгыз аз булгач, бер сәгатьтән очрашырбыз.

Вильсур ике таза егете утырган машинага үзе артыннан барырга һәм күз иңләрлек бер тыкырыкта калырга кушты. Бүрегә кунакка барсаң, этеңне калдырма диләр. Күн пинжәге, дөресе, чуар күлмәге астыннан бронежилет киде.

Ике кара «Волга» тантаналы җыелышка чакырылган кунаклардай янәшә килеп басты. Тынлык. Сәет кунакны үз машинасында көтеп торды да, Вильсур оясыннан чыкмагач, аның янына күчеп утырды.

— Артка утырыйк,— дигән тәкъдимне Садыйков кабул итәргә мәҗбүр булды.— Узып баручыларның игътибарын җәлеп итмик әле.

Шактый сәер иде ике дошмани төркем абруйларын янәшә күрү. Бит Вильсур әмере илә, ничәмә тапкырлар Сәетне теге дөньяга озатырга тырыштылар. Яраткан хатынының, энесенең үлемендә дә аның катнашын инкяр итүе кыен. Мансурны, «тәп-ләп» хуҗасы, «Эдельвейс»ның арка терәге Андрей Северцевны һәм башка бик күпләрне вакытсыз гүр ияләре итүдә дә хәзер озын бармаклы кулларын тез башларына җәеп утырган Сакмановның катнашы юк дип исбатлавы, белгәннәрне шуңа ышандыруы кыен. Шайтаннан иман сорап килгәннәр диярсең үзләрен.

Машинасыннан чыгып, аның ягына атлаганда, Вильсур ирексездән Сәетнең төз гәүдәсенә карап сокланып куйды. Киң каеш белән тарттыр-

ганнан соң да, йөкле хатыннарныкы мәсле бултәеп торган корсагын бер дә хупламыйча капшап алды. «Каян килә бу симерү, диета тота, атнасына бер көн авызына кайнаган судан башка ризык капмый. Бандитны әнә вакыт та, пуля да, симез шашлык белән бәлеш тә алмый. Ярый хет чәченең аклыгы белән аны куа килә. Тиздән ике блондин булабыз инде. Уенда нәрсә аның, белгән юк. Туктале, бу юлы дилбегәне үз кулыма алыйм әле, дөядән биек фил барын белеп торырга тиеш ул».

— Нәрсә, Сәет Яруллович, сезгә тагын безнең тир түгеп тапкан акчаларыбыз кирәк булдымы? Бушлай серкә дә татлы тоеламы? — диде Садыйков, исәнләшү, кул бирешү кебек вак-төяккә кадерле вакытны әрәм итеп тормастан.— Ал байлыгымны, ал соңгы тиенемне, үземә генә кагылма. Кызым әле бала гына, аны үстерәсем бар.

Сөйләшү бурычларны түләүгә, малны бүлешүгә килеп терәлсә, ул, әлбәттә инде, теше-тырнагы белән карышачак. Болай, сүз өчен, дәҗҗалның күңелен йомшарту өчен генә әйтүе. Махы бирмәстән генә. Соңыннан, телен вакытында төйнәп куя белмәве, дуга белән печән чабуы өчен үкенде. Тутый теле аркасында читлеккә керә. Шуңа күрә, көлүе дә сыек чыкты.

Чынында Вильсурның куркуын яшерергә тырышуы иде бу. Кәчле эт алдында боргаланган әнчеккә охшап торуын аңламады.

«Нишләп бу тәртәгә тибә. Бүренең башын табага салсаң да тәгәрәп төшәр, диюләре дөрестер, күрәсең»,— дип уйлап алды Сәет.

— Сүзне, чакырган кеше буларак, мин башларга тиешмендер. Җитди сөйләшүгә әзер булмасаң (бу юлы «син»гә күчәргә итте), мин үз машинама чыгып утырам. Аерылышабыз. Бөтенләй очрашмаган кебек.

— Теге вакытта шуның өчен чакыргач,— дип, акланмакчы булды Садыйков.

— Аннан соң, күпме утлы-яшенле өермәләр үтте безнең газиз башлардан. Мин чүт-чүт исән калдым. Синең күпме егетең әрәм булды. Араларында барысы да шакал булмагандыр. Ул хәлләрне искә төшерсәң,үч сакласаң, янәдән сугыш юлына чыгарга гына кала. Ә мин сине башка нияг белән чакырдым.

— Тыңлыйм.

— Син заманаларның нык үзгәргәнен тоясыңмы?

— Замана гел бер инде ул. Үзебез үзгәрәбез.

Садыйков аның ягына борылып, гаҗәпләнеп карап алды.

— Күптән түгел «хокуклы караклар» җыелышында мөнәсәбәтләрне корал ярдәмендә хәл итү тыела, дигән карар кабул ителгән, бу карарны үтәмәгән, килешүне бозган һәркем үлем җәзасына тартыла, дигән өстәмә ясалган. Чыннан да, урам төркемнәре арасында да канлы бәрелешләр кими бара, авторитетлар утырган машиналар азрак шартлый, ялланган үтерүчеләрнең иҗат дәрте кими, сүрелә килә. Дөрес, башка регионнарда хатын-кыз киллерләр гаярьланып бара, диләр. Татар хатыннары — өй тавыклары — бу дәрәҗәдә күтәрелмәсеннәр иде. Бәлки аларның урыс, хохол, яһүд, азик ирләренә ястык булып яшәүләре хәерлерәктер бу очракта.

Без эшебезне башлаган дәвердәге шикелле (Вильсурның комсомол үткәненә дә ишарә бар иде), «таналар» белән кәеф-сафа кору, төннәр буе рестораннарда типтерү, хәмер белән теләсә ничек шаяру, соңыннан берәр тәүлек ваемсыз гырлап йоклау чоры узып бара. Канлы орышлар, көпәкөндез атышулар, тоткыннар алу, күп кеше катнашындагы җәнҗаллар милиция әһелләренә дәүләткә сводка бирү һәм чираттагы йолдызны алу өчен генә файдалы.

Куркып, сагаеп, почмакка кысылып утырган Вильсур сүз кыстырып куярга җөрьәт итте.

— Без аларга болай да үзебезнең ахмаклыгыбыз аркасында нык ярдәм иттек инде. Бер-беребезне тотып биреп. Мин үзем дә туйдым бу тормыштан.

Көндәшенең фикерен баш ымы белән хуплап, Сакманов үзенең концепциясен ачуны, җәюне дәвам итте.

— Мылтыклар, мәргәннәр бәйгесе чорыннан икътисадый, сәяси көрәш дәверенә кереп барабыз. Хәзерге бизнеста җиңеп чыгар, дәүләт структуралары белән дуслаша, тартыша, ярыша алыр өчен, арадашчыларыбызга, үзебезгә нисбәтән кырыслыкны һәм таләпчәнлекне арттырырга кирәк.

Вильсур, дәресен әзерләп килгән мәктәп укучысы төсле, олы балдаклы кулын (Сәетнең бармакларында бизәнү әйберләре күрмәгәч, балдагын салып калдырмаганына үкенде) өскәрәк күтәрде. Сүз сорый, янәсе.

— Җинаятьчел мохит белән бәйләнештә тормаган сату-алу оешмалары янау һәм талау объектына әйләнәчәк. Сез үзара сугышны, бүлешүне, үтерешне туктатырга дип тәкъдим итәргә чакыргансыз, дип уйлыйм. Мин үзем дә шул фикергә килдем. Арыдым, туйдым.

— Табышыгызның күпме өлеше кораллы саклаучылар, гафу итегез, киллерләр тотуга китә?

Садыйков җавап бирергә ашыкмады. Серне ычкындырып куймагае! Хәер, ул табышыгыз күпме дип сорамый ич.

— Санаганым юк. Ну, яртысы, кырык проценты китә торгандыр.

— Үзара сугышны туктатсак, аларның байтак өлешен кыскарта алачакбыз. Тынычрак йокларбыз да! Күңелләребездә дошманлык сакланса да, ул явыз көч булып тышка чыгарга тиеш түгел.

— Казан каласының тынычлыгы икебездән генә торса, мин риза,— диде Вильсур.

— Без шәһәр өчен җавап бирмибез. Үз ярларыбызга кайтып төшәргә вакыт. Ә саклау-яклау эшләрен без милициягә тапшырырбыз. Без, ниһаять, аңларга тиешбез: бу дөньяны инде усаллык белән җиңеп булмый. Инсафка килергә вакыт,— дигән фикер белән тәмамлады Сәет сөйләшүне.

— Батыр булсаң, батырлан, үлемең булмасын хатыннан дип, хак әйтәләр икән,— дип, шактый сәер җөмлә кыстырып куйса да, комсомол узаманы сөйләшү-аңлашудан шулай ук канәгать иде.

Бик озак сөйләшеп утырдылар Сакманов белән Садыйков ул көнне. Бүлдерүче булмады. Дусларча, кул бирешеп аерылыштылар. Соңыннан Сәет Вильсур белән аңлашуга шул чаклы вакыт вә җегәр әрәм иткәненә үкенде. Чөнки шул көнне үк «Эдельвейс» ширкәтенә башка җитәкче сайлап куялар. Берничә көннән комсомол узаманы бер дә юктан гына төрмә бусагасын атлап уза...

## 25

Ул көнне Сәет Фәридә фатирында кунып калды. Көтмәгән, уйламаган җирдән. Тәкъдирдә шулай язылган булгандыр.

Төньяк калавылында, мунчада юынып кайтканнан соң, мәгъшукасын өенә китереп куйды. Беренче катта, малай-шалай кебек, чапычопы килеп үбешteләр дә, шәфкать туташы өскә менеп китте. Чыгу юлына борылган бәхетле ир күзләренә ышанмады. Әле генә бер җан иясе күренми иде тирә-юньдә. Җир астыннан килеп чыккандай, урам юлында ике яшүсмер аркылы басып тора. Багана башындагы утның яктылыгы йөзләренә төшә. Сәетнең хәтерендә берсе — озын гәүдәле, бөртән битле, калкан яңаклы булып кереп калган. Икенчесе — Дон Кихотның турылыклы Санчо Панчосыдыр инде, тәбәнәк буйлы, карасу йөзле иде. Мәсьәләне нәкъ менә курачы көр тавыш белән, кабыргасы илә калкытып куйды:

— Батя, дай папироску. Курить охота.

Тартырга сорауның бәйләнү өчен алдавыч сәбәп кенә икәнен Сәет яхшы белә. Кеше кулын тәмәкегә тыккан арада, кастет йә башка тимер белән башына китереп оралар. Аңына килгәч, ул үзен эчке киемнән, кан эчендә таба.

Инде шактый шәбәйгән, һәркөнне диярлек спортзалда шөгыльләнгән, кул сугышларында азау теше чыккан Сәет «аучыларны» тукмап, изеп ташлый алыр иде. Пычранасы килмәдеме, ирендеме шунда, алдан әзерләнеп куелган егерме биш патронлы «Марго» пистолетын җәһәт кенә тартып чыгарып, кара көпшәне әле берсенә, әле икенчесенә юнәлтте.

Җавапны татарча бирде.

— Тәмәкем юк. Атып үтерә алам!

Җинел табыш турында хыялланган кәсепчеләр кискен борылып, төп көчне аякка төшереп, бер кеше сыярлык, ярты ягы гына ачылган ишеккә, янгынга тарган сарыклар кебек, берьюлы килеп кысылдылар. Кыска буйлысы житезрәк булып чыкты, куркыныч сызыкны беренче үтте, озынның билдән түбән өлешенә Сәет туфлиенең очын татырга туры килде. Чинап җибәрде. Артларыннан куа чыкмакчы иде дә, Фәридә иңенә килеп уралды. Чит-ят тавыш ишетүгә, аска йөгергән.

— Кемнәр алар, нәрсә кирәк?

Сакманов ачуыннан еш-еш суласа да, үзендә шаяртырлык көч тапты.

— Ике егет сине эзләп килгәннәр. Фәридә апа чакырган иде, диләр. Ул башка подъезда тора дип, чыгарып җибәрдем.

Җитди итеп өстәде:

— Шпана. Чишендерергә иде ниятләре.

— Сине шулай дулкынланган хәлеңдә өеңә җибәрә алмыйм. Миндә кунасың,— диде ханым катгый рәвештә.

— Өй артында машинам тора. Шоферга әйтеп килим.

— Юк, урамга чыгармыйм. Саклап торып, таш белән тондырырлар. Телефоннан әйтерсең...

Иркәләнеп елмаю. Тагын берәү, икәү, тулы бер атлама-обойма. Мә ал, барысы да сиңа... Арзанлы бүләк кадерлерәк була. Ир-зат ялындырып, кыландырып тормады. Үзенең дә Фәридәне ташлап китәсе килеп тормый иде. Фатирга күтәрелеп, чишенеп, машинасын, шалтыратып, кайтарып җибәрде. Хуҗабикә кофемы, чәйме әзерләү хәстәренә керешге.

Сәет кулын чайкап алырга дип ваннага кергән арада телефон «телгә» килде. Ирексездән, ачык ишектән, хатынның бик теләмичә, соңрак гасабилы, ачулы җаваплары колагына керде.

— Юк, дидем ич. Бүген дә, иртәгә дә, вообще вакытым юк. Үзем генә түгел. Неважно. Больше мине борчыма. Үтенеп сорыйм.

Шап итеп трубкәне куйганда, куе кызыл каны йөзенә менгән иде. Шалтыратучының күзләре шикелле үк каты, әрсез куллары тәненә, күкрәгенә кагылгандай булды. Нәрсә ди бит оятсыз: «Мин мәхәббәтемнән болай гына баш тарта торган ирләрдән түгел. Син барыбер минеке булачаксың. Җылы якка күчеп китәбез». Сорамый, таләп итә. Шәхси милке диярсең. Ярый әле, Сәет тәрбияле, йөгереп чыгып телефонга ябышмады, киресенчә, юыну бүлмәсендә юри озак маташты. Берни булмагандай, өстәл янына чыгып утырды, кофега өрә-өрә, сорап куйды.

— Әллә кемдер шалтыратты инде? Мине эзләмиләрме? Теге егетләр...

Йөзе, аның теләгеннән башка, үпкәчел төсмер алды, иреннәре бөрешге.

Фәридәгә, үзен кулга алып, җавапны әзерләп куярга вакыт бирелгән иде.

— Энем, синең кайнишең, кунарга кайтыйм әле, ди.

— Мин алып биргән малосемейкада кунасы килмимени? Аягым өши димс?

— Миндә шактый вакыт яшәде. Өйрәнгән инде. Күмәчкә май ягып биримме?

Күмәчкә май. Тәмледер ул. Үзең генә ашасаң. Кем беләндер бүлешмәсәң! Ул сине белеп, танып йөри, маңгаеңда тәкә мөгезенең үсүен күреп, шуннан ләззәт алып яши. Төрмәдәге төсле: мин сине күрәм, син мине юк. Араларында кемдер торганлыгын Сәет элек тә сизенә иде. Сер ныграк

яшергән саен, тирәнгә чәчкән орлык кебек, бүлтәеп, бүселеп чыга. Кем икән ул гыйфрит? Фәридә үзе әйтмәячәк. Ник калды ул кунарга, белмичә яшәсә җиңелрәк булыр иде. Теге хәшәрәтләр юлга чыкмаса, дүрт хатынының дүртесенә дә, «мин бүген фәләнегез янында кунам», дип ялганлап, барысын да, шәм төбенә утыртып, үз бүлмәсенә кереп ятып йоклаган Хива ханы мәсле, хәзер киң ятагында детектив «кисеп» ятыр иде.

Ишекне каты итеп ябып, чыгып китәргәдер дигән дуамал уй да үтте башыннан. Торып китә алмады. Әллә Фәридәне яратуы тоттымы, әллә үтәлмәгән бурычы тоткарладымы, ир урынында калды.

Бүген барыбер араларны ачыкларга кирәк булыр. Ак кырау төшәр микәнни аларның сират күперләрен кичеп уянган мәхәббәтләренә? Гыйшык сөрмәсе шулай тиз җеберме икән? Әйе, аларның мөнәсәбәтләренә Сәеткә билгесез явыз көч кизәнә. Өтек өмет белән, дөресе, хыял мунчаласыннан аркан ишеп яшәүгә ул риза түгел! Җанын көнчелек, хәтәр упкындай билгесезлек куши. Тимердән чокылмаган ул да.

— Йөрәгемә яра салудан тәм табасың, Фәридә. Болай килешми.

— Вәгъдә — иман, Сәет. Әйткәнемнән баш тартмыйм. Ашыктырма инде, зинһар, дим. Соңрак барысын да белерсең.

Кашларын сындыргалап, кара күзләрен өстәлгә кадап, өстәде.

— Тиздән мәңгегә синеке булырмын.

— Иясез ишәккә хуҗа табылыр.

— Сәетҗан, алай ук тупас кыланма инде. Вәгъдәле кыз өч елдан соң да әйләнеп кайтыр,— дип, шаяртуга борырга тырышты Фәридә.

— Төче сөйләргә, алдашырга өйрәнеп киттең түгелме? — дип, араларына бозның каян иңгәнен белмәгән Сәет, хатынның җанын көйдерде. Чын-чынлап үпкәчел тавыш белән өстәп куйды:

— Сабыр канатларымның сыну ихтималы бар. Аннан гаепләнне эзләп йөрербез. Сак белән Сок кебек.

— Аңлыйм мин сине,— дип, арттан килеп Сәетне кочаклап алды ханым. Үзенең дә йөрәге өзгәләнә, киеренкелек суларга бирми, тынына ябыша.— Сине түземле, чыдам, ышанучан булган өчен яраттым...

Мәгәр дөресен әйтә алмый. Ялганларга хыялы җитми, теле дә әйләнми. Фәридә үзен сыек сумалага килеп кунган карга кебек хис итте. Карга коерыгын тартып алырга көчәнгән арада, башы ябыша, башын йолкып алган мәлдә, коерыгы кереп бата. Талкынып тәк тора икән, ди. Фәридә дә менә шулай ике арада калды. Сәетне ярата, аның белән бергә булырга тели. Явыз Җирәннән, җәһәннәмнән курыккан кебек, шикләнә, шөлли.

— Сәет, зинһар мине ташлама, минем синнән дә якын, синнән дә кадерле кешем юк.

Каен күмере төсле кара күзләренә үтә күренмәле яшь бөртекләре төште.

— Ир-атның төнге кояшы — хатыны, диләр. Минем дә гел кояшлы буласым килә. Тик безнең арада бернинди яшертен сер, әйтеп бетерелмәгән ялган, алдашу калырга тиеш түгел,— дип, үз сүзендә нык торды Сәет.

— Синең янында көчсез бер күбәләк булып очып йөрисем килә.

— Күбәләк бер көнлек ул, Фәридә. Син миңа гомерлеккә кирәк.

— Чагыштыруым уңышлы булмады. Хатын-кызга бата инде ул.

Сәетнең бераз тынычланганын сизеп, баягы телефон турында Фәридә үзе сүз катты.

— Сине телефон шалтыравы борчый инде.

— Борчый дип...— Ир йөзенә, гәүдәсенә битарафлык чыгарырга тырышып, җилкәләрен сикертеп куйды.

— Машинаны кайтарып җибәргәнгә үкенеп утырам. Башкасы о'кэй.

— Шалтыраткан кеше минем иске танышым. Сиңа хәтле очрашкалаган идек. Хәзер бәйләнә. Бергә Казаннан китәргә димли. Кырым белән кызыктыра. Яратмаган кешең белән оҗмахның да тәмугтан гайре булуын беләм.

— Озатып куярмын. Эскорт белән.

Сәет хатын-кызның теңкәсенә тию, бәгырен яралау алымнарын яхшы үзләштергән иде.

— Синдә бала йөрәге, көнче йөрәк.

— Кырыктан узган кешене шулай алдап йөртсәләр, сакаллы сабый да, куш йөрәкле дә булырсың,— диде Сәет, шактый төксе тавыш белән.

— Сәет, җанымны телгәләмә, зинһарлап үтенәм. Вакыты җиткәч, барысын да сөйләрмен. Хәзергә шуны кистереп әйтә алам: мин сине, сине генә яратам. Үзең хәл ит. Тагын өч ай артыңнан, эт баласы кебек, ияреп йөрмәм. Артык мине игәүләмә.

Ир-зат бәйләнүе, сорау алуы белән кире чыгуы кыен булырдай саз- лыкка кереп баруын аңлады. Үзеңдә тукталырга көч тапты. «Ни хакы бар аның шулай бәйләнергә. Аның өчен кем ул. Үзеңне бел, куып чыгармаган өчен рәхмәт әйтеп, артыңны кысып кына утыр. Синнән, борынгы җырдагы кебек, «Старый муж, грозный муж» чыгарга мөмкин. Җаның, тәнең мәхәббәт белән тулы. Фәридәнең сулышы күтәрелүен, төшүен, йөрәгенең тоясың. Берәү белән дә очрашмыйча, сине көтеп утырырга тиеш булганмы ул? Гарип-горабә түгел ич, табигать үзенә тиешлесен таләп итә. Үзе ләтыйф, акыллы, уңган».

Сәетнең катлаулы уйларын Фәридәнең кайнар сүзләре, сулышы өзде.

— Сәетҗан, синең белән очраша... яши башлаганнан соң, үземә берәүне дә, аны да якын китергәнем юк. Балабыз бары тик синеке булачак.

Сәетнең гаҗәпләнүдән, югалып калудан ябылырга хәле җитмәгән иреннәренә Фәридәнең кайнар авызы кушылды. Барча үпкә-сагыш, кайгы-хәсрәтләр, көндәшләр, дөнья мәшәкатьләре онытылды. Сөю-сәгадәт сулышы гына калды бар җиһанында.

## 26

Бәгырьгә төшә торган, ямьсез, тәмсез озын-озак яңгырлардан соң, тылсымлы нәкышьләргә бай, ямьле әбиләр чуагы килде. Кояш нурлары җиһанга җылылык сирпеде, адәм балаларын яшәешкә җилкендерде.

Чын-чынлап терелеп, депутат урыны өчен көрәшеп йөргән Сәет һәр яңа көн өчен шатланып яшәде. Шул ук вакытта тормышның төрле кыйбла-кыйтгаларын, ачысын-төчесен күргән кеше буларак, ул бер нәрсәгә дә гаҗәпләнмәскә, һәр шәйне үз табигыйлегендә кабул итәргә өйрәнде. Үзенә үпкәләп йөргән Нургали Ваһаповның телефоннан шалтыратуын гаҗәеп бер күренешкә санамады. Әнә бит бетмәс-төкәнмәс күренгән пычраклардан соң, һава ничек сафланып, яңа юылган тәрәзәләр төсле чистарып китте.

— Исәнме, браток. Ваһапов әле бу.

Шул ук калтыравык, дерелдәвек тавыш. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, төп фикеренә күчте.

— Минем предложение барые. Табигать кочагына чыгып керергә. Пикник диләрме әле? Өч көнлек дөньяда яшибез, ял итеп калыйк бер.

Саргаеп кайгыга төшмәсә дә, җаны телгәләнмәсә дә, Сәет араларыннан кара мәче үтүгә борчылып, эче пошып йөри иде. Нургали кебек «уникаль» кеше белән аралашуы кызыклы, гыйбрәтле иде аның өчен. Айгыры айга сикерсә дә, аңа да «дуслар кирәк икән дөнья күтәргә». Шулай да Сакманов тәкъдимгә мөкиббән китеп, сикереп төшмәде. Вакыты да юк, күңеле дә тартмый. «Кит»ның аны эзләп табып, мәҗлескә чакыруына артык сөенмәвенең сәбәбен үзе генә белә: ашау-эчү табынында янәшә утырып, хәмер белән җылынып алгач, мәҗбүри рәвештә диярлек туа торган аңлашу-төрттерүләргә ул әзер түгел. Ихтыяҗы юк. Һәркем үзе белгәнчә, булдыра алганча, тәкъдирендә язылганча яши. Дәшүченә рәнҗетмичә, тагы да читкәрәк тибәрмичә генә баш тартасы иде.

— Чакыруыгыз өчен рәхмәт. Тик, Нургали ага, ачулана күрмәгез, кәефем бер дә әлләкем түгел. Теге хәлләрдән соң, үзегез беләсез, миңа эчәргә ярамый. Мәҗлес күрке җибәреп, бүкәй булып утырасым килми.

Чыбыкның теге ягында куркыныч тынлык урнашты. Табигатьтә агачларны тамырлары белән алып ташлый, хәерче йортларның түбәләрен туздыра, кешеләрне хәвефкә сала торган афәтле давыл алдыннан була торган пошымлы, сәер тынлык. Ниһаять, тавыш килде:

— Ничек инде дуслар, пусть иске дуслар чакыруыннан баш тарта аласың? Әлләкем булма әле! Йөрәгеңне йон басканмы әллә?

Нургалинең үпкәчел, рәнҗүчән, хәтере калучан холкын белгәнгә, аның нөктәле төрттерүенә бик исе китмәде. Аның алдында йөз суы түгәргә җыенмый. Мәгәр соңгы җөмләсе йөрәгенә тиде. Шул сүзләр белән Ваһапов аны Зөлфиясе өчен үч алу юлына алып чыккан иде. Адәм баласын хәтер йөртә. Хәтернең хәтерен калдырырга ярамый.

— Ярый, мин риза. Миннән ни, нәрсәләр кирәк булыр?

— Барысы да әзер. Көт, сәгать дүрттә синең арттан керермен. Минем машина белән барырбыз. Үзеңнекен алма!

Юри пышылдауга күчәргә итсә дә, тавышы барыбер гадәти кешенең көчәнеп кычкыруыннан катырак чыга.

— Кызлар алыйкмы?

— Андый нияттә булсак, мин үз кызымны — Фәридәне чакырам.

— Юк, юк. Үзебез генә ял итик әле бер. Ирләр кампаниясе.

Нургалинең тәкъдимен кабул иткәч, Сәетнең бер-бер җаваплы эшкә тотынасы килмәде. Кәгазьләрен караштырды да, полковник Гаяров белән сөйләшеп алды.

— Бездән көнләшеп, кызыгып, креслоңны саклап утыр әле анда кем, иптәш будущий генерал. Без — маевкага чыгабыз.

— Үзегезне тәрбияли, күңелегезне күрә беләсез, бывший хәерчеләр. Кемнәр белән?

— Ходай яраткан колына чыгарып куяр юлына... Ваһапов чакыра кунакка.

— Соң сез аның белән...

Гаяров тозы-борычы үзендәге, симез мишәр сүзен кыстырды.

— «Кит»ның дуслары берәм-берәм яныннан киткәч, хатасын аңлаган. Тәүбәгә килгән. Соң булса да, уң булсын, диләрме әле. Куенымда таш йөртмим бераүгә дә.

— Вильсур Садыйковка дамы?

— Хәтта аңа да?

— Ул бездә утыра. Шуны беләсеңме соң әле?

— Кит аннан! Мин шатланыр дип, шаяртасың инде. Ә «минә» — башкорт әйтмешли, до лампочки.

— Билләһи, дим.

— Элеккеге гөнаһлары өченме?

— Юк шул. За мелкое хулиганство. Бик баналь бер нәстә. Яшь хатынын санаториягә озатып, өйләренә, исерек килеш, секретарьшасы Сараны алып кайткан. Иң кызык вакытларына тещасы килеп кергән. Үз ачкычы белән ачып. Кухнядан пычак алып, кодагый боларга ташланган. Вильсур чәчәк вазасы белән яраткан әбисенең башына орган. Реанимациядә ята һаман да.

Хәзер Садыйковның башка гөнаһларын тартып-тартып чыгарабыз. Безнең системаның эш тәртибен сиңа сөйләп торасы юк. В курсе. Сезнең өчен дә куркам әле. Бергә җыелышсагыз, криминаль эшне көт тә тор.

Малаена машина алып бирешкәч, Гаяров Сәеткә нисбәтән масаеп, эреләнеп, һаваланып сөйләшүен туктатты, якынаеп китте. Трубкәне куяр алдыннан: «Сәет Яруллович, сак бул», — дип өстәүне кирәк тапты.

Фәридәгә дә хәбәр салды.

— Эфиоп гүзәле — аппагым, мине югалтма. Бабье лето белән хушлашып керергә булдык. Кайтканда, сиңа сугылырмын. Бәлки, куна-куна калырмын.

— Ярый, Сәетем. Зинһар, эчә күрмә. Ярый башлагач, үзем әйтермен. Җылы йон кофтаңны ки, эшләпәңне дә онытма. Башыңны сакла.

Нәкъ сөйләшенгән вакытта, Сакмановның Ибраһимов проспектындагы офисы янына биек тәгәрмәчле, Рәсәй юлларында да яхшы йөри торган «Джип» машинасы килеп туктады. Күтәргә дә, күттерергә дә яратмаган Сәет аларны урамда каршы алды.

Йөртүче урынында, озын чәчләрен талкытып, Җирән кукыраеп утыра. Машинаның эчен кара пыялалар каплый. Ай тотылган күн кебек, берни күренми. Арткы утыргычка кереп оялагач кына, Сәет тәүфикълы песи мәсле, почмакка посып утырган Мостафа Гаделевны таныды. Борчаклары пешә иде аларның. Сабыйларча сөенеп, тегенең кулын каты итеп кысты.

— Кайнар сәламнәр.

— Сине күрүгә шатмын,— диде ничектер боегыбрак утырган Мостафа.

Кайсы якларга юл тоту хакында сорашу кабул ителмәгән: чакыручы, машина хуҗасы һәм Тәңре кулында барысы да.

Машина Казансу елгасы күпере аша үтеп, шәһәрне уң якта калдырып, урап-чолгап, авылара юлдан китте, урман ызаны белән тәгәрәп, Сакмановка таныш булмаган күл кырыена килеп туктады. Юлны бармагы белән Ваһапов күрсәтеп барды. Табигатьнең искитмәле хозур бер почмагы булып чыкты алар килеп бөялгән урын. Тирә-юньдә салават күпередәй төрле төсләргә манчылган куе катнаш урман. Аяк астына төрле төстәге яфраклардан «әбиләр түшәге» җәелгән. Өсте кара сулы түгәрәк күл кырыен вак-төяк агачлар белән камышлар баскан. Кошлар тынган. Кемнеңдер елларын чигерүче саташкан күке тавышы да ишетелми. Шомлы тынлыкны Сәет ошатмады. Күңеленә аңлатуы кыен булган курку, шүрләү, шөбһә менде. Мәңгелек табигать кырында тормышларының төп өлешен яшәгән дүрт ир басып тора. Әйтерсең лә алар, Көнбатыш фильмнарындагы алып сатарлар, малкуарлар кебек, араларын ачыкларга килгәннәр. Хәзер шатыр-шатыр атышу, кычкырышу башланыр кебек. Сакманов бу авыр халәтеннән арынырга тырышты. Җитди итеп уйлаганда, куркырлык нәрсә юк иде. Җирән яугир яннарында, теләсә нинди дошмани көчне ник туганына үкендерә ала. Үзе дә чегән арбасыннан төшеп калганнардан түгел.

Бу тукталыш барыбер гайре табигый тоелды аңа. Гаделевнең дә кәефе югарыдан түгел. Вәгъдә ителгән шашлык исе борынны кытыкламый, күңелле кампаниянең эзе дә күренми. Нигә бирегә алып килде икән? Убырның элек тә пәрәнҗәле сәерлекләре җитәрлек иде.

— Нургали агай, нинди урын бу? Учак эзләре күренми, безнең килүне шатланып көтеп торган адәми затлар да күзгә эленми?

— Ашыкма, күрерсең! Барысы да алда.

Тавышы гадәттәгечә гырлап, киселеп чыкты, эчке дулкынлануны, кулларының калтыранып алуын бераү дә сизмәде. Ваһапов машинадан «Посольская» шешәсен алды, капотка алдан киселеп куелган ипи белән казылык, дуңгыз мае, калын пыялалы стакан куйды.

— Чит кешеләрсез, шау-шусыз гына синең булачак депутатлыкны билгеләп үтик әле. Бусы — бер. Икенчедән, Мостафа энекәш миннән аерылып, башка чыкты. Ул хәзер, минем шикелле үк, директор самостоятельного предприятия.

— Булмаган, тумаган депутатлыкны юып юешкә калырбыз,— дип, «Игелек» хуҗасы чын күңелдән карышкан булды.— Икенче турдан үтү өчен шактый акча түгәргә кирәклекне үзе генә белә. Бу сәяси юлга чыгуын Ваһаповның хупламаганын да сиземли.

«Кит» стаканга тутырып аракы салды.

— Үзем шәхсән примир күрсәтәм. Сезнең исәнлек өчен,— дип, бу юлы ялындырмыйча, күкрәк тирәсенә шап-шоп сукмыйча, чыраен да сытмыйча чәркәне бушатып куйды. Ипи капкан булды.

— Мине хурмәт итсәң, эчеп куй,— дип, тулы стаканны Гаделев кулына тоттырды.— Соңрак җырлап бирермен... Биермен дә, бәлки.

Тәкәллефле көлеп куйды. Күзләренә иңгән явыз шатлыкны биек машинаның почмагында чүмәшеп торган Җирән генә күрде.

Мостафаның ир-ат сый-хөрмәтеннән баш тарта торган гадәте юк. Араларындагы киеренкелек аның да җанын телгәли. Элеккеге баш инженер тамагына капкалаган арада, шешәдә калган аракы стаканга сыеп бетте. Нарасыйлар күз яше кебек, үтә күренмәле сыекчаны хуҗа Сакмановка сузды.

— Тот әле, браток, кәеф-сихәтләрен күтәреп җибәрик. Бу фани дөньяда барыбыз да кунаклар гына. Берәү дә ике тапкыр яшәми.

— Сезгә билгеле хәлләрдән соң, мин болай ук эчә алмыйм. Бераз вакыт бирим әле. Йотып кына куйсам ярамасмы?

«Кит» Гаделевка әйткән сүзләрен кабатлады.

— Мине хурмәт итсәң, шуны гына каплап куй.

— Шуннан гына торса. Нихәл итмәк. Авыр көннәр килде татар халкына,— дип, тынын ухылдап чыгарды да, бушаган урынга утлы сыекчаның яртысын агызып, калганын җәһәт кенә җиргә түкте. Җирән генә сизде «баҗа»сының хәйләсен.

— Күлне карап килик,— дип, очарга җыенган бөркет мәсле, кулларын-канатларын як-якка җәйде кунакчыл Нургали.— Нинди гаҗәеп матурлык, хөррият.

Ваһапов машинасының арткы көпчәгенә барып типте. Һавасы чыккандай тоелды. Бүген аны йөртүче гамәлен дә башкарган яугиренә, ым белән генә, көпчәкне тикшерергә кушты. Машинаның тәртиптә икәнен һәм Ваһапов курткасының эчке кесәсендә корылган наган барын тәгаен белгән, нидер сизенгән Җирән бу әмерне үтәргә ашыкмады. Булачак тамашаның бердәнбер шаһиты, «афишага баккан сакалбай кебек», читкәрәк китеп, күзәтүендә булды. Үзенә нинди язмыш әзерләнгәнне хәтта ул да белми. Бүген иртән, әлеге сәфәргә җыенганда, хуҗасы аңа тимер шкафыннан наганын алып бирде, чистартып, майлап, корып куярга кушты. Җирән аңа ялланганнан бирле, Ваһаповның кулына корал алганы юк иде. Белүенчә, табигать кочагына якын мәзһәптәшләре — Сакманов, Гаделевләр белән чыгарга җыена. Гаҗәбе: гадәттә азык-төлекне мул алдырырга яраткан Ваһапов бу юлы шашлык ясарга, тавык тутырырга кушмады, уылдык, яраткан мәрсин балыгын сатып алырга да кеше җибәрмәде. Үзе дусларын ямьле көзне бергәләп озатырга чакырды. Җирән кебек күпне күргән, «су асты агымнары»н да тоеп яшәгән, тәҗрибәле шымчы өчен дә «күп нокталы» урыннар җитәрлек иде. Егерме биш патрон сыешлы «пушкасын» әзерләтүен, «бу сакаллы сабыйлар, салып алгач, чыпчык йә буш шешәләргә атып уйнарга җыена торганнардыр», дип юрады. Үзе дә аңлата алмаган сәбәп белән, шаярып, кыстыргычка чын пулялар белән бушларын аралаштырып беркетте.

«Атламаның бушлары чыпчыкларга, тулылары шешә шәрифләренә»,— дип, яраткан шөгылен елмая-елмая башкарды.

Куәте миләренә менеп, кан хәрәкәтен тизләткән шәраб, кунакларның кәефләренә дә уңай тәэсир ясады. Ни өчен дип әле йөреп килмәскә, кулларны сихәтле күл суында юып алмаска? Һәркайсы үзенә бер тар, камышлы сукмак сайлап, лайлалы яр буена төште. Мостафа өлгеррәк булып чыкты, кулларын чәпелдәтеп, сөйләнә үк башлады: «суы иртәнге сөт кебек җылы, тагын берәр стакан кәксәк, коен...»

Сүзне, тынлыкны ату тавышы кисте. Сәет, ялт итеп, мылтык авазы килгән якка борылганда, арты белән машинасына терәлеп баскан Ваһапов кулындагы кара даҗҗалдан чыккан икенче кургаш Гаделев тәненә кереп ята иде. Сакманов корал көпшәсеннән чыккан аксыл төтенне һәм Ваһапов кулының аның тарафына борылганын күреп, берни аңышмыйча, зиһен төпкелендә уянган, үз-үзеңне саклау исемле табигый сизенүе белән,

аңсыз рәвештә, сыгылмалы гәүдәсен камышлар арасына ташлады, бер-бер артлы яңгыраган ике шартлауны ишетмичә, пычракка барып төште...

Машина артыннан барысын да күреп, ишетеп торган Җирән омон киеменең киң каешына кыстырган кечкенә наганын алып, якындагы юан агач артына сикерә. Җиргә сыена. Нургали камышлык эченә, суга егылган корбаннары янына барып, тикшереп тормыйча, пистолетын алга сузган килеш, «Джип»ның артына чыга.

Җирән — хуҗасына күз ташлый. Явызлыктан әллә нинди төскә кереп, чалшайган битне танымый. Кешенең йөзе — тәрәзә, анда барысы да күренә, диләр. Акылы йөгәннән ычкынганы, шашканы күренеп тора. Беренче булып атарга Җирәннең кулы күтәрелми.

— Ташла мылтыгыңны! Артка чиген, хәшәрәт!

Урман ягыннан килгән бу әмер, кызышкан үгезгә кызылны күрсәткән мәсле тәэсир итә. Нургали өн килгән якка төзәмичә, ата башлый. Мәче җитезлеге белән икенче агач артына сикергән Җирән хуҗасының пистолет тоткан кулының мускулына пуля озата. Иңбашына кургаш эләккән кул бау төсле сәлперәя, пистолет шап итеп җиргә төшә. Ике елдан артык Ваһаповның һәр әмерен, теләгген, өй эте кебек үтәп яшәгән ялчы куркыныч сызыкны җиңел үтә. Һәркемнең гомере бер генә, җаны газиз шул. Теләсә нинди бирелгән кол да тормышына куркыныч туганда, тешен күрсәтә, үзен яклау хәстәрен күрә.

— Бу — мин, тукта! — дип, гырылдый, мөгери, ыңгыраша Нургали. Көпшәсен аска төшереп, үзенә якынлашкан Җирәннең күзләренә күтәрелеп карарга көч таба. Салкын, мәрхәмәтсез, котып бозыннан башка нәрсә күрми. Йөзендә иман, мәрхәмәт әсәре таба алмый.

— Безнең хушлашу сәгате болай да якынлашып килә иде. Үзең ашыктырдың. Арба көпчәген югалтты. Теге мәетләрне бирегә алып мен!

Үзенең хуҗа, кит, пахан, патрон, босс, шеф икәнлеген онытмаган, Җирәннең сүзсез буйсынуына өйрәнгән Ваһапов карышырга булды: «Үзең алып кил, без аларны күл буена күмик. Юкса, икебезгә дә — каюк». Җирән наганыннан шул мизгелдә үк чыккан пуля туфлиенең очына килеп кадалды. Яугире элеккеге сәрвәрен күз уңыннан төшермичә, иелеп, икенче пистолетны кулына алды. Нургали бер кулы белән ярасын кысып, лап-лоп атлап, яр буена китте. Гаделевның авыраеп киткән җансыз гәүдәсен көч-хәл белән сөйрәп машина янына китереп салды. Икенче мәет артыннан китте. Мәгәр Сакманов егылган урын буш иде. Җир йоткан диярсең үзен. Су астына китә алмый, бик сай, куе камышлык. Пуляның аңа барып җиткәнен, Сакмановның гөп итеп егылганын үзе күрде. Могҗиза... Ваһаповның озак маташуын хупламаган Җирән, ике кулына ике пистолет тоткан килеш, яр буена килде. «Юк ул монда, качканмы, җир астына кереп киткәнме? Эшләпәсе генә йөзеп йөри». Нургали яр буена, шома лайлага ятып, капшана башлады, янына ук килеп баскан Җирәннең чалбарына исән кулы белән ябышты, үзенә тартып, егарга азапланды. Селкетә дә алмады. Бетон багана диярсең. Икенче аяк Ваһаповның авызын, борынын җимерде. Шарлап кан ага башлады. Анык бер карарга килгән Җирән чираттагы әмерен төшерде: «Машинага кереп утыр!».

Ваһапов машинасына көч-хәл белән менә алды. Ике шартлау тынлыкны бүлде. Нургали исән кулы белән янтавына, корсагына кергән кургашларны тотарга тырышып, буш урындык ягына авып төште.

Җирән каударланмыйча гына пистолетларын каешы астына кыстырып, тәкәне җилкәсенә алган сабан туе батыры кебек, Мостафа Гаделевның гәүдәсен арткы утыргычка күтәреп куйды. Күл кырыен, агачлар арасын күзләргә кереште. Сакмановны эзләве иде аның. Фәридәгә, аның яраткан хатынына, бәйләнеп йөргән кешене исән калдырырга исәбе юк. Артык шаһиты да кирәк түгел. Ваһапов сүзе хак булган: Сакмановның башын бизәгән кара велюр эшләпәсе генә, җиңүчене ирештергәндәй, су өстендә уйнаклап, йөзеп йөри. Гәүдәсе беркая да күренми. Аяк эзләре дә

калмаган. Жирәннең ачуы кабарды. Нургали пистолетын алып, җан дошманы булып киткән эшләпәгә өч пуля утыртты. Теге явыз, ирнең үзенә тишекләр ясавына исе дә китмичә, җил ритмына буйсынып, чайкалуын дәвам итте. Хуҗасын көтә иде ул.

«Мафия бессмертна»,— дип уйлап алды да, Жирән әле генә атыш барган урыннарны тикшерде, аягы белән кан эзләрен сөрткәләде дә, чит ил машинасыннан кирәк-яракны, радиотелефонны, мәетләрнең акчаларын, кулларындагы затлы сәгатьләрен үз кесәсенә күчереп, автомобильнең ягулык савытының өстен ачып, анда утлы шырпы ташлап, үзе читкә сикерде. «Джип» яна башлады, бераздан ут салюты бирде. Жирән янгынга якынрак килеп, саубуллашкандай карап торды, пумаладай озын «чәчләре»н, башыннан йолкып алып, утка ташлады. Глобус кебек такыр, йомры, чәчсез башына кара берет киеп, биштәрен кулына алып, ашыга-ашыга урманга кереп китте. Кечкенә бер аланда тукталып, Сәетнең кайтуын көтеп утырган Фәридә Мотыйгуллинаның өй телефонын җыйды.

— Фәридә, без — азат.

Жирәнне таныса да, берни аңламаган ханым:

— Нәрсә булды? Кем, каян азат? — диде.

Артык хәбәр биреп ташлаганын аңлаган ир сүзне кыскарак тотарга булды.

— Минем белән Евпаториягә китик! Анда йорт алуым турында беләсең. Чит илдә яшәп калыйк.

— Сакманов кая?

— Тиешле урынында.

— Кайда?

— Теге дөньяда. Минем тәкъдимгә ризамы?

— Юк... Мин Сакмановтан бала көтәм. Шуны үстерәчәкмен. Мине артык борчыма. Үзеңә кирәген алдың. Сәет исәнме?


— Үкенерсең!

Ханым белән сөйләшүдән соң бөкерәеп, кечерәеп калган Жирән поезд станциясенә юл алды...

Сәет Сакмановның киләчәгенә күрәзәлек итүе кыен. Әгәр исән-имин калган булса, ул, әлбәттә, Фәридәсе янына кайтып егылыр. Киләчәктә яхшысы да, гарасатлы җилләре, зәмһәрир суыклары да булыр. Кешедә кешене хөрмәт итү чорына якынлашып килгәндә, бәлки, ул да халкына хезмәт итәрдәй файдалы шәхес булып үсеп китәр. Кайгы-хәсрәт ул — тормышның бәхет белән чиктәш буразнасы, диләр бит...

*1995—1996.*

## ШИГЪРИЯТ



## Зиннур Мансуров

### Фәрештәгә әверелү

Әүвәлгеләр кылган әүлиялык
әллә ялган шунда, әллә чын:
шәһит киткән синең һәрбер затың
ничек фәрештәгә әйләнсен?!

Хаталанмас милләт хадимнәре
әллә шуңа ихлас ышанган;
мәликлеккә дәгъва әйләгәндәй,
кемдер бер янганда өч янган...

Яугиреңә ясин укылганда,
көндәшләрме әллә көлешә:
«Күгәрчендәй ак-пакь кавемнәргә
фәрештәлек күбрәк килешә,
фәрештәлек күбрәк килешә...»

Юансыннар, имеш, югарыдан
Аллаһ вәхиләрен иңдереп...
Кемнәр безгә канат текмәк була,
әҗәл белән иңгә-иң торып?!

...Кардәшләрем рәхмәт юлларының
томанына кереп күмелә.
Бәхетлеме шулай фәрештәгә
әверелгән халык —
кем белә?

## Татарлык

Имсез чирне ачкан Шагыйрь: «Татарлык...»
Сөйли китсәң, телне бизгәк тотарлык.

Сабыеның тырнаклары астыннан
ләззәтләнеп кер эзләве аз сыман.

Әйе, Иисус тәресеннән кан саркый...
Зөһрә кызны кем соң Айга кадаклый?!

Ханбикәсен биреп бөлгән сәүдәгәр...
Татарлыкта «тарлык» дигән сүз дә бар.

Өләшкәндә... дәүләт алган бар кавем.
Бакчы, аның «Җомга көн», дип бармавын!..

«Хәсәд, кинә илән тулган татарлык,
төяб илтеб Мәкәрҗәдә сатарлык».[1]

...Менеп татар «җеназасы-аты»на,
әләк белән китә Аллаһ катына...

## Сәйдәш ялгышы

*(Баллада)*

Әллә нинди шомлы буран чыкты —
бүтән хисләр, бүтән тоем да.
Фәрештәләр, дәррәү котырышып,
бии төсле пәри туенда.

Тазарткандай һәрбер тәрәзәне,
тиеп китә ап-ак канатлар.
...Авыл йорты. Хушлык. Бүген монда
куна калган олуг кунак бар.

Хәйям белми киткән чүнник сыен
җибәрәләр «бәлеш асты»на.
Сәйдәш кенә һаман тыныч түгел:
«Кызган саен нигә җан туңа?..»

Фәрештәләр бии фанфарага —
туктар микән бу туй өч көннән?!
Композитор гына ишетерлек
тавыш килә... буран эченнән...

Адашкандыр берәү... авылына
кайткан чакта кара буранда.
Кайтаваздай иңри «Коткарыгыз!»
камертоннан сизгер бу җанда.

Гарасатта йөрәк гажизләнсә,

[1] Г. Тукайдан.

ала иң югары нотаны...
Бәргәләнеп буран ятьмәсендә,
әллә бәгырь... Кәрим[1] ятамы?!

Фәрештәләр бии фанфарага,
өзгәләнә Сәйдәш ят моңнан:
«Халык чыксын, әйдә, эзләп табыйк —
тавыш килә амбар ягыннан!..»

Эзләделәр өмет өзелгәнче,
иләделәр карны он итеп...
Әүлиядәй затның ялгышуын
мөмкин булса икән онытып!

Мәэюсләнеп калды маэстро:
«Якны бутаганмын... карт юләр!..»
Мәрхүмкәйне мәгъриб тарафыннан
буран тынгач табып кайттылар.

Авылдашлар аңлый алдыларны
жаны көйгән сабый ир хәлен?!
... Ап-ак кардан Сәйдәш бара төсле,
тартып бара кара роялен...

## Сабан туенда чүлмәк вату

Җенем белән ордым бугай,
иртән торып сул яктан,—
әллә нинди сихри нурлар
чәчрәп китте чүлмәктән.

Ярчыклары арасыннан
агып торды яктылык;
күзне хәтта яулык аша
авырттырды шактый ук.

Вәйран булды парлакъ[2] савыт,
аһ, әйләнде ком-ташка...
Әллә соң мин күсәк белән
кизәндемме... кояшка?!

Буыннарым яңгырады,
жан үтәли акты моң.
Түктем төсле газиз әнкәм
гүрендәге яктыны!..

## Җомга көн күк катында

...Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтә вакыт хәтер йомгагын.

[1] Кәрим Тинчурин күздә тотыла.
[2] Парлакъ — нур чәчеп торучы.

Аныклыйдыр әнкәм онытына:
«Җидегәннең тажы — җомга көн...»

Җомгаларда идән юдыртмады,
сугармады хәтта яранын.
«Гыйбадәткә,— диде,— гыйбадәткә
багышлансын көнең, Йа раббым!..»

Әһле ислам намаз укыр чакта
тыеп торды башка гамәлдән.
Вагыйзләрчә әйткән вәгазьдәнме
әллә нинди гайре гамь калган?!

Тәкрар иткән үзе, тәгълим биреп,
үзе тапкан мине... җомга көн.
...Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтәм күктә хәтер йомгагын...

Сәламләшкән чакта сулышының
тоям никтер авыр булуын...
Калдырткандыр ничә намазыңны
тулгагыңа тормас бу улың.

Ярлыкагыл, диеп ялварганда,
мин Күк белән калам бергә-бер.
Языклыга кемнәр язылганын,
хәер, Аллаһ үзе беләдер.

...Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтәм, әни, хәтер йомгагын.
Нәүмизләтә калган намазларың —
туган көнем бүген — җомга көн...

## Ефәк тасма

Картлар йорты. Тынлык. Олпат агай
робагыйлар укып утыра.
Биләмәдәй күргән бүлмәсендә
таңга кадәр якты ут тора.

Дәртләндерә Хәйям дүртъюллыгы,
шәраб итеп аны эч кенә.
Картны йокы алгач, ефәк тасма
кереп ята китап эченә.

Иртәгесен кирәк сәхифәне
эзләп табу булмас мең нужа...
Кәнәфигә сеңгән иләмәннең
куенында затлы мәҗмуга.

Парчаланган якты пәрдәләргә
ачык тәрәзәдән җил бәрә,—
фанилыкта... әллә фәрештәме
канатларын җилпеп җибәрә?!

Аксакалның җанын саклагандай,
урындыкта тора таш мәче.
...Тәкъдирнамә ничек тәгаенләр,
кайсы биттә калыр тасмасы...

## Шаһитлек

Аккош күле. Төнге бакча.
Йокы алмый бөртек тә.
Кинәт чүгеп, биһуш калдым —
ис иңгән бит бөтнеккә!

Бәрәкалла, шушы төндә,
бәлки, шушы сәгатьтә...
Җирме күккә тынын өргән?!
Бераз гына сагайта.

Нигә әле шаһит булдым
туган чакта могҗиза?
«Бөтнек исе! Бөтнек исе...» —
эчтән кылдым мең нида.

Җанда шөбһә, җанда шатлык,
җанда сагыш — бар да бар.
...Мондый төндә яшәп калу
мәңгелеккә бәрабәр.

## Чалгы

Печәнгә чыгасы авылның
чарланып куелган чалгысы.
...Болында төн буе йөренде
Хозырга охшаган чал кеше.

Ямь-яшел таягын селкәүгә,
сайраудан тукталыр сандугач.
Нииндидер илаһи тамырга
чалгылар төртелер таң тугач.

Соңгы төн. Андызның шифасы
тамырга төшәсе иткән чак.
Пәйгамбәр чәчәге, сәҗдәгә
киткәндәй, егылыр иртәнчәк.

Күренеп югалды томанда
Хозырга охшаган чал кеше.
...Йөзенә салкын тир чыгарып,
уянды авылның чалгысы.

## Үкенечле ләйсән яңгыр

Сыенылган иске чиркәү диварына —
юкса анда, йәле, нәрсә җуйган мин?!
...Гөмбәз өсләп шарлавыклар аккан чакта
тәре юган суны... йотып куйганмын...

Эчмәгәнмен Зөһрә кызның чиләгеннән,—
кимсенүнең юшкыннары ай ачы!
Ай-яй ерак, Хак тәгаләм, ай-яй якын
хәрам — хәләл, хәләл — хәрам арасы...

## Дәһрилек

Көфер сүзләр килсә ялгыш,
авызга... икмәк тула.
Кемнәр анда Алла колын
үз колы итмәк була?..

## Эзәрлекләнү

Кырга чыгып йөрдем көзге таңда,
чыклы камылларга кагылдым.
...Гөнаһсызга сине елатканмын,
юкса белә идем — хак булдың.

Сиңа иңми калган хәләл җанның
газабына ничек түзәсе?
Тамырларым буйлап күтәрелә
камылларга тулган күз яше...

## Кавын сатучы хатын

Чарасыздан бастым чиратыма,
белешмичә әйбер хакын да.
Ымсындырды миндәй имансызны —
тылсым бардыр бу яшь хатында.

Нәфсехурлар иңри нәфислектән:
«...Үкендермәс соңра... үлсәң дә!..»
Кояш сутын эчкән ике кавын —
күкрәк биеклеге үлчәүдә.

Арасында, абау, арасында
күкләр белән тоташ тирәнлек!..
Көтмәгәндә шайтан котырттымы —
базар чиратында торам ник?!

Кавыннары нинди кавемнәндер,
чыкты үзе шундый кыз булып —

үртәгәндәй, күкрәк уртасында
алтын тәре тора кысылып...

Гаурәтенә карап гайрәтләнгән
гайре берәүләрне күзәтәм.
Кармалаучан комсыз карашларда
кабатлана кебек йөз хатам.

Кавын өчен чират алмый бугай
монда ир-атларның күбрәге...
Саташтырды башны сатучының
ташып торган тере күкрәге.

Газәлләргә күчәр гүзәллектер,
ничек инде, имеш, эч янмас...
Тәтәйләргә хирыс татаркаем —
тотып карамыйча ышанмас.

Тыелганы тәмле тоеладыр —
агъвәләнгән күпме угланнар.
Әсирләүче күкрәк уртасында
башны югалтырлык урлар бар!

Түшендәге «тавык тәпие»нә
ирен тиеп китсә... Йа Хода!
Тартындырмый бугай татарымны
Айдан савылучы якты да...

Чиратымда тәмам чырсызландым,
өммәтемә әллә көч килеп?!
...Үртәләүче күкрәк уртасында
алтын тәре тора кысылып...

## Үлеп булмау сәбәбе

*(Саклык кенәгәсенә язылган шигырь)*

1 гыйнвар, 1992

Чыр-чуларсыз калган чыршыларда
төне буе җем-җем ут янды.
Яңа елда бөтен, бөтен халык
Сиражетдин[1] булып уянды:
«Таладылар!»

Иреннәргә кунып эределәр —
тәңкә карлар ачы, ах ачы!..
Үлә алмый халык — юкка чыкты
үлемтеккә дигән акчасы:
таладылар,
Сиражетдин,
чынлап таладылар...

[1] Г. Камалның «Банкрот»ындагы персонаж.

## Соңгы киңәш

Шигырь белән шөгыльләнде,
тәнкыйть тетте — уңмады.
Әллә теле, әллә дене,
әллә җене булмады...

Әрәм итте... фәрештәгә
тиеш каләм карасын
...Җене, килеп, киңәш бирде:
«Хәдис язып кара син!..»

## Тәкъдир искәртүе

*Г. абый турында уйлап*

Син теге гасырның төпчеге икәнсең —
шөкер ит, шөкер ит...

Җир шарын өлешләп, имана биргәннәр —
шөкер ит, шөкер ит...

Микулай патшаның икмәге эләккән —
шөкер ит, шөкер ит...

Аурупа илләрен күрсәткән... өч сугыш —
шөкер ит, шөкер ит...

Инде бит өченче хатынны җирләвең —
шөкер ит, шөкер ит...

Ничә мең күбәләк гомерен яшәдең —
шөкер ит, шөкер ит!..



## ПУБЛИЦИСТИКА

# АЗАТЛЫК — ТАТЛЫ СҮЗ



Кешелек тарихының, җәмгыять үсешенең бик күп өлеше Азатлык өчен көрәш сәхифәләреннән тора. Төптән уйлап карасак, бу — хезмәткә, иҗтиһатка, тынычлыкка, кояш астында үз урыныңны табарга омтылыш дигән сүз. Күрәсең, менә шуңа да инде затлы-акыллы итеп: «Азатлык — татлы сүз»,— дигәннәр.

Без яшәп яткан дәвердә генә дә кыйтгаларны милли-азатлык хәрәкәте чорнап алган иде. Бу хәлләргә иркенләп тукталуның хаҗәте юктыр, чөнки моны инде мәктәп балалары да яхшы белә. Һәрхәлдә, АКШ, Франция, Бөекбритания кебек империяләргә мәрҗәндәй сибелгән колонияләрен куллан ычкындыру җиңел булмагандыр. Әмма алар Азия, Африка, Латин Америкасындагы байтак кына халыкларга иреклe вакытында һәм кансыз-коралсыз диярлек тапшыра белделәр.

Хәтергә төшерик: Октябрь революциясеннән соң большевиклар да гаҗәеп бер демократик гамәл эшләп куялар ич — Россия составындагы Финляндиягә мөстәкыйльлек хокукы бирелә! Хәзер әнә Финляндия — муллыкта яшәүче, дөнья базарында мәйдан тоткан илләрнең берсе. Күпме табигый байлыкларга ия булуына карамастан, Рәсәйнең исә бүгенге көнгә кадәр сазлыктан, арталыктан, ызгыш-талаш кәсәфәтеннән башы чыкканы юк.

Рәсәйнең патшалардан ук калган күп кенә биләмәләрен үзенең канат астына җыйган СССР да — шулай ук империячел-тоталитар бер дәүләт иде. Ул таркалганнан соң әнә күпме союздаш республикалар үзләрен мөстәкыйль дәүләт дип игълан иттеләр.

Рәсәйнең ашказанында утырган, башка халыклар белән чагыштырганда аеруча нык сибелеп-таралып беткән татар халкына мондый бәхет эләкмәде. Чөнки тарихи бердәмлек җитмәү, форсатны куллан ычкындыру, чикләребезнең теләсә нинди кош-корт үтеп йөрерлек дәрәҗәдә үтәкүренмәле булуы, тагын-тагын башка күп төрле сәбәпләр безгә элек-электән аяк чала килде.

Шулай да, миңа калса, 1990 елның 30 августында республикабыз парламенты Татарстанның дәүләт суверенитеты хакында Декларация кабул итүе белән тарихыбызда зур эш башкарып калды. Ул көннәр истә... Башкалабызның Ирек мәйданын ничә көннәр, ничә айлар буена «Азатлык! А-затлык!» дигән сүзләр дер селкетеп тотты ул чакта. Без инде хәзер, ни генә әйтсәң дә, элекке түгел: уйларыбыз азат, өметләребез зур. 5—6 еллык тәҗрибә мисалларын бөртекләп санап тормастан, аерым алганда, Татарстанның халыкара мәйданда һаман саен ныграк урын биләвен, Казанда икенче тапкыр Бөтендөнья татар конгрессы үткәрелүне әйтеп китү дә җитәдер.

Без чынлап та мөстәкыйльлек алдыкмы соң? Бу сорауга җавап бирү өчен тулы бер фәнни-сәяси трактат язарга кирәк, әлбәттә. Шулай да кыскача гына әйтергә мөмкин: мөстәкыйльлек яулау юлында без беренче адымнарны гына ясадык әле, бик күп теләк-ниятләребез исә һаман кәгазьдә килеш кенә кала бирә. Хәтта ки Ирек (Азатлык) мәйданында ирек өчен көрәштә дә акрынлап түрәләр, номенклатура җиңеп чыкты! Алар вакытында хезмәт хакы ала, алар гөлбакчадай сарай-коттеджлар төзи. Йә, әйтегез, халыкка, интеллигенциягә һәм милләтчеләргә мондый рәхәтлек вә мөмкинлекләр тигәне бармы соң?..

Бүгенге көндә Казаныбызның иң биек ике ноктасы бар: берсе анын — айлы Сөембикә манарасы, икенчесе Хөррият кошы һәйкәле. Дөрес, Азатлык һәйкәле Америка Кушма Штатларында да бар. Башына гаделлек таҗы кигән, кулына утлы факел тоткан хатын-кыз сыны биек колонна очында басып тора. Хәтерләсәгез, кыерсытылган елларының берсендә Б. Ельцин Нью-Йорктагы бу һәйкәл өстеннән вертолет белән өч тапкыр урап узган иде. Телевизордан сөйләгән чакта: «Азатлык һәйкәлен өч тапкыр урап чыкканнан соң мин үземне өч тапкыр ирекләрәк итеп сиздем»,— дия-дия күкрәк какканы да истә. Сәясәтчеләрнен сүзе кылган гамәленнән нык кына аерыла шул. Чечен халкының азатлыгын буарга теләгән Президент, ике ел узгач кына, бу канлы сугышны көчкә туктата алды. Гомумән, Рәсәйдә милли мәсьәлә беркайчан да цивилизацияле юл белән хәл ителмәде, моның хәтта анык программасы да юк. Телләрендә: «Бербөтен һәм бүленмәс Россия» — шуның белән вәссәлам...

Академик Индус Таһиров әйткәнчә, «Бәйсезлек мәсьәләсен тарих үзе хәл итәчәк. Империя Казанны алудан башланды һәм без аны туктатырга да тиешбез». Чыннан да, чеченнарга караганда, татар халкына тарихи җаваплылык асылда иртәрәк тә, күбрәк тә салынган!

Аз гына ирек даулый башладыңмы, Мәскәү тизрәк: «Бездән башка яши алмыйсыз...» — дип лаф орырга тотына. Без Мәскәүдән башка да бик яхшы яшәр идек әле, Мәскәү үзе бит бездән башка яши алмый. Чынлыкта аны дистәләрчә субъект-регионнар туендырып тора. Хәтта, басымга түзә алмыйча, берзаманны чүт кенә Урал һәм Себер республикалары аерылып чыга язды түгелме?

Бәйсезлек — аерылып китү өчен түгел, тигез хокуклылык өчен кирәк. Үзәктә шушы гап-гади хакыйкатьне ни өчендер аңларга теләмиләр. Һаман күсәк, һаман йодрык. Рәсәй киңлекләрендә меңнәрчә гектар урманнар тиктомалдан яна, көлгә әверелә. Хәрби уеннар уйнаган булып ничаклы мал-мөлкәтне, акчаны җилгә очырганчы, танк һәм вертолетларны әнә шул урман утларына каршы җибәрсәләр, ил-көн өчен файда гына буласы бит югыйсә...

Азатлык турында уйлану менә бит ничаклы уй-фикерләрне, күңел сызланууларын актарып чыгара!

Әйе, 1996 елның августында — Татарстан Республикасы көнендә — элек Ленин мемориалы дип аталган, хәзер исә «Казан» милли-мәдәни үзәге дип йөртелүче бина каршында Хөррият кошына һәйкәл ачу тантанасы булган иде. Стиль-эшләнеше ягыннан беренче карашка сәер тоелган бу сәнгать әсәренең авторы — Саба якларында туып үскән татар егете, сынчы Кадим Җәмитов. Ул иҗат иткән һәйкәлнең асыл мәгънәсен төрле кешенең төрлечә аңлавы, кабул итүе дә бик ихтимал. Ләкин иң мөһиме — ул безнең күңелләрдә киләчәккә ышаныч тудыра!

Азатлык идеясе, һәрхәлдә, явызлык һәм гаделсезлеккә каршы көчне аңлата. Рух иреге — җәмгыятьне сәламәт яшәтүче, аны туендырып торучы кислород. Азатлык ул исәннәр өчен генә түгел, киләчәк буын өчен дә кирәк. Без, татарлар, яшәү тарихыбызда азатлык кошын инде ничә тапкыр кулыбыздан ычкындырдык. Бу юлы инде безгә азатлыкның канатларын каеручыларга бирмичек тә юл куярга ярамый. Ярамый!

Пикассоның Тынычлык күгәрчене искә төшә...

Казан күгендә Хөррият кошы канат кагына...

Мәскәү сәясәте күгендә исә ике башлы Каракош канатларын дәһшәтле селки... Бу кош бер башы белән көнчыгышны, икенчесе белән көнбатышны чукыпчукып алырга, канга батырырга мөмкин. Мондый кошны азатлык сөйгән халыклар берничек тә ярата алмаячаклар, билгеле.

Безгә тынычлык кошлары һәм азатлык җилләре кадерле.

**Рашат НИЗАМИЕВ.**

# Мөхәммәдъяр

## ӘСӘРЛӘРЕННӘН ПАРЧАЛАР

### Күк сандугачы («Төхфәи мәрдан»)

* * *

Мөхәммәдъяр, сиңа биргән Хакъ телне,—
Күк бакчасында бу сайрар былбылны.

Читен, хәтта аз шигырь да сөйләсәң,
Ирме соң син үз хәлеңне димәсәң!

Күпләр сөйләп бу дөньядан кичтеләр,
Сөйләү белән энже-дөрләр чәчтеләр.

Күпләр сөйли алмый,— сүзен кистеләр,
Күрә алмыйча, тән тишеп, кан эчтеләр.

Гакълың булса, җирдә калдыр сүзеңне,
Укыганнар ахыр данлар үзеңне...

Сөйлә татлы шигырьләрең мул сачеп,
Бу — табигать биргән сазга юл ачып.

Йөрәгеңне утта яндыр бу эштә,
Егетләрчә билең бәйлә һәр төштә.

И Илаһым, сиңа мәгълүмдер бу эш,
Тик бир миңа ялкынлы дәрт, хуш йөреш.

Сөйләгәндә йөзем һәрчак ак булсын,
Сүзләрем халыкка йомшак-пакъ булсын...

Минем эшем Илаһ биргән көчтәдер,
Бар сулышым халык өчен эштәдер.

### Дала («Нуры содур»)

Йәшел дала, гүзәл — ни юк. Чабында
Һәр тарафта атлар утлый табында.

Ул саф төрле чәчәкләрдән бизәлгән,
Хуш исле йәш үләннәрдән төзәлгән,

Чәчәклек белән капланган һәр төше,—
Күрсә моны — җәннәт дияр һәр кеше.

## Шагыйрьнең ягымлылык белән бөтен халыкка үтенеп киңәш бирүе. («Төхфәи мәрдан»)

Яхшы киңәш биреп сезгә, газизләр;
Әйтим, Ходам ярдәм итсә, хуш сүзләр.

Кешелеклек холкы кирәк ир өчен,
Сөйлим сезгә ачып кайбер сер әчен.

Хәким, булса синдә акыл һәм белек,
Исеңдә тот фикер: улдыр Игелек.

Бу игелек сезне дан юлга салыр,
Башыгызга олугълык таҗы сарыр.

И сәрви наз, тыңла колагың салып,
Дөньялыкта якын сердәшем калып.

Нәсихәтләр борынгылардан калган,—
Батырлыктан алар шулай өн салган.

Әгәр булсаң үзең син игелекле,
Кешеләрдән кызганма Егетлекне.

Олы булсын уе һәр ир кешедә,
Бөек булсын шуңа кылган эше дә.

Борын чөеп, мин-минлекне сатмагыз,
Онга — кибәк, серкәгә су катмагыз.

Шөгыль итсен Хаклыкны — ир куймасын,
Яман, яхшы турында да уйласын.

Гүзәл холыклы яманны яр итмәс,
Кирәкмәстән шәп дип, үзен хур итмәс.

Теләː явыз нәфседән котылырга,
Яхшы килсә бирәүгә — шат булырга.

Карындаштыр җан дусы белән дошман,
Пакъ тот үзеңне эчтән һәм тыштан.

И намуслым, изге кыл һәр кешегә,
Ул һич кылмас мәкер синең ишегә.

Яманлык кылучыга кылма йаман,
Яхшылык кыл, булдыралсаң, һәр заман.

Синнән күңел өзсә берәү, син өзмә,
Яхшылыкны ташлап, яманлык төзмә.

Һәр кем күрсә сине зур һәм көчле дип,
Тот нәсихәт: бел үзеңне кече итеп.

Бәхетсезләргә ирештер теләгең,—
Данлы эшең белән артыр кирәгең.

Кемнең йөзе оят белән туладыр,
Оят белән иман да нык буладыр.

Ишет, данлы Рәсүлебез ни дигән:
«Оят ул — иманның яртысы» — дигән.

Кешечә бул, булма җәберләүче зат,
Кешечә кыл бар эшеңне, чын ир-ат.

Юмартлык, дускаем, бирер зур муллык,
Юмартлыкка якын килмәстер хурлык.

Туйдыр икмәккә кешене, изге зат,
Мәңге калыр бу җиһанда яхшы ат.

Бозык якка күз салу һич кирәкмәс,
Булмас сүзгә колак тоту кирәкмәс.

Тел һәм күңлен ялган тотма кешегә,
Йөзең бер тот ир һәм хатын-тешигә.

Әдипкә сал колакны син һәр чакта,
Әдәпсез булмассың, кардәш, ул чакта.

Намус белән син хурлыкны күрмәссең,
Табын түреннән кешене сөрмәссең.

Үзеңнән бер йәшкә зурны хөрмәт ит,
Кечегә дә, олыга да шәфкать ит.

Өлкәннәрне, дәрәҗәләп, олы күр,
Кечегә дә рәхим-хөрмәт тулы күр.

Авырлыклар килсә кинәт, түзә бел,
Сабырлык ләззәте тәмен сизә бел.

Берәр кунак килә калса өеңә,
Тәңре байлыгын лаек ит көенә.

Көязләнмә кунак килсә,— каршында
Нәрсәң булса, алдына куй барсын да.

Яхшылыгың белән кеше күңлен ал,—
Нәсихәт яхшысы будыр,— колак сал.

## Китапның тәмамы («Нуры содур»)

Көйләп язган синең исемгә атап
Тәмам иттем төрки телендә китап.

Бәйтләре бере яхшы береннән,
Сүзләре вәгазь нәсихәт тереннән.

Акыллылар аны укып аң алыр,
Бу бичара колга карап таң калыр.

Һәрбер җирдән җыеп аның сүзләрен,
Ачтым монда асыл мәгънә йөзләрен.

Җилдәй исеп кичсә заман: яз, көзләр,
Йадкяр булып калыр җирдә бу сүзләр...

Күңелдә күпме бар иде байлыгым,
Йыллар рәнҗеп, җырда чәчтем барлыгын.

Мәгърүр булып күңлем хәзинәсенә,
Ни мохтаҗ соң читләр хәзинәсенә!

Белгечләргә өметләнәм, шулай да,
Җырларымнан файда күргән уңайда:

Искә алырлар бу сөекле кешене,
Дога белән зурлап аның эшене.

Йәнә үтенәмен яхшылардан —
Саф көйләрне белгән бахшилардан:

Сүзләремне минем үзгәртмәсеннәр,
Үзбаш саксызлык та күрсәтмәсеннәр.

Бүгенге әдәби телгә мәгънәви тәрҗемәне
**Шакир АБИЛОВ** башкарды.

**Әгъдәс Борһанов,**
тарих фәннәре докторы,
Россия Дәүләт гуманитар университеты профессоры,
Татарстан фәннәр Академиясенең почетлы академигы



# МИЛЛИ ИДЕЯ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Россия Федерациясе Президенты Б. Н. Ельцинның үтенече буенча, соңгы вакытта бик күпләр хәзерге заман урыс милли идеясен эшләп тәкъдим итәргә тырышалар. Әгәр дә элек шуңа охшаш нинди дә булса идея-фикерләр булган булса, ул урыс дәүләте идеясе булгандыр, мөгаен, урысларның милли омтылышлары асылын тәшкил итмәгәндер, дип исәплим. Чөнки «урыс милли үзаңын яңарту һәм ныгыту кирәк» дигән сүзләр, турыдан-туры яки читләтеп, урыс дәүләтенең бөеклек рухын, урыс халкының туплангaн-какшамас бөтенлеген яңарту һәм ныгыту кирәк, дигәнне генә аңлата. Шулай итеп, беренче урында дәүләтнең бөеклеге кала. Урыс дәүләте тарихы, урыс халкы гомер бакый хәерче һәм надан-томана хәлдә калганда да, дәүләтнең бөек була алуын дәлилли. Ә халык һич кенә дә бөеклеккә кызыкмый да, аңа омтылмый да. Чынлыкта халык бөтенләй киресенчә уйлый.

А. П. Чехов, урыс кешесе үткәннәрне хәтерләргә ярата, әмма яшәргә ярат-мый, дигән. Россия матбугатында булсын, радио-телевидениесендә булсын, һаман үткәнне сагынып яшәү хисләре чагыла, һаман бер җыр җырлана: «Ах, нинди Россияне югалттык бит?! Ничек итеп фәлән-фәлән чорларны кайтарыйк икән?! «Бу очракта берәүләр патша заманнарын, икенчеләре совет заманнарын сагына. Болай сыктаучы-сыкраучы урыс шовинистлары бер нәрсәне оныталар: икътисад өлкәсендә Россиянең «бөеклеге» һәрвакыт бюрократ түрәләр өреп кабарткан сабын куыгы шикелле генә иде. Миңа калса, хәзер урыс дәүләтенең төп кайгысы һич тә андый «бөеклек» турында кайгыру булырга тиеш түгел.

Кешелек дөньясы хәзер теләсә кайсы ил-дәүләтнең үсеш-казанышларын «кешелек үсеше индексы»ның төп өч күрсәткече белән билгели: уртача гомер озынлыгы, һәр кешенең табышы-байлыгының күләме һәм халыкның гомуми белем дәрәҗәсе. Бу күрсәткечләр буенча Россия хәзер 174 ил арасында, барлык Европа илләреннән диярлек, Азия һәм Латин Америкасы илләренең дә байтагыннан артта калып, 57 нче урында тора. Менә сезгә әзер милли идея: алдагы дистә елларда, әйтик, Барбадос, Чили, Латвия, Фиджи һ. б. илләрне узып китегез дә, Россияне һич югында беренче утыз ил дәрәҗәсенә күтәрегез! Аннары инде ерак киләчәктә,— 100—200 еллардан соң! — Германия, Англия, Франция, Италия һ. б. кебек тәрәккыятле илләр арасына да кереп, беренче унлыкта урын алырга омтылырга да була.

Ә калганы — ах-вах килеп сыктанулар-фәләннәр иләк белән су ташу, комнан бау ишү шикелле генә: беркатлы томана-надан халыкны алдау, аларны юк белән

куандырып, «сукбай булсак та — урысбай» дип җырлатып йөртү генә булыр. Урыс кешесенең үз хәерчелегенә-бөлгенлегенә мондый мөнәсәбәте, күренекле юрист-демократ А. Ф. Кони язганча, аны исертеп-талап, гомер буе йоклатып тотуның ачы нәтиҗәсе. Бу бәхетсез халыкны кемнәр талаган-бөлдергән соң? Революциягә кадәр — феодаллар һәм дәүләт, революциядән соң бүгенге көнгәчә дәүләт талый.

Халыкның үзаңына туган Ватанының хуҗасы, аның тулы хокуклы гражданы икәнлеген сеңдерергә вакыт җитмәдеме икән? Юкса, халык әле һаман да дәүләтнең подданные, ягъни нәрсәдер биргәнен көтеп, авызына карап торучы гына. Моңа кадәр «подданный» сүзен «гражданин» сүзе белән юкка гына тәңгәл куеп килмәгәннәрдер, бу да — халыкны алдауның бер төре. Ә асылда подданный — ул дәүләтнең колы. Бары тик шул гына.

Халыкны Ватанлы итү идеясен шундый итеп тамырландырырга кирәк ки, аның ил-Ватаныннан кадерлерәк һәм яраткынрак нәрсәсе булмасын, ул, гражданин буларак, чын күңеленнән: «Нинди иркен минем туган илем!» — дип куанып җырласын. Халык рухының мондый сыйфатын Европа дәүләтләре кебек тәрәккыятле дәүләтләрдә генә тәрбияләргә буладыр. Россия кебек азиат камырында кабарган дәүләттә бу мөмкин эш түгелдер, юкса кача алган «подданныйлары» Җир шарының барлык кыйтгаларына качып китмәсләр иде. Имин-иркен, мул тормышлы дәүләт төзү, әлбәттә, мәшәкатьле эш. Бик мәшәкатьле. Аннары шунысы да бар: кемнәр өчен борчылырга, янарга-көяргә тиеш соң әле бюрократ түрәләр? Аңгыра-томана халык өченме? Дәүләтнең ул түрәләре гомер-гомердән үзләрен «европалаштырырга» омтылган һәм азмы-күпме уңышка да ирешкән. Алар, кем әйтмешли, француз телен нижгар урыслары теленә катнаштырып сөйләшергә дә өйрәнгәннәр. Бүгенге түрәләр-байлар да бөтенләй «европалашкан» диярлек: «мерседес», «вольво» кебек чит ил машиналарында гына җилдерәләр. Россиянең яңа беренче вице-премьеры Борис Немцов, аларны үзебезнең «Волга» дигән «арбаларыбызга» утыртып, «европалашкан ялтыравык»ларын коеп төшермәк була-булуын. Ай-һай ла, шикләнәм, булырмы икән? Ишектән куганда тәрәзәдән керергә өйрәнгән түрә-чиновникларын Борис Немцов әле начар белә шикелле.

Дөрестән дә, көлсәң — көл, еласаң — ела! Ил моңарчы күрелмәгән җимереклектә-бөлгенлектә, икътисад таркалган, халыкның күпчелеге ач-ялангач, ә «милли» уй-фикерле ташбашларның үз кайгысы — ничек итеп шул җимерелеп таркалган «бөек» империяне урыс канаты астында саклап калырга һәм ныгытырга, имеш?! Әгәр дә Россия халыкларны яулап буйсындырудан, яңаданяңа җирләрне басып алудан юньле файда күрсә, бер хәер иде әле. Аның үз тарихындагы бихисап яулап алу сугышлары урыс халкын һаман да бөлгенлеккә генә төшерә килгән бит. Әрәмтамак-сорыкортларча тыгыну мөмкинлекләрен арттыра барып, ул сугышлардан тик дәүләт түрәләре һәм югары дәрәҗәле хәрбиләр генә файда күргән. Дәүләтнең бөтен мәнфәгате шул булган, аннары тагын яңа җирләр басып алу турында кайгырткannar. Монысы да, В. О. Ключевский язганча, «халык ябыгып бетерешкәндә, дәүләт симереп күбенсен өчен» эшләнеп килгән.

Хәзер инде колониальләштерүне яңача нигезләргә тырышалар. «Россия христиан демократик хәрәкәте» партиясе рәисе В. Аксючиц (Россиянең Дәүләт Думасы депутаты) бер мәкаләсен «Бер халык — бердәм дәүләт. Урыс кешесенең тарихи чакыруга җавабы» («Новая газета», 27.02.1997) дип исемләгән. Ул бу язмасында хәтта шуңа барып җитә, анынча, имеш, 1917 елга хәтле урыслар, украиннар һәм белоруслар бербөтен урыс милләте булган; алар у р ы с  т е л е н е ң төрле шивәләрендә — бөек урыс, кече урыс, белорус (ак урыс) шивәләрендә генә сөйләшкәннәр; украин, белорус дигән милләтләрне т а р и х  б е л м и; совет чорында да аларны милләт итәрлек бер-бер хәл булмаган; бары тик безнең күз алдында гына, хакимият башында очраклы рәвештә менеп утырган вакытлы кешеләрнең сәяси башбаштаклыгы аркасында, урыс милләте ботарланып аерым кисәкләргә таркатылган, имеш. Автор күрәзәлек итеп, болай дип яный: «түзем-сабыр халыкның түземлеген кирәгеннән артык сынау беренче карашка мәгънәсез тоелган котылгысыз урыс фетнәсенә китерәчәк һәм ул, иң беренче нәүбәттә, халыкның тормышчан абруй-дәрәҗәсе белән хисаплашмаучылар өчен шәфкатьсез булачак».

Урыс дәүләтен «коткаручы» тагын бер мәгълүм «иптәш» Г. Зюганов (монысы Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе рәисе, шулай ук Дәүләт Думасы депутаты), тырышып-тырмашып, дәүләт төзелеше мәсьәләләрендә күпмилләтле бөек Державаны саклап калу һәм үстерүнең меңьеллык «бай тәҗрибәсенә» таянырга чакыра («Новая газета», 13.03.1997).

Империяне торгызуны «фәнни» нигезләүчеләр дә бар. «Россиядә реформалар һәм контрреформалар. Модернизацияләштерү процессы цикллары» (Мәскәү университеты нәшрияты, 1996) дигән, гомумән алганда, болай гуманитар юнәлешле җыентыкның бер авторы В. В. Ильин бөек урыс милләтенең башка халыклар тарафыннан йотыла баруына борчыла. Аныңча, республикаларда дәүләтчелекне үстерүне ясалма хуплау, тарихи яулап алуларның нәтиҗәләрен валюнтаристик рәвештә юкка чыгару, урыннардагы славян диаспорасын тар-мар итү «милләтләрне эретү казанын» бик нык бозган икән. Ул урыс дәүләте канаты астындагы халыклар арасында тәрәккый бәйләнешне ныгытуга, бер яктан, артык тиз яулап алулар — Россия басып алган җирләрен үзләштереп өлгерә алмый (мескенгә бик ашыгырга туры килгәндер шул!); икенче яктан, большевиклар җирле халыкның милли-дәүләтчел үзбилгеләнү хокукын декларатив рәвештә дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәргәннәр — Россия тарихының үткәнендәге гаеп-кимчелек әнә шул дип саный. Ул хәзер үткәндәге бу яраксыз мирастан котылырга өнди. «Милләтләрне эретү казанын» камилләштерү, В. В. Ильин фикерләвенчә, беренчедән, үзәктән ерактагы өлкәләрне икътисади үстерү аша булса (бик файдалы гамәл булыр иде кана, ләкин урыс милләтенең җирле халыкны «эретеп бетерүе» максатында түгел!), икенчедән, милли-дәүләтчел үзбилгеләнү максаты белән, автономияләргә төп милләт вәкилләренең читтән кайтып туплануын туктату аша булырга тиеш икән. Имеш, кайчандыр туган җирләрен ирексездән ташлап төрле якларга сибелгән-чәчелгән ул «вак» милләтләргә тарихи Ватаннарына кайту мөмкинлеген бирмәскә, тыярга кирәк. Шул ук вакытта үзәктән — Россиядән этник импортация үткәрүне, ягъни, кеше аңларлык тел белән әйтсәк, урысларны шул милли төбәкләргә күпләп күчереп утыртуны хупларга киңәш итеаә. Автор уенча, шул очракта гына «колонизацияләү нигезле» булыр, чөнки этник урыслар үзәкнең табигый ставленниклары, ягъни үзәк мәнфәгатен күзәтү өчен куелган кешеләр, урыннарда урысларның ярдәме-булышлыгы булмаса, империя тупикка төртеләчәк. Шунлыктан, үзәкнең урыс диаспорасын ул төбәкләрдә һәрьяклап үстерергә, ныгытырга кирәк. Җирле халык үз туган җирендә үзен һәрвакыт кимсетелгән-буйсындырылган азчылык итеп тойсын — В. В. Ильинның төп мәсләге менә шул.

Әмма бу идея миллилек хокукына дәгъва итә алмастыр, мөгаен. Дәүләт мәнфәгате өчен ул ярашлы, әлбәттә. Дәүләт бюрократиясенә хезмәт итүче зыялылар бу идеянең һөҗүмчән рухын көчәйтергә тырышалар. Ә инде гади урыс халкына килсәк, үз төбәгендә җан саклап калырга Ходай көч бирсен аңа, чөнки аның мескеннең күрше өлкәләргә күчеп китәрлек тә чамасы юк — монысы «табигый монополияләр» тырышлыгы (тимер юл, һава транспорты, су транспорты һ. б.). Аннары, «үзәкнең урыс диаспорасы» дигәненне дә бит, Рязань, Тула яки башка төбәкләрдәге урыслар барысы да бер төрле дип, аларны тиңләштерү дә — тирән ялгышу.

Урыс булмаган халыкларны йотып-эретеп бетерү сәясәте иртәме-соңмы тулысынча җимереләчәк. Россия дәүләте ахыр чиктә аңлар, аңларга тиеш: милләтләрнең күптөрлелеге — кешелек дөньясының иң зур байлыгы ул. Бер генә милләтне югалту да, кешеләрнең җинаятьчел-саксыз һәм наданнарча хуҗалык итүе аркасында, табигатьтәге теге яки бу төр үсемлекнең яисә җәнлек-җанварның берәресе юкка чыкканнан ким югалту булмаячак. Бер милләт бетсә — дөнья мәдәнияте хәзинәсен тулыландырып торучы бер чыганак бетәчәк дигән сүз. Табигатьме-илаһи затмы төрле раса кешеләрен бар иткән, алар аннары милләтләргә аерылганнар. Бар итүче илаһи затка шулай кирәк булган. Димәк, беркемнең дә кешелек генофондына тыкшынырга хакы юк.

Әлеге җыентыктагы икенче автор А. С. Панарин исә урыс мессианчылыгы идеясен бөтенләй башка яссылыкта ачмакчы була. Аның фикеренчә, Көнбатыш дәүләтләре Россияне элек тә «Европа йортына» кертмәгән, хәзер дә кертми, киләчәктә дә кертмәячәк. Димәк, нәрсә эшләргә кала? Артта калган көчсезрәк ил-дәүләтләрне, әйтик, үзебез коралландырган Ирак, Ливия, Иран, Һиндстан кебекләрне әйдәүче «бөек» дәүләт булырга кирәк. Үзебез дә артта калган ил ич! Әмма без хәрби көч-куәтебез белән мактана алабыз әле.

Хөрмәтле авторның әлеге амбициясен урысларга хас буш масаю, шапырыну дип карыйк та, бу хакта сүзне озынга сузмыйча, аның СССР таркалу белән бәйле бер «закончалыкны ачуына» тукталыйк. А. С. Панарин болай дип яза: «...Россиядән ераклашкан саен, ил эчендә федераль үзәктән аерылган саен (монысы Татарстан, Башкортстан һ. б. карыйдыр инде. Ә. Б.) индустриальләштерүгә кадәр булган кадими заманнарга янадан егылып төшү булачак». Урыс җирлеген туфрагын саклау — яхшы, ә Евразиянең башка халыклары өчен шундый ук гамәл — начар, янәсе. Автор элекке СССРдагы һәм хәзерге Россиядәге урыс

булмаган халыкларның мәдәни «үсешенең алга китеше», үз мәдәниятләрен, үз тарихларын кысрыклап чыгарып, урыслаша бару галәмәте генә икәнлеген аңламаска тырыша. Чын закончалык шунда: бу халыклар хәзер үз милли мәдәниятләренә һәм телләренә әйләнеп кайталар, бу күренеш бер дә урыс мәдәниятенә нигезләнгән «тәрәккый инфраструктураны» юкка чыгару хисабына бармый, ул бу халыкларның элек үзләренә мөмкин булмаган дөньяның башка телләрен өйрәнүгә дә нигезләнә, онытылып барган үз телләренә кайтуына да нигезләнә. Гомумкешелеккә хас хикмәтле сүз бар: «Кеше ничә тел белсә, шул кадәр мәртәбә кеше». Евразия халыкларының тәрәккыяте бер урыс мәдәниятенә генә терәлеп калмаган. «Урыс канаты астында» чакта ул шулай булган, хәзер алай булмаячак. Инде ничәмә гасырлар үзләштерелеп килгән урыс мәдәниятеннән киләчәктә дә баш тартмыйча, үзеңне үз милли мәдәниятең белән дә баету мәслихәт. Һәм бу хәл бер дә урыс мәдәниятен кысу-чикләү түгел. А. С. Панарин исә Россия дәүләтчелеген үтереп мактый, имеш, ул «дөньяга күп санлы этносларны саклап калу могҗизасын күрсәтте, аларны эретеп бетермәде, кысрыкламады, этносгегемон аларны измәде-сытмады.» Бу — авторның чи наданлыгымы, әллә белмәмешкә салынуымы? Аңлашылмый. Урыслардан кала, буйсындырылган барлык халыкларны йотып бетерергә өлгерә алмау хәзер казаныш итеп күрсәтелә. Гаҗәп яшәүчән булган татар милләтенең дә ким дигәндә өчтән бере манкортлаштырылган; шәһәрләрдә яшәүче белоруслар үз телләрен бөтенләй югалтканнар, совет чорында Минск шәһәрендә бер генә белорус мәктәбе дә калмаган; Казанда исә бердәнбер катнаш урыс-татар мәктәбе бар иде; барлык татар түрәләре, күпчелек техник һәм гуманитар зыялылар үз телендә ипи-тозлык кына сөйләшә алалар иде; татар теле татар телендә язучылар һәм авыл укытучылары өчен генә булып калды; егерменче еллар башындагы халык исәбен алу белән чагыштырганда хәзер без йөзләрчә халыкларны югалттык; күптән түгел бер язучы кисәге үзәк матбугатта мактанып язып чыкты: урыслар татар ханнарын яулап алмаган булса, үзләре дә бүген 150 миллион түгел, ә нәкъ татарлар хәтле генә калырлар иде, имеш (7 миллион).

Урыс халкының «югары рухы» турында үҗәтләнеп сөйләнүләр ачуны китерә. Президент канцеляриясендә эшем кешесе булырга тырмашып йөрүче фән кандидаты С. Кортунов «Югары милли бурыч» («Новая газета», 07.10.1995) дигән мәкаләсендә Көнбатыш үзенең гомуми ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүче җәмгыятенә альтернатива эзли дип расламакчы була. Һәм ул аны, имеш, Россиядән табачак, икътисад чорына алмашка икътисадтан соңгы — гуманитар мәдәниятле, зыялы, рухи бай карашлы кешеләр чоры киләчәк, андыйлар бездә тулып ята, шунлыктан, кешелек дөньясы белән дә бүлешә алабыз, янәсе. Мин бу фән кандидатына каршы болай дип язып чыккан идем: «...кешелек дөньясын тынычлыкта калдырып торыйк әле. Җир шары өстендә безнең рәхмәт илә бер гасыр чамасы эленеп торган «бөтендөнья коммунистик революциясе»нең домокл кылычын, ягъни бүкәйне әле яңарак кына алып ташладык бит, бер уңайдан кешелекнең өчтән бер өлешен үзебезнең «кайгыртуыбыздан» да коткардык, без анда коммунистик диктатура режимын көчләп таккан идек. Үзебездәгечә, урыс мәдәнияте тарафыннан башка халыклар мәдәниятен йоту идеясен күтәреп чыгып, яңадан безне бөтен дөньяга каршы куюның бер хаҗәте да юк. Бу — максатка да ярашлы түгел, тормышка ашмас буш хыял гына. ГУЛАГларыбыз белән, Ирак, Иран, Төньяк Корея, Куба, Африканың каннибаллык режимнарына һ. б. ярдәм кулы сузуыбыз белән даны чыккан сәяси һәм әхлакый багажыбыз безгә бөтен дөньяны өйрәтү хокукы бирәме? Имин-тыныч, мул тормышлы халыкларга, аннан да битәр үзебез шикелле өметсез хәерчелектә яшәүчеләренә нинди рухи байлык тәкъдим итә алабыз соң?» («Новая газета», 28.10.1995). Әйтәсе килгәнем шул: матди байлыгың булмаса, рухи байлыгың да юк. Кыскасы: «Икмәк булса, җыр да була». Монысы — бердән. Икенчедән, Россиядә рухи байлык матди байлыктан өстен, дип лыгырдаулар тамаклары тук, өсте бөтеннәрнең ач-ялангач халыкны төпсез чуманга утыртырга тырышуы гына ул. Элитаның мәдәнилек дәрәҗәсе белән гади халыкның мәдәнилеге арасында — җир белән күк арасы. Әйе, зыялыларның бик аз бер катлавы бай рухияткә ия, аларны дәүләт чиновниклары-түрәләр белән дә бутарга ярамый. Кагыйдә буларак, бу катлау зыялыларның халыкны ихлас сөйгән өлеше булыр. Ул «югары рухият»нең чишмә башы кайда соң? Шул хакта уйлау комачауламас иде. Бәлки, ул халыкның мәңге бетмәстөкәнмәс интегүләрендә, җәфа чигүләрендәдер? Һәм хәзер кемнәрнеңдер, рухи байлыгыбыз югала, матди байлык өстенлек ала бара, дип сөйләнүләренә игътибар итеп торасы юк. Матди байлык арта бара икән, димәк, без тәрәккыятле дөньяның төп эзенә керергә тырышабыз, дигән сүз. Аллага шөкер итик, шулай

булса! Матди байлык рухи байлыкның үсеше өчен нигез булыр, әмма ул кычкырып торган капма-каршы ике полюста булмас, урталыкта булыр.

Гомумән, рухият, мәдәният турында сөйләгәндә, җәмгыятьнең югары һәм түбән катлаулары арасындагы гаять зур аерымлыкларны искә алабыз икән, урыс халкында уй-ният белән гамәли эшләр арасында да гаҗәеп тигезсезлек — ассиметрия ятканлыгын, төрле идеяләргә сәләтле булып та, ул идеяләрне, технология теленә күчереп, тормышка ашыра белмәү нәрсәдән килә икәнлеген дә искә алырга тиешбездер. Россия — гамәлдә тормышка ашырылмый кала килгән зур теоретик ачышлар иле. Мин моны күпчелек халыкның наданлыгы белән генә аңлатмас идем, чөнки бу наданлык үзе аңлатуны таләп итә һәм аның сәбәпләре мәгарифнең, мәдәниятнең, Россиягә хас булганча, начар финанслануында гына да түгел.

Гомуми идеяләр, зур ачышлар алдынгы карашлы һәм талантлы кешеләрнең хәерче урыс чынбарлыгын камилләштерергә омтылуыннан килә. Ә ул идеяләрне гамәли эшләргә күчерү өчен тарихның, җәмгыятьнең башка затлары — идеяләрдән гамәли файда алырга сәләтле һәм теләге булган гражданнар кирәк. Андыйлар Россиядә һәрвакыт аз булган, чөнки урта сыйныф гомумән өешып җитмәгән, дөресрәге — хакимият башында утыручылар аңа өешырга мөмкинлек бирмәгәннәр.

Күп кенә акыллы авторларның урыс кешесе, аның серлелеге, җанын аңлап булмаслыгы һәм тагын әллә нинди тузга язмаган сыйфатлары турында буш фәлсәфә куертуларына гаҗәпләнергә генә кала. Беренче карашка, чынлап та могҗиза бит! Революциягә кадәр матур әдәбият, музыка, тулаем сәнгать гаять тә югары биеклектә булган. Фәндәге тиңе булмаган ачышлар: Лобачевский, Кибальчич, Циолковский, Менделеев һәм тагын бик күпләр... Һәм шушы рухи байлыкның бөтенләй диярлек файдаланылмавы...

Халыкның гомере буе рәтле тормыш көтеп зарыгуы, йөрәген сыкратып торган күп гасырлык караңгылыктан чыгасы килү теләге — болар барысы да даһиларның акыл эшчәнлегендә ачык чагыла. Ләкин алар ясаган ачышларны тормышка ашырырга кеше юк — икътисадны, мәдәниятне һ. б. эшлекле рәвештә, рәтен белеп күтәрергә теләге булган гражданнар юк, гражданнар җәмгыяте юк, бары тик «өстерә һәм кертмә» принцибы белән яшәүче, бөтен нәрсәне үз астына җыйган дәүләт кенә бар. Бүгенгә кадәр бөтен өметләрне тик шул дәүләткә генә баглыйлар, моның бервакытта да булмас икәнлеген аңламыйлар. Чөнки мондый дәүләтнең исемен теләсә ничек алыштырып кына бер эш тә барып чыкмаячак. Азмы-күпме вакытлыча яхшырулар булырга мөмкин, ләкин иртәме-соңмы алар, Черномырдин әйткәнчә, «яхшырак булсын дип теләгән идек тә, һәрвакыттагыча килеп чыкты»га кайтып калачаклар. Дәүләт үткәрә торган барлык реформалар да,— ул реформаларны бездә бары тик дәүләт кенә үткәрә дә! — җимереләватыла да иске эзенә кайтып төшә. Чөнки дәүләт бит «һәрвакыттагыча булсын» өчен генә кирәк, ә инде «яхшырак булсын» өчен гражданнар җәмгыяте, гражданнар кирәк, кайчан нәрсә тамызыр икән дип, дәүләт кулына карап торучы подданныйлар түгел. Дәүләт — «бюрократиянең хосусый милке». Милли байлык халык кулында булмыйча, бары тик дәүләт кулында булганда гына бюрократия өстен сыйныф санала ала. Бюрократиянең акылы эләктереп алу инстинктына гына кайтып кала. Бетмәс алышынып тору, көндәлек ыгы-зыгы, башлыкка даими ярарга тырышу бу түрәләрнең акылындагы иҗади башлангычны бөтенләй юкка чыгара. Әгәр дә инде азмы-күпме зиһенлерәк булса, ул янә өстәге түрә эзеннән генә бара, шул эздән чыкмый, аңа каршы фикер әйтми. Үз-үзен даими тыеп тору, һәр адымын-сүзен уйлап-үлчәп яшәү акылның иҗат чаткысын баса. Бюрократ биләгән урыны-дәрәҗәсе белән үк тинтәк була. Акыл үсешенә ярдәм итә торган гади халык тормышыннан ул күптән аерылган. Никадәр аңгыра дисәң дә, бюрократ үзеннән акыллыракларның үзенә нинди куркыныч янауларын гына аңларлык. Шуңа күрә ул андыйларны эштән читләштерү җаен карый, хәтта физик юк итүгә кадәр барып җитә. Хәзерге идарәче даирәләрнең зиһене-интеллекты сай-кимчелекле булуының бер сәбәбе дә әнә шунда, әмма төп сәбәп — җәмгыятьтә урта сыйныф булмауда.

Әфәнделәр! Халкыгыз мәнфәгате белән дә шөгыльләнегез әле! Әгәр дә берәр вакыт ниндидер үлеп-бетеп баручы халыкның бөек урыс милләте кайгыртуына мохтаҗлыгы булган булса да, хәзер андый вакытлар үткән һәм, ышанам, мәңге кире кайтмас. Татарлар, мәсәлән, беркайчан да андый халык булмады. Кайбер халыклар турында, әйтик, Кавказ халыклары турында шундый караш яшәп килә: имеш, Россия Кавказдан китсә, анда үзара суеш-үтереш башланачак. Астан ут

уйнатып торучылар, араларына тыкшынучылар булса, анысы да мөмкиндер. Ләкин барыбер аларны көч белән басып торып булмый. Аларга икътисади, сәяси һәм мәдәни йогынты-ярдәм белән булышу яхшырак һәм нәтиҗәлерәк булыр иде. Хәзерге заманда бер генә халыкның да милли мәсьәләләрен читтән тыкшынып хәл итү мөмкин түгел. Күп кенә халыкларның ярлылыгы, алар арасындагы низаглар — бөек милләтләрнең колонизаторлык һәм яулап алу сәясәте нәтиҗәсе. Шулай булгач, аларга һәрьяклап ярдәм күрсәтү — үзе гаделл эш.

Инде килеп, А. И. Солженицынның «Безгә Россияне ничек итеп корырга» дигән программ хезмәтендәге кайбер фикерләргә тукталып үтик. Хәзерге заманның бөек русофилы, соңгы вакытларда хәтта шовинистлыгы ачыклана барган әдип, үз халкының авыр язмышына, аның бетеп юкка чыга баруына кайгырып һәм хафаланып, милли идея сыйфатында **халыкны саклап калу** максатын күтәрә. Ул бу идея-максатны үзе уйлап тапмаганын искәртә, аны әле Елизавета патшаның эшлеклесе П. И. Шувалов моннан 250 еллар элек үк әйткән булган. Мөгаен, Петр I патшалык иткән заманнарда империя халкының бик нык кимүен истә тоткандыр ул граф. «250 ел дәвамында императорлар Шувалов идеясенә бик салкын карап килделәр. Большевиклар турында әйтеп торасы да юк! Әмма хәзер дә мин җиде ел элек ясаган тәкъдимгә беркем дә диярлек җавап бирмәде... хаким катлау, ришвәткә сатылган булганлыктан, бу мәсьәләгә ваемсыз, ә ерткычлар — менә бу «грязнохватлар» («прихватизация» вакытында дәүләтне талап баеган «яңа урыслар». Ә. Б.) шулай ук ваемсыз, чөнки алар бүлешергә теләмиләр» («Русская мысль», 27.03—02.04.1997) дип ачынып яза А. Солженицын. Димәк, урынлы сорау туа: халыкны саклап калу идеясен кем тормышка ашырачак? Дәүләтме? Бүгенгә кадәр аның гадәтендә түгел мондый изге эш. Россия алып барган барлык сугышларда (бәлки, А. В. Суворовны исәпкә алмагандадыр) осталык белән түгел, сан белән алдырып, тишекләрне «туп ите», ягъни солдат гәүдәсе белән томалап килгәннәр. 1853—1856 еллардагы Кырым сугышында ук әле урыс армиясендәге югалтуларга һәм дошман армиясендәге югалтуларга ике якта ике төрле мөнәсәбәтнең Россия файдасына булмавын искәрткәннәр. Шул ук хәл 1904 елгы урыс-япон сугышында, 1914—1918 еллардагы урыс-герман сугышында да күзәтелә. Ә инде 1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында бер үтерелгән немец солдатына безнең ун үтерелгән сугышчы туры килә. Янарак булып үткән Чечня сугышында ничә «федерал» һәм, гомумән, чечен булмаган ничә кеше үтерелде икән? Гадел санап чыксаң, биредә дә саннар Россия файдасына булмастыр.

Россия дәүләте гомер-гомергә үз кешеләрен юк итү белән шөгыльләнгән һәм шөгыльләнә, дәүләт өчен халык артык күп, җитмәсә тагын «озак» та яшиләр — гомер озынлыгы европалыларга караганда «нибары» егерме елга гына ким. Ул кадәр халыкны ничек туйдырып тотмак кирәк? Бигрәк тә акчага кытлык һәм инфляция, ягъни акчаның кыйммәте туктаусыз төшеп торган заманда. Ә акча дигәнең — монетар дәүләт өчен иң кирәге: бердән, дәүләтнең социаль терәге булган күпмиллионлы чиновник-түрәләрнең тук-имин яшәвен тәэмин итү өчен (алар хәзер 18 миллион, һәр сигез гади кешегә бер түрә!); икенчедән, безнең идеалларны кабул иткән чит ил «союзникларыбызга» ярдәм итеп, «конституцион тәртип» урнаштыра-урнаштыра, үзләрен «бәхетле» итәргә теләгәндә «изге» максатларыбызны аңламаучыларны акылга утырту максатында да кирәк (мисалы — Чечня). Әнә шундый дәүләт эшләре өчен акча туплауның гасырлар буе сыналган ысулы да бар: һәр төрле «ВЧК» оештырып, шуның ярдәмендә талап җыела торган бөлдергеч зур салымнар, әле тагын яңарак уйлап табылган ысулны да өстик: халыкка хәләл хезмәт хакын, картларга-гарипләргә пенсиясен, студентларга стипендиясен түләмисең дә — вәссәлам! Дәүләт «бүреләре» дә тук, «сарык» халык та ачтан кырыла. Дәүләт мәнфәгатьләре өчен шулай кирәк тә! Чөнки әле Адам Смит ук исбат иткән: «Бөек халыклар... үз хөкүмәтләренең ил байлыгын әрәм-шәрәм итүеннән... ярлылана», — дигән. Хәерче һәм «рухи ярлы» халкыбызга әнә шундый дәүләт төзеп бирү — «демократларыбыз»ның иң зур хыялы.

А. И. Солженицын бер мәсьәләдә хаклы: милли идея югарыдан күрсәтмә белән ясала алмый, «ул йөзләгән-меңләгән башларда һәм күкләрдә үзе туарга һәм өлгерергә тиеш. Шулай булганда гына ул әкренләп оешып житә һәм илне алга алып бара». Ни кызганыч, Россиядәге «кеше материалы» язучы әйткән фикергә капма-каршы шул әле. Урыс кешесе өчен үз гомере дә, башкалар гомере дә «бер тиен дә тормый». Әдәби әсәрләрдә, бигрәк тә «патриотик» язмаларда

«янган йортка кергән», «колхоз атын коткару өчен бозлы сулы бәкегә ташланган» геройлар мактала. Әле кем, диген — безнең хатын-кызларыбыз, ә инде ирләр — «матросовлар», алары бездә йөзләрчә-меңнәрчә... Андый батырлар турында начар сүзләр әйтәсе килми. Әмма, валлаһи, алар арасында советлар заманындагы бер мәзәктәге шикелле «геройлар» да аз түгел. Коммунистлар партиясенә керүче берәүне тинтерәтәләр. Ул инде совет кешесенең мораль кодексы турында сөйләгән, эчмәскә, чит хатыннар белән йөрмәскә һ. б. сүз биргән. Шуннан партсекретарь сорый: «Ә тормышыңны партия өчен бирерсеңме?» — ди. «Бирәм, бирәм,— ди теге,— күкәемә кирәкме мина андый тормыш!»

А. И. Солженицын үзенең урыс халкын саклап калу милли идеясен иң түбәннән оешкан халык хакимияте белән бәйләп карамакчы була. Ә ул хакимият, үз чиратында, земстволарга (революциягә кадәр Россиядә җирле идарә системасы) барып тоташырга тиеш, земстволар сайланып куелырга тиеш, ди. Ай-һай, минем аларга, шулай сайланып оешсалар да, өметем-ышанычым бик аз...

Патша Россиясендә халыкның социаль составы ничек кенә начар булмасын, аның өчтән берен төрле дәрәҗәдәге хосусый милекчеләр тәшкил иткән, люмпен пролетариат чагыштырмача аз булган. Халыкның хәзерге составы исә совет чорындагыга караганда да бик начарайды: ул вакытларда бөтен халык милексез, дәүләткә ялланып эшли иде, эшсезлек юк, ярлы-люмпеннар юк, профессионал караклар да ул кадәр күп түгел иде. Ә хәзер ялланып эшләүчеләр эшсезләр, бомжлар, жуликлар, бандитлар белән сыегайтылды; соңгылары үз сазлыкларына көннән-көн күбрәк уңышсыз-бәхетсез җаннарны суыра тора; үзгәртеп кору, приватизация дигән булып, азчылык ертлачлар милли байлыкны талап-урлап бетерә яздылар.

Бары тик д е м о с к а (урта сыйныф милекчеләргә) таянган демократик шартларда гына чын демократик нигезләр өстенлек ала, ә инде авторитар режим шартларында, илбашы Президент авыз тутырып, әгәр парламент бик теләсә, мин аларның кирәкләрен бирермен, дип янап торган,— гафу итегез! — «дерьмократия» шартларында законсызлык, гаделсезлек чәчәк ата. Соңгы еллардагы парламентларыбызны искә төшерик. Алыйк иң соңгы СССР Югары Советын. Аны нигездә һаман да шул искелектә катып калган «дәшмәс күпчелек» тәшкил итсә дә, Сахаров, Афанасьев һәм башкалар кебек бик кыю, эшчән шәхесләр бар иде, алар ярдәмендә Югары Совет әле нәрсәләрдер эшләп кала алды. СССР таркатылгач (бер М. С. Горбачевны бәреп төшерү максатында!), РСФСРның Югары Советы законнар чыгару вәкаләтен үз өстенә алды. Монысының составы тагын да сыеграк иде. Шулай булса да, Президент Б. Н. Ельцин аны юкка гына танклардан аттырып таратмады. Ул Югары Советның әле хөкүмәткә каршы торырлык көче бар иде, аның рәисе дәүләт күләмендә дәрәҗәле шәхес иде. Аннары Югары Совет, исемен алыштырып, Дәүләт Думасына әверелде. Думага, дөресен әйткәндә, кем теләсә, шул кереп тулды. Аның рәисе И. П. Рыбкин, Р. И. Хасбулатовтан аермалы буларак, Дума мәнфәгатьләреннән битәр Россия Президенты Б. Н. Ельцин мәнфәгатьләре өчен тырышып йөрде, шуңа күрә дә Президент аңа якты чырай күрсәтте, бүгенге көнгә кадәр аны номенклатур исемлектән калдырмый йөртә. Хәзер эшләп килә торган икенче Дәүләт Думасы беренчесеннән дә кайтыш булып чыкты, ник дигәндә — ул коммунистлар-жириновскийчылар кулына калды. Әгәр дә реформаларда чынлап торып үзгәрешләр булмаса,— ул әле бик булырга охшап тормый,— алдагы Дума бернәрсәгә яраксыз булыр. Ни өченме? «Үзебез нинди, чанабыз шундый». Сайлаучылар нинди, депутатлар шундый. Без һаман хәерчеләнә барабыз. Мал-мөлкәтсез люмпен яхшы парламент сайлый алмый. Бер «ярты»га сатыла торган сайлаучы хуҗасына чүәкләр китереп бирүне яки мүччада, хуҗасының аркасын ышкый-ышкый: «Фәләнне кабул итегез, фәлән кәгазьгә кул куегыз, зу-у-ур табыш булыр!» — дип сөйләнүчене сайларга гына сәләтле.

Димәк, империячел омтылышлар да, дөнья халыкларына юл күрсәтмәктәге мессианчылык та, халыкны саклап калу идеясе дә хәзерге режим хакимлек иткән шартларда урыс милләтенең милли идеясе була алмый. Боларның баштагы иксез халыкның өмет-хыялларын чагылдырмый һәм, гомумән, тормышка ашарлык түгел, өченчесе — бүгенге дәүләтчелектә шулай ук әлегә мөмкин булмаган гамәлләр. Юкса халыкны саклап калу идеясе урысларның милли идеясе була да алыр, башкарып чыгу алшартлары булганда тормышка да ашар иде, әмма, кабатлап әйтәм, бүгенге хакимият җитәкчеләре аны һич кабул итә алмыйлар.

* * *

Минемчә, А. И. Солженицынның «халыкны саклап калу» дигәне тарихи Ватаныбыз Татарстанда яшәүче татарлар өчен дә, башка төбәкләрдәге татар диаспорасы өчен дә милли идея сыйфатында тулаем кулланыла ала. Ул берьюлы ике максатны берләштерер иде: беренчесе — татарларның манкортлашуын туктату, икенчесе — базар икътисадын үстерү юлында милләт буларак исән-сау калу, һәм биологик, һәм мәдәни яктан чәчәк ату. Бу максатлар ике алшарт булганда тормышка ашырыла ала: беренчесе — Татарстандагы татарлар җөмһүриятебез эшчәнлегендә икътисади, сәяси һәм мәдәни бәйсезлекне тагын да ныгытырга тиешләр, икенчесе — чит төбәкләрдәге татар диаспорасы милли-мәдәни автономия алырга тиеш.

Бу максатларга ирешү өчен үзәге хосусый милек иясе булган урта сыйныф гражданнар җәмгыяте төзергә кирәк. Андый җәмгыять уртак милекне бүлгәләп халыкка тарату юлы белән генә оеша ала. Аны булдыруда башка юл юк. Базар икътисады шартларында, ирекле конкуренция-ярыш хөкем сөргәндә, милек котылгысыз рәвештә финанс олигархиясе кулында тупланып, алар тарафыннан монополияләштерелә — милеккә бары тик алар гына хуҗа булу мөмкинлеге туа. Алар дәүләт хакимиятен дә үзләренә буйсындыра. Ә урта сыйныф әле яралгы хәлендә генә, аның хакимияткә хәлиткеч йогынтысы юк. Икътисадка дәүләт монополиясе булганда социализм чорында хакимият бюрократия кулында иде, урта сыйныф исә бөтенләй юк иде әле.

Күргәнебезчә, биредә төп мәсьәлә — хакимият белән милекнең үзара нисбәтендә. Илнең бернәрсәгә яраксыз үзенчәлеге дә әнә шул нисбәтнең дөрес булмавында. Хакимият һәм милек капитализмга кадәрге иҗтимагый-икътисади баскычларда бергә үрелеп килгән: колбиләүчеләр һәм феодаллар хакимлек тәиткәннәр, милек-байлык та алар кулында булган; коллар, крестьяннарның исә шымытыры да юк. Соңга таба шундый дилемма килеп туа: йә милек-байлык хакимиятне сатып ала, йә хакимият милек-байлыкны көч белән яулап ала. Көнбатыш капитализмның хәзерге демократик чорына кадәр, монополистик дәүләт чорында хакимлек финанс олигархиясе кулында булган. Шуннан һәртөрле гаделсезлекләр килеп чыккан — ил-дәүләт эчендә социаль мәнфәгатьләр өчен сугышлар-чуалышлар, ә чит дәүләтләр арасында империалистик сугышлар тынып тормаган. Россиядә Октябрь революциясе җиңгәннән соң, капитализмга кадәрле архаик-иске тәртип яңадан торгызыла, әмма ул «камилләштерелә» — колбиләүчеләр, феодаллар урынын милли байлыкка хуҗа, бар хакимлекне үз кулына туплаган большевистик тоталитар дәүләт яулап ала.

Большевиклар күптәнге урыс традициясен — хакимият белән милекнең үрелеп-кушылып бетүен ныгыталар һәм дәвам итәләр, патшаны (илнең баш алпавытын) дәүләт алыштыра. Шул рәвешле, дәүләт феодализмы җәмгыяте оештырыла. Әгәр дә революциягә кадәр Россиядә капитализмның тотрыклы үсешенә, дәүләтнең гасырлар буе халыкны талау сәясәте һәм эш-гамәле аркасында, милекчеләрнең күп миллионлы көчле урта сыйныфы булмау тоткарлык ясап торса, большевиклар буржуаз мөнәсәбәтләрнең үсеш юлларын тулысынча томалап куялар.

«Үзгәртеп кору» чоры башында без җәмгыятьне йотып, шуннан тамагы тыгылган тоталитар дәүләткә ия идек. Ни дәүләт җәмгыятьне төкереп чыгарып ташлый алмый, ни җәмгыять үзе аның ерткыч авызыннан котыла алмый иде. Шул сәбәпле, кинәт кенә көч туплап алган демократия алдына бер бурыч килеп басты: дәүләтне гражданнар җәмгыяте төзерлек итеп үзгәртеп корырга кирәк. Ә моның өчен, югарыда әйтеп үткәнебезчә, хосусый милекчеләрнең урта сыйныфын булдыру фарыз. Икътисадта хосусый милекчелек мөнәсәбәтләре өстенлек итәргә тиеш булып, ул мөнәсәбәтләрне канунлаштырырга, шул рәвешле, барлык гражданнарга да хосусый милеккә ия булу хокукы бирергә кирәк иде. Моңа кадәр халыкның милексез кол-ялчы хәлендә булуын истә тотып, әлеге хокукны матди яктан ныгытырга да кирәклеге көн кебек ачык иде. Дәүләт кулыннан алынган икътисади милли байлыкны, мафиоз түрәләр кулында калдырырга ирек бирмичә, аның төп хуҗаларына кайтаруны тарихи вакыйгалар үзләре таләп итсәләр дә, хакимият моны эшләмәде. Ул нәкъ киресен эшләде, милли байлык таланып бетте. Урта сыйныф оеша алмау аркасында гражданнар җәмгыяте дә туа алмады. Әмма бу вәзгыятьтә коммунизм чорына әйләнеп кайту өреге дә бар, хаким режимның башка төр диктатурага тәгәрәп төшү мөмкинлеге дә кала. Әмма... «керән тормадан төче булмас...»

Хосусый милекчелеккә нигезләнеп, гомумкешелекнең тәрәккыяте эзенә кайту котылгысыз. Мәсьәлә шунда: аңа нинди юл белән кайтырга? Көнбатышта капи-

тализм, феодаль милеккә булган монополияне бетереп, милекне халыкка таратып, шул рәвешле феодаль привилегияләргә чик куеп һәм феодаль җәмгыять эчендә феодал булмаганнарның әкренләп туплаган мал-мөлкәтенә үзләре хуҗа булу хокукын законлаштырып килә-килә, аякка баскан, ныгыган. Дәүләтнең милеккә булган монополиясен без дә шул рәвештәрәк чикләргә — милекне халыкка таратырга тиешбез. Шулай иткәндә, без яңа базар мөнәсәбәтләрендә яшәп китәрдәй социаль катлам булдыра алыр идек. Әмма сиксәненче еллар уртасында демократик үзгәртеп коруларны күтәреп алган «демократларыбыз» ни 18—19 гасырларда Европада булып үткән революцияләрнең тәҗрибәсен, ни егерменче гасырның икенче яртысында Көнбатыш һәм кайбер Көнчыгыш демократик илләрнең капиталны демократияләштерү — халыкка тарату тәҗрибәсен исәпкә алмадылар. Алар башлангыч капитал туплау юлында, бер яктан, «кыргый капитализм» ысулы белән күпчелек халыкны бөлдереп, икенче яктан, дәүләтне талап, шул рәвешле, үз араларыннан инде бүгенге көндә дәүләт аппараты белән үрелеп-кушылып беткән финанс олигархиясенең яшерен структураларын булдырдылар. Әмма дәүләтнең бу сәясәте хәзер халык массаларының кискен каршылыгына килеп сөрлекте. «Үзгәртеп кору» — реформа үзе торгынлыкта хәзер.

Мондый шартларда Татарстанның, анда яшәүче татарлар һәм башка халыкларның үз үсеш стратегиясен һәм тактикасын тирәнәйтергә-көчәйтергә кирәк. Әлбәттә, сүз аларны Россиядән аерып кую турында бармый — монысы мөмкин эш түгел, Татарстанны алгы сафларга чыгарып, аннары Россиянең калган төбәкләрен дә аның үрнәгенә ияреләк итәргә иде. Хосусый милеккә каршылык психологиясе урыс халкының аңына сеңгән, шуңа күрә Россияне бүгенге кризисыннан демократик юл белән чыгарып булмас дип уйлыйм. Халыкның түземе төкәнгәч, дәүләтебезнең аларны бу юлы да алдаганына янә бер тапкыр инангач, мәсьәләне яңа революция ясап хәл итәргә тырышырлар, ул исә иң кан коюлы юл булыр шикелле.

Россия башында утыручыларда, «үзгәртеп кору» башланганда ук, Көнбатышның алдынгы демократик дәүләтләре булышлыгыннан башка ил үзлегеннән генә алар юлына аяк баса алмас, дигән фикер өстенлек иткән булса кирәк. Мин исә эчке мөмкинлекләрне эзләп табу тарафдарымын. Аерым алганда, шундый мөмкинлекләрнең берсе итеп Татарстанны, татар халкын күрәм. Тарихи шартлар шундый булган ки, Россия дәүләтенең язмышы борын-борыннан ук татар дәүләтенең язмышы белән бәйле булып, ул аңа охшаш рәвештә барлыкка килгән-оешкан. Һәм Россия дәүләте шул сыйфатын империячел максатларда да бик әйбәт кенә файдаланып килгән. Хәзер инде заманалар башка. Шуңа күрә дә Россия дәүләте җимерелеп төште. Янә сәеррәк бер тәңгәллек күзгә ташлана: Россия дәүләтен ялган федеративлыктан чын федератив дәүләт итеп үзгәртеп кору эше Татарстаннан, татарлардан башланды. Реформаларны да Татарстан, Мәскәүнең «шок терапиясе» дигән шәфкатьсезлегеннән аермалы буларак, «базар мөнәсәбәтләренә йомшак керү» ысулы белән башлап җибәрде. Хәзер инде бу үрнәккә чит илләр дә игътибар итә, Россиянең күп кенә төбәкләре дә Татарстан тәҗрибәсен өйрәнә.

Халык байлыгының бер өлеше, дәүләт бюрократиясенең ризалыгы белән, тегеләйме-болаймы, төрле шикле эшкуарлар кулына һәм тагын әллә кая таралып бетсә дә, төп милли байлык әле һаман да дәүләт кулында. Бигрәк тә җир үзе һәм җир асты байлыклары. Татарстанга мондый шартларда эшне ни-нәрсәләргә хуҗа-ия булуын исәпкә алудан башларга, җөмһүриятебез байлыгының һәр гражданга тияр өлешен ачыклап, аннары халык кулына шуны раслаучы кыйммәткә ия кәгазьләр (облигация, акция, вексель һ. б.) тоттырырга кирәктер. Халыкның бушлай килгән байлыкны әрәм-шәрәм итеп бетерү теләге барлыгын истә тотып, үзенә тигән өлешне аз гына булса да хак куеп сатып бирү мәслихәттер, бәлки. Ә инде алай түләп алырга мөмкинлеге булмаганнарга бик аз процентлар белән кредитка бирергә була. Бәлки, нефть акцияләрен хәзер үк шул рәвешле сатарга мөмкиндер. Әлеге кыйммәтле кәгазьләр Дәүләт банкы тарафыннан акча белән тәэмин ителгән булырга тиешләр, милекче аны теләсә кайчан үзе теләгәнчә файдалана — йә үзе эшләгән предприятиенең акцияләрен сатып ала, йә берәр кооперативка пайга сала, йә мөстәкыйль берәр үз эшен башлап җибәрә. Дәүләт предприятиеләренең бик зарурилары гына дәүләт кулында калдырылып, калганнары акционерлык җәмгыятьләренә әверелеп бетәргә тиешләр.

Милли байлыкны хосусый милеккә әверелдерү бер максаттан — каһәрле түгәрәктә әйләнүне бетерү максатыннан чыгып эшләнә: юкса, үләт вакытында типтерүче череп баеган азчылык һаман байый; күпчелек халык, бөлгенлеккә төшеп,

әхлакый яктан да таркала бара — нәтиҗәдә башлангыч капитал туплау чорында котылгысыз революция-контрреволюция шикелле афәтләр кабатлана тора.

Мәсьәләнең авыр ягы шунда — милекне бер төрле рәвештә дә монополияләштерүгә юл куелырга тиеш түгел, милекне бетереп булмый, ул бары тик берәүләрдән икенчеләр кулына гына күчә, аның иң начары — дәүләт бюрократлары. Димәк, мәсьәләгә башкача якын килү зарур: хосусый милекне юк итәргә тырышмыйча, аны конкуренция-ярыш шартларында үстереп, әмма бер өлешен, базар әйләнешендә алай-болай бөтенләй юкка чыкмасын өчен, кыйммәтле кәгазьләрдә калдырып барырга кирәк булачак. Анысы һәркемнең милли байлыктагы өлеше булып калыр, ул гражданнарның кагылгысыз табыш чыганагы булыр, әмма эшләмичә генә ашап ятарга җитмәс. Моның бертигез дәрәҗәдәге ике максаты бар: гражданнарның мул-имин тормышы һәм милли байлыкның монополияләшмәве. Гражданнарның үзләре эшләп тапкан һәм милли байлыктагы үз өлешенә кушылган кадәре табышы-милке базар әйләнешендә йөрергә тиеш була. Гражданнарның базар әйләнешенә катнашмаган һәм шунлыктан милли байлыктан да, үзләреннән дә аерып алып булмый торган баштагы милке, үзләренең акционерлык һәм кооператив предприятиеләре аркылы, хосусый милекчеләрнең тотрыклы урта сыйныфын булдыруны җиңеләйтә. Кыска вакыт эчендә күпмиллионлы д е м о с — ирекле-бәйсез халык хасил була.

Халык хуҗалыгының мондый ысулы бер өстенлеккә ия: беренчедән, сүз барлык социаль катлаулар турында бара, икенчедән, турыдан-туры житештерү тармагында эшләүчеләрнең генә түгел, ә җәмгыять алардан башка яши алмый торган төрле хезмәткәрләрнең дә мәнфәгатьләре үтәлә. Милекнең халык кулына күчүе тәэмин ителә һәм, шул ук вакытта, милли икътисадның бөтенлеге сакланып кала. Милли байлыкка идарәче даирәләр дә, идарә ителүчеләр дә хуҗа була. Шулай итеп, бүген дәүләт милкенә кулын салган түрәләр дә калган гражданнар белән тигезләнәләр. Һәркем хуҗа да, хезмәткәр дә булып кала — без зарыгып көткән чын демократик хакимият барлыкка килә. Ул, һичшиксез, сайланып куела, димәк, үз тиңдәшләре — милекчеләр алдында җаваплы була, эш-гамәлләре турында хисап биреп бара, аннары, хосусый милекнең табыш китерә торган үз өлеше да икътисадка салынган булганлыктан, ул икътисадның уңышлы үсешендә үзе дә матди кызыксынган була.

Үзенең күпмилләтле, шул исәптән, урыс халкының да шактый күп булуы белән аерылып торган Татарстан — социаль юнәлештәге базар икътисадын тормышка ашыру өчен иң кулай төбәк. Соңгы еллардагы вакыйгалардан күренгәнчә, ул бер дә «бөек дәүләтчелек» уенчылары кулындагы вак акча хәлендә калырга теләми. Татарстанның суверенитеты-бәйсезлеге буенча референдум үткәрер алдыннан мин «Комсомольская правда» газетасында: «Җөмһүриятебезгә нинди генә көчле басым-һөҗүмнәр ясалмасын, референдум барыбер узачак. Минем карашымча, әгәр анда куелган сорауга җавап уңай булмаса,— монысыннан Аллам сакласын! — референдумны Татарстанда яшәүче урыслар харап итте, диячәкләр, бу исә милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бик нык кискенләштерәчәк. Безнең төбәктәге күп гасырлык дуслык-татулыкка, үзара тыныч, килешеп яшәүгә чик куелачак,» — дип язып чыккан идем. Татарстанлы урысларның акыллы булуларына сокланам хәзер: төрле казыну-тыкшыну, котыртуларга карамастан, алар Мәскәүнең «бишенче колоннасы» булудан баш тарттылар, референдум соравына уңай җавап бирделәр.

* * *

Милли мәсьәләләрне татар диаспораларында хәл итү катлаулырак та, авыррак та. Табигый ки, чит милләтле төбәкләрдә татарлар никадәр генә күп булмасын, алар үзләренә аерым гражданнар җәмгыяте төзи алмыйлар. Әмма милекче урта сыйныф оешуга үзләреннән шактый саллы өлеш кертә алалар. Татарларның кайбер милли үзенчәлекләре моңа тулы мөмкинлек ача: аларның мал-мөлкәткә бирелгәнлеге, сәүдәгә, вак һөнәрчелеккә күңел салуы, белемгә-фәнгә, мәдәнияткә, технологик алымнарны үзләштерергә омтылышы, ничек кенә сәер тоелмасын, башка халыкларныкына караганда көчлерәк сакланып калган. Читтәге татарлар арасында югары квалификацияле белгечләр, сәүдә, сервис, фән һәм мәгариф өлкәсендәге хезмәткәрләр, соңгы вакытта исә бай гына эшмәкәрләр, банкирлар бик күбәйде.

Хәзерге катлаулы заманда татарларның исән-сау яшәүләре дә, тормыш итүләре дә канәгатьләнерлек. Татарстанда булсын, чит төбәкләрдә булсын, хәер

сорашучы татарларны күрмәссен, ә шактый мул яшәүчеләре байтак, дворникмы ул яки носильщикмы, эшчеме яки хезмәткәрме — һәрберсе хәзерге күчеш чоры шартларына ничектер яраклашкан-җайлашкан.

Татарларның күңелләрендә үз милләтен саклап калу идеясе өлгереп киләме соң? Бу сорауга җавап уңай булыр дип уйлыйм. Мәскәүдә һәм башка урыннардагы күзәтүләремнең нәтиҗәсе шундый: паспортларында татар язылып та, туган телләрен бөтенләй белмәгән (телен ул йә Ватаныннан аерылып югалткан, йә тумыштан белми), урыслашкан татарлар да туган телләрендә сөйләшергә омтылалар, төрле татар җәмәгать оешмаларына теләп йөриләр; тел белүчеләр алдында үзләрен уңайсызрак тойсалар да, милли мәдәниятебезгә тартылырга тырышып, татарча спектакль-концертларны калдырмыйлар. Советлар заманында мондый хәлнең булганы юк иде, киресенчә, урыс телен начар белүчеләр оялып яши иделәр. Үзләренең этник бербөтенлеген югалткан татарларның соңгы ун ел эчендә бу бөтенлекне торгызырга омтылышы — татар халкында сакланып калу хисенең милли идея буларак туа килүенә ышанычлы дәлил. Милләтебезнең яңару-үсү процессын татарларның милекче урта сыйныфын булдыру юлы белән ныгытырга кирәк. Татар милли капиталы, гражданнарның һәм татар байларының маяларын бергә туплап, шул рәвешле татарларны милекче итү бурычын алга куйганда гына барлыкка килә алыр. Бу капитал тарихи Ватаннарына күченеп кайтырга мәҗбүр булган качакларга ярдәм күрсәтүдә дә бер таяныч булачак. Кайда яшәвенә карамастан, барлык татарларга да хезмәт күрсәтә торган Татар халык банкы оештырырга да вакыттыр. Ул банк Татар халык университеты ачып җибәрергә матди нигез була алыр иде. Университетта татарлар яшәгән барлык төбәкләр өчен милли кадрлар әзерләп чыгарылыр иде, аңа халыкара статус бирү дә мәслихәт булыр иде.

* * *

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең 1997 елның август аенда II Бөтендөнья татар конгрессын җыю турындагы тәкъдиме татар милләтенең киләчәк язмышы өчен борчылудан килеп тугандыр дип уйларга кирәк. Ничәмә-ничә гасыр дәвамында тупикка барып төртелгән милләтебезне аннан чыгарырлык нинди дә эш-гамәлләргә сәләтебез барлыкка өметләнүеннән тугандыр. Соңгы ун ел эчендә булып узган тарихи вакыйгалар безгә бик кулай-уңайлы мөмкинлекләр ачкан иде, әмма без ул вакытны булдыксыз рәвештә исраф итеп бетердек шикелле. Ә бит узган гомерне кайтарып алып булмый...

Татар милли капиталын булдыру идеясе I Бөтендөнья татар конгрессыннан соң озак та үтмәстән әйтелгән иде, әмма ул иштелмичә калды. Ә бит аны тормышка ашыру Татарстан өчен, читтәге татар диаспоралары өчен гаять зур таяныч булыр иде. Без исә җөмһүриятебезнең чикле мөмкинлекләренә генә исәп тоттык. Татарстандагы ике миллион татар чит төбәкләрдәге үзеннән ике-өч мәртәбә күбрәк булган татарларны үз җилкәсендә күтәрә алмый, әлбәттә. Киресенчә булырга тиеш.

II Бөтендөнья татар конгрессы да, аннан соңгы гамәлләребез дә түрәләр ярата торган гадәти банкет-мәҗлесләргә генә әйләнеп калмас дип ышанасы килә. Бәйсез Дәүләтләр Берләмлеге илләрендәге татар җәмгыятьләре дә эшлекле киңәшләр көтә.

Әйе, бушка сөйләнеп йөрүләрне туктатып, гамәли файдалы эшләр эшләргә вакыт бик җиткәндер. Милләттәшләр, сызганыйк җиңнәрне!

*Мәскәү.*
*Апрель, 1997 ел.*

# ИР ҖАНЫНДА — НИ БУЛМАС!



*Зәет ага Мәҗитов — күпләребезнең университет буенча укытучысы, остазы. Әйе, озак еллар буена татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты булды ул: кырык елга якын вакыт аралыгында университетта сабак алып, әдәбиятка килгән берничә буын язучылар — аның шәкертләре. Бигрәк тә шагыйрьләр. Тыйнак, тыштан бик тыныч күренгән, хәтта юаш кебегрәк Зәет агадан әдәбият теориясе, фольклор, Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясе буенча байтак мәгълүматлар алган кеше без! Бигрәк тә Фатих Кәрим шигърияте турында ялкынланып, гашыйкларча дәрт белән сөйләгәне хәтердә. Шулай булмыйча! Актаныш районының Иске Айман авылында туып үскән, Пучы мәктәбендә (Нур Баян кебек якташ шагыйре белән горурланып!) укыган, аннары университетта белем алганда үзенең шигырьләре матбугатта күренә башлаган Зәет Мәҗитов аспирантурага калдырылгач та, диссертация темасын «Фатих Кәрим поэзиясе» дип ала; 1955 елда аны яклап, филология фәннәре кандидаты исемен алгач та, шул темага, шул чор шигъриятенә тугры кала (1954 һәм 1979—1981 елларда, ике тапкыр, Фатих Кәримнең «Сайланма әсәрләре»нең өч томлыгын чыгаруы гына күпне сөйли. Кереш сүзе генә дә ни тора! Ә искәрмәләр-аңлатмалары?!). «Сугышчан поэзия» исемле китабы (1978) әнә шул мәхәббәт җимеше, үз этисе кебек үк, сугышта һәлак булган татар яугирләренә багышланган фәнни һәйкәлдер. Бу өлкәдәге хезмәтләре белән безне, булачак шагыйрьләрне дә, югары гражданлык поэзиясе белән тәрбияләгән ләбаса! Аннары, шул елларда Татарстан язучылар берлегенең шагыйрьләр секциясе җитәкчесе буларак, аның яшьләргә аерым бер кайгыртучанлыгы хәтердә. Җөмләдән, 1965 елда узган язучылар съездында шигърият буенча докладны ул ясады; шунда ул беренче буларак безнең буын шагыйрьләренә киң тукталды (Равил Фәйзуллин һәм шушы юлларны язучының исемен, зур өметләр баглап, вакыйга буларак әйтеп узды), ә инде яшьләр иҗаты һәм иректле шигырь турында бәхәсләр кузгалгач, матбугатта безнең буын турында үз фикерен әйтеп, «Хәерләре белән үссеннәр» исемле әтрафлы мәкалә язып чыгуы исемдә. Без аңа һаман да рәхмәтлебез. Әйе, күп шагыйрьләр, зур исемнәр, төрле-төрле характерлар, язмышлар, мәхәббәтләр булгандыр — шәкертләре белән күп еллар аралашуында. Әмма Зәет агада көнчелек, хөсетлек, тарлык, кинә-үч кебек сыйфатларны беребез дә белми — моңа иманым камил. Һәр укытучы-остаз кебек үк, «данлы, олуг шәкертләре» фонында ул үзе күмелеп тә калгандыр... тәгаен шулайдыр да ...әмма Зәет ага үзенә, холкына, табигатенә һәм шагыйрьлегенә дә тугры калды. Шагыйрьлеге дигәннән... 1953 елда «Таңгы җыр» исемле беренче китабын, аннан соң уннан артык мәҗмуга бастырып чыгарган (арада «Рәхмәт яусын» (1977), «Чыклы сукмак» (1987) исемле сайланма характердагылары да, «Ярсу Ык» (1966) кебек шигъри повесть та, поэмалар да, җырлар, мәсәлләр, юмор-сатира бәйләмнәрен туплаган китаплары да бар!) әдип гомере буе үзен шагыйрь санады, шигырьгә тугры калды, каләмдәшләре өчен сөенде, поэзия мәсьәләләренә багышлап мәкаләләр язды. Кыскасы, бүгенге олуг юбилее — 70 яшенә дә ул шагыйрь булып, яңа шигырь бәйләмнәре, бүгенге ил үзгәрешләренә, халык, тел язмышына үзенең актив карашы булган аксакал булып, чын мәгънәсендә татар улы татар булып килде. «Ачулы еллар дәфтәре»ннән дип атала без тәкъдим итә торган шигырьләр... Әйе, «мәңгелек сер» булган кеше күңелендә, «ир җанында — иярле, йөгәнле ат ятар», дигәннәр. Шагыйрь күңелендә дә ниләр генә булмас! Ә ачылырга, янарга, милли асылына кайта-кайта язарга теләк зур анда. Афәрин, Зәет абый! — дибез.*

*Рәдиф ГАТАШ.*

# Зәет Мәҗитов

## «АЧУЛЫ ЕЛЛАР» ДӘФТӘРЕННӘН

### Исә җил

Исә дә исә көзге җил,
Бер көчәеп, бер тынып.
Имән тикле имән гүя
Тора чак-чак тотынып.

Җилгә каршы талпына кош,
Оясына кайтмакчы,
Ачуы чыккан төсле, җил
Аны артка атмакчы.

Мәһабәт тә, шөбһәле дә
Иделдәге гарасат.
Ярларга сугыла дулкын,
Гүя ярсып чапкан ат.

Әллә ниләр уйлап куям,
Җаным куба бу мәлдә...
Ачулы җил, ярсу дулкын,
Мин үзем сезнең хәлдә!

*1977*

### Сарылык

Бөтен җирем сары бүген,
Сары болын, тугаем:
Бер дә юкка сары булмас,
Сагыналардыр, мөгаен.

Бөтен нәрсә сары бүген,
Сары хәтта ак каен.
Агачлар да юксынадыр,
Сагынадыр, мөгаен.

Сары өйләр, урам, шәһәр,
Кояшым сары, Аем.
Йөземне дә, җанымны да
Сагыш басты, мөгаен.

Уйлар, гамьнәр, хәвефләрнең
Бергә килеп барысы
Әллә миңа сарылдымы
Бөтен дөнья сарысы?!

*1991*

## Әсир

Бер әсир мин, чорналдым чор гамьнәренә,
Утларына, суларына, чәчәгенә,
Бил турайтмас эшләренә, хәстәренә,
Язмышларны чөеп йөрткән хәтәренә.

Чуалдым мең каршылыкның җәтмәсенә,
Күз камагыч алдау сипкән кояшына,
Парадлары, ялган тулы речьләренә,
Һәм коточкыч химиясе, АЭСына.

Чолгандым кан-яшьле илләр мәхшәренә,
Һәм әйләндем юл югалткан бер юлчыга.
Көлү кушып языйм дисәм, шигыремә
Әрем булып, дөньясына ачу чыга.

*1992*

## Ашыкма

Гомерләр күп нәрсә, күп гыйлем өйрәтте,
Җаннарны талкыды, бәгырьне көйрәтте.
Өйрәтте сәер һәм чарасыз һөнәргә —
Вәгазьләр сөйләргә, теләкләр теләргә:
Йолдызым, ашыкма, ашыкма сүнәргә!

Күп булды үтелгән сикәлтә юллар да,
Үзәкне өшеткән хәвефле еллар да,
Һәм булды тиеш чак бик кыйммәт түләргә,
Теләргә өметләр өзелгән көннәрдә:
Бәхетем инеше, ашыкма кибәргә!

Иң кыйммәт дусларны күп булды югалту;
Иң сөйгән кешегә җитмәде юату;
Күп вакыт өйләрдә җитмәде көйләр дә,
Рөхсәт ит соңгы кат, соңгы кат теләргә:
Гөлкәем, ашыкма, ашыкма шиңәргә!

*1994*

## Иртә

Кояш әле чыкмаган да,
Офыкта тик ал төсе.
Капкан ләкин агачларга
Уты — алтын яктысы.

Шундый тыйнак, әйтерсең лә
Бөтен дөнья туктаган.
Зифа камыш, үләннәргә
Көмеш булып чык яуган.

Иртәнең сихри ямена,
Рәхәтенә кинәнеп
Кашкарый кызлары көлә,
Әкрен генә тирбәлеп.

Җәүһәр-якутлар иңгәнме —
Җем-җем итә күл өсте.
Дулкынлатып ефәк күлне
Бер оя үрдәк төште.

Һәр нәрсә саф, тере, җете,
Сизелә: кояш чыга.
Кармагын салыр чак җитте
Ярдагы балыкчыга.

Әфсенләп кармак-җимнәрен
Килә бер ипле җиргә.
Балык та чиртер күрәсең —
Акбае котә бергә.

Мин бу вакыт шундый хәлдә:
Гел тылсымланган төсле.
Бәхетлеме мондый мәлдә
Йокыга талган кеше?

Тереме таң хозурына
Игътибар итмәүчеләр?
Җир-әнкәнең тын җырына
Исләре китмәүчеләр?

Яшә, и Җир бөеклеге!
Җанның илаһи чагы!
(Гомернең дә шундый көне
Бер кайтса иде тагы!)

*1994*

* * *

Беркем белми, белмәс, белмәсен дә,
Беләм, беләм, беләм мин генә:
Бу дөньяда иң сөекле кешем,
Иң кадерле кешем син генә.

Беркем белми, белмәс, белмәсен дә,
Беләм, беләм: син бар бу җирдә,
Син бар, димәк, гөл бар, нур бар җанда,
Кояшым бар, Ай бар күңелемдә.

Беркем белми, белмәс, белмәсен дә:
Наз чишмәсен син ул эчердең.
Тик син генә, бер син, бер син генә
Гомерлек яз миңа китердең.

Белсен ләкин, белсен яшь тә, карт та,
Белсен һәркем, күкләр һәм хәят:
Әҗәлдән дә олы, өстен көч бар,
Мәңгелеккә тиң көч — Мәхәббәт!

*1995*

## Юл чатында

Килеп чыктым юл аерылган төшкә,
Торам юл чатында,
Юл югалтып зур хәвефкә төшкән
Юлчы сыйфатында.

Уңга таба китсәм — кара урман,
Таныш түгел яклар.
(Байтак булды урманнарда кунган,
Ялгыз туңган чаклар).

Сулга китсәм, читкә тарта төсле
Барасы ягымнан.
Очрамый да шунда хет бер кеше —
Кичкәрәк калынган.

Юл чатында торам аптырашта:
Кайсы юлдан китим?
Нигә шулай кирәкмәгән чакта
Тиз килә соң бу төн?

Ник бу гомер яшәлде соң һаман
Аптырау эчендә —
Ике юл чатында туктап калган
Мосафир төсендә?

Ник ал-гөлгә манып мактасак та
Барасы якларны,
Тиргә батырганчы kayласак та
Йөк тулы атларны —

Әле сазга, әле кантарлыкка
Килеп төртелдек соң?
Тураеп атларлык хәлләр юкка
Бөгелеп йөрдек соң?

Бүген дә бит алда кара урман,
Һәм шикле юл чаты.
Кая барма — баскын, угъры тулган,
Һәм күренми якты.

Нинди юл бу? Юлы кая илтә?
Калдык юл чатында.
Уйлый китсәк — бүген ил хәвефтә,
Юлсыз сыйфатында.

Уйга батып юл чатында торам,
Караңгы да төште.
Кайда соң син Хөзер Ильяс сыман
Юл күрсәтер кеше?

Әллә син дә юлны бутадыңмы
Минем шикелле үк?
Яна идең, инде тукталдыңмы
Өметең үк сүнеп?

Кил син кабат, кабыз факелыңны,
Бу туктар көн түгел.
Утың белән яктырт барыр юлны,
Бел: хәлебез мөшкел!

*1996*

# УЙНЫЙ ЙӨРӘК...



*Шушы җирдә инде ярты гасыр гомер итүче Наис Гамбәр хакында минем тәгаен хөкемфикерем бар, әлбәттә. Булмыйча соң! Беренчедән, ул — минем якташ. Бер үк мәктәптә унберне йомгаклап чыктык. Яшерен-батырын гына язган тәүге шигырьләребезне бер-беребезгә укыдык. Бер-беребезне: «Һа! Син — бөек!» — дип макташтык.*

*1992 елда Наиснең «Баш очымда — Кояш» исемле китабы чыкты. Андагы шигырьләрнең кайберләрен без көндәлек матбугатта укый килгән идек инде. Яратып, рәхәтләнеп укыдык. Инде менә аның күңел дәфтәре — җан серләре тупланмасы безнең кулда. Кайсы яклары белән кызыктыра соң безне Наиснең шигырьләре? Әлбәттә, һәр сүздән бөркелеп торган ихласлык белән.*

*Ул шигырьләрдәге манзаралар, шәхесләр, сөйгән ярларның толым җылысы, кыланмышлар, урман шавы, яландагы үләннәрне назлы гына сыйпап узган кичке җил назы — һәммәсе дә миңа бик яхшы таныш. Әйткәнемчә, без — якташлар.*

*Әдәбият өлкәсендә галим кешеләр, гадәттәгечә, төгәл, бәхәссез һәм... коры шигырьләр яза. Һәм үзен хаклы саный. Наис тә әдәбият галиме. Әмма аның фәнни юнәлештәге язмаларын укыганда үзеңне, купшы сүз өчен әйтүем түгел, шигъри язма укыгандай хис итәсең.*

*Ул сурәтләгән шәхесләрне, мөгаен, хәтерлисездер: Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Рәис Даутов, Гәрәй Рәхим, Мөдәррис Әгъләм, Фәрит Гыйльми, Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм бүтән күренекле затларыбыз.*

*Наис элегрәк яшәп килгән традицияне — язманың башында авторны мактап, ахырында кимчелекләр хакында әйтүне, исем санауны өнәми. Үзе ихлас шагыйрь булараk, ул иҗат процессын бик яхшы белә һәм курыкмыйча тирәнгә чума. Һәм, сүз дә юк, энҗене тирәнгә, озакка чума белүчеләр генә таба...*

*...Шигырь дигәнең һәркем өчен дә дип язылмый. Яшь чакта кызлар белән хат язышканда болай дип конверт тышына яза идек: «Яратсаң — укып бак, яратмасаң — утка як!»*

*Шигырьгә карата мөнәсәбәт тә нәкъ шундый ук. Һәм бу ифрат табигый дә.*

*Наиснең шигырьләре арасында мин үз күңелемдә йөрткән шигырьләр байтак. (Үземнең хакта да ул күңел юатырдай сүзләрне аз әйтмәде.) Хәтта мин аның бер шигырендәге юлны эпиграф итеп алып, аерым шигырь дә яздым:*

*Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер —*
*Безнең бәхет бары Мөслимдәдер!*

*Шулай, Наис. Ык көтә безне... Аның тыгыз, йөгерек агымы көтә... Шулай көткәндә йөрәкне уйната торган хис шигырь дип атала түгелме соң? Шигырь — йөрәк уйнаганның җимеше ул.*

**ЗӨЛФӘТ.**

## Наис Гамбәр

### ЕЛЛАРДАГЫ ЮЛЛАР

#### Кылганнар йөгерә...

*«Дала буйлап кылганнар йөгерә...».*
Ә. Еники

Кылганнар йөгерә, кылганнар...
Дулкыннар йөгерә сөрлегеп;
(Акъәби йөридер кырларда
Ак мамык шәленә төренеп.)
Кылганнар йөгерә сөрлегеп.

Хәтер — җил; мәңгелек җил-давыл,—
Актара учаклар куызын;
Шәфәкъләр — кып-кызыл, кан кебек;
Дала — киң; көн — кыска; юл — озын...
Җил тузгый учаклар куызын.

Офыкта — чатырлар; яна ут,—
Учак та җилпенә, тынгысыз;
Таң белән — сәфәргә, сәфәргә!
Хыял — ук; хис-хәнҗәр — кынысыз.
Чатырлар каршында яна ут.

Акъәби торгандыр сәхәргә,
Җилләрдән көткәндер хәбәр-өн,—
Кылганлы кырлардан Ак атта
Бер кайтыр Ил кичкән хәләлең.
Акъәби көткәндер хәбәр-өн.

«Ир-егет җанында ат ята» —
Акъәби сүзе бу колакта...
Кайсыбыз менәчәк толпарлар
Кешниләр тибенеп улакка?!
«Ир-егет җанында ат ята».

Кылганнар йөгерә, кылганнар...
Кырлардан йөгерә сөрлегеп;
Акъәби учагы сүнгәнче
Булырмы сәхәргә өлгереп?!
Дулкыннар йөгерә сөрлегеп.
Кылганнар йөгерә...
Йөгерә...

## Син — бер генә

Меңнәр арасында син — бердәнбер,
Син бер генә дөнья йөзендә;
Бер гомер ул нәрсә?!
Мөмкин булса
Бирер идем унын, йөзен дә

Сиңа гына... Син кайларда хәзер,
Җир шарының кайсы төшендә?!
Нинди билгеләрдән танып дәшим
Очрата калсам төшемдә?!

Чәчкәләрең кайда орлык коя,
Туфрагына нинди түтәлнең?!
Син гөл идең, сеңлем, һичберкайчан
Шиңмәс гөле ерак үткәннең.

Дуслар, иптәш, таныш, якыннардан
Бармы кешең «абый» диярлек?!
Син — беренче идең, син — бер генә
«Сеңлем» итеп башым иярлек.

## Мәхәббәт

Әкиятләр укый идем шашып:
«Таһир белән Зөһрә» кыйссасын,—
Кешеләрдән качып тын бакчада.
...Ah,
Шул чакта ук уйда син булгансың.

Агачларга менеп, биеклектән
Ерак кырлар түрен күзләдем,—
Ачылдылар хозур манзаралар.
...Ah,
Шул чакта ук сине эзләдем.

Нинди киң бу дөнья,— йөгер, уйна,—
Яшьлек белми кимлек, тарлыкны:
Күге биек, йолдызлары якты.
...Ah,
Белдем шул чак синең барлыкны.

Болыннарга чыктык, таңга каршы
Көлә-көлә сүтеп тараттың
Гөлләр исе сеңгән чәчләреңне.
...Ah,
Мин шул чакта сине яраттым.

Чыкты җилләр, ышыкладым сине,
Кулы каты була ир-атның,—
Кочагымда килеш сулды гөлләр.
...Ah,
Мин шул чакта сине елаттым.

Тынды дөнья, күтәрелде кошлар,
Мин аларга төзәп ук аттым,—
Берсе төште егылып алларыма.
...Аһ,
Мин шул чакта сине югалттым.

Мин идем ул сыра залларында
Бер почмакта оеп утырган,—
Яшьләр тулы касә кулларымда.
...Аһ,
Мин теләдем сине онтырга.

## И мәхәббәт!

Һәр тән буйлап ага бер агым су,
Һәр күкрәктә ага бер җырым,—
Җанны кап урталай ярып үткән,
Телеп-телеп үткән бер җылым.

И мәхәббәт! Шөкер, миндә дә бар
Синнән калган шушы бер яраң:
Аны уйлыймын да — үлеп тереләм,
Өр-яңадан туып яңарам.

* * *

Төтеннәре туры чыкканнарның
Урау була кайтыр юллары,
Дигән иде кырда юлаучы карт.
Мин юлымны озак юлладым

Ахырысы... Сырындылар сара —
Эзләр күмелә, сүнә, югала.
Кичәгедән калган хатирәләр
Тоныклана бара. Юк алар.

Урамнар буш. Койма ярыгыннан
Өреп торган әрсез җил генә,
Хәбәре юк инде дигән кебек,
Иләгендә карлар җилгәрә.

Ак төтеннәр чыкмый морҗагыздан,
Капкаларга йозак эленгән.
Өянкегез моңсу. Ак йөзләре
Телем-телем булып теленгән.

Төтеннәре туры чыкканнарның
Урау була кайтыр юллары,
Диде юлаучы карт.
Сезгә житкәч,
Хәлсез калды аяк-кулларым.

* * *

Еллар үтеп, юллар югалса да,
Сүтелсә дә гомер сүсенем —
Мин эзләрмен синең эзне генә
Җырларыма кергән сеңелем!

Еллар үтеп, юллар югалса да.

* * *

Урман. Тын. Шомлы уфылдый
Бары ябалак кына;
Югыйсә таң аткан иде бит
Әле яңарак кына.

Көн туган иде яктырып,
Бар җиһан нурда иде;
Офыклар көләч... Кояш та
Иң биек турыда иде.

Кай ара иңде эңгерләр,
Кай ара җитте киче?
Төн куып җитте юлчыны
Урманга кергәч... Читен.

Сәфәргә чыккан иде ул
Моннан мең еллар элек,—
Сихри атаулар артында
Гүзәл балкышлар күреп.

Барды да барды,—дәштеләр,—
Борылып карамады;
(Төн. Урман. Байгыш уфылдый
Очында караманың.)

Алда — үр... Анда — яктылык.
Үзәндә — күләгәләр.
(Күлмәге — ертык. Юләрлек
Гел шулай түләнә лә.)

Таң белән — юлга. Юллары
Чытырман урман аша.
...Уйлый ул. Уен биштәрләп,
Йокыга урынлаша.

Урман. Тын. Авыр уфылдый
Бары ябалак кына.
Таңнарга ерак... Сүңде көн
Әле яңарак кына.

* * *

Минем өчен
Әкияттәге Шәмшәрифтән гүзәл
Утыз йортлы туган Бүләкнең
Хәтер томаннары аръягында
Торып калган нәүмиз сурәте.

Көннәр якты монда.
Томаны да
Үтә күренмәле, сөт томан;
Күпереп тора ястык болытлары
Килиманджаро карлары сыман.

Таулар бик күп җирдә.
Тик аларны
Ничек кенә җан аямасын —
Газизерәк барыбер
Чана шуып үскән Шәех тавы —
Авылымның Фудзиямасы.

* * *

Әйтәсең кайчак: «Тузгыттың
Бер дигән тормышымны.»
Җимердем хәрәбә өстенә
Корылган куышыңны.

Өермә... Хәбәр бирсәңме —
Күптән юк булыр идем!
Хәзер билгесез тарафка
Аткан ук кебек инде.

Йә нигә сиздермәдең бер
Артык йөк икәнемне?
Юкса, мин арбам чүмәлеп
Киткәнне көттеримме?
Шикләнмә тагын юлыма
Аркылы басар, диеп.
Ябып куелган тәрәзне
Вакытсыз кагар, диеп.
Курыкма, төшмә хафага,
Урынсыз борчуларың.
Сиңа да җайсыз түгелдер.
...Мин дә иркен суладым.

* * *

Сүрелде көннең күзләре,
Шым калды әрәмәлек;
Җанымда — тегермән ташы ла,
Суларга бәрәм әле.

Уянсын кошлар, балыклар
Тегермән буасында;
Таң атса, дөнья кендеген
Буардай буласың да...

Иске тегермән...
Җен кызы
Тор да син, үр дә чәчең,—
Югыйсә синең урманда
Карт дию — ялгыз яшим.
(Чикләвекләр кысыр быел,—
Төшләрен алды яшен.)

Тегермән ташы...
Ватылган,—
Суларга бәрәм әле.
Ачылсын көннең күзләре,
Терелсен әрәмәлек.

## Бәлки...

Бәлки юкка барлык омтылышлар,
Бушка бәлкем сөю-янулар?!
Поезд киткән инде... юллар ябык,—
Алда яна кызыл семафор.

Йөгереп каршы чыктым... Уты гына
Чагылып калды соңгы вагонның;
Һәм күренеп барды — офыккача —
Тәрәзәдән сузылган кулың.

Минме соңга калдым,
әллә синме
Иртә киттең?! Кайда буталыш?
Бәлки минем соңгы вокзалымдыр
Таныш түгел шушы тукталыш?!

Бәлки шулай үзенеке итәр
Әрем баскан шушы кыр-үзән?!
Без җирнеке барбер — күкрәгенә
Күкрәк куеп авам йөзтүбән.

Мин ятармын олы юл читендә
Ерак киңлекләргә күз атып:
Килер поездларны каршы алып,
Китәрләрен —
Хәерле юл теләп озатып.

# РӨСТӘМ МИНГАЛИМГӘ — 60 ЯШЬ



Тау итәгенә уралып-уралып ага торган нәни генә инеш-елга. Ятим әнке һәм һәр татар авылларында була торган бәрәңге бакчалары... Рөстәм Мингалим мине үзе белән яртеп алып кайткан иде, тыйнак кына әйтеп куйды: «Туган авылыңны күрсәт, дигән идең — менә шушы авыл була инде ул. Элекке елларда, сәвитский итеп, «Йолдыз» дип атала иде», — дип, авыр көрсенеп куйды. Йөрәгемне нәрсәдер чәнчеп үткәндәй булды: әремкычытканлы ташландык йорт нигезләренә игътибар итмәгәнмен икән бит әле мин...

> Сүндер утны, ялыктым мин
> бүген көн яктысыннан...

Рөстәм дустым бу юлларны җитмеш биенче елда ук язган булган... Бүген ул, әнә, мине иртеп кайткан да, бәрәңге бакчасының ызанына да басарга кыймыйча, бер мизгелгә туктап калган. Туган туфрагына баткан туфлиен, тишелеп килгән берәр бәрәңгене таптамыйм-имгәтмим дигәнрәк шикелле, аягын кая күтәреп басарга да җөрьәт итмичә торган чагы иде шагыйрь дустымның. Рөстәм Мингалимне аңлыйсыгыз килсә, аны балачагы үткән җиренә генә бастыр — бар шигъриятенең серенә шунда гына төшенерсең.

Бүген бер бакчаның ызанына да басарга-казырга кыймыйча, мине иртеп кайткан да, үзе аптырап торган Рөстәм Мингалим инде ул. Һәр язганының кырыслыгы да, моңы да шунда аңлашылыр.

Мәскәүнең ГИТИСында Югары театр курслары эшли, театр сәнгатенең дәүләт институты профессоры Виталий Вульф бервакыт: «Миндә Казаннан Рөстәм Мингалимов дигән бер егет укыды — минем белән бәхәскә керерлек бердәнбер кеше иде ул,— дигән иде.— Курс тәмамлангач, хушлашу банкетына да мин анда Рөстәм Мингалимов булганга гына бардым.» Америка драматургы Теннесси Уильямсның даһи булмавын төшендереп биргән үзенең укытучысына Рөстәм шул банкетта! Көндәлек тормышның әдәби китапларда язганнардан күпкә катлаулырак икәнен тәки аңлаткан тегеңә!

Рөстәм Мингалим иҗатына бәя бирү — тәнкыйтьчеләр эше. Мин аның каләмдәше генә, шуңа күрә, ак көнләшү белән көнләшеп, аңа чын-чынлап кызыгып, үз әсәрләренә исем кушудагы осталыгын гына әйтеп үтәм: «Тау астында илле бүре», «Өченче бүлмәдә эт яши», «Дүрт кешелек утыргыч» һәм башкалар...

Татарстан язучылар берлеге бинасында бер кечкенә бүлмә бар: өч йөзләп тулы хокуклы язучының һәм язучы булырга чиратка баскан тагын өч меңләп кешенең һәрберсе ул бүлмәдә кимендә унар тапкыр булгандыр. Чөнки анда көзге ачы җилләргә дә бирешмәгән бер «җылы йөрәк» утыра. Ул дисталәгән-йөзләгән яшь язучыларга фатихасын бирә, үз иҗатына кирәкле иң мөкатдәс-изге уй-фикерләрен аларга учлап-учлап өләшә, китапларын әзерләшә, үсеп-үрләп китүчеләр өчен чын йөрәктән сөенә белә. Кем ул? Ул — Рөстәм Мингалим. Менә аның алда мин искә алган бер шигыре ничек тәмамлана:

> Сүндер утны, яшьлекнең шәт
> Шигъри аслы шулдыр ул:
> Янганны сүндерә алу,
> Һәм сүнгәнне — яндыру.

Әнә шулай кечкенә очкынны да зур ялкынга әйләндерә белә безнең алтмышына җитеп килгән дустыбыз. Аңа иҗади җимешле озын гомер, саулык-сәламәтлек телик әле бүген!

Ризван ХӘМИД

Рөстәм Мингалим

# ТАУ АСТЫНДА ИЛЛЕ БҮРЕ

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ СӘЕР ТАМАША

Катнашалар:

Ясам улы Ишкуар (хуҗа).
Ярдәмче.
Хатын (Ишкуарның хатыны).
Белгеч (әтәчләр белгече).
Таныш (Ишкуарның диңгез буендагы танышы).
Тавык караучы.
Беренче егет.
Икенче егет.
Карт.
Дулкын ханым (җыелыштагылардан берәү булып та катнаша).
Диңгез ханым (җыелыштагылардан икенче берәү булып та катнаша).
Якташ (Ишкуарның якташы, җыелышта композитор булып та катнаша).
Кисүче (җыелышта шагыйрь булып та катнаша).
Шофер (җыелышта хор җитәкчесе булып та катнаша).

Җыелышларның беренчесендә тагын өч-дүрт хезмәт кешесе булырга тиеш. Артыграк булса да яхшы. Монысы театр мөмкинлекләреннән һәм режиссер теләгеннән тора.

## I БҮЛЕК

### Беренче күренеш

**Башта микрофонда тавышлар гына ишетелә:**

— Тамашабызны башлыйбыз. «Тау астында илле бүре!»

— Юк, алай түгел!

— Алайса, «Сары тавык турында!»

— «Сары тавык турында» түгел. «Тау астында илле бүре» дә түгел. Бу тамашаның исеме — «Тимер әтәчләр!» булырга тиеш.

— Син ни сөйлисең?

— Шулай. Әсәрдә бүреләр бөтенләй күренми. Тавык — тавык кына инде ул... Ә менә әтәчләр! Үзем сатып алган әтәчләр!

— Алайга калса, әсәр тавык турында да, әтәчләр турында да түгел. Ә кайчандыр бер хуҗалык белән идарә иткән, үз тирәсенә ялагайлар туплаган, үз-үзенә, үз сүзенә генә ышанган хуҗа турында. Әйе, Ясам улы Ишкуар турында!

— Кит әле... Крокодиллар янына...

— Әйе, әсәрдә — Ишкуар! Аның танышлары, якыннары, әтәчләре, тавыгы, чебеше...

— Алайга калсамы? Дөньяда андый сары тавык булуы, тавыкның алай ук сары булуы дөрес түгел.

— Менә, менә, менә... Сизденме? Шуның өчен автор әсәрне «Тау астында илле бүре» дип атаган.

— Сиздем, исем тапмаган.

— Режиссер ул исемне кабул иткән.

— Ялгышкан... Ә тамашачыны алдарга ярамый.

— Сез хәзер уенны бозасыз!

— Мин уйнарга җыенмыйм!

— Син соң нишләргә җыенасың!

— Мин яшәргә җыенам.

— Алайса, яшә. Без киттек. Үзең генә озак яши алырсыңмы икән?

**«Тау астында илле бүре» көе яңгырап тора. Пәрдә ачылганда көй тына... Калкурак урын. Ясам улы Ишкуарның эш бүлмәсе. Каядыр — елга һәм башкалар.**

Әтәчләр белгече *(зарлана-зарлана килә)*: Таң белән тагын шалтыратты. Бүген иркенләп бер йокलармын дигән идем. Юк. Бу нинди хуҗа? Тагын чакыра. Тагын әтәч эзләргә кушадыр инде. Атна буйларына йөгерәм, эзлим, сайлыйм... Атнага бер әтәч табып кайтам. Әле ошатмый тора... Инде менә ун елга, ун елга *(хисаплый)*. Бер атнага бер әтәчтән: айга уртача — дүрт әтәч, елга — кырык сигез, ун елга — дүрт йөз сиксән әтәч сатып алганмын. Бер тавыкка бит ул. Ике йөз әтәчне кире саттык. Сиксән әтәч сары тавык өчен сугышып, мәрхүм булды. Калган ике йөз әтәч — тимер әтәчләр! Ике йөз тимер әтәч — бер тавыкка! Мондый нәрсә кайда булганы бар? Белмисез. Аңламыйсыз сез әтәчләр белгеченең хәлен. Яшьлек үтте, һаман әтәч эзлим. Инде әллә үзем әтәч булыйммы?!

**Ул әтәч булып кычкыра. Аңа башка әтәчләр кушыла: берсеннән-берсе сәеррәк тавышлар ишетелә.**

Барысы да үзем сатып алган әтәчләр!

**Ул Ясам улы Ишкуарның эш бүлмәсенә керә. Бүлмәдә — диван. Өстәл һәм башкалар. Стеналарда зур-зур итеп эшләнгән тавык рәсемнәре. Өстәлдә — телефон. Ясам улы Ишкуар бик мавыгып тавык рәсемнәрен карый.**

Ишкуар: Минем сары тавык болай гынамы соң? Җитми. Рәссамнарда әллә талант җитми, әллә үз эшләренә бирелгәнлек җитми. Әллә иксе дә җитми... Ни хәтле рәссам эшләде...

Белгеч: Күп тырышлык куелган инде, күп.

Ишкуар: Тырышлык күп куелган. Ә табыклар, җентекләп карасаң, бер-берсенә охшап җитмәгәннәр. Минем тавык бер генә... Мондагы һәр рәсем — шул бер тавык рәсеме ләбаса?!

Белгеч: Тавыкка охшаганнар бит. Матурлар.

Ишкуар: Матурлар?! Алар минем тавыкка охшамаган. Минем тавыкның, минем сары тавыкның мәнә бу җирендә әле кызыл каурые бар икән. *(Кулы белән күрсәтә.)* Баштарак мин аны үзем дә күрмәгәнмен. Ә рәссамнар — күптән күрмәгән! Юк бит ул каурый монда, мәнә кара — юк!

Белгеч: Алай артык күзгә күренеп тормагач, ул кызыл каурыйның бу рәсемдә булуы мөһим түгелдер, бәлки?

Ишкуар: Сәнгать — барын да күрергә тиеш! Нәрсә беләсең син сәнгатьтә?!

Белгеч: Гафу итегез.

Ишкуар *(уйланып торгач)*: Әтәч кирәк. Кичә алып кайткан әтәчеңне сат.

Белгеч: Кичә бу әтәч ярыйсы, дигән идегез.

Ишкуар: Кичә — кич иде. Бүген — иртә. Әтәчне яңадан карадым. Тавык шикелле йөри, ошатмадым.

Белгеч: Бәлки аны тавык үзе ошаткандыр.

Ишкуар: Мин ошатмаган әтәчне тавык ничек ошатсын! Башың бармы синең? Эшлиме башың?

Белгеч: Соңгы айларда гына да бөтен тирә-юньне яңадан әйләндем. Мин булмаган хуҗалык, мин кермәгән йорт, мин күрмәгән әтәч калмады.

Ишкуар: Сат. Яңаны алып кайт. Нәрсә ул тирә-юнь? Ерактан эзләргә кирәк!

Белгеч: Хисаплап тордым. Хәзерге көндә безнең ике йөз әтәч бар. Бәлки әлегә шулар җитеп торар, ә? Юкка чыгым ясамыйбызмы, дим? Бер тавыкка ике йөз әтәч, бәлки, җитеп торыр? Ялгышмыйбызмы, дим?

Ишкуар: Беренчедән, мондый мәсьәләдә миңа акыл бирмә. Үз акылым җитәрлек. Чыгым мәсьәләсе синең җаваплылыкта түгел. Аның өчен кайгырма. Синең эшең — әтәч сатып алу, безгә кирәкмәгәнен яңадан сату. Эшең авыр булса, акчасын яхшы аласың. Икенчедән, син нишләдең? Артык акыллы була башладың. Хәтта минем белән телләшә башладың. Мин Ясам улы Ишкуар белән телләшә башлаган кешеләрне яратмыйм.

Белгеч: Гафу итегез.

Ишкуар: Син болай түгел идең. Эшлим, табам, булдырам, йөгерәм, дип кенә тора идең. Кеше идең бит син.

Белгеч: Гел генә йөгереп тору...

Ишкуар *(аны бүлеп)*: Кем йогынтысына бирелдең?

Белгеч: Хатын үпкәли. Тавык күңелен күрә-күрә, минем күңелне күрергә вакыт тапмыйсың, ди. Тиргәшә башлады. Синдә генә ахыры күренмәгән эш, ди.

Ишкуар: Эшләмәсәң, яшәп булмый. Шулай диген син хатыныңа. Аңлат. Минем дә хатын күңелен күрергә вакыт җитми. Хатын тиргәми. Аңлаттым. Гаиләдә — тәртип.

Белгеч: Синең хатын алтын ул, ул хатын миндә булса...

Ишкуар *(бүлеп)*: Нәрсә дисең?!

Белгеч: Әтәч эзләп гомер үтә.

Ишкуар: Гомер кешегә үтәр өчен бирелә.

Белгеч: Сез мине дә аңларга тиеш. Бер сары тавык...

Ишкуар *(бүлеп)*: Ул сары тавык минем өчен ни икәнне беләсең бит. Янәшәсендә күңеле теләгән әтәч булсын! Аңладыңмы?

**Телефон шалтырый. Ишкуар ала.**
**Ул телефонга сөйли.**

Бирегез, бир... Әйе...

Белгеч: Ике йөз әтәч бер тавыкка, бәлки, бьелга...

Ишкуар *(бүлеп)*: Хәзер үк юлга чык! Әтәч кирәк. *(Телефонга.)* Сиңа түгел, түгел бердәнберем.

**Әтәчләр белгече китә.**

Исән-сау гынамы? Яхшы ял итәсеңме? Җибәрәм, җибәрәм. Хатынкаем, йөрәк маем, әллә син анда акча белән диңгез буасыңмы? Ярый, ярый. Кулда мал барда, мин исән чакта, диңгезләрен буып куй... Чирләмә, чирли генә күрмә. Ябыгып булмый дисеңме? Ябыкма! Мин сине юан булганың өчен яраттым. Син юанайган саен ныграк яратам... Җаным, синең күңелең нечкә. Нечкә кызлар күңеленнән дә нечкәрәк. Тибрәнеп торган кыл кебек: бар да кебек, юк та кебек. ...Үбәм. Әйе, нәкъ шуннан үбәм, җаным. Тик башта чәчеңне, аннан кашыңны, озын керфекләреңне, аннан соң иягеңдәге мин яраткан миңне... Юкны сөйләмә, күз нурым! Бавыр кисәгем, эшем муеннан. Бик сагындым. Ялыңнымы? Унбиш көнгә озайтырга уйладыңмы? Ярар. Акча бүген үк җибәрәм. Йөрәгеңне, нервларыңны тынычландырып кайт. Сау бул.

**Ишкуар урыныннан тора. Тавык рәсемнәрен карый.**
**Ниндидер көй сызгырына. Җырлап куя.**

*Минем өчен, минем өчен,*
*тавыккаем, бәгырькәем.*

Юк, алай түгел.

*Минем өчен, минем өчен,*
*сары тавык, бәгырькәем.*

— Көе шулайрак булырга тиеш. Сүзләре дә шәп булырга тиеш. Шикләнәм шул. Юньле нәрсә яза алырмы шагыйрьләр? Композиторлары юньле көй табармы? «Сары тавык турында җыр» — бу исем ярыйсы... Яңа җыр язу өчен ярыш ачканга күпме гомер үтте?! Җыр һаман юк. Булдыксызлар. Боламыклар. Пешмәгән пәрәмәчләр. *(Телефоннан шалтырата.)* Хәерле көн! Бу мин әле... Әйе. Җыр кайчан өлгерә? Ничек инде, бәлки? Җыр күптән кирәк. Утырып көнетөне тавык турында язасы чакта, йоклап ятасыз! Миңа алып килергә кирәк. Карар идек. *(Ачуланып телефон трубкасын куя.)* Асылда эшләр тәртиптә.

**Ишек шакыйлар.**

Ишкуар: Керегез.
Белгеч *(керә)*: Хөрмәтле...
Ишкуар: Син һаман китмәдеңме?
Белгеч: Тавык...
Ишкуар: Аның исеме бар. Сары тавык!
Белгеч: Сары тавык...
Ишкуар: Нәрсә, әтәчне бирмиме әллә?
Белгеч: Күз күрмәгән, колак ишетмәгән хәл: сары тавык йомыркасын утка сала.
Ишкуар: Анда синең ни эшең бар?!
Белгеч: Янып торган утка сала бит.
Ишкуар: Мин аңа үзем куштым!
Белгеч: Үзең куштың?! Учакка?!
Ишкуар: Әйе, үзем куштым. Ә син юлыңда бул. Үз эшең белән шөгыльлән. Тавык үз эше белән шөгыльләнә.
Белгеч: Гафу итегез. Үзегез куштыгыз алайса. Мин әтәчне тоттым. Хәзер сатарга китәм. Яңаны, менә дигәнне табармын. Булдырырмын.
Ишкуар: Шулай сөйләшергә кирәк. Хәерле юл.
Белгеч *(сөйләнә-сөйләнә китә)*: Үзегез кушкансыз икән алайса.
Ишкуар *(ялгыз калгач, үз-үзенә)*: Күз күрмәгән хәл, имеш. Менә күрегез, карагыз. Үрнәк алыгыз... Тәртип булды, тәртип бар һәм тәртип булачак! Ул көй сызгырына башлый. Аннан җырлап ук җибәрә.

**Минем өчен, минем өчен,**
**сары тавык, бәгырькәем,**
**утка сала күкәен.**

*(Шатланып.)* Әйе, «Сары тавык турында җыр»ның кушымтасы шулай булырга тиеш. Әх, бу шагыйрьләр, композиторлар — беткән башлар! Шуны да уйлап чыгара алмыйлар бит. Язып куярга кирәк моны, югыйсә онытылыр. *(Кәгазь ала, сызгырынасызгырына яза.)* Көе дә ярыйсы... Ә кушымтага хәтле нинди зәтле сүзләр табарга мөмкин? Әйтик, беренче куплет:

*Карасы булыр тавыкның,*
*булыр аның аклары.*
*Сары тавык сатып алгач,*
*күңелләрем шатланды...*

Менә бу сүзләргә кушымтасы килеп кенә ябыша инде, тавыкка койрык ябышкан кебек. Әйтик, икенче куплет:

*Урам тулы сары тавык,*
*чын сарысы бер генә.*
*Шул тавыкның кыткаклавы*
*истә калыр гомергә...*

Менә бит! Шәп! Шагыйрьләр моны шәм яндырып эзләсә дә таба алмый.

**Ишек шакыйлар**

Керегез!
Урман кисүче *(керә)*: Исәнмесез.
Ишкуар: Исәнмесез! Узыгыз. Утырыгыз. Ни йомыш?
Кисүче: Мин урман кисүче.
Ишкуар: Урман кисүче бу вакытта урманда булырга тиеш.
Кисүче: Хөрмәтле...
Ишкуар: Урман беттеме?
Кисүче: Әлегә бетмәде.
Ишкуар: Шулай булгач?
Кисүче: Пычкылар үтми. Игәү бетте. Узган атнада ук китерергә вәгъдә иткәннәр иде. Кәтәбез, юк. Кәтәбез, юк. Йөз чакрымнан кайтырга туры килде. Эш туктады.
Ишкуар: Эшне туктатмаска, кисә торырга кирәк иде. Күпер салучыларга бүрәнә кирәк.

**Шул вакыт ишек ачыла. Ишкуарның шоферы керә, ул эчкән**

Шофер: Сез миңа... Сез мине...
Ишкуар *(шоферына)*: Торма басып, утыр!
Шофер: Рәхмәт. Сез яхшы кеше. *(Диванга утыра.)*
Ишкуар *(урман кисүчегә)*: Күпер миңа да, сиңа да, һәммәбезгә дә кирәк!
Шофер *(узалдына)*: Миңа берни дә кирәкми...
Ишкуар: Җырлама!
Кисүче: Пычкылар үтми.
Ишкуар: Вәгъдә биргәч, китергән булырлар иде. Ә сез тизрәк эш туктатасыз.
Шофер: Бик дөрес... Әй, сәлам, урман кисүче!
Ишкуар *(шоферына)*: Син йә тыныч утыр, йә чыгып тор. Соңыннан сөйләшербез.
Шофер: Чыкмыйм, миңа монда рәхәт.

**Шоферны очкылык тота. Ул йоклап ук китә.**

Кисүче: Үтмәс пычкылар белән кистек. Хәзер бөтенләй кисеп булмый башлады.
Ишкуар: Игәүсезләр, пычкысызлар... Теш белән кистеләр! Әнә, сары тавык утка күкәй сала! Аңлыйсыңмы? Мә кәгазь *(язып бирә)*. Бездә хәзер игәүдән күп нәрсә юк. Йөз чакрымнан кайткач, ала кит. Бирерләр. Башка вакытта мондый мәсьәләләр белән Ярдәмчегә мөрәҗәгать итә торган бул. Минем зуррак эшләрем бар.
Кисүче: Ярдәмчегезгә кердем, ишеге бикле иде. *(Китә.)*
Ишкуар *(узалдына)*: Яңа күпер! Аның аша елга аръягыннан, еракларлан безгә... *(Өстәл өстендә бармакларын уйнатып ала. Шоферы янына бара.)* Килеп җиттек! Ач әле күзеңне, тор! Бас, бас. Менә шулай. Син кем?

Шофер: Мин. Мин, хөрмәтле... Мин сезнең шофер.
Ишкуар: Җилкуар!
Шофер: Хөрмәтле... *(Очкылык тота.)*
Ишкуар: Исерекбаш.
Шофер: Бер йотым су...
Ишкуар: Машина кая?
Шофер: Хөрмәтле...
Ишкуар: Синең белән эшләп булмады, җитте!
Шофер: Эштән китәсезме? Сау булыгыз. Ярата идем сезне.
Ишкуар: Тинтәк!
Шофер: Дорфа сез, хөр... *(Очкылык тота.)* Сез эчкәч, кешегә бәйләнмәгез, хөр... *(Очкылык тота.)* Боксер ич *(очкылык тота)* мин.
Ишкуар: Син эштән азат. Азатлык бирдем мин сиңа, боксер.
Шофер: Яшәсен азатлык! Яшәсен, шулай бит?
Ишкуар: Шулай. Укыдыңмы минем карарны... кергәндә?
Шофер: Нинди карар?
Ишкуар: Кара карар. Тәртибең өчен сине эштән азат иткән кара карар. Укыдыңмы?
Шофер: Укымадым. Мин машина йөртәм, сезне йөртәм. Бок *(очкылык тота)* с-сны беләм. Мин укый белмим һәм белмәм дә.
Ишкуар: Алайса, тыңла! Син хәзер минем шоферым түгел. Өеңә кайт.
Шофер: Мин беркая да кайтмыйм. Андый закон юк.
Ишкуар: Башсыз. Бар, кит.
Шофер: Дорфа-а-а! Шофер кеше белән? Боксер кеше белән?!
Ишкуар: Сиңа сүзем бетте.

**Шоферын ишеккә озата. Шофер карыша.**

Шофер: Минем сезгә сүзем бетмәде һәм бетмәс тә. Мондый закон кайчан чыкты? Боксер кеше белән?!

**Ишкуар Шоферын чыгарып җибәрә.**

Ишкуар: Куркалар иде. Йөгереп торалар иде. *(Йодрык янап.)* Өйрәтәм мин сезне. Шым булырсыз!

**Ишек шакыйлар. Ишкуар ишек ача.**

Рәхим ит, нечкә бил.
Тавык караучы *(керә)*: Ачыгып та, арып та беткәнсездер. *(Өстәлгә ашамлыклар куя.)* Бигрәк эшегез күп шул. Исенә төшермәсәң, ашарга да оныта бит ул ир-ат. Ябыгып калдыгыз. Хатыныгыз, илдан кайткач, танымый да торыр. Ятлар белән чуалган дип уйлый күрмәсен. Хатын-кызның, эше дә булмаса, башында гел ир генә була шул аның. Көнләшеп тә куяр...
Ишкуар: Көнләшмәс. Миндә тәртип һәм тәртип булачак!
Тавык караучы: Тавык караучы булып урнашканнан бирле үземә игътибарым җитми.
Ишкуар: Син бик чибәр.

**Телефон шалтырый.**

Тавык караучы *(телефонга үрелә)*: Алып биримме?
Ишкуар: Кирәкми, төшке ял вакытым җитте.
Тавык караучы *(билләрен тоткалап)*: Ике ел элек кенә моннан күпкә нечкәрәк идем.
Ишкуар: Син һаман шул...
Тавык караучы *(үртәп тә, масаеп та)*: Әтәчләр караучы йөз ирнең иллесе миңа гашыйк.

**Ишкуар көнләшүен аңлата — тамак кырып ала. Сәер музыка башлана. Караңгылык.**

## Икенче күренеш

**Ишкуар үзенең эш бүлмәсендә. Елмаеп, нидер уйланып йөри. Ишек шакыйлар һәм ишек әкрен генә ачыла.**

Ишкуар: Мөмкин, мөмкин!

**Ишектән Якташы керә. Шул ук вакытта телефон шалтырый. Ишкуар телефонны ала.**

Ишкуар *(телефонга)*: Кәтәм. *(Ишектән керүчегә.)* Бер-ике минут... Хатын шалтырата. Бик ерактан. Утырып торыгыз сез, утырыгыз. *(Телефонга.)* Ике күзем карасы, син үзеңме бу? Тавышың матурланган, тавышың! Акча алгансыңдыр? Мин дә сагындым. Төшләремдә күрәм. Берүзеңне генә күрәм! Син кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме?! Көлке түгел! Башка алай шаярма. Яхшы булган. Кат-кат үбәм. Фәкать шуннан үбәм. Кайчан сине каршы алмаганым бар? Шулай диген. Бөтен нәрсә тәртиптә. Сау бул. *(Һаман басып торган кешегә.)* Кем сез? Ни йомыш?
Якташ: Валлаһи алла булгансың, яшьти.
Ишкуар: Алла ук түгел лә... Туктале, тукта...
Якташ: Танымый да тора, саескан.
Ишкуар: Сыбызгы! Син ич бу! *(Кочаклашалар.)*
Ишкуар: Яшьти, сыбызгы! Сыбызгы!
Якташ:

*Кай ара килеп чыккан,*
*келәткә кереп чыккан,*
*кетәккә кереп чыккан —*
*саескан, саескан!*

Ишкуар: Утыр, утыр әле, якташ.
Якташ: Утырабыз аны.
Ишкуар: Кайлардан, ничек килеп чыктың бу җәһәннәмгә?
Якташ: Туп-туры авылдан. Оҗмах күрергә уйладым. Сиңа юлыктым, синең оҗмахка.
Ишкуар: Оҗмах түгел бу, җәһәннәм. Шулай да дөресен әйтим, яшәп була.
Якташ: Ишетеп тә белдем. Биләмәләреңне дә күрдем, бүлмәңне дә... Көчле яшисең.
Ишкуар: Минем инде иң зур хуҗалыкларның берсе. Хуҗалыктагы тәртипне ныклап яңарту белән мәшгульмен. Миңа эш тә-

жрибәсе минекеннән күп булган дәрәҗәләр каршында, күршеләр каршында сынатырга ярамый. Җаваплылык!

Я к т а ш: Мин шофер гына.

И ш к у а р: Шоферлар да дөнья йөген тарта.

Я к т а ш: Шулай анысы...

И ш к у а р *(ишекне бикли)*: Эш вакыты бит, яшьти. Эш минем муеннан. Минут саен булмаса да гел кеше керә. Төрлесе керә.

Я к т а ш: Бала-чагаң күпме?

И ш к у а р: Хатын гына әлегә.

Я к т а ш: Ун елдан соң очрашу! Минем ике бала...

И ш к у а р: Мин соң өйләндем.

Я к т а ш: Эшеңне тоткарламыйммы?

И ш к у а р: Эш турында үзем кайгыртырмын. *(Эчемлек чыгара.)* Әйдәле, әз генә... Очрашу хөрмәтенә...

Я к т а ш: Кирәкми. Күңелдә әлегә башка уйлар. Җан тыныч түгел.

И ш к у а р: Кичтән дисеңме?

Я к т а ш: Очраша алсак.

И ш к у а р: Миңа кайтып тор. Ачкыч бирәм. *(Бүлмә ишеген ачып куя.)*

Я к т а ш: Мин кунакханәгә урнаштым.

И ш к у а р *(сөйләнә-сөйләнә бер кәгазьгә телефон номерын яза)*: Ике нуль дә, өч нуль дә, тагын ике нуль. *(Көлә).* Бу минем телефон булыр.

Я к т а ш: Шундый номер да буламыни?

И ш к у а р: *(Язган кәгазен якташына бирә.)* Мә, җәһәннәмгә шуның белән шалтыраталар.

Я к т а ш: Миңа оҗмах номеры гына кирәк иде. *(Телефон номерын кесәсенә тыга.)*

И ш к у а р: Оҗмахка да шул номер ярый. *(Кычкырып көлә.)*

Я к т а ш: Синең дөньяң серле икән.

И ш к у а р: Тау-тау серләр арасында чәчәкле-чуклы әкият дөньясы. Оҗмахы да, җәһәннәме дә үзебезнеке. Бездә бар да тәртиптә! *(Бүлмәсен караштырып, горурланып тора.)*

Әй! Яшьти! Минем капканы саклаучы дию пәрие ничек сине миңа уздырды?

Я к т а ш: Мин аның унике башына — унөч уй салдым. Ул уйлап калды, мин сиңа кереп киттем.

И ш к у а р *(җитдиләнеп)*: Булыр, синнән булыр. Мине дә уйлаттың. Хәтерне уяттың. Сагындыра туган як, бик тә сагындыра.

Я к т а ш: Ничек болай үк күтәрелә белдең?

И ш к у а р: Сер.

Я к т а ш: Миңа гына әйт?

И ш к у а р *(уйланып торганнан соң)*: Көннәрдән бер көнне тавык сатып алдым. Көненә ун күкәй сала торган тавык. Хәзинә!

Я к т а ш: Шаярма.

И ш к у а р: Чынлап.

Я к т а ш *(шаярып)*: Кая бар ул андый тавык?

И ш к у а р: Миндә.

Я к т а ш: Берсен әллә миңа сатасыңмы?

И ш к у а р: Булмый, яшьти. Ул дөньяда берәнберу тавык.

Я к т а ш: Ничек таптың син аны?

И ш к у а р: Ялгыш... Тавык китергән хәзинәне сатып, кәҗә алдым. Кәҗә сөтен сатып, сыер алдым. Сыер сөтен сатып, ат алдым.

Я к т а ш: Шаярма инде, яшьти...

И ш к у а р: Менә сиңа кирәк булса? Мин аңа бәйнә-бәйнә чын дөресен сөйләп утырам. Ул ышанмый... Атта чабып, дуслар таптым, дуслар күтәрде. *(Көлә.)*

Я к т а ш: Атыңны миңа күрсәтерсеңме?

И ш к у а р: Ат тиз картая, мин аны саттым.

Я к т а ш: Сыерыңны?

И ш к у а р: Сыерны сгып суйдым... Кәҗәне кире булганы, тыңламаганы өчен тибеп үтердем.

Я к т а ш: Тибеп?!

И ш к у а р: Әйе. Бакчага кергән иде. Типтем дә үтердем. Тавык калды. Утка күкәй сала... Минем өчен! Менә ул миңа кирәк! Миңа шундыйлар кирәк.

Я к т а ш: Каты күңелле икәнсең син, яшьти.

И ш к у а р: Бөтен кеше кебек, гади бер кеше.

Я к т а ш: Каты, каты. *(Урыныннан тора.)* Мин сиңа шофер кирәген ишетеп килгән идем дә...

И ш к у а р: Болай булгач, уйлыйсы бар, дисеңме?

Я к т а ш: Юк.

И ш к у а р: Ә уйлыйсы бар. Утыр, утыр син, яшьти. Ике нәрсә хакында безгә ныклап уйлашырга кирәк.

Я к т а ш: Беренчесе?

И ш к у а р: Бер савыттан бергә шулпа чөмергән чагыбыз бар иде. Менә безнең арада нинди якынлык. Йодрык кебек бердәм булып яши алабыз! Шулаймы?

Я к т а ш: Шулай. Тагын без нәрсә хакында уйлашырга тиеш?

И ш к у а р: Шул хәтле якын кешенә боерык бирү, житешсезлекләрен әйтү, карышса — чара күрү кыен. Эштә андый хәлләр була.

Я к т а ш: Яшьти, алайса мин китим. Сиңа шофер табылыр.

И ш к у а р: Туктале... Малай булмыйк. Без бит дөнья күргән ирләр. Минем машина әйбәт, яңа... Эш турында сөйләшмичә булмый бит инде ул.

Я к т а ш: Эшнең нәрсә икәнен беләбез. Үзең әйтмешли, дөнья күргән ирләр.

И ш к у а р: Каты күңелле кеше син. Каты! Мин бит болай гына. Безнең ишеләрне йөртү шактый мәшәкатьле икәнне алдан әйтәсем килде.

Я к т а ш: Сезнең ишеләрне дә йөрткән бар.

И ш к у а р: Каты! Безнең як гадәте синдә. Горурлыгың да үзебезнеке.

Я к т а ш: *(Китәргә җыена.)* Ярый...

И ш к у а р: Димәк, тәҗрибәң бар. Килешербез, яшьти. Җиденче яртыда ук шалтырат.

Я к т а ш: Хәзергә сау бул.

И ш к у а р: Ярый, кичкә хәтле! Шалтыратканыңны көтәрмен.

**Якташ чыгып китә.**

И ш к у а р *(үзалдына)*: Сыбызгы дигән, әй! Әкият... *(Телефоннан шалтырата.)* Хәерле көн! Әйе, мин. Ничек анда бәхет сарае? Төзү эшләре әйбәт барамы, дим? Булыр,

бар да булыр. Төштән соң үзем күренермен. Тизрәк төзеп бетерәсе иде, кешеләр бик көтә. Булды. *(Телефон янынnан китә. Шул мәлдә аның колагына «Сары тавык турында җыр» көе ишетелә башлый.)* Әнә бит, әнә. Көе колагымда, сүзләре тел очымда тора. Теге иләс-миләсләр, томаналар, сөрхәнтәйләр һаман яза алмый.

**Ул кулына үзе җыр язган кәгазьне ала. Кәгазьгә тагын ниләрдер яза... Телефоннан шалтырата.**

Алло! Мин бу... Менә нәрсә: мин сүзләрен дә, көен дә таптым. Җыр өстенә авторы һәм композиторы дип, сезнең исемнәрне генә язып куясы калды. Шуны үзегез эшләрсез. Башка катнашучылар күренми. Сезгә беренче урын! Беренче урын сезгә, дим. Әйе! Иртәгә иртүк миңа килегез. Җыелышып бер сөйләшү кирәк булыр. *(Каядыр тавык кытаклый.)*

Төзәтәсе урыннары булса, җырны төзәтербез. Бүген түгел, иртәгә. Бүген эшләрем күп. *(Шул мәлдә ишек шакыйлар. Сәгатенә карап.)* Кер, әйдә. Кер.

Тавык караучы *(керә)*: Ачыгып беткәнсездер. *(Ала килгән әйберләрен өстәлгә куя.)* Кем иде ул?

Ишкуар: Минем яңа шоферым.

Тавык караучы: Әйбәт кешегә охшый.

Ишкуар: Минем якташ, яшьтәш.

Тавык караучы: Ягымлы елмая.

Ишкуар *(ишекне әчтән биклап)*: Гаиләсе, балалары... Шыйк булырга уйлама. Ике баласы бар.

Тавык караучы: Ә хатыны?

Ишкуар: Хатыны берәү генә! *(Өстәлдәге ашамлыкларны карап.)* О-hо-hо! Ниләр генә юк монда?! Кош сөте дә бар.

Тавык караучы: Тырышам инде. Акча үзегезнеке.

**Телефон шалтырый. Аны алучы юк.**

**Ишкуар** *(өстәлдән ике йомырка алып)*: Бусы бушлай килгән хәзинә! Үзебез тапкан хәзинә!

Тавык караучы: Чип-чиста, өсләрендә ун ел тавык утырса да чебеш чыгасы юк.

Ишкуар: Чип-чиста!

**Телефон шалтырый. Алучы юк.**

Тавык караучы: Уза гомерләр... Тавык карап... Өч кенә ел элек моннан күпкә нечкә идем.

**Сәер көй башлана. Тавык караучы диванга утыра. Караңгылык.**

## Өченче күренеш

**Бүлмәдә Ишкуар, Ярдәмче, Шагыйрь, Композитор, Тавык караучы һәм башкалар. Кемдер сөйләшүләрне язып утыра.**

Ишкуар: Шулай итеп, безнең бүгенге җыелышуны — нәкъ үз вакытында җыелышу, нигезле җыелышу, гаять мөһим эш дип карарга кирәк. *(Таныштыра.)* Арабызда — шагыйрь, композитор. Мактауга, зур ихтирамга лаек серле-сихерле кешеләр! Ягъни, үзләренең иҗатлары белән канат куеп, безнең авыр, олы эшләрне күккә күтәрә торган кешеләр.

Карт: Һай, рәхмәт төшкерләре!

**Ишкуар кул чаба. Ана башкалар кушыла.**

Ишкуар: Инде рөхсәт итсәгез, җыелыш тезгенен мин үземнең ярдәмчегә тапшырам.

Берәүләр: — Сөйләсен, сөйләсен!
— Бездән рөхсәт!

Ярдәмче: Үгезне мөгезеннән алып башласак, шуны әйтергә кирәк: бу бердәнбер җыр. Башка җыр килмәде.

Берәү: Башка бер җыр да килмәде?!

Ишкуар: Килмәде.

Берәү: Анысы яманрак чыккан икән.

Тавык караучы: Бер тавыкка бер җыр бик җиткән.

Башка берәү: Ялкаулар алар шагыйрьләр, композиторлар.

**Ярдәмче тамак кырып куя.**

Кемдер берәү: Нигә алай дисең, карале! Җыр язу — ул сиңа әтәч карау гына түгел.

Кайсыдыр *(кызып)*: Әтәч карауның ни хәтле авыр эш икәнен белсәң, син болай сөйләшмәс идең. Әтәч карауның бүген ни дәрәҗәдә кирәк эш икәнен аңламыйсың син. Ул эш белән без йөз дә ике таза ир кара таңнан кара кичкә хәтле мәшгуль. Әйе, әтәчләр карыйбыз. Авырлыгын бик тоябыз. Алар бит борынгы әтәчләр түгел. Бүгенге әтәчләр. Аларны чистартырга кирәк... Ашатырга, йоклатырга һәм уятырга да кирәк.

Карт: Һай, рәхмәт төшкерләре!

Берәү: Әтәч карауның...

Ярдәмче: Тынычлык, тынычлык!

Икенче берәү: Кара тавык турында бер генә җыр диген, ә?!

Тавык караучы: Кара тавык түгел, сары тавык!

Кемдер берәү: Барыбер түгелмени, җыры тавык турында булгач!

**Ишкуар тамак кырып куя.**

Тавык каручы: Барыбер булса, кинәшмәгә җыелмас идек.

Ишкуар: Тынычлык, тынычлык!

Кемдер: Халык тынычлана белми ул. Халык белән эш итсәң... Карарны үзегез генә чыгарыһга да куярга иде.

Арадан кемдер: Син алай димә халык турында, матри!

**Ишкуар графин шакый. Тынычлык урнаша.**

Ярдәмче: Бер генә җыр язылган дип, гаҗәпләнмәгез. Җитди тема, зур җаваплылык сорый. Күпләр яза башлаганнар иде, билгеләнгән көнгә өлгертә алмадылар. Шунысы куанычлы, язылган җыр әйбәт күренә. Ул куелган таләпләрне канәгатьләндерә, өметләрне аклый. Ясам улы Ишкуарның да фикере шулай.

Берәү: Җырны тыңларга кирәк!

Берәүләр: — Шунын өчен җыелдык бит инде!

— Тыңларга кирәк! Тыңлыйбыз!

Ярдәмче: Үзегезгә мәгълүм. Арабызда утырган бөек авторлар әле күптән түгел генә «Безнең кызларның бәдәне тимер белән жиз генә» дигән җыр яңгыратып, безнең кызларга, безнең якка — миллионлаган күзләрне, миллионлаган күңелләрне җәлеп иттеләр. Зур хезмәт салынган бу җыр да уңышлы чыкса...

Кемдер *(Ярдәмченең сүзен бүлеп)*: Чуар тавык турындагы бу җыр да...

Тавык караучы: Сары тавык диген!

Кемдер: Аның бер кызыл каурые бар икән дип сөйлиләр сөйләвен.

Ярдәмче: Юк!

Тавык караучы: Без аны... *(Йолкыдык, диган хәрәкәт ясый.)*

Ишкуар: Сабыр, сабыр! Сары тавыкның кызыл каурые бар иде.

Тавык караучы: Хәзер юк.

Ишкуар: Күптән юк. Ул саргайды.

Карт: Һай, рәхмәт төшкере!

Кемдер: Бу җыр да уңышлы чыкса, җәелә инде безнең дан бөтен дөньяга.

Кемдер: Тамаша була инде, бер могҗиза була!

Ярдәмче: Хәзер җырны тыңлап карыйбыз. Әлегә җыр өйрәнелеп, шомарып җитмәгән. Шулай да тыңлыйк, бәялик.

**Барысы да тынып кала. Композитор уйный. Җырны кәгазьдән карап җырлый.**

*Карасы булыр тавыкның,*
*булыр аның аклары.*
*Сары тавык сатып алгач,*
*күңелләрем шатланды.*
*Минем өчен,*
*минем өчен*
*сары тавык, бәгырькәем,*
*утка сала кукәен.*
*Урамнарда сары тавык,*
*чын сарысы бер генә.*
*Шул тавыкның кытаклавы*
*истә калыр гомергә.*
*Минем өчен,*
*минем өчен*
*сары тавык, бәгырькәем,*
*утка сала кукәен.*
*Кыр өстендә түгәрәк кул,*
*кипми җәй дә, кыш да ул.*
*Уттан-судан курыкмаган*
*сары тавык бездә ул.*

**Кушымтага кемнәрдер кушылып китә.**

*Минем өчен,*
*минем өчен*
*сары тавык, бәгырькәем,*
*утка сала кукәен.*

**Җыр тәмамлана. Кул чабулар.**

Бераүләр:
— Афәрин! Дан бу җырга!
— Ә шагыйрьгә, композиторга нәрсә?
— Дан композиторга! Шагыйрьгә дан!
— Дан!

Ярдәмче *(Нидер шакый, халыкны тынычландыра.)* Яңа җырга карата нинди конкрет фикерләр бар? Тәкъдимнәр юкмы?

Карт: Мөмкинме?

Ярдәмче: Рәхим итегез.

Карт: «Шул тавыкның кытаклавы истә кала гомергә» түгел, «Коймаларга менеп басса, бар дөньяга күренә» диярга кирәк. Шулай әйткәндә җыр тагын да ачыла, тавык тагын да ераккарак күренә. Күренсен барлык дүрт тарафка! Үзебезнең тавык ич!

Бераүләр:
— Күренсен! Үзебезнең тавык!
— Бөтен кеше күрсен!

Ярдәмче: Тагын сөйләргә теләүче бармы?

Карт: Бар. Җырның исемен «Сары тавык турында җыр» түгел, «Сары тавык турында мәңгелек җыр» диярга кирәк.

Бераүләр:
— Менә әйтте ичмасам! Дөрес!
— Мәңгелек булсын! Шулай, мәңгелек!
— Әйтсә әйтә инде ул — безнең таз көрҗә!

Ишкуар: Тынычлык, тынычлык?!

Ярдәмче: Башка фикерләр юкмы?

Карт: Бар. «Минем өчен, минем өчен» дигән юлларны үзгәртергә.

Бераүләр:
— Ник? Нигә?!
— Анысын үзгәртми генә тор әле!

**Ишкуар графин шакый.**

**Карт: «Безнең өчен» диярга кирәк. Минем өчен булгач, ул бит бер генә кеше өчен була! Шулай җырласам, дөнья минем хакта ни уйлар? Шуны аңлыйсызмы?**

**Арадан бераү кычкырып көлә.**

Икенче бераү: Бик кирәгең бар иде синең дөньяга.

**Ишкуар графин кага.**

Ярдәмче: Сүзегез беттеме?

Карт: Бар.

Бераүләр:
— Җитте!
— Әйтсен, син нәрсә?!

Карт: Җырның юллары исемнән чыга шул. Ах, аны үз кулыңа тотып укысаң икән?!

Бераүләр:
— Укы! Әнә, кәгазьдән карап җырлады бит әле.
— Укырга җыелдык бит. Сөйләшергә җыелдык.
— Укысын, бирегез үзенә кәгазен!

Карт: Укый белмим шул. Белсәм мин аны...

Бераү: Синең өчен яңадан җырламаслар.

Ярдәмче: Беттеме әйтер сүзләр?

Карт: Бар. «Кара тавыклар бар» дигән юлны әйтәм.

Ишкуар: «Карасы булыр тавыкның» диелгән анда.

Карт: Әйе, шуны әйтәм. Андый юл кирәкмәс. Минс гафу итегез, кирәкмәс андый сүз.

Бераү: Ни өчен?

Карт: Шундый якты җырда — кара тавык бит, кап-кара тавык.

Бераү: Нәрсә? Әллә дөньяда кара тавык юкмы?

Карт: Бездә булмаска тиеш, безнең якты туган ягыбыз турындагы җырда... Капкара тавык?! Килешми, иптәшләр!
Берәүләр:
— Нишләп килешмәсен?
— Нәрсәсе бар аның?
— Җырда гел кара тавык кына түгел. Агы да бар, сарысы да...
Ярдәмче *(Картка)*: Башка фикерегез юкмы?
Карт: Бар.
Берәүләр:
— Җитте, җитте! Аның сүзе бетмәс!
— Сөйләсен!
— Кирәкмәс, эшкә барасы бар!
— Менә дигән җыр!
— Хөрмәтлебез Ясам улы Ишкуар аны безгә хәтле караган инде. Әйбәт җыр!

**Ишкуар үзенең ярдәмчесенә «бу карт белән сөйләшүне туктатырга» дигән ым ясый.**

Карт *(Ишкуарның ымын аңлап, күреп)*: Хөрмәтлебез Ясам улы Ишкуар! Мин, үзегез сөйләшергә чакыргач, әйттем... Мин... Юк, сөйләшмим. Сүзем бетте. Әйбәт җыр.
Берәү: Башта ук шулай диләр аны!
Берәүләр:
— Безгә бик кирәкле, менә дигән җыр!
— Матур җыр, безгә файдалы җыр!
Ярдәмче: Бер-беребезне кабатламыйк. Тагын кемнең сүзе бар?
Карт *(онытылып, урыныннан торып)*: Мөмкинме? Ә юк, юк. Минем сүзем юк, мин утырам. *(Утыра.)*
Арадан берәү: Минем сүзем бар.
Ярдәмче: Тыңлыйбыз.
Сүз сораучы: Без күпер салабыз бит инде. Барыгыз да күперне белә. Менә шул хакта «Дөньяда булмаган күперне без инде төзеп куйдык аны» дигән җыр язарга иде.
Ярдәмче *(чыгышларны язып баручыга)*: Әйе, язып куй бу кинәшне. *(Башкаларга)* «Сары тавык турында мәңгелек җыр»га карата тагын кемнең сүзе бар?
Берәү: Беренче урынны бирергә кирәк үзләренә. Җыр турында сезнең фикер уңай булгач, безнеке дә уңай.
Берәүләр:
— Уңай, уңай!
— Дөньяга шауласын!
Ярдәмче: Хөрмәтлебез Ясам улы Ишкуар, нидер әйтергә теләмисезме?

**Ишкуар баш селкеп, сүзе югын аңлата.**

Ярдәмче: Әйтелгән фикерләр искә алыныр. Халык әйтсә, хак әйтер, диләр. Бу безгә билгеле, бу безнең үлчәү. Инде эшебезне йомгаклыйк, нәтиҗә ясыйк. Яңа җыр авторларына беренче урынны бирергә дигән кешеләр, кул күтәрегез.

**Кул күтәрәләр, берәү күтәрми.**

Берәү *(кул күтәрмәүчегә)*: Нишләп кулыңны күтәрмисең?!
Кул күтәрмәүче: Җыр аңламыйм мин, дөресен әйткәндә... Миңа кара тавык та, сары тавык та, агы да, кызылы да, аклы-кызыллысы да барыбер.
Берәү: Барыбер булгач, күтәр!

**Соңгы кеше дә кулын күтәрә.**

Ярдәмче: Димәк, бертавыштан. Кулларыгызны төшерегез. *(Сары тавык турында җыр көе ишетелеп ала... Ярдәмче җыелышны яба.)* Бүгенге катлаулы һәм куанычлы сөйләшүебезне шуның белән тәмамлыйбыз. Шагыйрь, композитор-җырчы берничә минутка кала, башкаларга китәргә мөмкин.
Китүчеләр:
— Исән булыгыз.
— Рәхмәт.
— Композиторга рәхмәт, шагыйрьгә.
Карт: Исән генә була күрсеннәр. Алардан башка без нишләр идек...

**Калырга кушылганнар кала. Башкалар китә. Беразга тынлык урнаша.**

Ишкуар: Җырга артык күп тыкшынуына карамастан, картның кирәкле генә фикерләре дә булды.
Шагыйрь: Мәңгелек сүзе.
Ишкуар: Мәңгелек сүзе чыннан да бу җырга кирәк. Аннан җырны тизрәк яңгыратырга!
Ярдәмче: Ишетсеннәр!
Ишкуар: Беренче куплетның соңгы ике юлы да бүген минем колакка ятып җитмәде.
Шагыйрь: Әйбәт бит!
Композитор: Хөрмәтле Ясам улы Ишкуарның колагы... Аның колагы... Ул әйткәч...
Ярдәмче: «Коймаларга менеп басса, бар дөньяга күренә!» Бәлки, бу юлны җырга алыргадыр. Карт, бәлки, бу очракта хаклыдыр.
Ишкуар: Мин дә шулай уйлыйм.
Шагыйрь: Шулай эшлибез аны. Сез әйткәч, без әзер.
Ярдәмче: Сез әзер дә, җырны озаккарак суздыгыз.
Ишкуар: Ярамый болай әкрен булырга. Язасы да язасы. Көннәр матур, төннәр нинди! Иҗат кешесе йокламаска тиеш. Кешеләрне җырлатырга, аларга яшәү дәрте өстәп торырга кирәк. Бу эшне бергәләп, уңышлы гына ерып чыктык. Аның өчен сезгә рәхмәт.
Композитор: Үзегезгә рәхмәт.
Шагыйрь: Безгә нәрсә... Безгә рух сез бирмәсәгез...
Ишкуар: Рухны кешеләр бирә. Ишеттегез бит. Алар бездән җыр көтә. Аларның җырлыйсы килә. Ярый, уңышлар телим. *(Кулларын кыса.)*
Композитор: Хөрмәтлебез, безгә... Җыр акчасын, беренче урын акчасын безгә... Бүген үк бирсәгез...
Шагыйрь: Әйе, акчасын бүген үк, мөмкин булса?
Ярдәмче: Шундыйрак уй бар иде. Акчасын сезгә... Акчасын сезгә әгәр әтәчләтә бирсәк?
Композитор *(аптырап)*: Әтәчләтә?! Әтәчләтә...
Ярдәмче: Әтәчләтә инде...
Шагыйрь: Әтәчләтә? Алай? Ничегрәк?
Композитор: Бездә... Безнең тавык та юк бит әле.

Ишкуар: Ярый, иртәгә шалтыратырсыз. Акчалата бирербез.
Композитор: Рәхмәт сезгә.
Шагыйрь: Исән булыгыз. *(Китәләр.)*

**Караңгылык, күчеш. Икенче көн. Эш бүлмәсе. Бүлмәгә Ишкуар белән Ярдәмче керә.**

Ишкуар: Акчаларын бирдегезме?
Ярдәмче: Бирдек.
Ишкуар: Эшлексезләр, боламыклар, җитлекмичә туган нәрсәләр. Аларга акча кирәк! Үзебез катнашмасак, кулларыннан эш килəсе юк. Уяна алмыйлар.
Ярдәмче: Иҗат кешеләрен каешлап торырга кирәк, уянсыннар өчен.
Ишкуар *(пидер актарына. Моңланып йөри)*:

*Әй-йәй-йәй-йәй,*
*ай-йәй-ай-йәй,*
*сары тавык, бәгырькәем,*
*утка сала күкәен.*

Ярдәмче *(аптырап башын тота, утыра)*: Йа, хода?!
Ишкуар: Нәрсә булды?
Ярдәмче: Хата.
Ишкуар: Нинди хата. Син ни хакында?
Ярдәмче: «Утка сала йомыркасын» булырга тиеш.
Ишкуар: Ә ни өчен ул «йомыркасын» булырга тиеш?
Ярдәмче: «йомырка» — дөрес була. Ә тегесе, тегесе...
Ишкуар: Нәрсә булган тегесенә?!
Ярдәмче: Анысы, хөрмәтлебез, оятсыз сүз. Безнең якта алай әйтмиләр. «Йомыркасын» диләр.
Ишкуар: Безнең якта әйтәләр. «Утка сала күкәен» диләр!
Ярдәмче: Хөрмәтлебез? Яхшы түгел, иштәләр бит.
Ишкуар *(аптырабрак)*: Иштәләр?!
Ярдәмче: Әйе. Соң тыңлап торалар бит, карап торалар.
Ишкуар *(тагын да аптырабрак)*: Бәлки, бәлки... Шулай була ул, була. Борчылма. Алар түгәрәк ясап йөгерәләр, үзләре яшелләр? Әйеме?
Ярдәмче *(халәтен тамашачы белән уртаклашырга теләгәндәй)*: Йөгермиләр.
Ишкуар: Йөгермиләр? Койрыклары, мөгезләре дә бар кайберләренең... Вак кыналар, шулаймы?
Ярдәмче: Зурлыклары төрлечә. Койрыклары миңа күренми, мөгезләре дә...
Ишкуар: Сиңа күренми?
Ярдәмче: Күренми.
Ишкуар: Алай булгач, аларның ваклары тычкан инде, зурраклары — күсе. Син борчылма. Аларны яшел тычкан дип-тә йөртәләр. Үтә ул, үтә... Йөгермиләр, тик торалар дисең, ә? Торсыннар, йөгерсеннәр, ятсыннар, селкенсеннәр. Син аларны уйлама. Мондый чакта башка нәрсә уйларга кирәк. Әллә врач чакырыйммы?
Ярдәмче: Мин сәламәт.
Ишкуар: Сәламәт, әлбәттә. *(Ярдәмченең башын тотып карый.)* Әллә шулай да врач чакырыйммы?

Ярдәмче: Соң кешеләр... Кешеләр бар бит.
Ишкуар: Бар, әлбәттә, бар. Син алардан курыкма. Аларга карама. Уйларыңа башка юнәлеш бир. *(Ярдәмчене үзенә таба бора.)* Миңа карап утыр. Алар сиңа тими. Алар барысы да минем якташ. Менә шулай утыр.
Ярдәмче: Ничек инде? Ничек инде алар барысы да сезнең якташ булсын? Гафу итегез!
Ишкуар: Син үзең каян әле?
Ярдәмче: Чимбәрледән.
Ишкуар: Чимбәрледән?!
Якташ: Әйе, Чимбәрледән.

**Ишкуар көлә, тагын да ныграк көлә.**

Ярдәмче: Ник минем туган ягымнан көләсез?!

**Ишкуар тагын да ныграк көлә.**

Ярдәмче: Сез?!
Ишкуар: Чимбәрле?! Андый җир юк бит ул!
Ярдәмче: Бар, нишләп булмасын?
Ишкуар: Менә сиңа — әкият!
Ярдәмче: Әкият түгел.
Ишкуар: Әкият булмаса, әйт. Кем белә синең Чимбәрлеңне? Үзеңне кем белә?
Ярдәмче: Алай кирәкми, хөрмәтлебез Ясам улы Ишкуар.
Ишкуар: Менә, менә! Менә! *(Тагын көлә.)* Ясам улы Ишкуар шул. Шуңа күрә бөтен кеше миңа якташ. Мине бөтен кеше белә.
Ярдәмче: Бәлки, белмәгәне дә бардыр, дөнья зур.
Ишкуар: Белмәгәне булса, белгертербез! Икәүләп! Сине дә белгертербез! Килештекме? *(Ярдәмчегә кул суза.)*
*Ярдәмче (елмаеп кул бирә)*: Күптән... Төштән соң мин бирердә булмам. Күпер салучылар янына китәм. Күпер әйбәт чыга. Карап торсаң — салават күпере!
Ишкуар: Салават күпере? Кирәк ул халыкка!
Ярдәмче: Мине шул гына бераз борчый. Кешеләр үзсүзләнә, усаллана, кирелənә башлады. Күпер төзү эшләрен тоткарлап куймасыннар. Ниндидер көч безгә каршы. Бу чирдән котылырга кирәк. Тиз арада котылырга.
Ишкуар: Иртәгә минем хатын да кайта. Аның белән дә киңәшләшербез. Баш бар анарда... Безнең хуҗалыкта тәртип булды! Тәртип булыр!

**Ярдәмче китә. Ишкуар уйланып кала. Якташының хәзергә хәтле шалтыратмавы да аны бераз борчый булса кирәк.**

Ишкуар: Югалды, сыбызгы. Кара син аны? Шалтыратмады да, килмәде дә. Үпкәләде. Хәерлегә булсын. Һәр кешегә ярап булмас.

**Телефон шалтырый. Ишкуар тыңлый:**

Тыңлыйм. Синмени әле? Укый-яза беләме? Документлары тәртиптәме? Чимбәрле-

дән? Якташ дисең алайса? Алырга кирәк. Мин ярдәмче сүзен жиргә сала торган хужа түгел. Шулай ит. Булды. *(Телефонны куя. Сәгатенә карый.)* О-һо-о!

**Тиз-тиз барып ишеген ача. Тавык караучыны каршы ала.**

Котәм, нечкәбил. *(Ишекне бикләп куя.)* Моның ял сәгате, димәсләр. Күрерләр. Иркенләп ашарга да мөмкинлек бирмәсләр.

Тавык караучы *(өстәлгә ашамлыклар куя)*: Иртән сезгә төшемне сөйләп бетерә алмый калдым.

Ишкуар: Үзем дә нәкъ шундый төш күрдем, шушында синең белән утырабыз. Хатын ишек шакый.

Тавык караучы *(Ишкуарны бүлеп)*: Ачма!

Ишкуар: Ул иртәгә кайта, бүген түгел.

**Сәер көй башлана. Караңгылык. Күп тапкыр телефон шалтырый.**

## II БҮЛЕК

## *Дүртенче күренеш*

**Ясамның эш бүлмәсе. Ясам урынында аның Ярдәмчесе. Бүлмәдә Ясамның хатыны да бар. Ишек шакыйлар.**

Ярдәмче: Рәхим итегез!

Якташ *(керә)*: Исәнмесез!

Ярдәмче, Ясамның хатыны: Исәнмесез! Узыгыз. Утырыгыз.

Якташ *(тәкъдим ителгән урынга утырып)*: Сүзем Хуҗаның үзенә иде.

Ярдәмче: Йомышыгызны миңа сөйли аласың. Аның вазифаларын вакытлыча мин алып барам. Безнең монда бихисап эш бит. Яңа дәүләттәге кебек. Ясам улы Ишкуар хәтта артыграк җитди кеше. Безне калдырып, эшләрне ташлап китә алмый йөрде. Үгетли торгач, үзен көчкә-көчкә генә ялга озаттык.

Якташ: Ул минем якташ. Һөнәрем буенча мин шофер. Моннан бер ел элек эш сорап, якташ янына кергән идем.

Якташ: Шофер дисез?

Якташ: Бүген эш сорап килүем түгел. Якташның кәефен генә белеп чыгыйм дигән идем... Бик авыр хәбәр шул... Бер төн эчендә барысы да юкка чыккан. Йә күккә ашканнар, йә җиргә ингәннәр, имеш.

Ясамның хатыны: Ясам улы Ишкуарның кәефе яхшы. Эшләре күп булды. Бик арып калган иде. Шуңа күрә үгетләп, үзен ялга җибәрдек. Мин аның хатыны булам.

Якташ: Сезне күрүемә шатмын... Бик күңелсез хәбәр шул.

Ярдәмче: Нинди күңелсез хәбәр?

Хатын: Әйбәт ял итәм, ди. Шалтыраткан иде. Сез килгәндә өйдә булмавы гына кызганыч. Ә ник безгә эшкә урнашмадыгыз?

Ярдәмче: Бездә яшәү шартлары яхшы.

**Оч кеше бергә сөйләшеп торсалар да, игътибарлары бергә җыйналмаган. Аларның һәркайсы — үз уенда.**

Якташ: Әллә сез ишетмәгәнсез дә...

Хатын: Бездә яхшы гына түгел. Бездә һәркем бәхетле. Акчасы күп, кайгысы юк. Җырлап яши.

Ярдәмче: Әлбәттә, бәхетеннән канәгать була белмәүчеләр, хуҗалар турында гайбәт сөйләүчеләр, вәсвәсә таратып йөрүчеләр дә табыла. Күп эшләргә яратмый, күп сөйләргә яратучылар. Алар сөйли тора. Үлә тора. Туа тора. Тормыш бу.

Хатын: Андыйлар һәр җирдә очрый.

Ярдәмче: Асылда бездә кеше тормышыннан бик канәгать. Бездә эшчән, берберенә карата игътибарлы, ихтирамлы кешеләр. Якташыгыз янына урнашырга кирәк булган сезгә.

Хатын: Уртак тел табып, әкияттәге кебек яшәр идегез.

Якташ: Ул чакта якташның сөйләшүе миңа начаррак тәэсир итте. Башкача килмәм дә дип киткән идем. Тагын килдем. Ни әйтсәң дә — бергә үскән идек. Бәлки, җирдә хәзер ул минем бердән-бер якташымдыр.

Хатын: Юкка үпкәләгәнсез. Кәефе бозылганрак чак булгандыр.

Ярдәмче: Ул кеше белән ягымлы сөйләшә.

Якташ: Минем белән башкачарак сөйләште.

Хатын: Сез аны аңламагансыз.

Ярдәмче: Ул бөек кеше!

Хатын: Ул кайчандыр хәтта шигырьләр яза иде. Хәзер вакыты җитми.

Якташ: Малай чакта без барыбыз да шагыйрь идек... Якташка ишеттерегез: безнең туган якта бөтен кеше бер төн эчендә юкка чыккан икән. Ни өчен, ничек юкка чыгулары да билгесез ди. Язуы гарәп йә татар телендә булган кәгазьләрнең карасы очкан. Шундый хәбәр бар безнең яклардан... Барыбыз да шагыйрь идек.

Ярдәмче: Ясам улы Ишкуар хәзер дә шагыйрь.

Хатын: Чын шагыйрь, күңелле кеше.

Якташ *(елмаеп)*: Хәзер сез аны бозгансыз.

Ярдәмче: Якташыгыз турында? Яхшы түгел, түгел.

Хатын *(елмаеп)*: Без бозык кешеләр түгел. Шулай булгач, аны ничек бозыйк?!

Якташ: Мактап бозуыгыз мөмкин. Кеше бозуның юллары күп.

Ярдәмче: Безнең тирәдә андый юллар юк. Без аларны бетердек.

Якташ: Сөреп, өсләренә чәчәк утырттыгызмы?

Хатын *(елмаеп)*: Чәчәк утырттык... Бездә шулай.

Ярдәмче: Бәхетле як!

Якташ: Мин бер бәхетсезне күрдем.

Ярдәмче: Кайда күрдегез?

Хатын: Нинди бәхетсез ул?

Якташ: Сезнең чәчәкле урамда. Бераз сөйләшеп тордык.

Ханым: Кеме үлгән? Ни булган аңа?

Якташ: Эшләдем, эшләдем, бер хатын белән бер балага җиткерә алмадым, ди. Узган ел үземне ташлап киттеләр, ди.

Ярдәмче: Кайда эшли ул? Исеме ничек үзенең? Бәлки, ана бер-бер ярдәм кирәктер.

Якташ: Исемен сорамадым... Сез чыннан да ишетмәдегезме?

Ярдәмче: Без... Ничек инде ишетмик?

Хатын: Эш яратмыйдыр ул безнең урамда сиңа очраган кеше. Юкны сөйләп гомер уздырырга ярата дыр. Йә хатыны...

Ярдәмче: Әйтәм бит, бәхетеннән канәгать була белмәүчеләр кайда да табыла. Хуҗаларны яманлыймы?

Якташ: Алай ук зур мәсьәләләр турында сөйләшмәдек. Үзе турында әйтә. Быел ыштансыз ук калдым, ди. Эшлим дисәң, эш булмады. Эше булса — көне булмады, ди... Сез бөтенләй ишетмәгән кебек.

Хатын: Без ничек инде ишетмик?!

Ярдәмче: Ыштан сатып ал, диярго идең син ул кешегә. Кисен иде. Кибетләрдә ыштаннан идәннәр сыгыла.

Хатын: Бездә кеше акчалы, акчалы.

Якташ *(урыныннан торып)*: Күрәсең, бу бәхетсезнең кесәсендә акчасы артык күп булган, шуңа ыштаны төшеп калгандыр.

Хатын: Сезнең белән сөйләшү күңелле. Сезгә шофер һөнәре түгел, башка һөнәр сайлау кирәк булган.

Якташ: Миңа шофер эше ошый. Ярый, китәм.

Хатын: Безгә керегез. Безнең өй зур, түбәләр биек, иркен. Саф һавалы болын кебек. Бүлмәләр күп, адашырга мөмкин. Ял итеп китәрсез.

Ярдәмче: Әйе, якташыгызның тормышын күрерсез.

Якташ: Рәхмәт, юлым ашыгыч. Машинам урамда. Якташка сәлам әйтегез.

Хатын: Менә бит ничек килеп чыкты. Якташы килде — ул юк. Бер атнадан кайта. Килегез, кунак булырсыз.

Якташ: Чакыруыгызны кабул итәм... Әлегә киттем. Яңа очрашуга хәтле. Сау булыгыз.

Ярдәмче: Уңышлар юлдаш булсын!

**Якташ китә. Беразга тынлык.**

Ярдәмче: Безгә мондый шофер кирәкми!

Хатын: Йә инде, йә. Мин барын да күрәм. Урын тапкан, эше бар. Күңеле күтәренке. Ул яшәр, менә миңа нишләргә?

Ярдәмче *(тиз-тиз барып радио җибәрә)*: Оныта язганбыз. *(Радиода җыр тәмамлана.)*

*Минем өчен,*
*минем өчен*
*сары тавык, бәгырькәем,*
*утка сала йомырка.*

*(Ярдәмче сөйләнә-сөйләнә телефонга бара.)* Бетәбез икән! *(Номер җыя.)* ...Радиодан нинди сүз яңгыраганны ишеттегезме? Шушы минутта. Әйе, мин бу, мин... Ирләр хоры кирәк. Ләкин җырга үзгәреш кергән. «Утка сала йомырка» дип җырладылар. Бәләкәй түгел. Бу коточкыч зур үзгәреш. Ясам улы Ишкуарның туган ягында «күкәй» диләр. Нәрсә булырмы? «Йомырка» дип җырлаган өчен Ясам улы Ишкуар хорда катнашучы биш йөз ирнең дә йомырка... Синекен дә! Ул бер атнадан кайтып җитә, җавап бирерсез. *(Ачуланып трубканы куя.)*

Хатын: Алар җавап бирер. Менә миңа нишләргә?

Ярдәмче: Сиңа ни булды?

Хатын: Булды. Хет әнә теге яңа күпергә барып, иң уртасына басып, суга сикер. Менә нинди бүген минем хәлем.

Ярдәмче: Суга сикерергә һәм төкерергә ярамый!

Хатын: Ясам улы Ишкуар кайткач, хәлем тагын да яманрак була. Суга сикерергә дә соң була.

Ярдәмче: Нәрсә бар? Ни булды сиңа, дидем!?

Хатын: Миңа киңәшең, хәтта ярдәмең кирәк.

Ярдәмче: Кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә әзермен.

Хатын: Анда минем танышым бар. Күптәнге танышым.

Ярдәмче: Нинди таныш? Кайда?

Хатын: Шунда инде, мин ял итә торган җирдә. Ир-ат бар. Анда яши торган кеше... Юк кеше түгел, сиңа да ярдәме тиярлек.

Ярдәмче: Йә-йә, шуннан?

Хатын: Кичә кич ул миңа шалтыратты. «Кабырчык» дигән ресторанда Ясам улы Ишкуар белән очрашкан. Минем ирем икәнне белеп түгел. Очраклы рәвештә очрашканнар. Ничектер килешеп киткәннәр. Ул Ясам улы Ишкуарны өенә чакырган. Аның өендә Ясам улы Ишкуар минем фоторәсемне күргән. Стенада...

Ярдәмче: Мин сине моның өчен асып куярга тиеш.

Хатын: Кичер. Мин аның белән сиңа хәтле таныш идем.

Ярдәмче: Фоторәсемең артына исемеңне язган идеңме? Әллә инде анысын хәтерләмисең дәме?

Хатын: Язмаган идем.

Ярдәмче: Шылтырат ул иргә. Фотога язмаган булсаң, исемеңне әйтә күрмәсен. Инде әйтмәгән булса... Икенче бер исем әйтсен. Мичувичиха, Хачувичими, дисен. Вичихучума дисен, дөньяда булмаган бер исем әйтсен, син икәнне сиздермәсен.

**Телефон шалтырый һәм тагын шалтырый.**

Хатын: Алла белсен... Исемеңне әйтмәдем, ирең икәнне ярый иртәрәк сизеп алдым, диде.

Ярдәмче: Димәк, әйтмәгән. Шулай булгач, Ясам улы Ишкуар...

Хатын: Шулай булгач?! Минем менә шушы борын, ияк, күзләрне, кашымны таный бит ул.

Ярдәмче *(көлә)*: Күргәне бар, дисеңме?

Хатын: Көлмә. Сез... Барыгыз да...

Ярдәмче: Исемеңне әйтмәгән, шунысы шәп. Шуңа шатлан.

Хатын: Йөзем? Ә йөзем?

Ярдәмче: Йөз кемдә юк? Синең йөзеңә йөзе охшаган шайтаннар беткәнме әллә бу дөньяда? Шылтырат ул кешеңә. Миллион чакрым ераклыктан килгән, сезнең якта эзе дә булмаган мәгъшукам, дисен.

Хатын: Ясам улы Ишкуар ышанмас. Эзли китәр.

Ярдәмче: Безнең күз күрмәгән, колак ишетмәгән илдән килгән артистка, дисен.

Хатын: Барыр, тикшерер.
Ярдәмче: Үз хатыным, дисен.
Хатын: Аның бит хатыны юк.
Ярдәмче: Бар иде, үлде, дисен.
Хатын: Ышанмас.
Ярдәмче: Ышаныр. Каберлеккә алып барып, каберен күрсәтсен. Бер түмгәк булып торган җирне күрсәтсен! Мең ел элек үлде, дисен.
Хатын: Бүген үк сөйләшәм. *(Иркен сулап, елмаеп куя.)* Рәхмәт. Нинди дә булса бер акыллы киңәш бирерсең, ярдәмең тияр, дип ышанган идем.
Ярдәмче: Болай ук уйлаганым булмады... Анда таныш ир, имеш. Ә мин монда синең өчен... Дингез йолдызы!
Хатын: Миңа бүген Ишкуар алдында бер кат кыен булса, синең алда...
Ярдәмче: Мин бит синең өчен... Кальмар!
Хатын: Алып кайтам мин ул фотоны. Сиңа бирәм!

**Караңгылык. Өзлексез телефон шалтырый.**

## Бишенче күренеш

**Заманча көй яңгырый. Каядыр дингез күренә. Бер өйдә мәҗлес. Ясам улы Ишкуар белән Дингез ханым, Ясам улы Ишкуарның дингез буендагы танышы белән Дулкын ханым парлашып биләр.**

Ишкуар: Мондый биюләр хәзер минем өчен түгел икән, Дингез ханым!
Дингез ханым: Безнең өчен! Икебез өчен!
Дулкын ханым: Мин дә арыдым бугай.
Таныш: Әйдәгез соң, ял итик!

**Көй туктала. Бию тәмам. Телефон шалтырый. Ишкуарның танышы телефонны ала.**

Мин тыңлыйм, исәнме... Кунакларым бар. Кайгырмаска киңәш итәм. Үзем шалтыратырмын, ярыймы? *(Кунакларга.)* Ник аптырашып калдык? Әйдәгез, өстәл янына рәхим итегез, кадерле кунаклар!
Дингез ханым *(Ишкуарга сырпаланып)*: Арытты да, рәхәт тә.
Ишкуар *(тутырып куелган рюмкаларның берсен ала)*: Сүзем бар!

**Башкалар да рюмкаларын ала.**

Дингез ханым белән Дулкын ханым өчен шигырь укыйм. *(Урыныннан торып укый.)*

*Парлы да булдык бугай без,*
*ялгыз да калдык бугай.*
*Саласын — салдык бугай без,*
*янасын — яндык бугай...*
*Шуңа бүген рюмкаларны*
*томабыз салкын гына.*
*Ник соң әле без суындык?*
*Тирә-юнь — ялкын гына!*
*...Яна аең, кояш — яна,*
*ялкын җирдә агыла...*
*Кар суларын ялкын ялый,*
*чәчәкләргә кабына.*
*Яна офык, яна капкаң,*
*стенаң, урындыгың...*
*Яндырып йөзгә кагыла*
*кайнар караш, кайнар тын.*
*Яшь кызлар чаткы кебекләр,*
*ханымнар — учак бугай.*
*Юк, әле без янмаганбыз,*
*безнең янар чак бугай.*
*Калган гомер янар бит, дип,*
*куркышып калмыйк әле.*
*Дөнья дорли, ә без нәрсә?*
*Әйдәгез, салыйк әле!*
*Шуннан соң карарбыз.*

Таныш: Афәрин! *(Рюмкасын Дулкын ханым рюмкасына тигезеп ала.)*
Дингез ханым: «Ханымнар учак» дигән җире бигрәк тә кайнар әйтелгән.

**Эчемлектән авыз итеп куялар. Күңелле музыка — «Тау астында илле бүре» көе... Дулкын ханым җыр башлый. Калганнар үз җае белән җырга кушыла.**

*Күлмәгемә яңгыр тиде,*
*кибәр әле, киптергәч.*
*Үптермәсәм, соймим, диде,*
*азган диде, үптергәч.*
*(Кушымта.)*
*Тау астында гына*
*илле бүре тора,*
*кемне ашарлар икән?*
*Әллә бүреләргә*
*бирергәме үзен,*
*әллә ташларга микән?*
*Сандыгымда ике күлмәк,*
*икесе дә кимәгән.*
*Әйтмәм, диде, беркемгә дә,*
*дусларына сөйләгән.*
*(Кушымта кабатлана.)*
*Кисәң туза, кисәң туза,*
*кисәң туза икән лә.*
*Башкаларга күзен сала,*
*минем белән үткәндә.*
*(Кушымта кабатлана.)*
Дингез ханым *(урыныннан торып)*: Китәргә вакыт.
Ишкуар *(урыныннан тора)*: Күңелсез хәбәр.
Дулкын ханым *(көзге янына бара, чәчләрен рәтли)*: Безне югалтканнардыр, гайбәте таралыр.
Таныш *(ханымнарга)*: Килешенгәнчә, кичтән котәбез.
Дингез ханым *(шаярыбрак)*: Кич җитте дә түгелме соң инде?!
Ишкуар: Бераз ял итеп алырлык вакыт бар. Бөтен нәрсә тәртиптә... Дөньяда — тәртип!
Дулкын ханым: Саубуллашып тормыйбыз. Озата чыкмагыз.

**Ханымнар китә.**

Ишкуар *(уйланып торгач)*: Тынлык.
Таныш: Вакытлыча тынлык.
Ишкуар *(стенадагы фоторәсем каршына барып баса)*: Димәк, бу минем хатын түгел.

Таныш: Синең хатын түгел.
Ишкуар: Бу синең хатын?
Таныш: Минем хатын.
Ишкуар: Минем хатын түгел инде?
Таныш: Юк инде, юк.
Ишкуар *(бүлмәне караштырып)*: Минем эш бүлмәсе дә шушы бүлмәгә охшаган. Кызык нәрсә инде ул — яшәү.
Таныш: Ярдәмче белән сөйләшәм, дигән идең. Ничек анда хәлләр? Тавык нишли анда, тавык? Шул сары тавыкның серен тәки миңа әйтмәдең.
Ишкуар *(кычкырып көлә, күпмедер эчкәнлеге сизелә)*: Сере юк аның, күкәй сала...
Таныш: Ә ник ул сиңа шул хәтле кадерле?
Ишкуар: Чебеш чагыннан күңелемә ошады.
Таныш: Шул хәтле әтәч асравыңа да төшенмим.
Ишкуар *(тагын кычкырып көлә)*: Ә син гомере буе марка җыйган кешеләрне төшенәсеңме? Йәисә бөтен өен кактус белән тутырган кешеләрне? *(Күпмедер эчкәнлеге тагын да ныграк сизелә.)* Аларның эшен төшенәсеңме?
Таныш: Аларның эшен төшенәм, хобби!
Ишкуар: Минем эшне төшенмисең?
Таныш: Хобби?
Ишкуар *(тагын кычкырып көлә, аннан кинәт җитдиләнеп кала)*: Ярдәмче минем — сәләтле. Эшли дә, эшләтә дә белә. Куанычлы яңалыклар әйтте. Биш йөз кешелек ирләр хоры оештырган. Яңа җыр башкаралар. Ул җырда минем дә зур өлешем бар. Көендә дә, сүзләрендә дә...
Таныш: Но-о-о?! Син шундый эшләргә дә сәләтлемени?
Ишкуар: Сәнгать ярата м. Җыр ярата м, шигырь.
Таныш: Әйтәм бит, үсәргә тиеш син, үсәргә! Киләчәгең — колачыңа тиң булырга тиеш. Шуңа барырга!
Ишкуар: Юлын эзләү кирәк инде.
Таныш: Юлын мин табармын.
Ишкуар: Тагын яңалык бар. Күпер төзелеп беткән. Елгасы артык гайрәтле иде, язларда якын килерлек түгел. Шуңа салават күпере салып куйдык! Мин бит ул күпер аша сары тавыкка елга аръягыннан, ераклардан — әтәчләрнең күркәдән зурларын кайтарачакмын. *(Стенадагы фоторәсемне яңадан барып карый.)* Ничек шул хәтле охшарга мөмкин диген, ә?!
Таныш: Әйтмә дә?!
Ишкуар: Ике тамчы су кебекләр.
Таныш: Кирәк бит?!
Ишкуар: Димәк, синең хатын?
Таныш: Минем хатын, минем хатын.
Ишкуар: Ул минем хатын түгел инде, әйеме?
Таныш: Түгел инде, түгел.
Ишкуар: Минеке түгел?!
Таныш: Синеке түгел.
Ишкуар: Синеке.
Таныш: Минеке. Искә төшә дә, кыен. Миннән кимнәрне сөймә дип үлде, мәрхүмә. Аңа тиңне каян табасың?
Ишкуар: Узганнарны исеңә төшереп, борчыдым. Ачуланма.
Таныш: Беләсеңме? Хатыныңны күрсәм, артык авыр булыр дип, чакыруыңа каршы килгән идем. Ләкин... Уйлап торам да... Мин сиңа кунакка барып чыгармын... Түзәргә калгач, түзәрсең — әрнемә йөрәккәем! *(Рюмка ала.)* Әйдә берәрне? *(Эчеп куялар.)*

Ал әле кара уылдык... Күп ул бездә, диңгездә.
Ишкуар *(нидер капкалап)*: Хатын башка җирне сайлаган иде. Мин шушында килдем. Син коенып кайткан сулар миңа үз булыр, үрдәккәем, дидем мин аңа, һәм шулай булды да... Бу минутта, моннан өч мең чакрым еракта, нишли икән анда минем хатын? Өч мең чакрым!
Таныш: Синең киләчәк — минем истә булыр.

**Ишкуар шунда танышының колагына нидер әйтә.**

Анламыйм.

**Ишкуар тагын пышылдый. Танышы ишетми.**

Нәрсә?
Ишкуар: *(Бу юлы сүзләре аңлашылырлык тавыш белән.)* Чибәр, чукынмыш, Диңгез ханым. Чиркәү ишеге шикелле.
Таныш: Шул чибәр бу төндә синең карамакта булачак!
Ишкуар: *(Кинәт сагаеп.)* Тш-ш-ш! Хатын ишетмәсен.
Таныш: Өч мең чакрым араданмы?!
Ишкуар: Әйе. *(Ишеккә юнәлә.)* Мин дә кайтып, бераз тәртипкә кереп киләм... Өч мең чакрым арадан ишетә.
Таныш: Син ни сөйлисең?!
Ишкуар: Ишетә! Белмисең син минем хатынны!
Таныш: *(Ишектән озатып кала.)* Югалма.
Ишкуар: Нәкъ вакытында биредә булырмын. *(Чыгып китә.)* Таныш: *(Үзалдына.)* Ишетә, билгеле. Хәзер мин аңа шалтыратам бит. *(Телефон номеры җыя.)*

**Караңгылык.**

## Алтынчы күренеш

**Ясам улы Ишкуарның эш бүлмәсе. Хужа борчулы, ул ишекле-түрле йөри. Ишектән Ярдәмче керә, Хужа өстәле янындагы урындыкка барып утыра, ниндидер бер йомыш белән, каядыр чыгып кына керүе.**

Ишкуар: Атам!
Ярдәмче: Синең башта һаман шул.
Ишкуар: Уйлап кара син аны. Әллә кайда, әллә кем өендә аның фоторәсеме. Анадан тума шәрә. Кешегә сөйләргә оят. Хатынның үзенә әйтергә дә оялып йөрим әлегә. Сиңа гына сөйләдем. Йоклый алмыйм, төннәр буе күз алдымда шул өй, шул фото. Атам мин хатынны.
Ярдәмче: Кирәкми.
Ишкуар: Суга салам.
Ярдәмче: Җүләр булырсың.
Ишкуар: Ул фоторәсем синең хатыныкы булса? Моннан өч мең чакрым еракта,

чит ир өендә аны күрсәң? Син акыллы булыр идеңме? *(Пауза.)* Асам!

Ярдәмче: Акыллы булыр идем. Үзең... бөтенләй үк гонаһсызмы?

Ишкуар: *(Тамак кырып куя.)* Хәтерләмим. Мин хатынны аерам.

Ярдәмче: Ул кеше бит сиңа әйткән. Үземнең хатын дигән.

Ишкуар: Әйтте.

Ярдәмче: Ышанмадыңмы?

Ишкуар: Ышандым.

Ярдәмче: Шулай булгач...

Ишкуар: *(Бүлеп.)* Хәзер тагын шикләнәм. Бәлки, ул алдагандыр.

Ярдәмче: Ай-һай. Алдар микән?

Ишкуар: Мин ул кешене кунакка чакырдым. Килә. Шунда бер-бер нәрсә ачыкланыр. Әгәр ул фоторәсем...

Ярдәмче: *(Бүлеп.)* Җирдә хатыннар бихисап. Бер-берсенә охшаган хатыннар икәү генә түгел, бик күпләр. Шул гаҗәпме?

Ишкуар *(уйланып)*: Шулай дисеңме?

Ярдәмче: Шулай, дим. Әлбәттә, мин синең хатынны син белгән дәрәҗәдә белмим. Ләкин мин күрәм бит. Ул тыйнак, басынкы.

Ишкуар: Сөйләшмә!

**Шул вакыт ишек ачыла, ике егет керә.**

Егетләр: Хәерле көн. Мөмкин микән?

Ишкуар һәм Ярдәмче: Кotәбез. Хәерле көн!

Беренче егет: Яңалыклар белән килдек.

Ишкуар: Яхшы.

Икенче егет: Яхшы түгел.

**Ишектә Әтәчләр белгече күренә.**

Ишкуар: *(Әтәчләр белгеченә.)* Бераздан чакырырмын.

**Әтәчләр белгече китә.**

*(Егетләргә.)* Килүегез яхшы, дим, килүегез. Йә, ниләр ачыкланды?

Егетләр: Котырталар. Котырталар.

Ярдәмче: Тәгаенрәк?!

Беренче егет *(ишеккә күрсәтеп.)* Кеше бар.

Ишкуар: Ишетми ул.

Икенче егет: Саңгыраумы?

Ярдәмче *(ишекне яхшылап ябa)*: Ишек калын.

Беренче егет: Ишәк караучылар арасында өч котыртучы бар.

Икенче егет: Яшелчәчелектә эшләүчеләр арасында — биш.

Беренче егет: Игенчелектә — биш.

Икенче егет: Шоферлар арасында — ун. Шуларның берсен бүген үк тотып...

Беренче егет: Шифаханәгә урнаштырырга кирәк дип уйлыйбыз.

Икенче егет: Үзе безгә күптән түгел генә эшкә кергән.

Ишкуар: Чимбәрледәнме әллә ул?

Беренче егет: Юк. Менә мин Чимбәрледән.

Икенче егет: Мин дә Чимбәрледән.

**Ишкуар әле егетләргә, әле Ярдәмчегә карый.**

Ярдәмче: Әйе, әйе. Чимбәрледән.

Ишкуар: Якташлар?

Ярдәмче: Якташлар, хөрмәтлебез Ясам улы Ишкуар. Безнең әтәч караучыларның да хәзер яртысы Чимбәрледән. Аларга ышанып була.

Беренче егет: *(Ишкуарга кәгазь суза.)* Монда барысы да язылган. Исемнәре, эшләгән җирләре... Ясам улы Ишкуардан уңмадык. Янына булдыксызларны, ялагайларны җыя диючеләр бар.

Икенче егет: Хуҗалык байлыгын туздырып, калганын кесәләренә тутырып, качарга җыеналар диюче дә бар.

Беренче егет: Барысын бергә җыеп... *(Асып кую мәгънәсенә ишарә ясый, кулы белән.)* Кызганырлык түгелләр. Әтәчләргә каршы сүз сөйлиләр.

Икенче егет: Бу чын яшәү түгел, әкият булды. Әкиятнең ахыры да килер, бер күрербез, диләр.

Беренче егет: Бер балыкчы «Сары тавык турында мәңгелек җыр» дан көлде. Җыр түгел, диде һәм өч этаж ярым итеп сүгенде. Кәгазьдә сүзләре бар. Әлегә сезгә менә шулар. Калганнары эзенә дә төшәрбез.

Ярдәмче: Тиз төшәргә кирәк!

Икенче егет: Тиз төшәрбез.

Ишкуар: Котлыйм, Чимбәрле егетләре. Җирдә Чимбәрле барына мине ышандырдыгыз. Эшегез мактауга лаек, утырышыгыз. Хәзер биргә мөһим шәхесләр килә. Тыңлап калырсыз, күреп. Киләчәктә сезгә кирәк булулары да бар.

**Егетләр утырыша.**

*(Ярдәмчегә.)* Җыелыштан соң беренче чиратта шушы кәгазь белән шөгыльләнергә кирәк. Күрсәтергә кирәк үзләренә әкият ахырын. *(Ишек ачып.)* Кер! *(Үз-үзенә сөйләнә.)* Асылда тәртип һәм бездә һәрвакыт тәртип булыр.

Әтәчләр белгече *(ишектән керә)*: Хөрмәтле...

Ишкуар: Ике минутка. Якынрак кил.

Әтәчләр белгече: Мин ишеттем. Әтәчләрне...

Ишкуар *(аны бүлеп)*: Бармы синең күзләрең?

Әтәчләр белгече: *(Ярдәмче белән киңәшүен аңлатып.)* Без киңәштек.

Ярдәмче: Әтәчләр өлкәсендә мин белгеч түгел шул инде.

Ишкуар: Ахыр чиктә, әтәч сайлау белән ни өчен ул шөгыльләнергә тиеш? Моның өчен син бар. Син белгеч. Безнең башка эшләр муеннан.

Әтәчләр белгече: Хөрмәтлебез...

Ишкуар *(аны бүлеп)*: Бүген үк сат. Мин югында алган сигез әтәчеңне дә сат. Шулар да әтәч булдымы? Карап тордым, алар юньле генә итеп койма өстенә дә менә алмыйлар.

Әтәчләр белгече: Бәлки алар...

Ишкуар: Эндәшмә! Әнә, сары тавык... Күкәен утка сала. Төшенәсеңме? Безгә ачуланышмыйча эшләргә кирәк. Нинди күпер корып куйдык! Кем өчен? Синең өчен! Түбәсен күккә терәп бәхет йорты җиткердек. Се-

знең өчен... Халык өчен... Шуларны уйлый белик... Уйлашыйк, бәлки сиңа ярдәмче билгеләргә вакыт житкәндер.

Әтәчләр белгече: *(Шатланып.)* Хөрмәтле...

Ишкуар *(аны бүлеп)*: Иртәгә кер. Бүгенгә сүзебез бетте. *(Сәгатенә карый.)* Кешеләр кабул итәм.

**Әтәчләр белгече китә.**

Беренче егет: Кара син аны?!

Икенче егет: Телләшергә жыена?!

**Ишектән Шагыйрь, Хор житәкчесе, композитор һәм башкалар керә. Уртак сәламләшүләр. Барысы да утырышалар.**

Ишкуар: Без бүген «Сары тавык турында мәңгелек жыр»ның хәзерге хәле һәм аның киләчәге турында тагын бер кат сөйләшеп алырга жыелдык. Бу сөйләшү безгә ник кирәк? *(Пауза.)* Бу сөйләшүне бер генә жыр белән чикләп карарга ярамый. Бу сөйләшү — киләчәктә яңа жырлар тудырырга әзерләнү.

Берәүләр:

— Дөрес! Шулай!

— Бик дөрес!

Ишкуар: Бездән көлүчеләр бар. Тавык турында жырлыйлар диючеләр бар. Әйтсеннәр. Без яхшы беләбез, тормышта тавык та кирәк.

Берәүләр: Шулай. Бик дөрес!

**Телефон шалтырый.**

Ярдәмче *(телефонга)*: Бездә жыелыш... Әйе... Әйе... *(Ишкуарга.)* Ясам улы Ишкуар, хатыныгыз... Тыныч кына сөйләшеп торганда, кешеләрнең күз алдында... Хатыныгыз юкка чыккан.

**Кешеләр аптырашта. Тынлык.**

Ишкуар: Яхшы булган, әгәр дөрес булса. Телефонны куй. Безнең монда хатыннарыбыздан мөһимрәк эшләр бар... Тавыкка әтәч кирәк тә кирәк! Шулаймы?

Берәүләр: Шулай!

Ишкуар: Шулай булгач, без әтәч турында да язарбыз. Тормышның ни икәнен белмәгән кешеләрдә эшебез юк. *(Ялкынлана баруы сизелә.)* Алар безнең хакта теләсә ни сөйләсен! Кичә көтүлекләрдә йөреп кайттым. Җиленнәре сөт тулы сыерлар, калын йонлы сарыклар, бозаулар, бәрәннәр... Алларыннан мәһабәт мөгезле кәжә тәкәсе бара, аның турында матур жыр ник язмаска?! Маллар үзебезнеке! Бездә мал да, куәт тә, талант та житәрлек! Теләк кенә кирәк. Без теләгәч, тиз арада биш йөз кешелек ирләр хоры оешты. Үзебезнең хор! Оештыручысы да биредә.

Хор житәкчесе *(тора)*: Чимбәрле.

**Кул чабулар. Хор житәкчесе утыра.**

Ишкуар: Мәңгелек жыр кушымтасының соңгы юлын миннән башка үзгәрткәнсез икән. Моны ничек аңларга? Бу нинди тәртип?

**Телефон шалтырый.**

Ярдәмче *(телефонга)*: Әйе. Бездә жыелыш иде. *(Ишкуарга.)* Якташыгыз шалтырата.

Ишкуар *(телефонны ала)*: Сәләм, сәлам, сыбызгы! Син жирнең кай читеннән? Бездә эшлисең? Күптән түгел генә... Шофер булып... Әйдә, кил. Жыр тыңларсың. *(Телефонны читкәрәк этеп куя. Ярдәмчесенә.)* Теге сигез хәлсез әтәчләрне сатарга барышлары икән.

Беренче егет *(урыныннан торып)*: Хөрмәтле... Шул шофер...

Ишкуар *(егетне бүлеп)*: Аңладым, утыр.

Хор житәкчесе *(урыныннан торып)*: Без үзара киңәшләштек тә... беләсезме...

Ишкуар *(Бүлеп)*: Кушымтаның соңгы юлы... Җырлавыгызны тыңлап карыйк әле менә. Язып алганнар, аны миңа тапшырдылар.

**Дингез буендагы мәжлестә жырланган «Тау астында илле бүре» жыры яңгырый башлый. Ишкуарның тавышы аеруча ачык ишетелеп-ишетелеп ала. Ишкуар аптырашта.**

Нәрсә бу?! Кайдан бу?! *(Ул жыр яңгыраган урынны эзли.)*

**Җыр туктала, кабат дәвам итә.**

Кайсыгыз?! Туктатыгыз!

**Җыр туктала. Ясам барып стаканнан су эчә. Җыр тагын дәвам итә һәм туктала.**

Бу нәрсә?

Берәүләр:

— Жыр тавык турында булырга тиеш иде.

— Ә бу жыр бүре турында!

— Сез матур жырлыйсыз икән, хөрмәтлебез.

Ишкуар: Минем белән болай кем уйный?

**Тынлык. Ишкуар тагын су эчә. Кинәт ишек ачыла, бүлмәдәгеләр сискәнеп куя. Тавык караучы керә.**

Тавык караучы: Сары тавык утка күкәй салганда янып үлде!

Берәүләр: Үлде?! Янып үлде?!

**Ишкуар егылып китәр хәлдә, кулыннан стаканы өстәлгә төшә. Кемнәрдер Ишкуарны тоталар. Ярдәмче телефоннан шалтырата.**

Ярдәмче: Хәзер үк килегез. Йөрәге, йөрәге. Тизрәк! *(Ишкуар янына бара.)* Хәзер врач килә. *(Караңгылык.)*

## Соңгы күренеш.

**Хужалык биналарыннан читтә, калку урын. Түбәнрәк — таллар, елга, күпер. Каядыр юллар кисешә.)**

Карт: *(Күпердән килеп, калкулыкка үтә.)* Каркадиллар йөзеп йөри. Безнең елгада гомер булмаган хәл... Яңа күпер нәкъ уртасыннан убылырга тора. Барып әйтергә кирәк. Күпер башларына язу куйсыннар. Керергә ярамый дип язсыннар.

**Карт каршына Ишкуарның хатыны һәм дицгез буендагы Таныш килә. Таныш кулында чемодан. Алар картка игътибар да итмичә, ашыгып күпергә үтәләр.**

Әй, чемоданлы иптәш! Безнең акчаны кая алып китәсез?

Таныш һәм Хатын: Нәрсә?!

Карт: Хуҗаның чемоданын калдырыгыз, дим!

Хатын *(Танышка)*: Әйдә, саташкан карт ул.

**Аръякта машина кычкырткан тавыш.**

Таныш: *(Ашыгып киткән уңайга, Хатынга.)* Безгә кычкырта.

Карт: *(Китүчеләрне карап кала, үзалдына сөйләнә.)* Әле бу күпердән йөрүче дә булмады ләбаса. Кирәге дә юк аның безгә.

**Ишкуар килә. Тавык карауччы, Ярдәмче, Чимбәрле егетләре һәм башкалар аңа ияргәннәр.**

Тавык карауччы: Китмәгез?!

Ишкуар: Китәм!

Ярдәмче: Сезгә борчылырга ярамый. Тынычланыгыз. Сорыйбыз?

**Ишкуар һаман китәргә омтыла. Аны җибәрмәскә тырышалар.**

Берәүләр:
— Китмәгез?
— Безне калдырмагыз?
— Үтенәбез?

Ишкуар: *(Түгәрәк ясап йөгерә башлый. Башкалар аннан калмаска тырыша.)* Сары тавыкны сакларга да ярамаган булдыксызлар сез. Китәм!

Берәүләр:
— Сездән башка яши алмыйбыз.
— Без сезгә өйрәндек.

Карт: Һай, рәхмәт төшкерләре!

Ишкуар: Сез ялкаулар, коткы таратучылар, әләкчеләр, шымчылар! Кирәк түгел сез миңа!

**Ишкуар алга үтә, күпергә. Башкалар кала.**

Карт: Хөрмәтлебез, акчаны калдырыгыз!

Ишкуар: Нинди акча?!

Карт: Сезнең кесәдә. Безнең акча.

Ишкуар: Сезнең акча — сезнең кесәдә булыр. Яхшылап, капшап карагыз! *(Ашыгып китә.)*

Берәүләр: *(Ярдәмчегә.)*
— Китте. Бар мәшәкать сезгә калды.
— Сезгә, хөрмәтлебез. Сез генә...

**Берәү ашыгып килә, кулында сары тавык.**

Килүче: Ул янмаган!

Берәүләр:
— Янмаган?
— Мөмкин түгел!
— Ә ник мөмкин булмасын?

Ярдәмче: Янмаган! Ул исән!

Килүче: *(Тавыкны кулында тоткан килеш.)* Аны урлаган булганнар.

Берәү: Ах, караклар! Юлбасарлар, адәм актыклары!

Тавык карауччы: *(Елый.)* Әйе, урлаган иделәр.

Берәү: Безнең тавык түгел шикелле бу. Әллә алыштырганнармы?

Ярдәмче: *(Тавыкны кулына алып.)* Үзебезнеке!

**Башкалар җыела. Тавыкны карыйлар.**

Килүче: Аны урлап киткәннәр. Тикшергәннәр.

Карт: Бичараны шундый каты тикшергәннәр. Селкенә дә алмый.

Тавык карауччы: Селкенер ул исән булса.

Килүче: Ул ун йомырка салмый. Бик әйбәт караганда, көнгә ике йомырка салуы мөмкин икән. Тикшерүләр шуны ачыклаган.

Берәүләр:
— Булмас!
— Булыр да...
— Дөрес тикшермәгәннәр алар.

Тавык карауччы: Мин аны карадым. Мин беләм, хөрмәтле...

Ярдәмче: *(Бүлеп.)* Син аны тагын карарсың. *(Кулына тавык тоттыра.)* Коралланган каравыл куярбыз!

Берәүләр: Шулай кирәк! Бик кирәк!

Берәү: Ике генә күкәй салгач, унны салмагач...

Ярдәмче: *(Бүлеп.)* Ул көнгә егермене салачак!

Берәүләр: Ай-һай... Салыр микән? Салдырырбыз! *(Ярдәмчегә.)* Сезнең белән... Салдырабыз аны!

Ярдәмче: Миңа ярдәмче кирәк булыр.

Тавык карауччы: Әнә — ярдәмче, сары тавыкны тапкан кеше!

Берәүләр: Булдыклы кеше. Булсын, ул ярдәмче булсын!

Килүче: Мин ат печүче генә...

Карт: *(Бүлеп.)* Кеше печүче булмагач, ярый-ярый.

Берәү: Мондый зур үзгәрешләрдән соң, сары тавык турындагы җырны да үзгәртергә туры килер кебек.

Ярдәмче: Җыр шул ук, шул ук җыр кала. Анда үзгәреш бар һәм зур үзгәреш.

Берәүләр:
— Йомырка! Йомырка дип җырлыйбыз ич!
— Шулай, шулай!

**Каядыр янгын чыга. Янгын көчәя.**

Тавык каручы: Янабыз! Сары тавык, бәгырькәем, безгә чынлап та яну язган икән. Янабыз бит!

Карт: *(Җиргә җәйлап утыра.)* Янарлык маем да юк.

Ярдәмче: Хуҗалыкны инләп ут килә!

Берәү: *(Икенче бер тарафтан кычкырып пәйда була.)* Киләләр!

Карт: Ни бар тагын?

Берәү: Тау астында илле ач бүре! Монда киләләр! *(Ул йөгереп күпергә үтә. Аның артыннан Ярдәмче йөгерә. Ярдәмчегә башкалар ияра.)*

Чимбәрле егетләре: *(Башкаларга ияреп.)* Илле бүре!

Карт: *(Китүчеләргә.)* Кермәгез күпергә, уртасыннан убыла башлаган! Суда каркадиллар бар!

Тавык каручы: *(Әллә куркудан, әллә абынып ягылган, торалмыйча ята.)* Илле бүре...

**Тагын төрле яктан йөгерешеп килүчеләр һәм күпергә узучылар булырга мөмкин.**

Карт: Кая, карыйм әле.*(Бүреләрне карарга китә.)*

Тавык каручы: *(Тора, тавыгын күтәргән хәлдә, күпергә йөгерә. Тиздән кире килә, кулында тавыгы юк.)* Ишелде, ярты күпер суга китте. Барысы да суга киттеләр. *(Ул картны күрми кала, икенче бер якка уза.)*

Карт: *(Үзалдына сөйләнә, кире килә.)* Нинди бүре ди ул, сарыклар. Үзебезнең сарыклар. Илләләп булыр, анысы дөрес. Ялкын да бетте. Нәрсә яндырдылар икән анда? *(Җиргә утыра.)*

Тавык каручы: *(Кире борылган, Карт янына килә.)* Беттеләр. Барысы да суга киттеләр. Нишлибез, ә... Бабай?

Карт: Нишлибез дип... Яшибез! Китүчеләр артыннан китмибез. Хуҗалык исән, мин хуҗа булырмын... Хуҗа табылыр, тавыгың кая?

Тавык карауучы: Крокодилларга ташладым. Унны салмый ул. Көнгә — бер. Әле кайчакта анысы да булмый. Сары тавык астына үз тавыкларымның йомыркаларын куйдым. Исемемне...

Карт: *(Бүлеп.)* Гүзәл сурәтемне диген.

Тавык карауучы: Гүзәл сурәтемне Танылганнар тактасына үз тавыкларым күтәрде диярга тулы хакым бар.

Карт: Яшәү моңсуланыр, мәзәк кимер иде... Син булмасаң әгәр ул тактада...

Тавык карауучы: *(Сәер һәм серле итеп.)* Тактада түгел. Менә ул мин. Яшәүне моңсуландырмыйбыз аны, ба... ба... ба... Гафу, гафу ит... Әле сине бабай димәсәң дә була.

Карт: *(Тавык карауучының биленә кагылып.)* Ай, рәхмәт төшкерә!

Әтәчләр белгече: *(Әле генә килеп, шулай да Карт белән Тавык карауучыны күпмедер тыңлап, күреп торганнан соң.)* Бәхет сарае янган. Ә сез монда...

Карт: *(Әтәчләр белгечен бүлеп.)* Хәерлегә янсын. Ул бәхет сарае безгә түгел иде. Булган бәхетем сыярлык өем бар.

Әтәчләр белгече: Әтәчләр урамнарга сибелгәннәр. Сары тавыкны эзлиләр. Сез монда... Әллә нишлисез...

Карт: Табарлар. Тырышкан табар, ташка кадак кагар. Без — әллә нишләмибез. Ташка кадак кагабыз.

Тавык карауучы: *(Белгечкә.)* Әйе. Без ташка кадак кагабыз!

Әтәчләр белгече: *(Елмаеп килә. Башта Картның, аннан Тавык карауучының кулын кыса.)* Чын күңелдән котлыйм!

**Кинәт «Тау астында илле бүре» көе башлана. Әтәчләр белгече бер як читкә чигенә. Карт көйгә кушыла.**

Карт: *(Тавык карауучыга җырлый, аннан биеп үк китә.)*

*Бабай дисәң дә ярый ла,*
*абзый дисәң дә ярый.*
*Исән чакта җырлап алсаң,*
*йә биесәң дә ярый.*
*(Кушымта.)*
*Тау астында гына*
*илле сарык икән,*
*бар да түйга суярлык.*

*(Җырга Тавык каручы кушыла, биеп үк китә.)*

*Яшьлек узмый әле,*
*уйда — тузмый әле*
*ак күлмәк тә ак яулык.*
*Юка күлмәк иң өстеннән*
*шуып төшәр шикелле.*
*Шуып төшмәс тә шикелле,*
*төшмәүе дә икеле.*
*(Кушымта.)*

**Әтәчләр белгече янына Ясамның якташы килә. Мондагы күренеш аңа ошап китә.**

Якташ: *(Күңелле кычкырып.)* Монда ни булган? Нишли болар?

Әтәчләр белгече: Ташка кадак кагалар! *(Үзе «Тау астында илле бүре» ритмы җаена кул чабып тора башлый.)*

Якташ: Ташка? Кадак?! *(Кой ритмында кул чаба-чаба, Әтәчләр белгеченнән читкә, икенче бер урынга барып баса.)*

Карт һәм Тавык карауучы *(аларның җырына һәм биюенә Якташ белән Әтәчләр белгече дә кушылып китә)*:

*Ул да ялгыз, бу да ялгыз,*
*парлашсалар икән лә.*
*Мәхәббәтнең карты-яше*
*булмый, — дигән олкәннәр.*
*Тау астында гына*
*илле сарык икән*
*бар да түйга суярлык.*
*Яшьлек узмый әле,*
*уйда — тузмый әле*
*ак күлмәк тә ак яулык.*

*Тамаша тәмам.*

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**1. Бүгенге прозаның кайсы яклары Сезне сөендерә? Соңгы елларда басылган кайсы проза әсәрләрен яратып укыдыгыз? Нинди яңа авторларга аеруча зур өмет баглыйсыз?**

**2. Бүгенге прозаның нинди җитешсезлекләрен күрәсез? Аларның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

**3. Прозабызны үстерү өчен хәзер нәрсәләр эшләргә кирәк дип саныйсыз?**

**Рафаэль СИБАТ:**

**1.** Хәзер чыннан да ябык-ябылган темалар юк. Яз да яз гына! Бер идеология астына басылып яшәү — Рухны үтерә, җанны көйдерә. Чын язучы — иректе кош ул. Әгәр ул кошны идеологик читлеккә япсаң, бетте инде — саф сайравын көтмә. Тагы...

Бүгенге прозабызда миллилек: милли аң, милли җан, милли рух, милли горурлык үзен нык сиздерә башлады. Тарихыбызны чын дөрестән яктырту йөзеннән язылган романнарыбыз бар. Ә «Идел»дәге тарихи хикәяләр конкурсы — асылыбызга кайтуның матур күренеше түгелмени?! Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла, Җәмит Рәхимов, Вахит Имамов, Флүс Латыйфиларның тарихи романнары — урланган үткәнебезне, көлләр астына күмелгән яшәеш хәзинәбезне кире кайтару ич! Шунысын да искәртик: тарихчыларыбызның язганнарын аз белә халык, ә тарихи әдәби әсәрләрне күп укый. Тарих хет шул формада булса да кайта торсын.

Инде менә бөек шәхесләребез турында алар вафатыннан соң, бик озак та сузмыйча, биографик рухтагы романнар язу да әдәбиятыбызга кереп китте. Олуг рәссам Бакый ага Урманченың зур юбилее — тууына 100 ел тулуга ук диярлек — якты истәлек «Бакый» романын укыдык. Без күп вакытта формага — шәхси якка азрак игътибар бирдек һәм бирәбез. Шәхсән үзем «Казан утлары»н кулга алуга, башта андагы шигырь вә хикәяләрне, тәнкыйть мәкаләләрен, аннан соң гына повесть-романнарны, зуррак күләмле әсәрләрне укыйм. Ә менә Кыям Миңлебаевның 3 нче биттә башланган романын күрүгә, иң беренче әсәрнең төзелеше үзенә тартты: башта «Автордан» сүз башын укыдым, аннан «И баб»ны күрдем. Баб үзе үк шәп сүз, русның «баба»сы гына түгел, безнең телдә ул сирәк яңгырый, шунамы сискәндереп, үзенә магнитлады. Монда әле «Күл-Черкен» исеме бар һәм Бакый ага Урманченың 1977—1978 елларда әйткән сүзләре. Кызык бит, үзенә тарта бит — һәм әсәрне рәхәтләнеп укып киттем. Тормыш дөреслегенә хыянәт итмичә, олуг шәхесне гел «агарҭып» кына күрсәтмичә, язган автор бу романын. Тәэсирле итәм дип, вакыт-вакыт сурәтләүдә купшылыкка кереп алса да, роман нигездә уңай тәэсир калдыра. Әлеге әсәрне, беренчеләрдән булып, Гариф Ахунов та «Ватаным Татарстан» газетасында хуплап-мактап чыкты.

Суфиян Поварисовның Галимҗан Ибраһимов турындагы романы да күңелләргә май булып ятты. Мондый әсәрләрдән әдәби кимчелекләр дә эзлисе килми. Бары бөек язучыбыз турында булганы өчен генә дә укыйсың. Яратып укыйсың!

Язучы үзе турында ин дөресен үзе генә әйтә.

Нигәдер бездә автобиографик жанр бик сүлпән? Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗевтән соң автобиографик повесть-романнар язылмый яисә аз языла. Гаять үзенчәлекле әсәрләр ич алар, үзеңне көзгедә күрү генә түгел, ә күрсәтү. Мондый типтагы «чәчмә» укучыны ифрат та кызыксындыра.

Әнә Шәүкәт Галиевның «Хистәлекләр»ен генә алыйк. Кемгә ничектер, шул әсәре белән автор минемчә, шәп шагыйрь булу өстенә, әйбәт кенә прозаик та икәнен күрсәтте.

Ә публицистика? Нигә әдәби-публицистик һәм документаль әсәрләр аз татар прозасында? Язар кешеләр калмадымы әллә? Бар алар, бар! Әнә җаяү йөргәндә дә сигарет урынына кулына каләм-ручка тоткан Гариф Ахунов үзенең Тимерханын кай яктан гына күрсәтмәде инде! Теләсәң — була икән ич...

Бүгенгене бүген язу, бигрәк тә проза өлкәсендә, язучы өчен авыр нәрсә. Аны башта Вакыт, Җан казанында кайнатырга, бары шуннан соң гына сөземтә алырга кирәк. Шәхес культы зәһәрен үзләре татыган Ибраһим Салахов, Аяз Гыйләҗев, Гурий Тавлиннар кызыклы гына әсәрләр яздылар. Монда бигрәк тә Аяз Гыйләҗевнең дөреслеккә хыянәт итмичә: бик үк хурлап та, бик үк мактап та бетермичә язганын тоясың. Һәр илнең төрмәсе — әлеге илнең кичерәйтелгән моделе ул. Әнә шуны ачык аңлап язган автор. «Йөгез, бер дога!» шул хакта.

Ә. Еникиның «Кояш баер алдыннан», А. Хәлимнең «Гомернең ун көне», Р. Мөхәммәдиевнең «Утлы таба өстендә» әсәрләрен тыныч кына укып булмый. Инде шактый олы яшьтәге Зәки Зәйнуллинның иҗат активлыгы сөендерә. Мәгъсүм Хуҗин, Т. Миннуллин, Н. Гыйматдинова, Р. Зәйдулла, Л. Зөлкарнәй, Ләбиб Лерон, Ф. Яхинның проза әсәрләре дә куандыра. Соңгы елларда үзем өчен Тәбриз Мөбарәков, Факил Әмәк, Марат Закир исемнәрен ачтым. Ә Зөлфәт Хәкимнең «Гөнаһ» романын укыганда, Кафка сулышын тойдым, бигрәк тә аның «Заман» әсәре искә килде. Мансур Вәлинең тышкы бизәкләргә бик кызыкмый гына, экзистенциализм рухында язылган повесть, хикәяләрендә эчке кайнарлык белән әдәби әдәп бар. Алдагы елларда үзенчәлекле генә прозаик булып танылган Марсель Гали, Разил Вәли, Рашат Низами, Зиннур Хөсниярлардан сискәндереп җибәрердәй әсәрләр көтәм. «Ирекле тоткыннар» исемле беренче романы белән күңелне яулаган Роберт Айзатуллинга өмет баглыйм. Зарланмыйк: бар алар прозаиклар бездә, бар. Татар әдәбияты, кемдер уйлаганча алай ук саекмаган.

2. Бүгенге татар прозасының җитешсезлекләрен капмаласак:

— *а)* «Җанны дәваламыйча торып, Тәнне сихәтләндереп булмый», — дигән Сократ. Ә язучылар кемнәр? Алар бит Җанны дәвалаучылар, һичьюгы Җан-Рухка нур иңдерергә, якты лык кертергә тырышучылар. Әлбәттә, үз корсагыннан югарырак фикердә тора алмаган адәмнәрнең җанын дәвалау, анда нур балкытырга омтылу — бик авыр эш. Аның өчен, иң беренче, әдипнең үз Җаны нурлы, язганнары җанлы, Рухы якты булырга тиеш, ә бу һәр язучыда да алай түгел;

— *б)* бездә тулы бер Татар Әдәбияты Концепциясе тудырылмаган. Ул, әйе, күпмедер дәрәҗәдә бар, ләкин фәлсәфи нигезләнмәгән. Без әле шәрыкка, әле гарепкә ташланабыз, ә үзебез — кыл уртада. Татар өчен Азия Медиумы белән Европа Прагматлыгыннан торган симбиоз Әдәби Концепция һәм Фәлсәфә кирәк. Аның төп нигез ташлары булып Матурлык һәм Яхшылыкның Гармоник бербөтенлеккә, камиллеккә омтылуы ятарга тиеш;

— *в)* прозабыз артык «реаль-тормышчан». Әйе шул, бернигә дә хәйран калмыйча, сокланмыйча гына язарга яратабыз. Күп вакытта натуралистлар без. Ә Галимҗан Ибраһимов романтизмы кая? Яисә Фатих Әмирханныкы? Әгәр реалистик роман романтик рух белән сугарылмый икән, әсәр авыр сулый, аңа кислород һәм яктылык җитми. Шуңа шактый гына әсәрләребез, Ләбибә Ихсанова әйтмешли: «көн дә күреп торган хәлләргә язучы каләменнән төшкән әйбәт иллюстрация». Бервакыт миңа Мөхәммәт абый Мәһдиев: «Син Әхсән Баяновча язасың», — дигән иде. Кая төрттерде ул? Нәкъ менә Әхсән Баяновның романтик рухлы прозаик булуына, аның «Кама — Камилә»ләренә. Бу язучының барлык шигырьләрен белмәсәм дә, романтизм нык чагылган проза әсәрләренең барысын да укып чыктым һәм күңелем разый калды, чөнки аларда Җан-Рух яктырышы, сирпелеше бар;

— *г)* бүгенге каты телле, коры прозаны укыйсың да:

— Кайда хәзер Галимҗан Ибраһимовлар теле? — дисең. Татар теленең сыгылмалыгын, нәфисләгән, гаять колачлы икәнлеген, байлыгын, бөеклеген язучы әсәре үзе үк сөйләп торырга тиеш түгелме соң? Күбрәк Исхакыйны, М. Галәүне (русчадан татарчага әйләндерелгән булса да), Фатих Әмирханны, Гомәр Бәшировны, Әмирхан Еникины, Мөхәммәт Мәһдиевне, Гариф Ахуновны, Аяз Гыйләҗевне, Марсель Галине, Фәрит Гыйльмине укырга кирәктер бәлки? Ә без бик аз укыйбыз, аз беләбез. Язмаучы язучы белән укымаучы язучыны күз алдына да китерү кыен;

— *д)* соңгы елларда Вакыт Шәрифләре белән дә мөнәсәбәтләр шактый ук начар: укырга да вакыт юк, язарга да вакыт юк! Нинди монда дөнья әдәбиятын карап бару, «Казан утлары», «Идел» һәм башка журналларда чыккан әсәрләрне күзләргә дә вакыт житми. Ул вакыт дигәннәре тормыш-көнкүреш вак-төякләре өчен акча белән бер дәрәҗәдә тотыла һәм әрәм була. Чөнки, өлкән әдибебез Гариф Ахунов әйткәнчә, язучыга, чыннан да, ифрат аз түләнелә, шуңа ул утырып язасы урынга тормыш мәшәкатьләре артыннан чабып йөри.

— *ж)* бүгенге проза шактый «картая төште». Фикерне ачыкласак: яшьләр аз килә әдәбиятка. Факил Әмәк, Равил Сабыр, Заһид Мәхмүди, Марат Закирлар сирәк. Урта буын уртада калган көе йокымсырый, аз иҗат итә, ә картлар элеккечә үк мөнбәрдә! 30—40 һәм 50 яшьлекләргә татар әдәбиятын, аның авыр эш аты — прозаны үз кулларына алырга вакыт түгелме? Дөньяның әдәбият даһилары бу яшьләрдә үзләренең иң бөек әсәрләрен язганнар инде, ә Данте 35 яшь — кешенең иң биек ноктасы дигән. Дөрес, бүгенге татар прозасы корифейлары Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләжев һәм драматург Туфан Миңнуллин «Йә, нәрсә майтарырсыз инде сез бездән башка?» — дип, читтән генә карап торсыннар дигән сүз түгел бу, чын — шәп вә гүзәл сүзне 50 яшьтә дә, йөздә дә әйтергә мөмкин, әмма җиң сызганып хәзер 40—50 яшьлекләр, хәтта 30 ын гына тутырып килүчеләр эшләргә тиеш. Ә алар аз, бик тә аз яза;

— *з)* үзләрен, «писательская братия» дип йөртсәләр дә, көнчел җепләре белән тоташкан үзара рухи туганлык, эчке якынлык аз язучылар арасында. Ә яшерен хөсетлек үзен шактый ук сиздерә. Бу бигрәк тә бер-берләренең язганнарын укымауда һәм укыса да, күрмәмешкә салынуда нык сизелә. Без битараф. Арттан үзеңә ошамаганын хурлап йөрсәк тә, ошаганын күтәреп — мактап чыгарга рухыбызда көч житми, көнчел көзгесе каралган. Гомумән, ихласлылык житми. Шуннан ясалмалык та! Әдәбият язучы дигән ат алу урыны түгел, Пегас — ат бирү мәйданы да.

— *и)* и һәм дә! — Мәһдиев әйтмешли, тагы бер кимчелек: Олуг вә Чын Иҗатчы гомере буе бер төсле генә була. Хамелеонлану, заман җилләрендә флюгер булу — алар өчен ят нәрсә. Алыгыз әдәбият вә сәнгатебезнең даһиларын: Тукай, Урманче, Сәйдәш һәм Илһам Шакирны. Вафат булганнарының рухларын уятмыйча, соңгысына гына тукталыйк: әле ил-телне кысуларның шовинизм прессы астында иң ыңгырашкан алтмышынчы елларда, бигрәк тә 1968 елда, бу Җырчыбыз: «И туган тел», — дип аһәң — оран салмадымыни? «Ил — телне югалтмаска! — дигән чакыру Авазы иде ул, тагы...

— *к)* «Шагыйрьнең мактаучысы булсын!» — дигән В. Белинский, ә соңгы елларда әдәби тәнкыйть сүрәнләнде. Галимҗан Гыйльман, Равил Рахман кебек әдәбиятны нечкә сиземли торган сәләтле тәнкыйтьчеләребез бу эштән читкә тайчанды, ә көчле әдәбиятчыбыз Фәрваз Миңнуллин вакытсыз вафат булды. Рәис Даутов кебек язылган әсәрләр турында үз сүзен төпле генә әйтүче мөхәррир дә пенсиягә китте. Ибраһим Нуруллин, Нил Юзеев кебек күренекле әдәбиятчы галимнәребез дә бу дөньядан бакыена күчте. Ләкин...

Тормыш үз урынында бара, бушлыкны Галәм яратмый, һәр киткәнне килүчеләр алыштыра, шуңа «тәнкыйть юк та, тәнкыйть бетте» дип сөйләнүләр дә 100% хаклыкка туры килми. Бу өлкәдә оригиналь фикерле, мәрхүм олуг язучы Мөхәммәт Мәһдиев тә бик хөрмәт иткән Мансур Вәлине ник сызып ташларга? Ә ифрат акыллы, сабыр вә зыялы, затлы һәм зәвыклы профессор Фоат Галимуллинны кая куябыз? Шул ук Тәлгат Галиуллин, Хатыйп Миңнегулов һәм башка академик белемле галимнәребез исән-сау иҗат итә һәм яза ич. Тәлгат Галиуллинның «Тәүбә» романы аның талантлы прозаик икәнен дә күрсәтте. Шуңа, гомумән, татардагы әдәби процессны, проза үсеше турындагы уй-фикерләрне пессимистик ноталарда тәмамлау гөнаһ булыр иде сыман. Ни генә димә, оптимизмга урын бар гына түгел, ә урын — күп!

3. Прозабызны үстерү өчен хәзер нәрсәләр эшләргә кирәк дигәндә:

— Язарга һәм язарга! Матур һәм шәп әсәрләр язарга кирәк. Күбрәк язарга — Каләм начарланган булса да, үзенең тутыгып утыруын бер дә яратмый, аны гел үткенәйтеп торырга кирәк. Язмаучы язучы — коры исем генә... Һәрхәлдә, чын әдипләр язып яшәүчеләр алар.

*Май, 97.*
*Түбән Шөн.*

*Моннан 5 ел элек — 1992 елда татар халкы Казанның Явыз Иван тарафыннан яулап алынуына 440 ел тулу көнен билгеләп үткән иде. Казан ханлыгының тарихи язмышы Сөембикә язмышы белән үрелеп бара. Быел, 1997 елда Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикәнең вафатына да 440 ел тула. Шушы уңайдан без укучыларыбыз игътибарына филология фәннәре докторы, профессор Фатих Урманче мәкаләсен тәкъдим итәбез.*



**Фатих Урманче**

# СӨЕМБИКӘ БӘЕТЕ

## Сөембикә кайчан туган?

Жаек елгасының көньяк-көнчыгышында киң далалар, иксез-чиксез чүлләр, ярым чүлләр җәелеп ята. Көньякта алар Казакъстанның мәшһүр Бетпак даласына барып тоташа. Күлләр, елгалар монда бик аз. Эссе җәй урталарында алары да корып бетә. Беркайчан да булмагандай, бөтенләй юкка чыгалар. Тик комда гына үсә торган тигәнәкләр. Бик сирәк очрый торган вак-төяк куаклыклар. Ара-тирә дөя, ат көтүләре. Үзәннәрдә, елгачыклар буенда вакытлыча җәйләүгә туктаган нугай авыллары. Ерак түгел казакъ, күчмә үзбәк тирмәләре дә очрар. Бу иксез-чиксез далалар өстәл кебек тигез. Үтә күренмәле зәп-зәңгәр күк. Нәкъ баш өстендә, әллә кайда югарыда, күк түбәндә зур һәм мәрхәмәтсез кояш. Бөтен дөнья, җиһан вә галәм әнә шул чиксез-кырыйсыз далаларга-чүлләргә һәм төпсез күккә сыеп беткәндәй тоела.

Моннан биш йөз еллар элек нугай халкы әнә шул якларда гомер сөрә иде. Чиксез кырлар-чүлләр буйлап алар кайвакыт хәтта Хәрәзем, Үргәнеч вә Бохараларга кадәр барып житәләр. Бигрәк тә җыйнак гәүдәле йөгерек нугай атлары һәм нугай куйлары белән сату итүче сәүдәгәрләр — алыпсатарлар.

Илдә күптән урнашкан тәртип буенча, нугай халкында ханнар булмый. Илдәге иң зур түрә — бәк. Унбишенче йөзнең башында Муса бәкнең улы — Исмәгыйль морза Җаекның көнбатышында хөкем сөрсә, олы улы — Йосыф көнчыгышында морзалык итә.

Нугай урдасының башкаласы Сарайчык та үзенчәлекле язмыш кичерә. Ундүртенче йөз ахырында, 1391 һәм 1395 елларда Аксак Тимер Алтын Урданың Сарай-Бәркә, Хажи Тархан кебек зур калаларын, бик күп авылларын юкка чыгарып, яндырып талап киткәндә, Сарайчык каласы исән-имин кала. Шул ук кала тирәсендәге җәйләүләр, мал-туар, кала-салалар да афәткә тартылмый. Күрәсең, бу очракта Аксак Тимер белән бергә Идел-Җаек урталыгына Нугайдан

чыккан Идегәйнең килүе дә уңай роль уйнагандыр. Шул ук Идегәй нәселеннән булган Йосыф морза гаиләсендә Сөембикә Идел-Җаек киңлекләрендә уналтынчы йөз башында дөньяга килә.

Югарыда куелган «Сөембикә кайчан туган?» дигән сорау күп еллар — гасырлар буена галимнәрне, язучы-шагыйрьләрне кызыксындырып, борчып килә. Аңа җаваплар да төрлечә. Халык бәете бу сорауга бик кыска һәм төгәл җавап бирә: «Мең дә биш йөз унбиштә бу дөньяга килгәнмен». Мәгълүм ки, баш каһарманның туган вә үлгән елларын күрсәтү иң элек жанр традицияләре белән бәйләнгән. Аның тарихи чынбарлыкка туры килмәве дә мөмкин. «Сөембикә бәете»нең барыннан да элек әдәби әсәр булуын да онытмыйк: анда китерелгән тарихи мәгълүматларның дөреслеген ачыклау өчен ышанычлы тарихи документларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Дөрес, Сөембикәнең тормыш юлына караган ышанычлы документлар сакланмаган. Булганнары да урыс елъязмачылары каләме астыннан чыккан. Аларга да чын күңелдән ышанып булмый. Һәрхәлдә, әнә шул чыганаклар нигезендә Сөембикә турында махсус һәм күләмле очерк язган тарихчы Һади Атласи ханбикәнең туган елы да, үлгән елы да билгеле түгел дип, бернинди дә конкрет дата күрсәтми. Гүзәл ханбикә хакында күләмле кыйсса язган Рабит Батулла бу хакта болай ди: «Сөембикә — Нугай әмире Йосыф бәкнең иң сөекле, иң гүзәл, иң акыллы, иң шөһрәтле кызы. 1516 еллар тирәсендә туа...» Бу датаны нинди чыганактан алуы турында язучы бер сүз дә әйтми. Димәк, аны инкарь итеп тә, хуплап та булмый. Тик шуны гына әйтик: язучының «1516 еллар тирәсендә» дигән сүзләренә караганда, ул үзе дә бу мәгълүматка ышанып бетми булса кирәк.

Энциклопедик характердагы галим Ризаэтдин Фәхретдин Сөембикәнең туган елын төгәл — 1519 дип күрсәтә. Хәтта гадәттәгечә «тирәсендә» сүзенә дә мөрәҗәгать итми. Кайбер башка чыганакларда якынча шул ук 1515—1519 еллар күрсәтелә.

## Бәет кай чорга карый?

Мәгълүм ки, бәетләр тарихи яки тормыш-көнкүреш вакыйгалары артыннан ук, ә инде сүз төрле сугышлар, баш күтәрүләр кебек зур вакыйгалар турында барса, шулар белән бер үк вакытта иҗат ителәләр. Бәетләрнең бу әһәмиятле үзенчәлегенә игътибар итеп, Габдулла Тукай болай дигән иде: «Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык. Чү, аз гына бернәрсә «шылт»! иттеме, инде аның тугрысында иртәгә урамга бәетләр чыга. Мәсәлән, Гайнетдин дигән кеше үземе яки кызымы бер гаеп эшләгән икән — бетте инде, урамда бәетен җырлыйлар».

«Сөембикә бәете» турында да Гомәр ага Бәширов язмасында шуңа якын фикер уздырыла: «Шул көнне крипечдин чыгарып, Казанки суына еткәнче Казан музыкантларының уйнап барган моңлы маршы көенә язылган (бу) шигырьләр гүя Сөембикәнең үз агызыннан сөйләнгән кебек тәрҗемәи хәледер».

Шулай да «Сөембикә бәете» XVI гасырның икенче яртысында иҗат ителгән дип кистереп әйтеп булмый. Бәет гүзәл ханбикә вафат булып, берничә гасыр үткәч барлыкка килгән булса кирәк. Ә бәлки ул берничә йөз ел буена, язма рәвештәме яисә күңелдә йөрепме, төрле үзгәрешләр кичергәндер, еллар-гасырлар үткән саен, аның нигезендә яткан тарихи вакыйгалар, фактлар онытыла баргандыр. Бәетнең алдагы юллары нәкъ әнә шул хакта сөйли: «Казаннарга Кырымнан китерде бәне тәкъдирем, Казанның бер яшь ханы Җангали булды ирем».

Сөембикәнең беркайчан да Кырымда булмаганлыгы мәгълүм. Нишләп соң бәет аны Казанга «Кырымнан алып килә»? Нишләп бәет нугай халкын гомумән белми? Күрәсең, моның җитди тарихи сәбәпләре бар. Конкрет тарих вакыйгаларыннан билгеле булганча, Нугай иленең бәге Йосыф, яраткан кызы Казанда ханбикә булуына карамастан, 1551 елда үз кызының иреген саклап калуда да, 1552 елда Мәдһиш Иван Казанга соңгы тапкыр һөҗүм иткәндә дә бу тугандаш илгә ярдәм кулы суза алмый. Аның «барлык тырышлыгы», «изге теләкләре» урыс патшасына «җылак» хатлар, ярлыклар язудан узмый. Хәтта нугай морзаларының кайберсе Явыз Иванның баскынчылык сәясәтен хуплап, хәтта аңа Казанны яулап алырга ярдәм итәргә әзер торулары турында махсус хатлар язалар. Ә инде 1552 елның октябрендә, Казан яулап алынгач, күрәсең, элегрәк, һәрхәлдә — туган-тумачалык, кода-кодагыйлык мөнәсәбәтләре бик тыгыз булган Казан-Нугай арадашлыгы гомумән өзелә, юкка чыга. Бигрәк тә 1554 елдан соң,

Явыз Иван Нугай урдасының күршесе — Хажи Тархан ханлыгын яулап алгач. Шуның белән бергә Казан-Нугай арасында кайчандыр булган якынлык, туганлык гомумән онытыла. Нәтиҗәдә Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикәнең дә нугай кызы булуы хәтердән чыга.

Казан-Кырым мөнәсәбәтләре исә башкачарак юлдан бара. Мәгълүм ки, Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген, азатлыгын яклауда һәм саклауда Кырымнан килгән ханнар Сәхиб Гәрәй, аеруча Сафа Гәрәй, соңгысы һәлак булгач, шулай ук Кырымнан килгән һәм күп еллар буе Хан гвардиясе башында торган Кошчак углан әйтеп бетергесез зур роль уйныйлар. Хәтта Казан Явыз Иван тарафыннан яулап алынгач та, Кырым ханы Дәүләт Гәрәй күп еллар буе Явыз Иван белән житди дипломатик сөйләшүләр алып бара. Аның бердәнбер теләге — Хажи Тархан һәм Казан ханлыгын Рәсәй колониясе хәленнән азат итү була. Кискен дипломатия әһәмиятле нәтиҗәләр бирмәгәч, 1571 елда Дәүләт Гәрәй Мәскәүгә махсус яу чабып, Явыз Иванга Казан белән Хажи Тарханны азат ит, югыйсә синең башыңны бетерәм, дип, Мәскәүнең шактый бистәләрен яндыра, 100 яки 150 мең әсир алып, Кырымга кайтып китә. Дәүләт Гәрәй явыннан коты алынган Мөдһиш Иван, гадәттәгечә, Мәскәүдән качып кына исән кала. Күрәсең, әнә шундый вакыйгалар белән бәйле рәвештә, бәеттә Казан-Кырым мөнәсәбәтләре башкача яктыртылуы бик табигый янгырый.

Тик шуны да истә тотарга кирәк: югарыда әйтелгәннәрнең барысы да «Сөембикә бәете»нең «Татар халык иҗаты» күптомлыгында басылган вариантына карый. Шул ук бәетнең башка версияләрендә мәсьәлә башкачарак һәм «тарихка якынрак» хәл ителә. Әйтик, Г. Бәширов тарафыннан «Сөембикә» журналында бастырылган версиядә бер кушымта кат-кат кабатлана һәм анда Сөембикәнең нугай кызы булуы да берничә тапкыр әйтелә:

Сөембикә атым, нугай затым, кая минем хан дәүләтем,
Сабый чагым, нурлы йөзем, морза кызы булган вакытым.

## Ханбикәнең беренче ире

Югарыда бәеттән китерелгән өзектәге тагын бер игътибарга лаек гыйбарә Сөембикәнең беренче иренә кагыла: аның хакында ханбикә «Казанның бер яшь ханы» ди. Бу сүзләргә игътибар итүебезнең сәбәбе — Җангалинең туган елы хакында төрле карашлар яшәп килә. Һади Атласи сүзләренә караганда, Сөембикәгә өйләнү мәсьәләсен Җангали үзе генә хәл итә алмый. 1533 елда Мәскәүнең бөек кенәзе Василийга махсус илчеләр җибәреп, аңардан рөхсәт ала. Ханның яше турында галим болай ди: «Кайсыбер елъязмаларның сүзләренә караганда, Җангали Казан ханы булганда 15 яшендә иде. Болай булганда аның Сөен-бикәгә өйләнүе 16 яшьләрендә булып, үлгәндә яше 18 дә була». Биредә, минемчә, гаҗәпләнерлек берни дә юк! Беренче тапкыр Казанга хан булганда Сафа Гәрәй белән Шаһгалигә нибары уңөчәр яшь була. Яшь бала-чагаларны Казан тәхетенә утырту ул заманалар өчен гадәти бер хәл булган булырга тиеш. Олы тәхеттә бала-чага ханнар утырганда, Казанның күп санлы түрә-морза-карачылары ни теләсәләр, шуны эшлиләр. Әнә шунда булмадымы икән Казанның ул чорлардагы төп фаҗигасе? Бәлкем Җангалинең хөкемдарлык итүенең нибары ике елдан соң фаҗигале рәвештә өзелүе дә аның яшьлеге, «малайлыгы» белән бәйләнгәндер?! Бик аз ханлык итү дәвамында Җангали берниндн житди эш башкара алмый. Аның ил эчендәге һәм халыкара сәясәте Мәскәү ни кушса шуны эшләүдән ары китми. Заманасы өчен бу дөньяның бердәнбер гүзәле булган япь-яшь Сөембикә сылугә өйләнү дә Җангалигә бернинди бәхет китерми. Беренче тапкыр кияүгә чыкканда Сөембикәгә шулай ук нибары 13—14 яшь була. Әмма шуңа карамастан, ул рухи яктан да, физик яктан да тулысынча өлгергән кыз була. Бу хакта ышанычлы чыганакларга таянып сөйләргә мөмкин. Һәрхәлдә, Һади Атласи, берникадәр ирония белән булса да, түбәндәгеләрне яза: «Сөен-бикәнең Җангалигә баруы «Алманың пешкәнен аю ашар» дигәнгә туры килгән була. Ике елдан соң ул шушы аюдан да коры калды».

Күзәтелә торган бәет тә Җангали белән Сөембикәнең үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсенә берниндн яңалык өстәми. Бәеттә уздырылган бердәнбер фикер — Сөембикә бик яшьли тол кала:

Хан бикәсе булгачдин, ике ел гына торгачдин,
Тол калдым, кайгылы булдым, хан дөнья куйгачдин.

Сөембикә белән Җангали арасында шәхси мәхәббәт түгел, адәм рәтле мөнәсәбәтләр дә булмагач, ил эчендәге тәртип тә юкка чыга башлый. Әнә шул шартларда, хан булса да, җелеге булмаган Җангали юкка чыгарга тиеш иде. Берничә ел элек Мәскәү кенәзеннән үзләре чакыртып китергән Булат бәк Ширин белән ханбикә Гәүһәршад бу эшне үзләре башкарып чыгалар. Тарихчы Р. Әмирхан: «Җан Гали 1535 елның 25 сентябрендә үтерелә. Ләкин бу үтерүнең тәфсиле, шартлары, урыны турында чыганаклар бик каршылыклы мәгълүматлар бирәләр»,— дип язса да, хәзер тарих фәнендә Җангали Казансу буенда үтерелә дигән караш хөкем сөрә.

## Сафа Гәрәй белән Сөембикә

Җангали хан үтерелгәннән соң ханлыкның да, Сөембикәнең дә хәле авыраеп китә. Казанның түрә-морзалары, бигрәк тә Булат бәк Ширин белән Гәүһәршад, күрәсең, моның шулай буласын алдан сизеп, Җангалине һәлак иткәнчегә кадәр үк Кырымнан Сафа Гәрәйне чакыртып куйган булалар. Бу хакта бәеттә тик бер генә җөмлә белән әйтелә: «Кырымлык Сафа Гәрәй Казанга хан булды». Казан тәхетен икенче тапкыр Сафа Гәрәй 1536 елда яулап ала. Мәскәү яклы түрә-морзаларның байтагы Мәскәү ягына качалар.

Сафа Гәрәйнең Сөембикәгә өйләнүенә һәм Сөембикә өчен Казанның яңа ханы белән ханбикә арасындагы мөнәсәбәтләргә бәет тә кыскача тукталып үтә: «Өч хатыны булса да, дүртенчегә мине алды». Дөрес, Сафа Гәрәйнең Сөембикәгә кадәр дүрт хатыны була. Шуларның берсе урыс нәселеннән булып, бик иртә, күрәсең, туган иленнән аерылу хәсрәтеннән үлеп итә.

Бәет нигездә Сөембикәнең шәхси тормышы вә шәхси кичерешләре белән сугарылган булса да, илдәге иҗтимагый хәлләрне, зур тарихи вакыйгаларны читләтеп үтми. Бу еллардагы Казанның хәле турында бәет шулай ук кыска, әмма тарихи вакыйгаларның асылын аңлардай мәгълүматлар бирә: «Дөньялары хафалы, заманалар буталды, Казанга күрше илләрдән падишалар күз салды». «Күрше илләр» дигәндә биредә бер генә ил турында сүз бара булырга тиеш: сүз, һичшиксез, Мәскәү кенәзлеге һәм аның агрессив-колониаль сәясәте хакында бара. Бу хакта Риза Фәхретдин болай дип яза: «Сафа Гәрәй бу мәртәбәсендә Казанга кереп хан булганнан соң, Мәскәү тарафдарлары булган мөселманнар Мәскәүгә: «Гәүһәршад бикә Ибраһим хан кызы белән Булат мирза Мәскәү тарафындадыр, әгәр дә Мәскәүдән Шаһ Гали җибәрелер булса, аны кабул итәрләр вә Сафа Гәрәй ханны урыныннан куарлар, Мәскәү идарәсенә буйсынырлар»,— дип яздылар».

Чыннан да, 1536 елда, Сафа Гәрәй яңадан тәхеткә утыргач та, Мәскәү белән Казан арасында сугышлар, төгәлрәк әйткәндә, вак-төяк бәрелешләр әледән-әле кабатланып тора. Әнә шул вакыйгаларны гомумиләштереп, бәет болай ди: «Сафа Гәрәй вакытында бик күп булды сугышлар, һәркайдан яу килгәчтин авыр булды сулышлар». Әйтелгәнчә, Казанга каршы яу XVI гасыр урталарында тик бер генә яктан — Мәскәү кенәзлегеннән килә. Тик алар төрле вакытта төрле юллардан — Нижгар, Пермь, Нократ якларыннан киләләр. Бәеттәге «һәркайдан яу килгәчтин» сүзләре шуны күрсәтә булырга тиеш.

Шул ук елларда Мәскәү Казанга каршы зур сугышка әзерләнә: сугышны бер генә юнәлештә алып бару өчен, Литва белән биш елга солых килешүе төзи. Мәскәүнең бу нияте хакында хәбәрдар булган Кырым ханы, Сафа Гәрәйнең абыйсы Сәхиб Гәрәй Казан яклы булып, әгәр Мәскәү Казанга каршы күтәрелсә, урыс җирләрен тар-мар итәчәген әйтеп, бөек кенәздән тыныч кына утыруын таләп итә. Бәлкем Кырым ханының әнә шундый җитди кисәтүе нәтиҗәсендәдер, 1538—1540 елларда Мәскәү белән Казан арасында сугыш-бәрелеш булмый.

Бу тынычлыкны Казан түрә-морзалары бозалар. 1541 елда Мәскәүдә Казаннан шатлыклы хәбәр алалар: хөкүмәт башында торган Булат морза Мәскәүгә Чабыкеев җитәкчелегендә биш кешедән торган илчелек җибәрә һәм түбәндәгеләрне хәбәр итә: Мәскәүнең бөек кенәзе Сафа Гәрәйгә каршы үзенең гаскәрен һәм воеводаларын җибәрсен, ә алар — Казан морзалары Сафа Гәрәйне юк итәчәкләр яки кулга алып, воеводаларга тапшырачаклар. Һади Атласи язуынча, 1541 елда Казанда ханга каршы астыртын кузгалыш башлана. Коткычыларның башында Булат бәк тора. Мәскәү Казанга каршы сугышка әзерләнә, Казанга яу чабу һәм кенәзлекнең көньяк чикләрен Кырым гаскәреннән саклау өчен гаскәр туплый башлый. Бу вакыйгалар хакында Казан ханы шунда ук абыйсы Сәхиб Гәрәйгә хәбәр сала. Шул ук вакытта Мәскәүдәге кенәз И. Бельский хөкүмәте җиңелә һәм 1542 елда сугыш булмый кала. Мәскәү белән солых килешүе төзелә. 1545 елга кадәр Мәскәү белән Казан арасында тыныч мөнәсәбәтләр урнаша.

Тик 1545 елның апрелендә ни өчендер Мәскәү өч яктан Казанга каршы яу йөри. Бу куркыныч еллардагы вакыйгаларның бер үзенчәлеге — Мәскәү явын Казанга еш кына ханлыкның түрә-морзалары үзләре чакырып китерәләр һәм Сафа Гәрәйгә каршы баш күтәрәләр. 1546 елда хан Кырымга качып китәргә мәҗбүр була. Башта ул Хаҗи Тарханнан алынган гаскәр ярдәмендә Казанга бәреп кермәкче була. Әмма Казан морзалары Сафа Гәрәйгә буйсынудан баш тарталар. Хан, теләпме-теләмичәме, Нугай морзасы, каенатасы Йосыф янына бара. Хан белән Йосыф морза мөнәсәбәтләре яхшыдан булмый. Шулай да морза ханның үтенечен кире какмый, углы Юныс кул астында нугай явы җибәреп, Казанны алышырга булыша.

Сафа Гәрәй Казанны алырга киткәндә, Сөембикә үзенең Нугай йортында кала. Ул тик 1547 елның җәендә, Сафа Гәрәй өченче тапкыр Казанга хан булып килгәч кенә кайта. Шул ук 1547 елда Сафа Гәрәй белән Сөембикәнең беренче һәм бердәнбер уллары дөньяга килеп, аңа Үтәмеш Гәрәй дип исем кушалар.

Сафа Гәрәй хан дәверендә Мәскәүнең бердәнбер теләге — Казан ханлыгын буйсындыру була. Сафа Гәрәй моңа кискен каршы торып, Мәскәүгә буйсынуны күз алдына да китерә алмый һәм, баһадир хан буларак, Казанның милли һәм дини мөстәкыйльлеген тулысынча саклап кала.

Бәет бу хан чорындагы катлаулы вакыйгаларны да читләтеп үтми:

> Үндүрт ел гомерем үтте Сафа Гәрәй хан белән,
> Казан шәһәре күңелсез юлда түккән кан белән.
> Шәһәр тышында сугыш, эчендә тулган афәт,
> Шул тынгысыз вакытта Сафа Гәрәем вафат.

Халык бәетенең бу сүзләре тарихи чынбарлыкка тулысынча туры килә. Аларны, әйтик, Риза Фәхретдин сүзләре белән чагыштырып карарга мөмкин: «Сафа Гәрәй Казан шәһәрендә үзенең сараенда 1549 елның март (сәфәр) аенда вафат булып, хатыны Сөен белән ике яшендә булган угылы Үтәмеш Гәрәй калды... Соңгы мәртәбә ханлыгы 14 ел микъдарында булды. Шулай итеп, Казанда ханлыгы тәхминән, ягъни якынча 22 ел (24 ел — Ф. У.) булып, үлгән вакытта 40 (42 — Ф. У.) яшендә булмыштыр». Галимнең бу сүзләренә искәрмә биреп, Р. Әмирхан түбәндәгеләрне өсти: «XVII йөз Кырым тарихчысы Мостафа әҗ-Җәннәби аның турында: «Сафа Гәрәй хан иң бөек һәм куәтле падишаларның берсе булды. Ул 27 ел дәвамында хөкүмәт сөрде. Аның заманында дәүләт иминлеге яшәде, биләмәләре моның җинүчән коралы химаясендә чәчәк аттылар»,— дип язды.

Сафа Гәрәйнең үлеме турында бәеттә тик бер генә җөмлә белән әйтелә. Бәлки бәетне иҗат итүчеләргә бу фаҗиганең чын сәбәпләре мәгълүм булмагандыр. Кайбер чыганакларның мәгълүматлары фәндә киң таралган булса да, житди ышаныч уятмый. Р. Әмирхан бу хакта болай ди: «Урыс елъязмасында язылганча, исерек килеш битен-башын юганда юынгыч корпусына башы белән бәрелеп үлүе бер дә ышаныч уятмый». Бу — чыннан да шулай: Сафа Гәрәйнең дошманнары Казанның үзендә дә, Казаннан тыш та житәрлек дәрәҗәдә күп була. Әгәр Җангали хан үзенең булдыксызлыгы белән үзенә дошманнар җыйса, Сафа Гәрәй киресенчә — үзенең кыюлыгы, батырлыгы, сугышчан баһадирлыгы нәтиҗәсендә шул ук язмышка дучар була. Сафа Гәрәй үзенең дошманнарын никадәр аяусыз рәвештә җәзага тарткан булса, Казанның Мәскәү яклы түрә-морзалары да аның белән шулай ук эш иткәннәр булырга тиеш. Һәрхәлдә, Сафа Гәрәй үзенең дошманнары тарафыннан үтерелә дигән фикер киң таралган.

Сафа Гәрәй һәлак булгач, гадәттәгечә, Казан хуҗасыз кала. Бу көтелмәгән бәхетсезлек Сөембикә өчен бигрәк тә авыр була. Хәзер инде Сафа Гәрәйнең Казандагы һәм Мәскәүдәге күп санлы дошманнары, һичшиксез, үзенең яраткан ире белән бер караштa, бер үк теләкләрдә булган Сөембикәнең дошманнарына әвереләләр. Бәеттә вакыйгаларның гомуми барышы ярыйсы ук яхшы билгеләнә. Ханбикә үзен ике ут арасында калгандай хис итә: бер якта Мәскәүдәге Мәдһиш Иван, икенче якта Казанның шул ук Мәскәү яклы түрә-морзалары. Бәеттә бу хакта ачыктан-ачык әйтелә:

> Мәскәү ханы Казанны алмак була үзенә,
> Казанлылар фетнә ача, карамыйлар сүземә.

Әмма Сөембикә, житлеккән сәясәтче вә дипломат буларак, югалып калмый. Мәрхүм Сафа Гәрәйнең васыяте буенча, Казан тәхетенә аның улы Үтәмеш Гәрәй утыртыла. Сөембикә үзе сабый ханның житәкчесе, тәрбиячесе итеп билгеләнә.

Төрле күтәрелешләр, үзара сугышлар килеп чыкмасын дип, ханбикә яңа хөкүмәт төзи. Аның җитәкчесе итеп Хан гвардиясе башлыгы Кошчак углан билгеләнә. Ләкин Сөембикәнең бу уңышлы адымнарына карамастан, ханлыктагы үзара ызгыш-талаш, хакимият өчен көрәш туктамый. Бәет бу хакта да әйтеп үтә:

Башкара алмыйм эшемне, тыңлата алмыйм кешене,
Һәркайсы үзе белгән булып, йөртteләр уртак эшне.

## Ил башында — Сөембикә

Ил эчендә тәхет өчен үзара сугышны тыеп калып булса да, ызгыш-талаш, Сөембикәгә каршы көрәш дәвам итә. Явыз Иван да үзенең Казан ханлыгын тулысынча яулап алуга юнәлтелгән элеккеге сәясәтен көчәйтеп җибәрә. Мәскәү патшасының төп ниятеннән хәбәрдар булган Сөембикә алдагы зур сугышка әзерлек чаралары күрә. Казанның хәле авыр булуы турында ул атасы, 1549 елдан Нугай Урдасының илбиләүчесе — бәге булган Йосыфка да, Кырымга да хәбәр җибәреп, алардан ярдәм сораган булырга тиеш. Әмма бу илчеләр Кырымга да, Нугайга да барып җитмәгән булса кирәк. Чөнки ул елларда Казан ханлыгы чикләре Мәскәү яклы урыс-татар-казаклардан оештырылган хәрби дружиналар күзәтүе астында була.

Бирелә аеруча ассызыклап түбәндәгеләрне әйтергә кирәк: кызы Сөембикәнең хәле фаҗигале бер төс алган 1549 елда Йосыф бәк үзен бик сәер тота. Һади Атласи бу хакта болай ди: «Сафа Гәрәй ханның үлүе бәккә ишетелгәч, ул, Сөен-бикәне Шаехгалигә бирмәкче булды. 1549 елның җәендә Иванга ярлык язып, Сөен-бикәне Шаехгалигә бирергә теләвен белдерде». Әгәр дә хәл чыннан да шулай гына булса иде! Йосыф бәк Явыз Иванга ханлыктан Мәскәүгә качкан түрә-морзаларны һәм аларның хәрби көчләрен Казанга каршы сугышта файдаланырга киңәш бирә.

Уйларга кирәк, бу мәсьәләне хәл иткәндә, Йосыф бәк үзенең кайчандыр өзелеп яраткан кызы ихтыяры белән берничек тә хисаплашмый. Югыйсә әле генә өлгереп җиткән гөлчәчәктәй сылу Сөембикәнең инде картаеп килгән һәм киребеткән сатлык Шаһгалигә кияүгә чыгарга ризалык бирмәячәге көн кебек ачык иде бит! Күрәсең, Йосыф бәк үзсүзле һәм кыю Сафа Гәрәй һәлак булгач, Казанны үз йогынтысы астында калдырырга тырышкан. Һәрхәлдә, Йосыф бәкнең әлеге Явыз Иванга язган хаты белән танышкач, күңелдә бик авыр хис кала.

Әнә шундый шартларда Сөембикәнең хәле чыннан да фаҗигале була шул. Бу хакта халык бәете ярыйсы ук тәфсилләп сөйли:

Морзаларга мин әйттем, Мәскәү белән белешик,
Һичбер җәбер итмәсә, буйсыныйк та килешик.
Тыныч торсак, күп еллар каннарыбыз түгелмәс,
Мәскәү белән сәүдә кылсак, дәүләтебез кимемәс.

Бәеттәге бу сүзләрнең барысы да тарихи чыганаклар белән раслана дип әйтер идек, тик түбәндәгеләре генә шик уята: «Һичбер җәбер итмәсә». Беренчедән, Сафа Гәрәй кебек баһадир хан һәлак булгач, Мәскәү берничек тә Казанны «җәберләми» тора алмаячак иде. Мәскәү, гомумән, беркайчан да кемне дә булса җәберләми тора алмый: бу аның бик борынгыдан килгән һәм берничек тә дәвалауга бирелми торган «тарихи чире»! Аннан соң, бирелә сүз гади җәберләү, кыерсыту, кимсетү турында, ахыр чиктә — хәтта протекторат урнаштыру турында да бармый: сүз Мәскәү тарафыннан Казанны хәрби көч белән тулысынча тар-мар итү, яулап алу һәм ханлыкның башкаласын — Казанны, һичшиксез, урыс шәһәренә әйләндерү турында бара.

Икенчедән, бәеттәге Сөембикә исеменнән әйттерелгән «буйсыныйк та килешик» сүзләре дә шактый зур шик уята. Балачактан ук тирән милли рухта тәрбияләнгән Сөембикә, сүз дә юк, беркайчан да Мәскәүгә буйсынырга ризалык бирмәс иде: бу аның ирек сөючән холкына, табигатенә, милли тойгыларына берничек тә туры килми.

Хәер, ил башында Сөембикә ханбикә торып, аның хөкүмәтен Кошчак угландай батыр җитәкләгәндә, Мәскәүгә буйсыну мөмкин түгел иде! Шулай булгач, бәетнен башка сүзләренә игътибар итеп карыйк. Алары тарихи чынбарлыкка туры килә кебек. Явыз Иванның баскынчылык сәясәтен күреп һәм белеп торган Сөембикә хөкүмәте солых килешүе төзү өчен Мәскәүгә илчелек җибәреп карый. Бу хакта Атласи түбәндәгеләрне яза: «Нугай мирзалары Иванга сатылып тор-

ганы хәлдә, Казан зарарына эш итеп торды. Сөен-бикә Иванны ни чаклы яратмаса да, шулай ук аның илә барышлыкта булуны чын күңеленнән теләмәсә дә. 1549 елның 6 июлендә улы Үтәмеш Гәрәй исеменнән Бахшанда исемле кешене Мәскәүгә җибәреп, Иван илә барышлыкта булырга теләген белдерде». Әмма Явыз Иванның хәзергә бердәнбер нияте — тиз арада Казанга яу чабып, аны буйсындыру була. Шуна күрә ул Сөембикә илчелегенә, Атласи әйтүенчә, болай дип җавап бирә: «Безнең илә барышлыкта булырга теләсә, яхшы илчеләр җибәрсен!» диде. Аның болай диюе күз буявы гына булып, ул Казан өстенә барырга уйлап куйган иде». Чыннан да, нибары берничә ай үткәч, Явыз Иван зур гаскәр белән Казанга каршы яуга чыга. Бу вакыйгалар турында да бәеттә шактый тәфсилле сөйләнә:

> Мәскәү әйтте: сугышмагыз, мин Казанны алырмын,
> Рәнҗемәгез, ахырында яхшы ук җәфа салырмын.
> Шуны ишеткәч, Кырымга китәргә дә уйладым,
> Күрәчәкләр булганга, кабул түгел теләгем.
> Караштылар морзалар, Мәскәү сүзен алмыйлар,
> Каршылыкны мәскәүләләр миннән диеп аңлыйлар.

Мәскәүлеләр чыннан да Казанның тышкы сәясәте башында тик Сөембикә генә тора дип уйлаганнардыр. Алар ялгышмаган булса кирәк. Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алырга ашкынуы Казан ханлыгына гына түгел, Кырым ханлыгына да, Нугай урдасына да каршы юнәлтелгән иде. Моны Кырым белән Казан аңласалар да, нугай морзалары аларга бик үк колак салмый. Төрки-татар дөньясының бу еллардагы төп фаҗигасе дә шунда.

Сөембикәнең хәле бик авыр булуын акрынлап Йосыф бәк тә аңлый башлый һәм Явыз Иванга карата сәясәтен үзгәртмәкче була. 1549 елның октябрендә ул Иванга тагын бер ярлык җибәрә. Анда мондый сүзләр бар: «Хәзерендә минем кызым Казанда, минем ыругларым да анда. Мин Казанга сезнең илә килешергә боерырмын, мин сезне килештерермен. Инде сезнең илә килешергә теләмиләр икән, ул чагында җәй көне син кырдан, мин бу яктан барырмын. Минем өчен син аларны хәзерендә тар-мар итмә. Мин сине Казан илә килештерермен. Сезгә түләк түләргә боерырмын». Бу сүзләрне укыгач та: «Үз хөкемдарын да тыңламаган Казан морзалары, ай-һай, нугай бәге сүзенә колак салырмы икән?» — дигән нигезле сорау туа.

1551 елның кышында Сөембикә Мәскәүгә солых килешүе төзү өчен улы Үтәмеш Гәрәй исеменнән тагын бер илчелек җибәрә. Әмма Сөембикәнең дә, Йосыф бәкнең дә Явыз Иванга җибәрелгән хат-ярлыкларының һәм илчелекләренең Казан өчен дә, Нугай өчен дә житди нәтиҗәсе булмый. Киребеткән Мөдһиш Иван Казан ханлыгы җирендә Зөя каласын төзергә дигән карарга килә һәм ныклап эшкә керешә.

Мәскәү белән сәяси мөнәсәбәтләр әнә шулай аеруча кискенләшкән бер чорда Казанның Мәскәү яклы морзалары Кошчак угланга, дөресрәге, Сөембикә хөкүмәтенә каршы күтәрелеш оештыралар. Үзенең 300 гаскәре белән Кошчак углан Казаннан чыгып качарга мәҗбүр була. Юлда урыс-татар казакларыннан торган зур, көчле дружинадан җиңелеп, исән калган 46 кеше, шулар арасында Кошчак углан үзе дә, Мәскәүгә юнәлтелә һәм шунда, Явыз Иванга һәм христиан диненә хезмәт итүдән кискен баш тарткач, җәзага тартыла.

Казанда Мәскәү яклы морзаларның башбаштаклыгы шул дәрәҗәгә җитә ки, алар ил башында торган Сөембикә белән ифрат тупас сөйләшеп, аның алдында төрле шартлар куя башлыйлар. Атласи язуынча, Казанның олуглары башта Сөембикә янына килеп, аңа түбәндәгеләрне сөйлиләр: бикә, без хәзер ни кылырга да белмибез; синең һәм безнең үз өебездә хуҗа булуның чигенә җиттек бугай. Безнең үз җиребездә кала салып, зур туплы гаскәр белән безгә каршы сугышырга җыенган урысларга без ничек каршы торыйк? Әнә шундый шартларда калгач, безгә хәзер Шаһгали янына барып, аңардан гафу үтенергә, безгә падишаһ булып килергә, сине үзенә хатынлыкка алырга ризалык бирүен үтенергә тиешбез. Атласи сүзләрен түбәндәгечә дәвам итә: «Бу сүзнең агышына караганда, аны сөйләүче кешеләр Казан олугларының Сөен-бикә яклылары булып, болар Сөенбикәне Шәехгалигә бирмәкче, шулай итеп Казан халкын тынычландырмакчы булалар. Кайсыбер елъязмаларның сүзләренә караганда, Сөен-бикә үзе дә тышкы яктан риза булды. Казан халкының күбрәге исә Сөен-бикә илә Үтәмеш Гәрәйне Иван кулына тапшыру уенда иде».

Ләкин Сөембикәнең һәм Казан халкының ханны һәм аның васыясен дошман кулына биреп җибәрергә риза булуын берничек тә күз алдына китереп булмый. Безнең бу шикне халык бәете дә раслый:

Мәскәү соңгы солыхны башкаларга яд кыйлган,
Мине Мәскәүгә озатуны солыхка бер шарт кыйлган.
Казандагы түрәләр солыхка кул куйганнар,
Мине Мәскәүгә озатып, тыныч тормак булганнар.

Чынлыкта исә вакыйгалар урыс елъязмаларындагыча һәм Атласи язганча түгел, бераз башка юлдан китә. Моның төп сәбәпләреннән берсе — Кошчак угланның Казаннан китүе. Бу трагик вакыйга ике төркемнең, Мәскәү һәм Кырым тарафдарларының көрәше нәтиҗәсе иде. Хәзер инде ханлык башына Сөембикәнең дошманнарыннан торган хөкүмәт килә. Аның җитәкчеләре: Ходайкол углан һәм Нургали Ширин морза — Сөембикәнең дошманы булган Булат бәк Ширин улы. Бу кешеләр солых шартлары турында Сөембикә белән киңәшеп торганнардыр дип уйлау — беркатлылык булыр иде.

Шулай да яңа хөкүмәт ханлыкны урыс баскынчыларыннан ничек кенә булса да коткарып калырга тырыша кебек. Шунда ук Зөя каласына Казанның ул еллардагы сәете Колшәриф җитәкчелегендә һәм Төмән морзасы Бибарс Растов белән илчелек китә. Илчелек түбәндәге шартларга риза була: Казан морзалары хан тәхетендә утырган Үтәмеш Гәрәй белән Сөембикәне Мәскәүгә «шәһрәтле тоткынлыкка озаталар»; Казанда булган урыс әсирләренең барысын да берсүзсез азат итәләр; шулай ук кырымлыларның һәммәсен Мәскәү патшасына тапшыралар. Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәйне тоткынлыкка алып китү өчен Казанга кенәз Петр Серебряный килә. Аның янында зур гаскәре була. Әйтерсең, сүз бер хатын-кыз түгел, зур һәм ныгытылган кирмәнне хәрби көч белән яулап алу турында бара! Бәет бу хакта да тарихи вакыйгаларга тәңгәл мәгълүматлар бирә:

Солыхтан соң илче килде мине Мәскәүгә алырга,
Дәүләтемнән аерып, горбәт[1]леккә салырга.
Нидер чара тәкъдиргә, юктыр янда һич кешем,
Алындым мин хәбескә, мөшкел булды һәр эшем.

## Үтәмеш Гәрәй язмышы

Сөембикәне Казаннан алып китү турында Р. Фәхретдин түбәндәгеләрне яза: «Кенәз Оболенский Иделдә көймәсе белән көтеп торадыр иде. Сөен Бикәне, Үтәмеш Гәрәй вә барлык иптәшләрен көймәсенә йөкләп, Мәскәүгә алып китте». Тарихтан билгеле булганча, Сөембикә утырган көймәне Мәскәүгә кадәр шактый зур гаскәр озата бара: урыслар бер нәрсәдән куркалар — юлда Сөембикәне әсирлектән коткару өчен кузгалган Казан, Нугай яисә Кырым гаскәрләре белән бәрелеш, сугыш булуы мөмкин... Кызганычка каршы, төрки илләрдән ни Казан, ни Нугай, ни Кырым хөкемдарлары, күрәсең, бу хакта уйлап та карамаганнар! Ярый, Казан морзалары үзләре саттылар ди ханбикәне! Ә кайда булды икән бу чакларда Сөембикәнең сөекле атасы, илбиләүче нугай бәге Йосыф яисә аның уллары, Сөембикәнең агай-энеләре?! Берни дә уйламадылармы икәнни алар үзләренең туганнарының фаҗигале язмышы хакында?

1551 елның 12 августында Сөембикәне һәм Үтәмеш Гәрәйне Зөядән Мәскәүгә алып китәләр. Ханбикәне Мәскәүгә алып килгәч тә, бәет мәгълүматларына караганда, Казан һәм Зөядәге хәл кабатлана:

Кызлар мәйданы дигән бер урынга илттеләр,
Бераз карап торгачтын безне йортка керттеләр.
Кергән йортка каравыл куйдылар бер ун кеше,
Чыгармыйлар, йөртмиләр һәм кертмиләр бер кеше.

Казанның соңгы ханбикәсенең Мәскәүгә әсир буларак китерелүе турындагы хәбәрләр, еш кына төрле риваять-легенда формасын алып, Мәскәүдә, бигрәк тә идарәче даирәләрдә таралган булырга тиеш. Нәтиҗәдә урыс патшасы сараенда бик күп халык җыелган булуы табигый. Бәеттә бу хакта да бер-ике сүз белән әйтелә. Чөнки анда сүз җитди вакыйгалар, ханбикәнең киләчәк язмышы турында бара:

Падишаһ та шунда үзе, миңа әйтә бер сүзне,
«Балаң монда асралыр, иргә бирәм мин сезне».
Диеп шунда баламны кулымнан да алдылар.

---

[1] *Горбәтлек — читтә йөрү; хибес, хәбәс — кулга алу, тоткын итү.*

Әсирлектән янган идем, тагын утка салдылар.

Ишеттем мин, баламны поплар алганнар диеп,
Гакылы да юк сабыйны диннән чыгаралар дип.

Бәлкем мондый хәбәрләрне Сөембикә күптән көткәндер. Әмма әлеге катгый, коточкыч сүзләрне патшаның үз авызыннан ишетү — көннәр, атналар буе дәвам итеп килгән фаҗигане, кайгы-хәсрәтнең иң югары, иң куркыныч ноктасы була. Урыс хөкемдарлары өчен исә бу гадәти сәясәтнең бер чагылышы гына булгандыр: гадәттә алар татар-төрки илләреннән тоткынлыкка эләккән угланнарны, ханзадәләрне үзләренчә — урысча тәрбияләргә тырышканнар. Моның өчен алар ханзадәләрдә үзенең туган иленә, халкына, теленә нәфрәт тәрбияләү максаты куялар. Шул ук вакытта әлеге угланнарда урыс иленә, теленә мәхәббәт тәрбияләү шулай ук җитди бурыч дип хисаплана. Шулай да әлеге ханзадә-угланнарны иленнән һәм халкыннан биздерүнең иң ышанычлы һәм кырыс юлы — аларны көчләп чукындыру, диненнән аеру. Сабый Үтәмеш Гәрәйне дә шундый ук язмыш көтә. Аны биредәге бердәнбер якын кешесе булган әнисеннән аерып, чукындыру турында да төрле мәгълүматлар бар. Һади Атласи бу хакта түбәндәгеләрне яза: «Аның динен алыштыручы митрополит Макарий, чукындыру атасы Савва Крутицкий исемле епископ иде. Макарий Үтәмеш Гәрәйнең динен алмаштырганнан соңра олуг князь Иван янына җибәрде. Иван анарга үзенең сараенда торырга боерып, аны укырга-язарга өйрәтү өчен бер кеше билгеләде». Ярым-ялган урыс елъязмаларында гадәттә Үтәмеш Гәрәйнең динен үз теләге белән алмаштыруы турында языла. Бу уңайдан С. Алишев бик хаклы рәвештә: «5 яшьлек баланың «үз теләген» алу авыр булмагандыр, әлбәттә»,— дип яза.

Ниндидер юл белән тоткынлыкка алып кителгән төрки-татар углан — ханзадәләрен чукындыруның бик зур сәяси мәгънәсе дә була: динен, милләтен алыштырган ханзадә киләчәктә берничек тә үзенең мөселман илендә хан тәхетенә дәгъва кыла алмый! Моны урыс патшалары бик яхшы беләләр. Шуңа күрә кулга эләккән хан-ханзадәләрне көчләп чукындыру — Мәскәү сәясәтенең җитди бер юнәлеше була.

Шаһгалинең килбәте, дөресрәге — килбәтсезлеге хакында шактый тулы мәгълүматлар сакланып калган. Әнә шундый килбәтсез, картаеп каткан бер адәм актыгын Сөембикә, хәтта теләсә дә, ярата алмаган булыр иде. Халык бәетендә бу хакта күп сөйләнми: ханбикәнең Шаһгалигә мөнәсәбәтен, тирән нәфрәтен ике юллы, әмма зур эчтәлеккә ия булган өзектә генә әйтеп бирә:

Шул ук елны мине дә падиша бирде бер ханга,
Касыймдагы Шаһгали — Казанга дошман җанга.

Ундүрт ел буена Казанда яраткан ире Сафа Гәрәй белән бәхетле тормыш кичергән, шул елларда башкаланы, аның акыллы түрә-морзаларын гына түгел, гади халыкны да чын күңелдән яраткан гүзәл ханбикә «Казанга дошман җанны» яратыр иде дип уйлап булмый...

## Моңсу язмыш истәлеге

Казан һәм Сафа Гәрәй кабере белән саубуллашканда Сөембикә башкала халкына үзенең җылаулары белән мөрәҗәгать итә. Әнә шул җылауларда, башкалары белән бергә, ифрат та әһәмиятле бер фикер әйтелә: ил башында торган ханбикәне тоткынлыкка алып китү — ул барыннан да элек ханлыкның киләчәктәге фаҗигале язмышы символы. Чын тарихта шулай булып чыга да! Дөрес, Казан ханлыгының соңгы көннәрендә Сөембикә инде еракта — Мәскәүдә тоткынлыкта була. Әмма әлеге вакыйгалардан ул һәрвакыт хәбәрдар булып тора. Шулай булгач, алар бәеттә дә билгеле бер чагылыш таба:

Мине алгач, сугышка әмер булды барырга,
Мәскәүлеләр белән бергә Казанны һәм алырга.

Шаһгалиләр барганнар, Казанны да алганнар,
Мине саткан морзаларның башын җиргә салганнар.

Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәйне урысларга сату-сатмау турында бездә шактый язылды. Тик бу очракта Сөембикәнең үзе дә, бәет авторлары да сүзне

тик «сату» турында гына алып баралар. Димәк, аны махсус сатмаган очракта да коткарып калырга мөмкин булган дип уйлый Сөембикә һәм хәтта бәет авторлары да. Нинди дә башка шартларда, әйтик, Казанның дошманнары билгеле бер әхлакый, һич югы — дипломатия таләпләренә таянган очракта, Сөембикәне «сатмау» һәм мәсьәләне башкача хәл итү бәлкем мөмкин дә булгандыр. Әмма моның өчен оешып килгән Рәсәй империясенең тирә-ягындагы ил-халыкларны үзенә тиң дип тануы кирәк булыр иде. Тик Рәсәй моңа бара алмый. Бу — Рәсәйнең үзенә генә хас сыйфат түгел: империя төзү юлына баскан сәяси һәм хәрби юлбашчылар бер нәрсәне гадәттә бик яхшы аңлыйлар — бер илдән, бу очракта үзеннән туган иленнән генә империя төзеп булмый. Империя төзү өчен баскынчылык, вәхшилек, билгеле бер дәрәҗәдә кыргыйлык юлына басарга кирәк. Моны Явыз Иван бик яхшы аңлый...

Тик халык бәете бу мәсьәләләрнең берсен дә читләтеп үтми. Көчләп чукындырылганнан соң Үтәмеш Гәрәйне анасыннан аерып, Мәскәүгә, Явыз Иван янына алып китәләр, дидек. Мәдһиш Иван аны урыс вә христиан дине рухында тәрбияләүне махсус кешеләргә тапшыра. Димәк, сүз әле сабыйлыктан чыкмаган баланы гайре табигый бер юнәлештә, туган иленә, халкына, Ислам диненә, мөселманнарга, хәтта кадерле анасына да тирән нәфрәт, дошманлык рухында тәрбияләү турында бара. Озак вакыт та үтми, Явыз Иван үзенең гайре табигый максатына ирешә: сабый Үтәмеш Гәрәй бөтенләй башка кешегә әверелә. Аңарда татарлык, мөселманлык рухының эзе дә калмый. Бу яктан бәеттә түбәндәге, шулай ук гайре табигый, соң дәрәҗәдә сәер яңгыраган юллар аеруча игътибарга лаек:

Гариб балам Үтәмеш алты яшенә җитте,
Фани дөньядан китте, аннан бер кайгым бетте.

Күренә ки, биредә Сөембикә үзенең бердәнбер улы үлгәч, нинди дер канәгатьләнү хисе кичерә, бер кайгысының бетүе турында хәбәр итә. Шулай булгач, аның улы исән вакытта анасына кайгы-хәсрәттән башка берни дә китерә алмаган булып чыга. Күрәсең, бу чыннан да шулай булгандыр: бердәнбер улы Үтәмеш Гәрәй Сөембикәнең кан дошманы булган Явыз Иван белән дуслашып китә. Ни көтәсең инде иленнән, халкыннан, сөекле әнисеннән аерылып, даими аларга нәфрәт вә дошманлык рухында тәрбияләнгән сабый баладан?! Аеруча зур түймәҗлесләрдә яисә тантаналы, патшаларча ауга чыкканда, Явыз Иванның уң ягында Шаһгали булса, сул ягында Үтәмеш Гәрәй, хәзер инде Александр Сафакиреевич була!

Чынлыкта исә Үтәмеш Гәрәй анасыннан соңрак, 20 яшендә, Р. Әмирхан язганча, «1566 елның 11 июнендә вафат була. Мәсхәрә һәм хөрмәт бергә катышкан «тантана» белән ул патша фамилиясе әгъзалары белән берлектә кремльнең Архангел соборында күмелә».

Сөембикәнең соңгы көннәре һәм үлеме хакында нинди дер дәрәҗәдә төгәл мәгълүматны безнең мәшһүр тарихчыларыбыздан энциклопедик характердагы галим Риза Фәхретдин генә язып калдырган: Сөембикә «ире Сафа Гәрәй, бигрәк тә улы Үтәмеш Гәрәй хәсрәте белән янып-көеп вафат булды, диләр. Ул 38 яшьләрендә, 1557 елда вафат булмыштыр».

Кайбер тарихи чыганаклардагы аерым хәбәр чаткылары да шул ук фикерне раслый кебек. Касыйм шәһәрендәге Шаһгали мавзолеенда бер таш кыйпылчыгы табылган. Анда «1557» саны гына сакланып калган. Ташның башка өлешләре уылып беткән. Кайбер галимнәр: менә бу таш кисәге Сөембикә кабереннән калмадымы икән? — дип фараз кылалар.

Дөньяга килгән адәм кайгы күрмичә тормый,
Дөньяда шат йөргәннең дә туфрактыр ахыр урыны.

Бәетнең соңгы юллары ханбикәнең соңгы елларыдай моңсу. Чыннан да, хәзер, 1557 елда Сөембикәнең туган иле Нугай урдасы Явыз Иван тарафыннан яулап алынган; әтисе юк — 1554 елда туган энесе Исмәгыйль морза кулыннан шәһит киткән; бердәнбер баласы да, номиналь ире дә ханбикәнең, Казанның һәм Нугай далаларының, гомумән мөселман-төрки илләрнең кан дошманы булган Явыз Иванның якын дусларыннан. Беркайдан һәм берничә ярдәм көтү мөмкинлеге калмаган. Ятимлек, ялгызлык, чит-ят җирдә кара урмандагыдай адашканлык. Әйтелгәнчә, нибары 37—38 яшьләрендә Сөембикә дөнья куя. Бәхетле тормыш кичергән кеше болай яшьли үлми! Тик, ни кызганыч, сөекле Сөембикәнең кабере кайда булуын әлегә кадәр беркем дә белми...

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТАРИХ МИЗГЕЛЛӘРЕ...

*Казан ханлыгы шагыйре Мөхәммәдьярның 500 еллыгын каршылап.*

Шагыйрь Әхмәт Рәшит ошбу олуг бәйрәмне 1996 елда басылган «Мөхәммәдьяр» исемле поэмасы («Мирас», 1996, 9 сан) белән каршылады, чал тарихтан янә бер мизгелне өзеп алып (элегрәк язылган «Сөембикә», «Колшәриф» әсәрләре янына), кулыбызга, рухыбызга бирде. Казан ханлыгы дәвеpeнeң өч олы шәхесенә шигъри һәйкәлен тәмамлады ул.

Мәшһүр шагыйрь Мөхәммәдьяр намена багышланган әсәренең хатимәсендә, башлам кәлимәсендә үк Ә. Рәшит үзен бу сызланулы, әрнүле юлга алып чыккан максатын борынгы каләмдәшенә мөрәҗәгатьтә ачып сала: «Мин гасырлар аръягыннан дәшәм сиңа, Сүзләремдә һич юк үпкә, рәнҗү, кинә; Заман белән заман, әйдә, кавышсын да, Сөйләшикче кыл уртага салып кына».

Шагыйрь остазына тәрбияле оныкларча, әдәп саклап, итагатьле генә мөрәҗәгать итсә дә, бу — җавабы мәҗбүри булмаган бизәкләү чарасы, риторик эндәш кенә түгел.

Шуннан соңгы юлларда ике дәвер, ике дөнья, әмма берүк телдә сөйләшүче шагыйрьләр арасында аңлашу, араларны «ачыклау», урыны-вакыты белән бәхәс уты да дөрләп кабынып китә. Хакыйкатьнең бер өлеше бүгенге көн шагыйре кулында булса, аның икенче ягы үткәндә, ерак тарихыбыз бабларында ята. Киләчәк әнә шул чакматашлар тудырган чаткыдан туа...

Чорлар чатындагы сөйләшүнең җиңелдән булмавы аңлашыла. Чөнки XVI гасыр башы шагыйре Мәхмүд хаҗи угълы халык тарихының иң хәтәр бер вакытында яшәп, иҗат итеп киткән шәхес... Без хәзер татар халкының кем һәм аның кемнәргә кирәк булганлыгын, нәрсәгә хезмәт иткәнен аңлау югарылыгына күтәрелеп барабыз кебек. Өстән төшкән әмергә буйсынучан, үтәүчән, «туган илнең һәр карыш җире өчен соңгы тамчы канына хәтле көрәш» кебек шигарьләргә ихластан ышанган татар халкы 1941—1945 елларда бик күп гаярь улларын, тумый калган балаларын югалтты бит. Татар авыллары биргән корбаннар исемлеген укып шаклар катасың! Ике йөз йортлы авылдан кимендә ике йөз кеше һәлак булган! Икешәр, өчәр ир-егетен югалткан гаиләләр тулып ята. Элеккеге СССРдагы һәр халыктан чыккан геройларны, генералларны, маршалларны санныйлар — әмма халык санына нисбәтән бирелгән корбаннарның, югалганнарның тулы исемлеге юк. Хаким даирәләргә файдалы булмаганда, «сатлык җан»нар статистикасы да эндәшми... Татар халкы сугыш корбаннарының саны буенча күпләрне артта калдырыр иде дип уйлыйм.

Шул рәвешле, «сугыш» поэзиясенең элеккеге кайбер әхлакый-фәлсәфи терәкләре какшаса да, шигърияттәге көчемлелек, төрле буын татар шагыйрьләре арасындагы җанлы җепләр сузылу фикере искермәде, киресенчә, ул тулырак ачыла бара. Шул ук шартлы алым «Мөхәммәдьяр» поэмасының да үзәгендә ята, әсәрнең композицион бөтенлеген тәшкил итә.

Шигъри аһәң, хис — тарихны урыныннан кубара, гасырлар катламын үтеп, иртәнге томанны кисеп төшкән кояш нурларыдай, үткәнгә юл ала. Мөхәммәдьяр белән Ә. Рәшитне йөрәк төбендә, кичереш төпкелендә яткан халык хәсрәте, милләт сагышы, басып алучыларга нәфрәт һәм мөстәкыйль яшәеш рухы, Ватандарлык тойгысы якынлаштыра. Дәүләтчелек ул — кулдан төшеп китеп, вак кисәкләргә ватылган бәллүр савыт кебек икән. Ualган, сибелгән кыйпылчыкларны җыеп алуы, ябыштыруы, ялгавы мөмкин түгел. Түрә бәкләр үзләренең түбән матди мәнфәгатьләрен йөгәнли, туемсыз нәфесләрен калыпка утырта алганда, Идел йортны кулда тотып калуы, бәлки, мөмкин дә булгандыр.

Ваемсызлык, битарафлык кебек гадәтләребез хакында борынгы бабаларыбыз бик төгәл әйтеп калдырганнар. Урхун-Йәнисәй буйларында Күлтәгин истәлегенә уеп калдырылган таш язмаларда болай диелгән.

Түрк будун ток арык ок сән
ачсык тосык өмәзсән
бир токсар ачсык өмәзсән.

(Төрек халкы, тукмы син, ачмы,
ач булырсыңмы син, тукмы — ул турыда уйламыйсың.
Бер туйгач, ачлыкны уйламыйсың).

*Н. Хисамов тәрҗемәсе.*

Икенче бер язмада: «Төрк халкының бөтенесе шулай диде: дәүләтле халык идем. Кайда инде дәүләтем? Кем дәүләте өчен тырыштым»,— кебек катлаулы, четерекле, тормышчан сораулар куела. Мөкамлы Казан бәкләре бу хакыйкатьне оныталар.

Ике чор шагыйре нәкъ менә түрк будуннарының холкы, фигыле турында тирәнтен уйланалар. Үткән өчен түгел, киләчәк гаменә. Ә. Рәшит Казан ханлыгы дәвереннән «Төхфәи мәрдән», «Нуры содур» кебек гаҗәеп киң колачлы, әхлакый-әдәби зәвыклы, нәзек шигъри бизәкләре белән сүз челтәрен тукыган әсәрләр калдырган затны бәхәскә тартып кертә.

Мөхәммәдьяр үзенең күләмле поэмаларын казанлыларның үз мөстәкыйль дәүләте булган заманда, үзләре хуҗа булган Идел-Чулман елгалары суы чупылдавын тыңлап, аның әдәп-әхлак кагыйдәләре, яшәеш тәртипләре, фәлсәфә кануннары турында уйланып язган. Шундый әсәрләр халыкка кирәк булган, алар шагыйрьнең моңлы авазында җанын иркәләгән. Артында әнә шундый яхшымы, яманмы үз хөкүмәтең, туган телеңдә боерыклар төшерүче хакимиятең торганда киңәш бирүе, үгет-нәсихәт агызуы да кыен түгелдер. Мөхәммәдьяр әсәрләренә хас олы су тынлыгы, кара урман шомы, эчке ярсуның, шашкын хисләлекнең ярлардан ташып чыкмавы шундый арка терәге нык булудан килә торгандыр.

Ике чор шагыйрен фаҗигале тарих, каргаларның матәм җыры гына якынлаштырмый. Урманнар, күлләр, зәңгәр күгебез, Зөһрә кызлы моңсу аебыз, кендек каныбыз тамган, бабаларыбыз күмелгән җиребез — шул ук. Татар халкы үз байлыкларына хуҗа булу, телен саклап калу өчен туктаусыз көрәш алып бара. Үткәннең асыл затлары бу юлда безгә таяныч, илаһи терәк... Поэманың үзәк каһарманы Мөхәммәдьяр — чегән арбасыннан төшеп калганнардан түгел. Ул Казан ханнары гаебен үз өстенә алырга ашыкмый. Әсәрдә ул: «Мин күптәннән гүр иясе, нигә инде кузгатасың туфрак булган җәсәдемне», «Җаным минем инде ходай хозурында», «үткән-беткән, уты сүнгән, калган күмер», дип җитди аңлашудан тайчылырга, үз чорына «күчеп» утырырга тырышып карый. Ә хакыйкать тарих чоңгылында, төптә ята. Шул рәвешле поэмада олы тарихи, җәмгыяви мәсьәләләр үзәккә алына, шуларга җаваплар эзләнә.

Ә. Рәшит Мөхәммәдьярны үзенең олуг юбилеена «әзерләнгән» фәлсәфи фикерле, киң колачлы, үткен телле шагыйрь буларак кына тәкъдир итәргә дә хаклы иде. Казан чоры шагыйрьләренең исемнәре килеп җиткәннәре арасында Мөхәммәдьяр таш кыя төсле калкып тора бит.

Юк шул. XVI дәвер сүз остасы белән XX гасыр ахырындагы татар шагыйре арасында гәп нәфисләү чаралары, сурәтле фикерләү алымнары, телебезнең сыгылмалы күәсе турында гына бара алмый. Арада һаман да каны саркып торган уртак яра ята... Борчулы сорау тора. Ни өчен гөрләп чәчәк атып яшәгән Казан ханлыгы шулай тиз юкка чыккан соң? Бик күп мәмләкәтләр җиңелгәннән соң да янәдән аякка басканнар бит... Ә Казан?

Өлкән каләмдәшенә казый булудан, аны хөкемгә тартудан бигрәк, хәзерге шагыйрь бимазалы сөальләрен күбрәк үзенә бирә. Ватан бәйсезлеген саклау өчен сукасын — кылычка, урагын җәяле укка алыштырган игенче, һөнәрче, кызыл малчы, мәдрәсә шәкерте гаепләме? Әллә алтын-көмешкә, зиннәткә чумган, үтә күренмәле кытай ефәгенә төренгән җарияләре янынннан китә алмаган сарай даирәләре дилбегәне кулда тота алмаганмы?

Язмыш үзе биргән дәүләтен, хак бүлгән җирен югалткан Казан Ханлыгының җиңелү сәбәпләре тарихчылар тарафыннан тәфсилләнгән. Әмма поэма авторының совет чоры тарихчыларына ышанычы юк: «Телмәр сөйләп сүзне чүпкә батырдылар. Ә үзләрен Мәскәүләргә чакырдылар — Тоттырдылар «галим» дигән катыргылар». Тарихчылар дошманның 150 меңлек чирүенә каршы нибары 30 меңлек татар гаскәре торуы, әрмән диаспорасының су саклагычларын шарт-

латуга ярдәм итүе, хәзер Татарстан башкаласы үзәгендә һәйкәл куелган Бутлеровның полковник бабасының корылмаларны шартлату белән оста шөгыльләнүе h. б. якларын ачыклаганнар.

Төп сәбәпләрнең берсе — төрки халыкларга әлеге дә баягы бердәмлек житмәү. Бөтен христиан дөньясы Ауропада урнашкан бердәнбер мөслими ил — Казанга ташланганда, төрки дәүләтләрнең берсе дә ярдәмгә килми, читтән күзәтеп торуны артыграк күрә, күсәкнең икенче башы тиздән үзенә килеп төшәсен сизенми (хәзергә тамагы тук!), бу афәт мине читләтеп үтәр дип үз-үзен алдый.

Шуның өстенә татар кешесе — табигате белән нечкә хисле, үпкәчел. Ахырын, нәтиҗәсен, соңын уйламыйча үпкәли ул. Тарихка дөньяның иң әшәке кешесе булып кереп каласын уйламаган Шаһгали дә үзен ханлыктан куган Казанга үпкәли, Камай да үпкәли... Шуннан сатлык җаннар туа. Алар тамак ялына хезмәт итеп, җиңүченең колы булып, үз халкыннан бәддога алып, билгесезлектә юкка чыкканнар.

Аннан соң татар — бик ышанучан халык. Сөембикәне малае белән Иван Грозныйга биреп җибәргәндә Казан бәкләре явыз патшаның күнелен йомшарту, үзләренә мәрхәмәтлек алу турында хыяллангандыр. Аң кергәндә инде соң була, терсәкне тешләп булмый.

Мөхәммәдьяр Казанның 1552 елда җиңелүенең, фаҗиганең нигез сәбәпләрен үзенчә аңлата. Хакимнәр «гыйш-гашрәттә сафа сөреп көне-төне» илне саклау хәстәрен күрмәделәр, дип чор даирәләренә кискен хөкемен чыгара. Ә Чыңгыздан калган камил кануннардан урыс файдалана белде, «Безнекеләр һаваланып йөри бирде». Автор дошманга анык бәясен әйтә: «Мәскәү кенәзләре исә бер булдылар, берәм-берәм берләштеләр — бер булдылар». Чыннан да, чит дәүләт гаскәриләре ел дәвамында Казан төбендә кала коралар, ә ханлыкның хуҗалары бу афәтне күрмәмешкә салышып, хакимият, байлык бүлешеп яталар.

Мөхәммәдьяр шул дәвер өчен зур тәрәккыяткә ирешкән, Иван Грозный гаскәрләре белән килгән кешеләргә бетмәс-төкәнмәс күренгән байлыклары, затлы сарайлары, китапханәләре, җимеш бакчалары белән шаклар катырган Казан ханлыгының «ахырзаманын» күрә. Шагыйрьнең тирән кичерешләрен Ә. Рәшит болай сурәтли:

> Исәп-сансыз үлек иде һәр адымда,
> Кызыл канга батты ап-ак күлмәгем дә,
> Йөрдем... Йөрдем... бердәй иде көн дә, төн дә...
> Төш идеме... өн идеме... — белмәдем дә.

Шагыйрь үз үлемен дә шунда таба. Гөрзие белән башына китереп суккан «күзе тонган исерек кеше» өчен шагыйрен ни дә, олы затын ни! Ул үтерүчеләргә каршы тора алмый: «Мин бит шагыйрь, кан коючы яугир түгел».

Әлбәттә, Мөхәммәдьярның ничек, ни рәвешле һәм кайчанрак үлүен берәү дә тәгаен белми. Әсәрдә исә шагыйрь фаразы, әдәби алым. Татар шагыйрьләренең язмышы шулай. Татар-төрк сүз осталары беркайчан да «коеп куйган шагыйрь» дәрәҗәсендә генә калып, мактау ташы өстендә утырып, сәяси давыллардан, милләт язмышыннан читтә калмаганнар. Хәер, аларның беришесе хан сарае кырында тамак туйдырып, сәрвәрнең үзен, тирәлеген, мул мәҗлесләрен, кискә ау чабуларын, гакылын, булган йә уйдырма батырлыкларын мәдхия нурында коендыру юлын сайлый. Ә ихлас чичән-шагыйрьләр исә, илнең кайгы-хәсрәтен йөрәгенә алып, халкының язмышын, моңын, халәти вә иҗтимагый тормышын сурәтләүне максаты итеп куя. Боларның авызы бал-майны сирәк татыса да, алар барыбер — бәхетле, аларның исеме халык җанында яши, мәңгелектә кала. Олы исемнәрне, тарихта эзле шагыйрьләрне ил, халык күтәрә. «Шагыйрьләр — милләтнең хәтере», — дип язуы белән М. Әгъләмов хаклы. Болгар дәүләтенең манкуллар тарафыннан юкка чыгарылу дәверендә атаклы Кол Гали шәхесе калка. Сәйф Сараи шөһрәтле Алтын Урданың йолдызы атылган чорда яши. Кызганыч ки, йолдызның канатлары аерым ханлыклар рәвешендә төрле якларга тарала, акрынлап билгесезлектә сүнә.

Әсәрләреннән күренгәнчә, Мөхәммәдьяр ханнар калҗасына якын шагыйрь булмаган, поэмаларының берсен Мөхәммәт Әмин төрбәсендә сакчы-мөҗавирлектә торганда язган. Мөхәммәдьяр — поэзияне кешегә әдәп-әхлак кагыйдәләрен сеңдерүнең ышанычлы чарасы дип саный. Әйтелгәнчә, анарда чынбарлыкны романтик буяулар аша тасвирлау юк. Нәсихәт кешене кимчелекләрдән арындыруга, рухи камилләштерүгә хезмәт итә, дигән иманда тора шагыйрь.

Мөхәммәдьяр үзе генә түгел, аның иҗаты да фаҗигале язмышка дучар була. Колачлы, гайрәтле әдипнең, фикер иясенең иҗат җимеше — мирасы билгеч

галимнәр күзенә XIX гасыр уртасында чалынса да, дөньяга һәм киң даирә укучыга безнең чорның илленче-алтмышынчы елларында гына барып житә. Ничә йөз еллар онытылып тору, бушлык, гаип булу... Әле дә иҗатының бер өлеше генә табылган дип уйларга нигез бар. Иван Грозный һәм аның яраннары Казанны алуга китапханәләрне, рухи-дини хәзинәләрне юкка чыгару, тәяп китү шөгыленә беренчел әһәмият биргәннәр. Бу гамәлнең әсасында тирән мәкер ята: язма мәдәнияты, әдәбияты, рухани милке булмаган халык мөстәкыйль дәүләткә ия булып яши алмый, хакы юк! Аны башка, көчлерәк, алдынгырак мәмләкәтләргә кушу зарури була. Үзенең тарихын, әдәби-сәнгати, фәлсәфи байлыгын, үткәндәге казанышларын белмәгән халык манкортлык язмышы белән ризалашырга тиеш була. Иван Грозный сәясәтен дәвам иткән большевикларның ашык-пошык, янгынга чапкандай, әлифбалар алыштыру белән уйнавының төбендә дә шул ук сәясәт ятты: халыкның тарихи аңын, белем баганаларын кисеп ташлау!

Нечкә хисле, сүзе-моңы табигый агышлы, ямьле вәзенле шигырьләр, халык яраткан җырлар авторы Ә. Рәшитнең башы-аягы белән тарихка кереп чумуы сәер тоелырга мөмкин. Күрәсең, максатлы рәвештә ул үзен шул олуг миссиягә әзерләгән.

Тарих ишеген шакуга җөрьәт иткән кешедән кимендә ике нәрсә таләп ителә. Берсе — белемле, укымышлы, бик күп фәннәрдән хәбәрдар, мәгълүматлы булу. Икенчесе — чыганакларны тәнкыйди иләк аша үткәрә белү, инде мәгълүм гыйльми, риваяти истәлекләрне яңача укый, бәяли, тарихи аң безгә китереп житкерә алмаган катламнарны яңача тәкъдир итә белү. Биредә сүз борынгы кулъязмаларны, архив истәлекләрен, кабер ташларын тынгысыз күңел, җан җылысы белән тулыландыра алу сәләте турында бара. Чыганаклар белән аз-маз аралашкан кешеләрнең күбесе үзләрен тарих буенча белгечкә саный башлыйлар. Татарның үткәне турында хәзер кем генә язмый, кем генә пәйгамбәрлеккә дәгъва итми! Чынлыкта исә, татар халкының килеп чыгышы, генезисы, фаҗигале язмышының сәбәпләре турында без әлегәчә бик аз беләбез.

Тарихи үткән турында әдәби әсәр язу ифрат катлаулы гамәл. Язучы сихерче, юраучы, әүлия, шаман булырга, ягъни үткәнгә күңел күзе, тоемы белән үтеп керә белергә тиеш. Шундый зат булу өчен янә бер бик «гади» шарт кирәк. Ул — үз халкының газиз баласы булып туу, ана телендә балигъ тәрбия алу, милләтең сызлавын шәхси яраң итеп дәвалау һәм, әлбәттә инде, үзең сурәтләгән чорында «яшәү». Чит-ят шивә әһеле синең тарихын хакында мавыктыргыч, төгәл, анык сюжетлы әсәр яза алса да, җаныңны җылыта, җәрәхәтеңне дәвалый алмас кебек. 1996 елда «Молодежь Татарстана» гәзитендә Сөембикә, ул яшәгән чор турында роман басылды. Безнең тарихка игътибарлы булуы өчен авторга рәхмәт әйтәсе килә. Татар тормышын, көнкүрешен сурәтләүдә, тарихи фактларны укуда чатаклыклар булса да, әсәр укыла, зиһендә кала. Әмма роман хискә, йөрәккә барып житми, күңел кыңгырауларын уята алмый. Теләкләре, ниятләре изге булганда да, Сөембикә рухына башка кавем кешеләре кулларын орындырасы килми. Аның турында Һ. Атласи, Батулла, М. Хәбибуллин, Ә. Рәшит кебек ифрат милли рухлы, татар тарихын үз йөрәк тибешедәй сиземләгән язучылар гына алынырга хаклы кебек. Шуңа күрә Ә. Рәшитнең «Сөембикә», «Колшәриф» поэмаларын укучы көтеп алынган әсәрләр итеп йөрәгенә үткәрде. Гариф Ахунов поэмалар хакында төпле, нигезле, әтрафлы, кешелекле мәкаләсе белән чыкты.

Сөембикә — халыкның олы вә әрнүле йөрәгендә, хиссият дөньясында иркәләп, буыннан буынга тапшырыла килгән изге заты, сөенече, ышанычы, өмете. Ул — милләт аналарына, бик күп татар хатын-кызларына хас гүзәл сыйфатларны, күңел нурларын үзенә җыеп алган шәхес. Тарих хәтере башка хатын-кыз образын сакламаган диярлек. Шуңа да аның образында горур мөстәкыйльлек белән язмышка буйсынучанлык, көрәшче холкы белән гаилә учагын саклаучы, алдан күрүчәнлек белән сабырлык бергә укмашкан, халык аны үзенең җырларында, бәет-риваятьләрендә үрнәк-өлге шәхес турындагы әхлакый күзаллавына якынайта, фәрештәдәй изге җан дәрәҗәсенә күтәрә. Андый шәхесләрне тарихи зарурият үстерә, замана чалымнарын өстәп, тулыландыра. Ә. Рәшит шул чыганак-бәяләргә таянып, тарихи поэмалары белән халкыбызның заманында көчле дәүләтләргә ия булган, бихисап олы шәхесләр биргән, борынгы һәм югары мәдәниятлы милләтләрнең берсе икәнлекне искәртә.

Ләкин татар халкы олы һәм фаҗигале тарихи юлында биниһая зыялыларын, батыр ул-кызларын югалткан. Күбесе эзсез югалган. Шагыйрь Ә. Рәшит шуларны барлау юлында. Сөембикә белән Колшәрифкә әтрафлы һәм тәфсилле әсәрләрен багышласа да, бу каһарманнары турында ул «Мөхәммәдъяр» поэмасында

да онытмый. Казан ханлыгы чорынын күренекле шәхесләре белән тирәнрәк таныштыру-кавыштыру юлларын барлавын дәвам итә. Сөембикә шәхесе турында күңелендә йөрткәннәрен, күзаллавын Мөхәммәдъярдан «әйттерә»: «Чыннан да ул хур кызыдай гүзәл иде. Бер караса үзәкләрне өзә иде... Аны күргән суфый кеше, тыеп үзен. Чокып алыр иде хәтта ике күзен».

Үз чоры кешесе, ислам тәрбиясе алган кырыс шәхес буларак, Мөхәммәдъяр Сөембикә «бәкләр кулында... тик курчак иде... Дәүләт тоту хатын-кызлар эше түгел», дигән кискен нәтиҗәсен чыгара, кабат бу мәсьәләне куертканда, «Вакытлыча бу җиһанда бөтенесе», дип бәхәсне фәлсәфи яссылыкка күчереп калдыра. Хәятның фанилыгы, тормышның үзгәреп торуы исәпкә алынырга тиеш дигән фикере анык.

Ә. Рәшит поэмалары янә бер хакыйкатькә инандыра. Тарихи әсәрләр үзәгендә эпик киңлекне укмаштырып, әйдәп баручы, көчле ихтыярлы шәхес образы торырга тиеш.

Шагыйрь әдәбиятның шул үзенчәлеген күз уңында тотып, читкә чыкмаска тырыша: Мөхәммәдъярны шагыйрь вә үз чорының күренекле шәхесе буларак үзәккә ала. Шигърият бит әле шуның өстенә тормыш-көнитеш ваклыкларын яратмый, күбрәк рухи дөнья матурлыкларын сурәтләүне таләп итә. Шул ук вакытта үткәннәр турында эре итеп язу — бүгенге көнебез хакында уйлану, рухлану өчен кирәк.

> Күңелемдә мең-мең сорау — җавап тапмыйм.
> Авызыма каптырырлар диеп ятмыйм —
> Дөреслекне кая гына эзләп чапмыйм.
> Милләт өчен иярләнгән дөлдел ат мин.

XX гасыр шагыйренең мең-мең сорауга җавап эзләп, бәргәләнүенә, өзгәләнүенә Мөхәммәдъярның җавабы әзер: «Илгә кирәк хакыйкатьне үзең эзлә».

Поэма хәзерге татар кешесенә үзенә уйланырга, эзләнергә урын калдыра. Ул — фикерләү рәвеше белән ачык әсәр. Һәркем милләткә кирәкле җавапны үзе тапсын, дөрес юлга үзе чыксын.

«Мөхәммәдъяр» поэмасында Ә. Рәшитнең иҗат дәрте, рухи җегәре, халык тарихын сурәтле фикерләү алымнары аша күзаллау сәләте тагын да тирәнрәк ачыла. Каләменең сугышчан гайрәте хәзерге чордагы бәйсезлек өчен барган көрәш турында бәян иткән өлешләрдә ачык күренә. «Көрәш кызды — нәтиҗәдә нидер алдык. Тик барыбер чын дәүләтсез кое калдык», — дигән нәтиҗәсе белән килешмичә мөмкин түгел.

Ә. Рәшит өчен тарихи исемле каләмдәше турында бәян итү үзмаксат түгел. Бу әсәрдә тарихи үткәнебез белән ныгытылган уй-хисләрен, ният-омтылышларын безнең чор, бүгенге сәяси, икътисадый халәтебез белән бәйли алган ул.

**Т. ГАЛИУЛЛИН.**

# ТАРИХИ ЗАРУРИЯТ

Татар имласын латин хәрефләренә күчерү хакында сүз инде байтактан дәвам итә. 1990 елның 30 августында Татарстанның дәүләт суверенитеты Декларациясе игълан ителгәннән бирле бәхәснең тынып торганы юк. Ләкин, ничек кенә булмасын, шуннан соңгы еллар эзсез узмады. Ниһаять, латин имласына күчүнең зарурлыгы белән телче галимнәр дә, әдипләр дә, укытучылар һәм телгә азмы-күпме мөнәсәбәте булган башка даирәләр дә килеште сыман. Хәзер инде төп бәхәс конкрет яссылыкка күчте — кайсы хәрефне ничек кабул итәргә? Бүгенге көндә вакытлы матбугат битләрендә берничә вариант гамәлдә йөри. Берәүләр аз гына камилләштереп иске «Яңалиф»не кайтару ягында булса, икенче берәүләр исә бөтенләй төрки халыклар өчен уртак имла булдыру, ягъни бер үк яңгыраштагы авазларны бертөрле хәрефләр белән белдерү ягында (андый вариант Төркиядә узган киңәшмәдә барлык төрки халыклар вәкилләре тарафыннан хупланган иде). Ләкин монда да фикер уртаклыгы житеп бетми. Шулай булуга карамастан, аерым фидакарьләр көче белән латин имласы акрынлап гамәлгә керә бара. 1992—1993 елларда Казанда башта «Яңалиф»тә, соңрак уртак төрки имлада халыкара «Dөnja» гәзите чыгып алды, 1993 елда «Мәгариф» нәшрияты профессор Вахит Хаковның «Telen belgәn il acar» китабын «Яңалиф»тә бастырып чыгарды. Бераз соңрак борынгы чор татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, «Идегәй» дастаны уртак төрки имлада дөнья күрделәр. Үз вакытында «Казан утлары» журналы да латин имласында уку үрнәкләре биреп барган иде.

Бәхәснең бөтен нечкәлекләренә кереп тормастан, шуны гына әйтәсе килә, латин имласына күчүнең өстенлеге бәхәссез. Без, ниһаять, татар теленең бөтен әйтелеш кануннарына туры килә торган әлифбага ия булачакбыз. Гарәп имласында язган вакытлардагыча, барлык төрки халыкларның уртак мәдәни бәйләнышлар мәйданын булдыруга таба сизелерлек адым ясалачак. Шуның белән бергә, татарга бөтенләй ят кириллица тамгаларының алынып ташлануы сәбәпле, әлифбада хәрефләр саны кими, ' билгесен, ягъни апострофны да кертеп, алар нибарысы 34 кә калачак. Һәм иң мөһиме — яңа имла туган телебезне чит-ят телләр басымыннан, аларның касәфәтеннән йолып алырлык көчле корал да ул. Чөнки аңа чит сүзләрне «татар тегермәнендә тартырлык» мөмкинлекләр салынган.

«Идел» журналы редакциясе һәм татар иҗтимагый үзәге оештырган симпозиумда катнашучы бер төркем милләтпәрвәр зыялылар (Р. Хәкимов, В. Хаков, Х. Курбатов, Д. Исхаков, Ф. Сафиуллин, Ф. Зөлкарнәй, Р. Мөхәммәтдинов, Т. Бариев, Ф. Латыйфи, Җ. Сөләйман, Г. Хәмиди, Ф. Уразаев һәм башкалар) тарафыннан әзерләнгән һәм расланган «Яңа имла төзүнең төп кагыйдәләре»ндә шулай ук яңа имланың технологиялелек, стандартлык, экономиялелек, артыклыктан качу, язылышта кагыйдәләр санын мөмкин кадәр киметү кебек аспектлары да күздә тотыла.

Журналның бу санында Сезгә, хөрмәтле укучылар, Кол Галинең яңа имлада басылып чыккан «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан бер үрнәк тәкъдим итәбез.

**Ф. ЛАТЫЙПОВ.**

**P. S.** Яңа имлада татар хәрефләренең бирелеш вариантларын күрсәтеп торуны кирәк тапмадык. Элеккеге «Яңалиф» яисә инглиз, алман, француз йә булмаса төрек телләреннән хәбәрдар зирәк һәм тапкыр укучы тәкъдим ителгән текстның берничә юлын укуга ук нинди хәрефнең кайсы авазны белгерткәнен үзе аңлаячак.

*Bismillahir-räxmanir-räxim*

## KEREŞ

Maqtawlar häm küp şökerlär Berdänbergä,
Milke daim häm mäñgelek ber täñregä,
Mölkätendä tiñdäşe yuq ul täñregä, -
Anı mäñge ülemsez dip beldek inde.

Añardan soñ anıñ dustı Möxämmädkä,
Näbilärneñ[1] iñ oluğı ul Äxmätkä[2],
İke uqlıq urını bar[3] ul Äxmätkä,
Aña bik küp sälam-xörmät bulsın inde.

1 Näbi - päyğämbär.

2 Äxmät - Möxämmädneñ küktäge iseme.

3 Möxämmädneñ uq atarlıq ike yıraqlıqtan torıp allanı kürüe turındağı legenda küzdä totıla.

Añardan soñ ğär iäse Siddiq[1] bar iç,
Mostafağa[2] ğär eçendä buldı ul iş,
İş bulunı üzenä ğär kürmäde hiç,
Tuğrılığı härkemnän dä artıq inde.

Añardan soñ däxi Ğömär Xättab uğlı,
Bar ğälämgä mäşhür ide anıñ ğädle[3],
Yöz meñ irdän artıq ide anıñ fäzlı[4] -
Dürt meñ dürt yöz mäçet bina qılğan inde.

Añardan soñ izge Ğosman şähidi bar,
Qör'änendä anı telgä aldı Cäbbar[5],
Zur tögällek büläk itkän aña Ğaffar[6] -
Tulı Qör'än xatasızın tözgän inde.

Annan Ğali qurqusızğa maqtaw kiräk -
Yöz meñnärcä ğäskärdän dä ğayrätleräk.
Hiç qılıç yuq Zölfeqärdän ütkeneräk,
Ğalidän dä batırraq zat hiç yuq inde.

Anıñ üzäk özgännäre ike yeget,
Din yulında köräşüçe, qanın tügep,
Berse - Xäsän, berse - Xösäyen - ike şähid,
Alar yäşli cännät ähle bulğan inde.

1 Siddiq - tuğrı. Möxämmädtän soñğı berençe xälifä Abubäker küzdä totıla.

2 Mostafa - saylap alınğan. Möxämmädkä qarata äytelä.

3 Ğädle - ğädellege.

4 Fäzlı - östenlege, kamillege.

5 Cäbbar - qüät, qodrät iäse (ilahiätkä qarata äytelä).

6 Ğaffar - säfqätle, ğafu qıluçan zat (ilahiät küzdä totıla).

15

Annan soñra ul dürt tuğrı xälifägä,
Ul tabiqin[1] ğölämä häm şähidlärgä,
Dindä bulğan bar äwliä şäxeslärgä -
Barçasınnan täñre razi bulsın inde.

Annan soñra ul bäxetle irännärgä,
Xaqnıñ söygän Mostafasın kürgännärgä,
Kimetüsez utız öc meñ irännärgä -
Barçasın da östaz diep belik inde.

Annan soñra ber ir çıqtı - ğilem tawı,
Anıñ belän kürkämlände islam danı,
Açıq, tögäl beläsezme ikän anı -
Şabit uğlı Noğman[2] dilär aña inde.

Annan soñra din başlığı bulğannarğa,
İmanğa - köç, islamğa - nur bulğannarğa,
Xaq̇tan daim räxmät yawsın häm alarğa,
Küp meñnärçä afärinnär bulsın inde.

Räximle ul ilahıma sıyınmıymmı,
Başım iep yarlıqawın soramıymmı,
Böyegemnän yardäm-duslıq telämimme -
Maqsatlarğa ireşterä tik ul inde.

Min ber zäğif siña sıyınam, izge iäm,
Min - yonçığan sinnän yardäm ömet itäm,
Xäteremne yaqtı it sin, yumart iäm,
Qödräteñ kiñ - sin bir yaxşı zihen inde.

16

1 Tabiğin - iärüçelär, päyğambärne kürep belüçelär.

2 Sabit uğlı Noğman - islam dinendäge ortodoksal dürt mäzhäpneñ bersenä nigez saluçı Äbu Xänifä.

Sinnän yardäm ömet itäm min zäğif qol,
Sine dälil itüçelär taba töz yul,
Ägär yardäm birim disäñ - qödräteñ mul,
Bu bändäñä dälilem bul üzeñ inde.

Min zäğifne sin xikmätkä taba yandır,
Ğibrät-xikmät söylätterep sin quandır,
Kükrägemdä yardämeññeñ şämen yandır,
Xäteremne yaqtı nurğa balqıt inde.

Küñelemä fiker-zihen yaqtısı bir,
Qodräteññän miña xikmät balqışı bir,
Min zäğifkä köçle ilham uñışı bir,
Qödräteñ bar, här äytkäneñ bula inde.

Xäteremnän şik-xatanı çäçrätep bir,
Canğa xikmät orlıqların sin çäçep bir,
Miña yardäm qapuıññı sin açıp bir,
Ğaqlım turı, telem tözek yasa inde.

Yärdäm bir sin xikmätlärgä qaytu öçen,
Ğaqıllılar añın-zihnen bayıtu öcen,
Yosıf säwçe äxwällären äytü öçen, -
Ğilmem kamil, telem tözek yasa inde.

Yosıfqa küp xällär niçek kilgänlegen,
Qärdäşläre Yosıfqa ni qılğanlığın
Һäm Misırda olı mälik bulğanlığın
Näzım belän sezgä äytep birim inde.

Bu cihanğa Yosıf näbi kilgän ide;
Ä atası Yağqub xaqnıñ söygäne ide,
Ä babası İsxaq - dinneñ tabibı ide -
Alla dustı İbrahimnıñ uğlı inde. 17

Moñardan soñ min xikmätkä küçäçäkmen,
Göl häm räyxan, ence-märcän sibäçäkmen,
Yosıf näbi xälen söyläp biräçäkmen -
Mö‘minnärgä bu faydalı añlañ inde.

Qıyssalardan, xikmätlärdän maturrağı,
Yalıqmıyca tıñlaw öçen tatlırağı,
Qör‘ändä dä bu xaqta süz bulğanlığı,
Şuşı qıyssa ikänlege açıq inde.

*Журналыбызның киләсе саннарында «Идегәй» дастаныннан, «Дөнья» гәзитеннән һәм яңа имлада дөнья күргән башка басмалардан да үрнәкләр тәкъдим ителәчәк.*

## «Җанга якын җаннар китә тора...»



*Сулдан уңга: шагыйрьләр Нури Арсланов, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким. 1980 ел.*

## «Кемнәр бар да кемнәр юк...»



*«Казан утлары» журналының редколлегия әгъзалары: Марат Мөлеков (1997 елда вафат) һәм шагыйрь Наҗар Нәҗми. Рәсем 1992 елда I Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә алынган.*

## «Менә без дә үсеп җиттек...»



*Сулдан уңга: яшь шагыйрьләр Ростәм Фәйзуллин (Акъегет), Зөлфәт, Марсель Галиев. «Идел» лагеренда уткәрелгән яшь язучылар семинары көннәре. 1972 ел.*

# ТОРМЫШ ЧЫНЛЫГЫН ЭЗЛӘП...

Утызынчы-илленче елларда татар балалар прозасын күләмле әсәрләр иҗат итү юнәлешендә үстереп алып китүче язучыларыбызның күренеклесе Гариф Гобәй (1907—1982) булды. Бу үзенчәлекле каләм остасы үз иҗатының башында ук «сюжетлы», эпик әсәрләр язарга кереште, татар балалар һәм яшүсмерләр әдәбиятын дистәгә якын күләмле повесть белән баетты.

Әдипнең әсәрләрендә без ике төп башлангыч — тарихи реаль вакыйгалар һәм революцион көрәш пафосының балалар күңелендә чагылыш тапкан героик романтикасы белән очрашабыз. Аның бөтен повестьлары да шул ике башлангычның сәнгатьле синтезы булып тора. Бу яктан Г. Гобәй әсәрләре күпмедер дәрәҗәдә рус совет балалар әдәбияты классигы А. Гайдар иҗатын хәтерләтә.

Язучы әсәрләрендәге тарихи чынбарлыкның чагылышы аларның тематикасында ук күзгә ташлана. Әйтик, Г. Гобәйнең өчтомлык Сайланмасына (Сайланма әсәрләр, өч томда.— Казан, 1968—1969) кергән 75 табактан торган җиде зур повестьның икесе — «Маякчы кызы» (1938), «Ялгыз йортта» (1939) әсәрләре гражданнар сугышы чорын үз эченә ала. «Каланча» повестенда автор колхоз төзелү елларына мөрәҗәгать итә, 40—50 елларда язылган «Замана балалары», «Маратның язмышы» повестьлары Бөек Ватан сугышы чорын тасвирлый, «Ләйсән яңгыр» (1957—1960) әсәре 50 еллар тормышына карый. Әдипнең балалар өчен язылган соңгы «Без үскәндә» (1960—1961) повесте авторның тарихи колачын тагын да киңәйтә — без анда революциягә кадәрге Казанда татар бистәсе тормышы картиналарын күрәбез. Шулай итеп, Г. Гобәй әсәрләрендә халкыбыз тормышының совет чорына караган ярты гасырлык көрәш тарихы җанландырыла. Балалар әдәбиятына язучы шундый эпик колач алып килде. Аның иҗатында без алда әйтеп үткән реаль чынбарлык әнә шуннан гыйбарәт.

Инде революцион көрәш романтикасын үз эченә алган икенче иҗат башлангычына да беркадәр тукталып үтик. Белгәнебезчә, совет әдәбияты 20—30 елларда үзенең яңа романтик күтәрелеш чорын кичерә. Ул елларда совет әдипләре социаль көрәш җиңүе белән рухланып, шуны үзләренең иҗат байрагы итеп күтәрәләр. Балалар әдәбиятында исә әлеге романтик рух аеруча ачык сизелә. Чөнки биредә ул объектив чынбарлык һәм әдәби-эстетик үсеш тенденциясеннән тыш, нәни каһарманнарның яшь үзенчәлегеннән чыгып та барлыкка килә. Олылар теге яки бу хакыйкатькә төрле сынау-эзләнүләр, ялгышу-икеләнүләр, киченеш-каршылыклар аша ирешсә, балалар тормышта, бигрәк тә шәхесе формалашкан бер чорда, өлкәннәрнең озак еллар буе туплаган акыл-тәҗрибәләрен, фикер-идеяләрен әзер килеш кабул итеп ала. Шул ук вакытта, яшьләргә генә хас сизгерлек белән ул тормышта барлыкка килә башлаган беренче яралгыларны «чиста килеш» эләктереп ала, аларны яшь йөрәк каны белән тәрбияләп үстерә, үзе дә янып, башкаларны да рухландырыр хәлгә җиткерә, аның үсүенә комачау иткән иске көчләргә каршы кискен көрәш уты ача. Яшүсмер баланың рухи дөньясындагы эмоциональ тирбәлешләр, фикер сөрешендәге максималистлык һәм, гомумән, аның тормышта канатланып очуы да юкка түгел, билгеле.

Илдәге революция ташкыны кузгаткан тарихи вакыйгаларның бала күңелендә тагын да масштаблырак үсеш алып, романтик яңа хыял биеклегенә күтәрелеп яңгыраш табуы моннан ачык аңлашыла булса кирәк. 20—30 елларда, димәк, революцион яңарышның шулай ук сабыйлык вакытын кичергән бер чорында яшәгән балаларның социаль көрәш дәртенә аерым бер күтәренкелек, өмет һәм эчке инану белән бирелүләре һич тә гаҗәп түгел. Олыларның гомер буе, буыннарның гасырлар дәвамында үткән катлаулы көрәш юлын алар гаҗәеп кыска чорда, тизләтелгән программалы гамәли шартларда үттеләр. Аларның 13—15 яшьтән кулларына корал алулары һәм өлкәннәр башлаган көрәш сафына кушылулары әнә шул хакта сөйли. Революцион романтика бу яшь буынның гадәти көндәлек яшәешенә әверелә. А. Гайдарның үзе яшәгән чорга һәм замандашлары

язмышына йомгак ясап, «обыкновенная биография в необыкновенноевремя» дип бәя бирүе очраклы түгел, әлбәттә. Димәк, бу чор балалар әдәбиятындагы романтика — объектив заман тудырган героик көрәш романтикасының һәм бала күңелендә аның яшь үзенчәлегеннән чыгып барлыкка килгән романтиканың бер бөтен булып керешүе, аерылмас бөтенлек хасил итүе ул. Романтиканың әнә шундый «икеле» — көчәйтелгән формасы тарихи-реаль тормыш вакыйгалары белән үрелеп, Г. Гобәй повестьларының нигезендә ята. Хәер, бу синтез язучының гомум бер сыйфаты гына түгел, ул аның әсәрләрен бер-берсеннән аерып куйган эчке билге дә булып тора. Нәкъ менә шушы реальлек һәм романтик бергә кушылу хасиятләре Г. Гобәй иҗатын үзенчәлекле ике этапка бүлеп карау ихтыяҗын китереп чыгара да.

Әдипнең 20—22 ел иҗат гомерен үз эченә алган беренче этапта без төп әйдәүче көчнең романтик пафос булуын, язучының тарихи тормыш чынлыгын әсәрләрендә романтик сурәтләү алымнарын алга куеп эзләвендә күрәбез. Аның алда саналган беренче биш әсәре әнә шул нигезгә корылган. Соңгы биш-алты ел эчендә язылган «Ләйсән яңгыр» һәм «Без үскәндә» повестьларында исә, киресенчә, өстенлек итүче төп көч булып реаль тормыш вакыйгалары тора. Әсәрләрдәге доминант көчнең кинәт болай алышынуы бер дә юкка түгел, билгеле. Моны иң элек заман сулышының үзгәрүе — күтәренке революцион көрәш һәм социализм төзелеше рухының билгеле бер дәрәҗәдә конкретлашуы — җиргә төшүе һәм реальләшүе итеп карарга кирәктер. «Ләйсән яңгыр» повестенда, әйтик, тормышыбыздагы зур җиңүләр белән бергә, кайбер тискәре якларның да шактый киң яктыртылуы шул хакта сөйләмимени?! Шул ук вакытта 60 нчы еллар әдәбиятында реализм иҗат методының үсү-ныгуын, бигрәк тә аның тәнкыйди реализм ирешкән уңай традицияләргә торган саен ныграк таянуын әйтеп үтәргә кирәк. Бу хәл, табигый ки, язучыларыбызның иҗат концепциясенә дә тәэсир ясамый калмады. Әлеге йогынты Г. Гобәй иҗатында да бик ачык сизелә, аның иҗатында да романтизмнан реализм ягына таба булган үзенчәлекле бер күчеш, иҗат методының трансформацион үзгәреше күзгә ташлана. Дөрес, әсәрләрнең төрле иҗат методы принципларына корылу факты (бу очракта повестьларның нигездә реаль детальләр җирлегендә хәл ителә башлавы) үзе генә әле эстетик сыйфат үсеше хакында сөйләми. Иҗат методларын бер-берсенә каршы кую, гомумән, бервакытта да көтелгән нәтиҗәләр бирми. Реализмга күчеш ясауны да дәрәҗәсе түбәнрәк торган романтизмнан котыла бару дип кенә аңларга кирәкми. Аларның һәр икесе бер-берсеннән башка яши алмый. Сәнгатьтә генә түгел, теләсә нинди танып белүдә дә объектив-субъектив, рациональ-эмоциональ башлангычларны диалектик берлектә карамый мөмкин түгел. Шуңа бу диалектик берлек күчешләренең төрле вариантларын да без барыннан да элек язучының үзен теге яки бу яссылыкта эзләве, тематикада булсын, идея-эстетик эчтәлектә яки формада булсын, үзе белән чынбарлык арасында гармоник бәйләнеш урнаштыруы дип аңлыйбыз.

Шунысы игътибарга лаек. Г. Гобәй үз иҗатында мондый гармоник бөтенлеккә — бу ике башлангычның органик кушылуына ике тапкыр: романтик рухлы иҗатының башында — «Маякчы кызы» (1938) һәм реалистик элементлар өстенлек алган соңгы иҗат этабында — тарихи «Без үскәндә» (1960—1961) повестьларында ирешә.

Шул рәвешчә, Г. Гобәй үз иҗатында тарихи чынбарлык һәм романтик рухлы балалар дөньясының үзара керешүеннән күптөрле гармоник бөтенлекләр хасил иткән дистәгә якын эпик колачлы повесть язды. Татар балалар һәм яшүсмерләр әдәбиятын яңа жанр үзенчәлекләре белән баетып, аңа тарихи масштаблык, романтик күтәренкелек, психологик һәм эстетик эзләнүләр, бер-берсен кабатламаган дистәләрчә якты образ бүләк итте.

**Равил РАХМАНИ.**

# ҺИҖРИДӘН — МИЛАДИГА ҺӘМ КИРЕСЕНЧӘ

Татар һәм гомумән мөселман дөньясы белән бәйле элеккеге (бигрәк тә XVIII—XIX гасырга караган) әдәби, публицистик, тарихи әсәрләрдә, шулай ук ислам дине белән бәйле материалларда вә гамәлләрдә ел исәбенең нигездә гарәп ай һиҗрәсе буенча алып барылганлыгы мәгълүм. Андый очракларда даталарны еш кына милади ел исәбенә (хәзер гамәлдәге календарь) күчерергә туры килә. Моның өчен түбәндәге формула файдаланыла (һ — һиҗри ел исәбе, М — милади ел исәбе):

$$М = һ - \frac{һ}{33} + 622$$

Миладины һиҗригә күчергәндә исә мондый формула белән эш ителә:

$$һ = М - 622 + \frac{М - 622}{32}$$

Әмма бу формулалар якынча исәпләү өчен генә яраклы. Шуңа күрә күп очракта бер системадагы конкрет ел (дата), ае һәм көне күрсәтелмәсә, икенче системада берьюлы янәшә торган ике ел белән билгеләнә.

Һиҗри һәм милади ел исәбен берсеннән икенчесенә тиз һәм дөрес күчерү өчен махсус җәдвәлләр (таблицалар) нык ярдәм итә. Алар җыйнаклык, уңайлылык һәм бигрәк тә урынны экономияләү җәһәтеннән бик кулай. Шундый таблицаларны Казанда беренче булып 1920 елда шәрекъ белгече Н. Ф. Катанов (1862—1922) бастырып чыгарган[1]. Академик Иосиф Орбели (1887—1961) аларны тагын да уңайлырак итеп эшләп, 1940 елда Ленинградта аерым китап рәвешендә нәшер иткән.

Әлеге китаптагы таблицалар миладиның 1941 елы белән тәмамлана. Шуннан соңгы ярты гасырдан артык вакыт дәвамында илдә мондый таблицалар нәшер ителмәгән булса кирәк, һәрхәлдә безгә мәгълүм түгел. Шушы бушлыкны тутыру максаты белән без, телгә алынган китаптагы таблицалар үрнәген нигез итеп алган хәлдә, XX гасырны тулаем колачлап, компьютер ярдәмендә әлеге эшне башкарып чыктык.

Бу таблицалар куллану өчен шактый җайлы. Мәсәлән, Мөхәммәт пәйгамбәр исән чорны чагылдырган беренче таблицаны карыйк.

| Таблицаның тәртип саны № 1 / Айларның тәртип саны | Һиҗри буенча 1 нче ел | (*) 2 нче ел | 3 нче ел | 4 нче ел | (*) 5 нче ел |
|---|---|---|---|---|---|
| | Милади буенча 623—624 нче еллар | 623—624 еллар | 624—625 еллар | 625—626 еллар | 626—627 еллар |
| 1 | 16. 7.5 | 5. 7.2 | 24. 6.7 | 13. 6.4 | 2. 6.1 |
| 2 | 15. 8.7 | 4. 8.4 | 24. 7.2 | 13. 7.6 | 2. 7.3 |
| 3 | 13. 9.1 | 2. 9.5 | 22. 8.3 | 11. 8.7 | 31. 7.4 |
| 4 | 13.10.3 | 2.10.7 | 21. 9.5 | 10. 9.2 | 30. 8.6 |
| 5 | 11.11.4 | 31.10.1 | 20.10.6 | 9.10.3 | 28. 9.7 |
| 6 | 11.12.6 | 30.11.3 | 19.11.1 | 8.11.5 | 28.10.2 |
| 7 | 9. 1.7 | 29.12.4 | 18.12.2 | 7.12.6 | 26.11.3 |

[1] Катанов Н. Ф. Восточная хронология//Известия Северо-Восточного археологического и этнографического ин-та в г. Казани. — Т. 1. — Казань, 1920. — С. 133—239.

(*) билгесе һиҗридәге кәбисә елларны белдерә.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | 8. 2.2 | 28. 1.6 | 17. 1.4 | 6. 1.1 | 26.12.5 |
| 9 | 9. 3.3 | 26. 2.7 | 15. 2.5 | 4. 2.2 | 24. 1.6 |
| 10 | 8. 4.5 | 27. 3.2 | 17. 3.7 | 6. 3.4 | 23. 2.1 |
| 11 | 7. 5.6 | 25. 4.3 | 15. 4.1 | 4. 4.5 | 24. 3.2 |
| 12 | 6. 6.1 | 25. 5.5 | 15. 5.3 | 4. 5.7 | 23. 4.4 |

Сульякның югары почмагындагы сан — биш елны эченә алган таблицаның тәртип санын белдерә. Беренче юлда еллар һиҗри буенча күрсәтелгән, ә икенче юлында шул ук еллар — милади буенча. Беренче баганадагы саннар мөселман елының айларын, ә калган биш баганадагы саннар — мөселман айлары башланган көнгә тәңгәл булган милади елның ай-көннәрен (даталарын) белдерә: 1) айның көне («число»), 2) ай, 3) атнаның көне (Халыкара стандартлар оешмасының билгеләмәсе буенча 1976 нчы елдан алып атнаның беренче көне булып дүшәмбе санала. И. Орбели бастырган китапта исә беренче көн итеп якшәмбе алынган). Таблицаларда һиҗри белән 990 нчы ел (азагына кадәр) Юлий календаре буенча, ә 991 нче һәм шуннан соңгы еллар Григорий календаре буенча күрсәтелде.

Таблицалардан файдаланганда мөселман айларының тәртип саннары белән эш ителә. Алар түбәндәгечә:

1. Мөхәррәм
2. Сәфәр
3. Рабигыль-әүвәл
4. Рабигыль-ахир
5. Җөмадиел-әүвәл
6. Җөмадиел-ахир
7. Рәҗәб
8. Шәгъбан
9. Рамазан
10. Шәүвәл
11. Зөлкагъдә
12. Зөлхиҗҗә

Тәртип саны так булган айлар 30 көннән, җөп булганнар 29 көннән килә. Кәбисә еллардагы соңгы айга 1 көн өстәлә.

Хәзер инде бер мәсьәлә чишеп карыйк.

Мәгълүм булганча, һиҗри ел исәбе Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәтеннән (күчеп китүеннән) башлана. Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәренә рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көнендә килеп җиткән дип уйланыла. Сорау: Мөхәммәтнең Мәдинәгә килеп җитүе милади ел исәбе белән (миляд — туу, туган көн мәгънәсендә, ягъни Гайса пәйгамбәрнең туган көне) кайсы вакытка туры килә?

Айлар исемлегеннән күренгәнчә, рабигыль-әүвәл аеның тәртип саны — 3. Җәдвәлне беренче баганасындагы 3 ле саны белән янәшәдә (һиҗринең беренче елы баганасында) 13 нче сентябрь, дүшәмбе көн икәнен күрәбез. Бу — рабигыль-әүвәл аеның беренче көне. Ә пәйгамбәребез әлеге айның 12 нче көнендә барып җиткән. Инде санап чыгарасы авыр түгел: Мөхәммәт Мәдинәгә милади белән 622 нче елның 24 нче сентябрендә җомга көнне барып җиткән.

Биредә шуны да әйтеп узарга кирәк: пәйгамбәребезнең һиҗрәте рабигыль-әүвәл аенда булса да, бу ел тулысы белән (ягъни мөхәррәм аеннан башлап) һиҗри ел санала, һәм ай һиҗрәсе буенча ел исәпләү системасында башлангыч дата итеп милади белән 622 нче елның 16 нчы июле — җомга көн кабул ителгән. Бу — безнең җәдвәлдән дә ачык күренә.

Мондый таблицалар милади белән күрсәтелгән даталарны һиҗригә күчерү өчен дә хезмәт итә ала. Атнаның көннәре өч календарьда да үзгәрешсез кала. Милади белән XVI гасырга караган бер таблицага күз салыйк.

| № 192 | (*) 956 1549 | 957 1550 | 958 1551 | (*) 959 1551—1552 | 960 1552—1553 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 30. 1.3 | 20. 1.1 | 9. 1.5 | 29.12.2 | 18.12.7 |
| 2 | 1. 3.5 | 19. 2.3 | 8. 2.7 | 28. 1.4 | 17. 1.2 |
| 3 | 30. 3.6 | 20. 3.4 | 9. 3.1 | 26. 2.5 | 15. 2.3 |
| 4 | 29. 4.1 | 19. 4.6 | 8. 4.3 | 27. 3.7 | 17. 3.5 |
| 5 | 28. 5.2 | 18. 5.7 | 7. 5.4 | 25. 4.1 | 15. 4.6 |
| 6 | 27. 6.4 | 17. 6.2 | 6. 6.6 | 25. 5.3 | 15. 5.1 |
| 7 | 26. 7.5 | 16. 7.3 | 5. 7.7 | 23. 6.4 | 13. 6.2 |
| 8 | 25. 8.7 | 15. 8.5 | 4. 8.2 | 23. 7.6 | 13. 7.4 |
| 9 | 23. 9.1 | 13. 9.6 | 2. 9.3 | 21. 8.7 | 11. 8.5 |
| 10 | 23.10.3 | 13.10.1 | 2.10.5 | 20. 9.5 | 10. 9.7 |
| 11 | 21.11.4 | 11.11.2 | 31.10.6 | 19.10.3 | 9.10.1 |
| 12 | 21.12.6 | 11.12.4 | 30.11.1 | 18.11.5 | 8.11.3 |

Бу таблицадан файдаланып, Явыз Иванның Казанны алуы (1552 нче елның 2 нче октябре) һиҗри белән кайчан булганын һәм атнаның кайсы көненә туры килгәнлеген исәпләп чыгара алабыз. Әмма бу очракта эш авыррак, ул беркадәр уйлап, кайвакыт язып-сызып та, гамәл кылуны таләп итә.

Милади 1552 = һиҗри 959.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 нче сентябрь, | сишәмбе | = 1 | шәүвәл |
| 21 нче —«—, | чәршәмбе | = 2 | —«— |
| 22 нче —«—, | пәнҗешәмбе | = 3 | —«— |
| 23 нче —«—, | җомга | = 4 | —«— |
| 24 нче —«—, | шимбә | = 5 | —«— |
| 25 нче —«—, | якшәмбе | = 6 | —«— |
| 26 нчы —«—, | дүшәмбе | = 7 | —«— |
| 27 нче —«—, | сишәмбе | = 8 | —«— |
| 28 нче —«—, | чәршәмбе | = 9 | —«— |
| 29 нчы —«—, | пәнҗешәмбе | =10 | —«— |
| 30 нчы —«—, | җомга | =11 | —«— |
| 1 нче октябрь, | шимбә | =12 | —«— |
| 2 нче —«—, | якшәмбе | =13 | —«— |

Нәтиҗә: Явыз Иван Казанны һиҗри белән 959 нчы елда шәүвәл аеның 13 ендә якшәмбе көнне яулап алган.

Мондый исәпләүләрне миладидан һиҗригә күчерә торган кайтарма таблицалар ярдәмендә башкарганда эш, әлбәттә, күпкә җиңеләя.

Киләчәккә төбәп, без яши торган гасырның азагын да кертеп, түбәндәге таблицаны тәкъдим итәбез.

| № 284 | 1416<br>1995—1996 | (*)<br>1417<br>1996—1997 | 1418<br>1997—1998 | 1419<br>1998—1999 | (*)<br>1420<br>1999—2000 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 31. 5.3 | 19. 5.7 | 9. 5.5 | 28. 4.2 | 17. 4.6 |
| 2 | 30. 6.5 | 18. 6.2 | 8. 6.7 | 28. 5.4 | 17. 5.1 |
| 3 | 29. 7.6 | 17. 7.3 | 7. 7.1 | 26. 6.5 | 15. 6.2 |
| 4 | 28. 8.1 | 16. 8.5 | 6. 8.3 | 26. 7.7 | 15. 7.4 |
| 5 | 26. 9.2 | 14. 9.6 | 4. 9.4 | 24. 8.1 | 13. 8.5 |
| 6 | 26.10.4 | 14.10.1 | 4.10.6 | 23. 9.3 | 12. 9.7 |
| 7 | 24.11.5 | 12.11.2 | 2.11.7 | 22.10.4 | 11.10.1 |
| 8 | 24.12.7 | 12.12.4 | 2.12.2 | 21.11.6 | 10.11.3 |
| 9 | 22. 1.1 | 10. 1.5 | 31.12.3 | 20.12.7 | 9.12.4 |
| 10 | 21. 2.3 | 9. 2.7 | 30. 1.5 | 19. 1.2 | 8. 1.6 |
| 11 | 21. 3.4 | 10. 3.1 | 28. 2.6 | 17. 2.3 | 6. 2.7 |
| 12 | 20. 4.6 | 9. 4.3 | 30. 3.1 | 19. 3.5 | 7. 3.2 |

Инде тагын бер мәсьәләгә тукталып узыйк.

Көндәлек матбугатта мөселман бәйрәмнәре күрсәтелгән материалларда, төрле календарьларда һәм китапларда күп кенә хаталар китә. Шулардан иң таралганы — бер көнгә аерма булу. Мәсәлән, 1997 ел өчен шундый даталар күрсәтелгән гәҗит материалында елның беренче яртысындагы даталар дөрес, ә икенче яртысындагылар — хаталы (һиҗридәге кәбисә елны исәпкә алмау бәласе). Безнеңчә, 1998 нче елда мөселман бәйрәмнәренең даталары түбәндәгечә:

| | |
|---|---|
| 25 гыйнвар | — **Кадер кичәсе** |
| 30 гыйнвар | — **Ураза бәйрәме** |
| 7 апрель | — **Гарәфә көне** |
| 8 апрель | — **Корбан бәйрәме** |
| 9—11 апрель | — **Тәшрикъ көннәре** |
| 28 апрель | — **Яңа 1419 ел башы** |
| 7 май | — **Гашура бәйрәме** |
| 22 июнь | — **Һиҗрәт кичәсе** |
| 23 июнь | — **Һиҗрәт бәйрәме** |
| 6 июль | — **Мәүлид кичәсе** |
| 7 июль | — **Мәүлид бәйрәме** |

| | | |
|---|---|---|
| 23 октябрь | — | **Рәгаиб кичәсе** |
| 16 ноябрь | — | **Мигъраҗ кичәсе** |
| 17 ноябрь | — | **Мигъраҗ бәйрәме** |
| 4 декабрь | — | **Бәраәт кичәсе** |
| 20 декабрь | — | **Ураза башы** — Рамазан аеның беренче көне. |

1990 нчы елда Мәскәүдә басылган «Мусульманские праздники» дигән бик күркәм китапта да 1990—2000 нче еллардагы мөселман бәйрәмнәренең ай һәм ай көннәре күрсәтелгән таблицада ураза һәм корбан бәйрәмнәренең көннәре (вакыты) тулаем диярлек дөрес түгел. Әлбәттә, бу гафу ителмәслек хаталар басмаханә гаебе белән киткән булырга охшый, әмма китаптан файдаланучылар өчен моның ни әһәмияте бар?

Биредә без, шул китаптагы хаталарны төзәтеп һәм таблицаны киңәйтеп (2005 нче елны да кертеп), файдаланучыларга тәкъдим итәбез.

**Мөселманнарның иң мөһим бәйрәмнәре**

| Еллар | Корбан 10 зөлхиҗҗә | Ураза 1 шәүвәл | Мәүлид 12 рабигыль-әүвәл | Мигъраҗ 27 рәҗәб | Кадер кичәсе 26 рамазан | Гашура 10 мөхәррәм |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1997 | 18/IV | 9/II | 18/VII | 28/XI | 4/II | 18/V |
| 1998 | 8/IV | 30/I | 7/VII | 17/XI | 25/I | 7/V |
| 1999 | 28/III | 19/I | 26/VI | 6/XI | 14/I | 26/IV |
| 2000 | 16/III | 8/I, 28/XII | 15/VI | 26/X | 3/I, 23/XII | 15/IV |
| 2001 | 6/III | 17/XII | 4/VI | 15/X | 6/III | 4/IV |
| 2002 | 23/II | 6/XII | 24/V | 4/X | 1/XII | 24/III |
| 2003 | 12/II | 26/XI | 14/V | 24/IX | 21/XI | 14/III |
| 2004 | 2/II | 14/XI | 2/V | 12/IX | 9/XI | 2/III |
| 2005 | 21/I | 3/XI | 21/IV | 1/IX | 29/X | 19/II |
| 2006 | 10/I, 31/XII | 24/X | 11/IV | 22/VIII | 19/X | 9/II |

**Илнур ҖАМАЛЕТДИНОВ.**





# ДУСКА СОҢГЫ СҮЗ

Уйларымның очына чыга алмый гаҗизләнәм. Арабызда инде Фәиз Зөлкарнәйнең юклыгына ышанасы килми. Юктыр! Булмас... Булырга мөмкин түгел! Менә ул гадәттәгечә кояш кебек балкып редакциябезгә килеп керер. Килеп керер дә ипләп кенә хәл-әхвәлебезне сораша башлар, күзләрендә акыл куәсенең чагылышы булып сизелер-сизелмәс кенә хәйләкәр елмаю очкынланыр сыман.

Дусларына бөтен барлыгын, күңел байлыгын ачып сала белгән олы затлардан иде ул. Тирән белемле, киң мәгълүматлы иде. Һәм бер дә кызганмыйча әнә шул хәзинәсен иптәшләре белән уртаклаша иде. Аның яныннан рухи баеп, күңеленнән бөркелгән җылылыктан сафланып кайтып китә идең. Аның белән аралашу, аңлашу рәхәт иде.

И дөнья! Җәй чилләсенең иң эссе, иң кызу өч көнен без аның белән бергә «Сәләт» лагеренда, балалар янында, балалар белән аралашып үткәрдек. И кинәнде инде Фәиз! Канатланып, очынып татар әдәбияты, аның киләчәге, яшьләргә баглаган өметләре хакында сөйләде, ачылып китеп, гомер булмаганча, кәлтә-кәлтә шигырьләрен укып ташлады, туган якларының матурлыгын мактап туя алмады...

Бераз бушангач якындагы буага су коенырга төштек.

— И-и-их, суы да суы,— дип сокланды Фәиз һәм Ык буйларында үскән малайларча колач салып ашкынып буа уртасына кереп тә китте. Күз күреме җиткесез киң буаның уртасына җитте, аны узып күздән югала язды.

Чыккач бу дуамаллыгын шелтәләвебезгә аклангандай көлемсерәп кенә җавап бирде:

— Их, егетләр, минем быел беренче тапкыр су керүем бит!

Сөйләшә-сөйләшә кайтып киләбез. Һәм кинәт Фәиз тагын үкенгәндәй әйтеп куйды:

— Лагерьда озаграк торылды. Авылда көтәләр бит. Печән чаба алмый калырмын дип куркам! Минннән башка чабып бетермәгәйләре... Бер каерылып печән чабасы иде...

Бу вакытта аның якты дөньяда нибары алты көн гомере калган булган икән!

Соңыннан белдек: теләгенә ирешкән — туган ягында, Башкортостанның Бакалы районындагы Саскүл авылында ике көн буе печән чабып кинәнгән Фәиз!

Әйе, башлаган эшен, уйлаган гамәлен ахырына җиткермичә туктамый торган, максатчан, ашкын хисле кеше иде ул.

Бу турыда язуы читен, күңелдә авыр югалтудан калган җәрәхәтләр әле төзәлеп тә бетмәгән. Алар, бәлки, шулай гомерлеккә калыр да. Моны иң якын дусты белән мәңгелеккә хушлашкан кешеләр аңлар дип беләм...

Чаллы—Казан юлында ваемсыз бер бәндәнең ялгышлыгы аркасында автомобиль һәлакәтенә юлыкты ул. Авыр яралар алды. Аның тормышын саклап калу өчен көрәш дүрт көн, дүрт төн дәвам итте. Хәле белән бөтен республика халкы кызыксынып торды. Әмма, аяусыз үлемне җиңеп булмады...

Үткен каләмле, нечкә зәвыклы тәнкыйтьче, шигъриятнең иң югары кимәленә ирешкән шагыйрь, үз тирәсенә яшь талантларны туплый белүче оста оештыручы, «Идел» журналының баш мөхәррире Фәиз Зөлкарнәйнең гомере бигрәкләр дә иртә, артык иртә өзелде шул. Тормышка ашырасы күпме якты хыяллары, уй-ниятләре өзелде. Әле аның басылуга әзерләнгән шигырь һәм тәнкыйть китаплары нәшрият цехларында...

Әдәбиятыбыз, мәдәниятебез тарихында үзенең лаеклы урынын алган әдипнең — олы күңелле якты шәхеснең истәлеге аның дуслары, каләмдәшләре күңеленә мәңге сакланыр, аның образы әле бик озак еллар безнең өчен үрнәк-өлге булыр. Шуңа өметләнәм, шуңа ышанам...

**Флүс ЛАТЫЙФИ.**

*«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре каләмдәшебезнең гаиләсенең, туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.*

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ ТӘКЪДИМЕ БЕЛӘН

Моннан өч ел элек, Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев тәкъдиме белән, элекке совет киңлегендәге низагълы хәлләрне җайга салу буенча Гаагада (Нидерланд корольлеге) консультатив «Түгәрәк өстәл» оешкан иде. 23—24 май көннәрендә биредә, Тынычлык сараенда, «Түгәрәк өстәл»нең чираттагы өченче сессиясе булды. Анда Россия Федерациясе белән Ичкерия Чечен Республикасы (ИЧР) арасындагы мөнәсәбәтләрне торгызу мәсьәләләре каралды. Әлеге сессия Татарстан Республикасы белән Ичкерия Чечен Республикасы арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы Шартнамәгә кул куелганнан соң ике көн үткәч һәм Мәскәүдә РФ белән ИЧР арасында Тынычлык һәм үзара мөнәсәбәтләр принциплары турындагы Шартнамәгә кул куелганнан соң ун көн үткәч үткәрелде. Россия һәм чит ил сәясәтчеләре-экспертлары Мәскәүдә «теләсә кайсы бәхәсле мәсьәләне хәл иткәндә көч кулланудан яисә көч куллану белән янаудан мәңгелеккә баш тартырга» дип килешүне канәгатьләнү белән билгеләп үттеләр. «Гаага инициативасы» дигән консультатив «Түгәрәк өстәл», уртак килешү белән кабул ителгән Белдерүгә, Мәскәүдә кул куелган Шартнамәгә бәя биреп, аны тынычлык һәм үзара аңлашуга ирешү өчен төп документ итеп саный. Өченче сессия утырышында Чечня икътисадын торгызуга барлык чаралар белән һәм һәрьяклап тотрыклы ярдәм итәргә, Кавказ төбәгендә тынычлык, иминлек һәм тотрыклылыкның нәтиҗәле механизмын эшләргә, үзара мөнәсәбәтләрне алга таба тагын да үстерү өчен РФ белән ИЧР арасында сөйләшүләр процессын дәвам итәргә кирәк, дигән мөһим карарларга килende.

Сессия эшендә ТР Президенты М. Шәймиев, ИЧР вице-президенты В. Асланов, Ингушетия Президенты Р. Аушев, РФ Президенты киңәшчесе Э. Паин, РФ Иминлек Советы секретаре урынбасары Б. Березовский, чит ил сәясәтчеләре-экспертлары катнашты.

### БАТЫРЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

7 июльдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Арча районының Казанбаш авылына килеп, биредәге «Известия» кумәк хуҗалыгында озак еллар рәис булып эшләгән Социалистик Хезмәт Герое Мирбат Хәстиевны 70 яшьлек юбилее белән тәбрикләде, бүләкләр бирде.

8 июльдә исә ул Казан Кремлендәге резиденциясендә Советлар Союзы Герое — легендар очучы, капитан Михаил Девятаевны кабул итте һәм аңа, 80 яшьлек юбилее белән котлап, Татарстан Республикасының Мактау Грамотасын тапшырды һәм исемле сәгать бүләк итте.

### МӘСКӘҮ САБАНТУЕНДА

Мәскәүдә һәр елны июль аеның беренче якшәмбесендә Сабантуй үткәрелә. Быел да ул 6 июль көнне Измайлов паркында зур оешканлык, рухи күтәренкелек белән узды. Әлеге олуг бәйрәмгә Татарстан белән Башкортостаннан, Түбән Новгород белән Пензадан, гомумән, Россиянең, БДБ илләренең күп кенә төбәкләреннән бихисап кунаклар килгән иде. Сабантуйны ачу тантанасында Россиянең Үзәк Европа өлеше һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзараты рәисе, Мәскәү Җәмигъ мәчете имам-хатибы Равил хәзрәт Гайнетдин, Россия һәм БДБның Европа өлеше мөселманнары Диния нәзараты рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиле Фәрит Мөхәммәтшин, Казан шәһәренең вице-мэры Рәшит Фәсхетдинов, Мәскәү хакимияте вәкиле Игорь Пономарев һ. б. чыгыш ясады. Сабантуйда спортның күп кенә төрләре буенча мавыктыргыч бәйгеләр үткәрелде, җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр бирелде. Казан һәм Чаллы сәүдә оешмалары милли ризыкларны, һәртөрле сувенирларны күпләп алып килгән иде. Татарстан сәнгать осталарының чыгышларын да тамашачылар бик яратып кабул иттеләр.

### ХАЛЫК ШАГЫЙРЕНӘ БАГЫШЛАП

Татарстан Республикасының Мәскәүдәге даими вәкиллеге конференцияләр залында Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимне искә алу кичәсе үткәрде. Аны әлеге вәкиллек һәм Татар «ПЕН-клубы» бергәләп оештырган иде. Әлеге кичәдә «ПЕН-клуб»ның тышкы элемтәләр сәркатибе Вахит Юныс, шагыйрьнең улы — күренекле галим-сәясәтче Рафаэль Хәкимов, тәрҗемәче Венера Вәлиева, язучы-академик Азат Әхмәдуллин катнашты.

### ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЧЫЛАРЫ КИҢӘШӘ

Мәгълүм булганча, Төркиянең Ататөрк культур, тел һәм Тарих институты, Ататөрк культур Мәркәзе җитәкчелегендә, төрек телендә 30 томлык (һәрберсе 600 биттән гыйбарәт!) «Төрки дөньясы әдәбиятлар тарихы» хезмәте хәзерләнә. Аның 13 томын әдәбият тарихы, 8 ен — антология, 5 томын

энциклопедик белешмә, 4 томын әдәбият белеме сүзлеге тәшкил итәчәк. Әлеге олуг хезмәтне язуда, төрек галимнәре белән беррәттән, башка төрки мәмләкәтләрнең һәм җөмһүриятләрнең (шул исәптән Татарстанның да) күренекле әдәбиятчылары катнаша.

«Төрки дөньясы әдәбиятлар тарихы»на багышлап, 1995—1996 елларда Анкарада ике киңәшмә-симпозиум уздырылган иде инде. Аның өченчесе быел 13—18 май көннәрендә Ташкентта үткәрелде. Анда «Әдәбиятлар тарихы»н 1997 елның ахырына кадәр язып бетереп, 1999 елда томнарны чыгара башлау турында килешенде.

Әлеге халыкара киңәшмәдә Татарстаннан вәкил булып «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы, язучы-академик Хатыйп Миңнегулов катнашты һәм чыгышлар ясады. Бер үк вакытта ул Үзбәкстан телевидениесенә дә кызыклы интервьюлар бирде.

### ЕРАК АРАЛАРНЫ ЯКЫНАЙТЫП

Калмыкия Республикасының халык шагыйре Давыт Көгелтиновка 75 яшь тулуга багышлап, Элиста шәһәрендә үткәрелгән тантаналарда Татарстаннан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары, язучы-академик Флүн Мусин һәм танылган шагыйрь — «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире Зиннур Мансуров та катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Алар, көчле алкышлар астында, юбилярга Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевның котлау сүзләрен ирештерделәр һәм аңа Сөембикә манарасы сурәте төшерелгән келәм белән исемле сәгать тапшырдылар.

### НӘШРИЯТ — КОНГРЕССКА

Татарстан китап нәшрияты, II Бөтендөнья татар конгрессын каршылап, байтак кына китаплар бастырып чыгарды. Алар арасында Р. Фәхретдиновның «Казан ханнары», Г. Батталның «Казан төркиләре», Я. Гришинның «Польско-литовские татары», С. Алишевның «Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV—XVI веках», Г. Исхакыйның «Остазбикә», Г. Гыйльмановның «Татар мифлары» исемле хезмәтләре бар. 1552 елда Казанны дошманнан саклаганда шәһит киткән Кол Шәрифнең «И күңел, бу дөньядыр...» дип исемләнгән шигъри җыентыгы һәм Б. Урманченың мәдәният-сәнгать әһелләренә багышланган зиннәтле альбомы да конгресс кунаклары күңеленә хуш килерлек итеп эшләнгән.

*ТУГАНДАШ БАШКОРТОСТАН ҖИРЕНДӘ*

### БАШКОРТОСТАН ТАТАРЛАРЫ КОРЫЛТАЕ

28 июнь көнне Уфада Башкортостан Республикасында яшәүче татарларның (ә алар биредә барлыгы 1 миллион 120 мең кеше исәпләнә) беренче зур җыены булды. Әлеге корылтайда Татарстаннан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харисов житәкчелегендәге делегация катнашты. Аның составында ТР Президенты киңәшчесе Рафаэль Хәкимов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Римзил Вәлиев, Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники, шагыйрь Госман Садә бар иде.

Башкортостан татарлары корылтаенда әлеге тугандаш Республиканың мөхтәрәм Президенты Мортаза Рәхимовның, БР Дәүләт Җыелышы Рәисе Михаил Зайцевның катнашулары һәм чыгыш ясаулары җыенның абруен тагын да күтәрде.

Корылтай бик күп мәсьәләләрне хәл итте, республикада яшәүче татарларның киләчәк үсеш юлын билгеләде. Башкортостанда дәүләт теленең өчәү — башкорт, татар һәм рус телләрендә булачагы турында килешенде.

Җыен II Бөтендөнья татар конгрессына 35 делегат сайлады.

Икенче көнне Казан кунаклары атаклы әдип Галимҗан Ибраһимовның туган җирендә булдылар, аның корылтай алдыннан гына ачылган музее белән таныштылар. Әдәбиятыбыз аксакалы Әмирхан ага Еникинең туган төбәгендә — Дәүләкән районында булу да күңелләрдә онытылмаслык якты тәэсирләр калдырды.

### ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ НЫГЫЙ

Моннан берничә ел элек Башкортостан белән Татарстан арасында үзара хезмәттәшлек турында Шартнамә төзелгән иде. Ул унышлы төстә тормышка ашырыла. Бу өлкәдә һәр ике республиканың да мәгълүмат һәм матбугат министрлыклары (җитәкчеләре — Галим Хисамов, Ислам Әхмәтҗанов) нәтиҗәле эшчәнлек күрсәтәләр. Шуның бер матур чагылышы буларак, 14—20 июль көннәрендә Башкортостанда «Татар һәм башкорт әдәбиятлары көннәре» булып узды. «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы» девизы астында үткән бу бәйрәмдә Татарстаннан «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, танылган шагыйрь Равил Фәйзуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Харис Әшрәфҗанов, Башкортостан ягыннан исә әлеге республиканың китап нәшрияты директоры Кадим Аралбаев, күренекле шагыйрь Абдулхак Игебаевлар катнашты. Тугандаш ике халык вәкилләреннән торган делегация Баймак районында, Сибай шәһәрендә, атаклы Темәс һәм Юлык авылларында булдылар, дисгәләрчә очрашуларда катнаштылар. Язучылар Чиләбе өлкәсе территориясендә урнашкан борынгы Аркаим мемориаль шәһәрчегенә дә сәяхәт кылдылар.

### Г. ИБРАҺИМОВ КУНАККА ДӘШТЕ

Бөек әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 110 ел тулган көннәрдә, Башкортостан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Равил Бикбаев житәкчелегендә бер төркем каләм әһелләре әлеге республиканың Авыргазы районы үзәгендә һәм Солтанморат авылында әдәби очрашулар үткәрде. Аннары тантаналар Уфада дәвам иттерелде. Әлеге чараларда Татарстаннан «Мәдәни җомга» газетасының баш мө-

хәррире, шагыйрь Зиннур Мансуров та катнашты һәм Г. Ибраһимов турында үзенең уй-фикерләре белән уртаклашты. Казан кунагы шулай ук Башкортостан телевидениесе аша да чыгыш ясады.

### ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ КӨННӘРЕ

24—27 июньдә Башкортостан Республикасында «Татар яшьләре көннәре» үткәрелде. Аны, «Азатлык» татар яшьләре берлегенең Уфа филиалы белән бергә, Балалар һәм яшьләр эшләре буенча дәүләт комитеты оештырган иде. Татар яшьләре җыенына Башкортостанның 20 ләп районыннан, Чаллыдан, Казаннан, Самарадан да байтак делегатлар килгән иде.

Җыенда үсеп килүче яшь буын алдында торган үтә мөһим көнүзәк мәсьәләләр — татар гимназияләре, милли мәдәният йортлары ачу, үз ана телебездә төрле дәреслекләр нәшер итү кебек проблемаларны чишү юллары турында сүз барды.

### КҮРШЕЛӘРДӘ КУНАКТА

Әлмәт татар дәүләт драма театры артистлары тугандаш Башкортостанда гастрольләрдә булып кайттылар. Татарстан кунаклары Уфа тамашачыларына күренекле драматурглардан Г. Камал, Ф. Бүләков, Н. Гаетбаев һ. б. әсәрләре буенча куелган спектакльләр күрсәттеләр.

Спектакльләрдә иң оста уйнаучы актерлардан Роза Салихова белән Фоат Зариповка «Башкортостан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

### ЯКТАШЛЫК ҖӘМГЫЯТЬЛӘРЕНДӘ

Башкортостан Республикасының Янаул районында туып, бүгенге көндә Татарстан башкаласында гомер кичерүчеләр, үзара берләшеп, якташлык җәмгыятенә нигез салдылар. Җәмгыятьнең президенты итеп, бертавыштан, Татарстанның халык шагыйре, күренекле драматург Илдар Юзеев сайланды. Вице-президентлар итеп «Татнефтепродукт» холдинг компаниясенең техник директоры Замфир Закиров, Казан дәүләт педагогия университеты проректоры Фираз Харисов, Татарстан радиосының баш мөхәррире урынбасары Рәзин Нуруллин расланды. Күренекле юрист Назим Сафин «Янаул» фонды рәисе итеп билгеләнде.

* * *

Татарстан Язучылар берлеге бинасында Казанда яшәүче мамадышлыларның якташлык җәмгыятен оештыру җыелышы булды. Җәмгыятьнең президенты итеп ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Татарстан халык депутаты Ринат Мөхәммәдиев, вице-президентлар итеп республикабызның төзелеш һәм архитектура министры урынбасары Мансур Абдуллин, Казан дәүләт педагогия университетының музыка сәнгате факультеты доценты, Татарстанның халык артисты Мингол Галиев, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, язучы Шаһинур Мостафин, оешманың сәркатибе итеп «Ватаным Татарстан» газетасы хәбәрчесе Люция Фәрштова сайланды. Мамадышлыларның Мәскәүдәге вәкиле итеп язучы һәм журналист — «Азатлык» радиосының Россия башкаласындагы хәбәрчесе Нәзифә Кәримова билгеләнде. Киләчәктә «Мамадыш якташлыгы» җәмгыяте филиалларын башка төбәкләрдә оештыру да күздә тотыла. Хәбәрләшү өчен адрес: 420012, Казан шәһәре, Х. Мөштәри урамы, 14 нче йорт. Телефон: 36-97-71.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Башкортостан Республикасы Президенты М. Рәхимов Указы нигезендә, танылган шагыйрь һәм драматург **Әнгам Касыйм улы Атнабаевка** «Башкортостан Республикасының халык шагыйре» дигән мәртәбәле исем бирелде. Ошбу Указ әлеге җөмһүрияттә яшәүче татарлар корылтае алдыннан игълан ителде.

* * *

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Указы белән, Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты әйдәүче гыйльми хезмәткәре — күренекле тарихчы-археолог **Равил Габдрахман улы Фәхретдиновка** «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Музыка сәнгате өлкәсендәге казанышлары өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисты Фәйзрахманов **Айдар Фәтхерахман улына** «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Казанның Ирек мәйданында шигырь бәйрәме.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** «Ир канаты — ат булыр».

Ю. ФИЛИМОНОВ фотолары.

محمديار



Мехаммәдьяр

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)